# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Сания ӘХМӘТҖАНОВА. Ак әләмем итеп шигырь типчим... *Шигырьләр.* ..... 3
Зәбир ГЫЙМАЕВ. Каторжан. *Роман.* ..... 8
Гөлсәрия БАСЫЙРОВА. «Алтын Күз» минем исем!.. *Шигырьләр.* ..... 58
Әлфис ГАЯЗОВ. Кайсы яктан чыга соң бу кояш? *Роман.* ..... 63
Рәшит БӘШӘР. Җәйнең соңгы алкышы... *Шигырьләр.* ..... 140
Ландыш ӘБҮДӘРОВА. Олабый. *Хикәя.* ..... 144

ЯҢА ИСЕМНӘР

Гөлназ ӘХМӘДИЕВА. Мин очышка әзерләнәм… *Шигырьләр.* ..... 150

«ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ...» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Энҗе ГАЛИӘХМӘТОВА. Мәрхәмәтле бул, балам. *Хикәя.* ..... 153

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Баһаветдин АДЖИЕВ. Шагыйрьдән соң илдә җыры җырлана. *Шигырьләр.* ..... 156

*Кайтаваз:* Лилия ФӘТТАХОВА. Бәхетнең дә, бәхетсезлекнең дә сәбәпчесе... ..... 159
Рәдиф ГАТАШ. Ләбиб Леронның чәчмәдә яңача ачылуы. ..... 160

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Равил РАХМАНИ. Себер – үзебезнеке?! ..... 161
Фәүзия СОЛТАН. Мин сызланам, син дә сызлан әле, укучым!
*(Шагыйрь Ркаил Зәйдулланың соңгы еллар лирикасына бер караш).* ..... 171

*Фотоархив:* Әдәби мизгелләр. ..... 176

ӘБҮГАЛИСИНА МӘГАРӘСЕ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Каюм Насыйри – православие уку йорты укытучысы. ..... 178

ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП

Хатыйп Миңнегулов, Әнгам Атнабаев, Мостай Кәримнең
Рәдиф Гаташка язган хатлары. ..... 185

Әдәби сканворд. *Рәис ГАБДУЛЛА төзеде.* ..... 187

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Дөньяны тынгысызлар хәрәкәткә китерә. *(Рахмай Хисмәтуллинның тууына – 90 ел).* ..... 188
Язмышымның дәрьясы: Казан – Төмән арасы (*Шәүкәт Гаделшаның тууына – 75 ел).*
*Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ..... 189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 9 (1223) 2024*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 28.08.2024, график буенча 28.08.2024, басылып чыгу вакыты 04.09.2024
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-1912. Тираж 4500.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.
12+
© «Казан утлары», 2024 ел



Сания
Әхмәтҗанова

# АК ӘЛӘМЕМ ИТЕП ШИГЫРЬ ТИПЧИМ...

## Сан дип түгел

Ярсу аргамагым, ялын тарап,
Каршы чаба саба җиленә...
Җирән чәчем, җилләр уңаена
Сибелә дә төшә иңемә.

Берләштекме, куш игезләр сыман,
Уртак ниятебез хакына?
Үр яулагач, тавы ымсындыра,
Уйлар биеккәрәк талпына.

Пар канатлы шигъри Тулпарым син!
Көн дә, төн дә дими очабыз.
Җирнең тарту көчен җиңә-җиңә,
Чиксез киңлекләрне кочабыз.

Мин хыялый бер җайдагың гына,
Ярдәм көтеп сиңа елышам.
Йөрәгебез тибә бер ешлыкта,
Сулышыңа тәңгәл сулышым.

Бәллүр тоякларың җирне капшый,
Килә туктап бер тын аласың.
Ясказгандай ташлап калдырырга,
Күңелемә курку саласың.

Иңдәшлектә тиңдәшлекне саклап,
Без максатка тиеш җитәргә!
Сан дип түгел, инсаният[1] белән
«Гомер марафон»ын үтәргә!

---

[1] Инсаният – монда: кешелеклелек.

---

Сания ӘХМӘТҖАНОВА (1962) – *шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе; Һ.Такташ һәм С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Пар алма», «Гәрәбә», «Язмышлар такыясы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Үлмәс ышаныч

Яңа Казан йөрәгемне назлый:
Көр тавышлы, җем-җем балкышлы...
Киң кочагы һәркемгә дә ачык,
Һәр почмагы җанга ятышлы.

Гранд-отельләр күккә үрмәлиләр,
Манаралар белән ярышып.
Казан-кала заман тизлегеннән
Бер сулыш та тормый калышып.

Күз иярми – көнләп зур биналар
Шәһәр кочагына сыена:
Иртән карыйм – бер йорт баш калкытса,
Кичкә баса бөтен буена.

«Нинди гүзәл минем башкалам!» – дип
Сокланасың, сөеп туймыйсың...
Иске Казан аша узган чакта
Чал язмышын аның уйлыйсың.

Гәүһәршатның толымына охшап,
Бөдрә таллар иелә Кабанга.
Болгар читегенең нәфис эзе
Орынгандай була табанга.

Ханбикәбез йөргән урамнарны
Иңли чорның иркә кызлары.
Гүя «Сөембикә» сүзен чигеп,
Бизи күкне йолдыз кузлары.

Башкаланы гизеп йөргән чакта,
Килми калмый уйга төрлесе:
Бинахакка чор корбаны булган
Казан ханлыгының «өре»се...

Куам читкә моңсу уйларымны,
Берәүдән дә без ким түгел лә!
Кичке Казан нурларына манып,
Якты өстим боек күңелгә.

Безнең Казан бөтен илдә берәү,
Илдә генә түгел – җиһанда!
Казанымның үлмәс ышанычы –
Иле өчен туар илханда!

## Хисләр яңарганда

Туган җирем! Йөзең һәрчак якты,
Табының мул, җылы кочагың.
Яңарырга тора бер ымыңнан,
Бер тыныңнан хисләр учагым.

Адымнарым синдә ышанычлы,
Горур күтәрелә иңсәләр.
Бәхет катыш кыенсынып куям,
Түрдәнрәк урын бирсәләр.

Туган җирем! Рух-калебем гүя
Синең туфрагыңнан укмашкан.
Соң йортым да синдә булса иде –
Җан тамырым сиңа тоташкан.

## Алга бармый

Дөнья минсез нишләгәндер инде? –
Кайтып кердем юлдан үз өемә.
Мин юк диеп, тормыш тукталмаган,
Дәвам иткән икән үз көенә.

Газеталар гүя көнен-көнгә
Халык хәлен җиткермәкче булган;
Журналлар да бу ай соңламаган –
Почта әрҗәм хәбәр белән тулган.

Яран гөлем яңа чәчәк аткан,
Сусаса да, буйга үсеп киткән.
Әрсез тузан кунган өстәлемә –
Мин юк дими, ул да туза икән.

Кай тарафтан нинди яхшы хәбәр?
Хәвеф килгән кайсы ил өстенә?
Зәңгәр экран гөлтләп кабынуга:
«Израиль...» – ди диктор. – «Палестина...»

Кемгә – тотык, кемнең – җан парәсе,
Җир-анасын бүлә балалары.
Кем көчлерәк, шулар һәрчак хаклы,
Корал – хаким, акча – Аллалары...

Уйландым да гаҗизләнеп калдым:
Акыл түгел, нәфес алдан чаба.
Бу кешелек алга бармый бугай,
Тәгәри күк әлмисакка[2] таба.
(Җәһәннәмгә димим... Тәүбә! Тәүбә!)

[2] Әлмисак – дин буенча дөнья яратылган вакыт.

## Көз кәефе

Канат сынап, ерак сәфәр алдыннан,
Төркем-төркем күчмә кошлар агыла.
Авырайган калын болыт ястыгы
Иңе белән түбәләргә кагыла.

Көр бәдәнле, тук йөзле көз, нык атлап,
Адым-адым керә бара көченә.
Тырыш халык, җыйнап көзге уңышын,
Бакчалардан өйгә таба күченә.

Җил дә раслый ярсып-ярсып куәтен:
Иләгеннән буш орлыклар җилгәрә.

Нәфис сынлы иркә гөлләр-чәчәкләр,
Калтыранып, таҗын коеп тирбәлә.

Яшьләр җәйчә: изү – ачык, яланбаш,
Көз кәефен кабул итми даулаша.
Төнгә кадәр шаярышып-уйнашып,
Карт-корыга йокы бирми шаулаша.

Җәй кояшын юксынышып кай ара,
Көнгә карый тәрәзәдән гөлләр дә.
...Искә төшеп, гәрәбәдәй якты көз
Җан җылытыр кышкы суык көннәрдә.

## Ана теләге

Баш очымда ак болытлар йөзә,
Күңел якты нурда коена.
...Күр, бер сабый, тәү адымын атлап,
Әнкәсенә килеп сыена.

Кулларымны кушып төбәләм мин
Күк гөмбәзе – чиксез чатырга:
«Язсын иде һәрбер хатын-кызга
Ана булу бәхетен татырга!»

Балаларым алсам кочагыма,
Шөкер итәм көнгә мең кабат:
«Үзең сөеп биргән бу бәхетне
Гомерлеккә, Раббым, Син ярат!»

...Ак өметкә җанны биләсәк тә,
Дөньялары кырыс, хаклыкта.
Аерылулар булсын вакытлыча,
Күрешергә язсын шатлыкта.

## Чигүче Йолдыз

Бизәк сайлый Йолдыз, онытылып
Чигү чигә, һәр кич утырып.
Бөредәге язгы гөлләр калка,
Болын-ашъяулыгын тутырып.

Төсле хыяллары кабына да
Лалә таҗларына кагыла.
Пар мендәрнең тышлыгында шыткан
Гөлбакчадан күзләр чагыла.

Гөлләренә куна таң былбылы,
Биеп кенә тора, һай, кулы.
Чиккән келәмнәрен сукмак итсәң,
Зөһрә кызга илтер Ай юлы.

Элмәк-элмәк тамбур җөйләр җөйләп,
Кул җиледәй җитез җыр көйләп,
Кирмән сөлгеләре чигә оста,
Чулпан йолдызына сер сөйләп.

Әнкәсенең бирнә өленгесе –
Борынгыдан килгән өлгесе.
Гөлләмәне яңа чәчәк бизәр:
Ул кушканы – аллы-гөллесе.

Шәфәкъ нуры төшкән йөзләрендә –
Болгар осталары чалымы.
Үткәннәрне киләчәккә бәйләп,
Чигү чигә татар ханымы.

## «Алмашыну»

*Уены-чыны бергә*

«Барып кайтыйк... бергә», – диде,
«Кая?» – дип тә сорамадым.
Үз картым бит, ышанычлы,
Кешенекен урламадым.

Атна-ун көн җитәр диеп,
Карарын ук әйтеп салды.
Гомер иткән, ияләшкән...
Миңа «әйе» сүзе калды.

«Артык кием алма», – диде,
Кат-кат итеп өскә кидем:
Йөкне бит ул күтәрәсе,
Җиңелрәк булсын дидем.

Барганчы – гел ул дигәнчә,
Йөрдем һаман биеп кенә.
«Ярар, иркәм, ярар, җаным!
Шулай-шулай!» – диеп кенә.

Барып җиткәч, «алмашынды» –
Үзгәрде дә куйды картым:
Көйләп кенә йөртә мине,
Китереп бар җаен-шартын.

«Ял ит, карчык», – диеп тора,
Ишек ачып, алдан кертә.
Яңа өйләнешкән кебек
Билдән кочып кына йөртә.

Җәннәт дисәң, җәннәт менә...
Рәхмәт инде, йөрәк маем!
Ялы – ун көн, балы – еллык,
Татып калыйк «ширбәт ае»н!

## Шомырт тәме

Иреннәрем белән уч төбеңнән
Берәм-берәм шомырт чемләдем.
Сулышымнан татлы тойгыларың
Кытыкланыр диеп белмәдем.

Берәм-берәм, имеш, шомырт чүплим,
Уч төбеңне үбеп-иркәләп.
«Алай итмә!» – диеп тыю түгел,
Тайпылмадың хәтта читкәрәк.

Син учыңны сузып басып тордың,
Рәхәт табып мине күзләдең.
Иреннәрең белән иренемнән
Үрелеп шомырт өздең, түзмәдең...

Уч төбеңнән шомырт сәйләннәре
Тәгәрәште җиргә коелып.
...Калсын бу кич шомырт тәме булып,
Җәйләр хәтеренә уелып.

## Ак әләмем итеп...

Үчләшүен синең горурлыкның
Мин китердем үзем чакырып...
Көнемне көл итеп, җилгә чәчтем,
Хәсрәт килгән кебек «аһ» орып.

Авыр юшкын йокты күңелләргә,
Сүзнең тәмен җуйдык, кадерен.
Гафу ителмәдем... Тибәрелгән
Белдеклелек алды җәберен.

Акыл саттым бугай... Ялгыштыммы,
Мин үземне хаклы дип белеп...
Ак әләмем итеп шигырь типчим,
Солых чырагыма ут элеп.

## Җил сихәте

Көзге җилнең үзгә бер исе бар,
Җылы җилнең иләс бер хисе бар –
Тирән итеп сулыш аласың,
Сихерләнеп туктап каласың.

Күкрәгеңә тула ул агылып,
Элгән кергә кала ул ягылып –
Йөзләреңә куеп иснисең,
Гүя артыш исен төснисең.

Бәлзәм сыман тынга сихәт бирә,
Һәрбер күзәнәккә үтеп керә.
Алып китә гомер буйлата,
Татлы мизгелләрне уйлата.

Күз алдына килә бөтен икмәк,
Әни мичтән ала әнә ипләп...
Икмәк исен тәмләп аласың,
Сулап көзге урман һавасын.

Баштан сыйпап, чәчкә кагылып китә,
Гүя затлы хушбуй тамызып үтә...
Көзге җилнең бу тик баласы,
Килә назлап кочып аласы.

Туган якта җил дә илһам бирә,
Вөҗүдеңә, аңга үтеп керә.
...Шигырем җил булып сирпелсен,
Җаныгызны сафлап бөркелсен.

## Исәм әле

*Исмәле, җил, туктале, җил...*
Халык җырыннан

Исәм әле, куеныңа керәм,
Кытыклансын йөрәк канатың.
Син иң баштан төс-битемә түгел,
Исәр булганыма җан аттың.

Исәм әле, күзләреңне үбәм,
Алар бары миңа карасын.
Мут карашың гөлтләп кабынсын да,
Керфек угың җанга кадасын.

Исәм әле, ахыргача исәм,
Күңел шикләреңне таратып.
Гомерлеккә диеп вәгъдәләшкәч,
Мин яртылаш калмам яратып.

## Сөю челләсе

Һич үкенмим нигә сөйдем диеп,
Мәхәббәттән кем соң ваз кичкән?!
Мин ул тиле гашыйк... һәм йотлыгып
Сөю касәсеннән наз эчкән!

Мин яратсам, үлеп гашыйк булам,
Буранлатып яшьлек хисләрем.
Июль киче, ә мин менә тоям
Кочагыңда сирень исләрен.

Ә мин таныйм коңгырт күзләреңдә
Яшьлегеңнең очкын карашын.
Мәхәббәтнең яше – унҗидедә,
Инкарь итеп берсе карасын!

Шомырт түгел, юкә чәчәкләре
Нурга мана июль кичләрен.
Җәйге челлә... Күңел – унҗидедә,
Канатлана яшьлек хисләрем!
Кабатлансын яшьлек хисләрем!

## Йөрәк белән

Җан сусады мәрхәмәткә,
Елмаюга, җылы сүзгә.
Дөнья үзе, шәфкать көтеп,
Карап торган сыман күзгә.

Кемдер синнән кабар ризык,
Бер йотым су өмет итә.
Берәүләргә сәлам биреп,
Хәлен белеп китү җитә.

Бер мизгелне багышласак
Тик бер тамчы яхшылыкка,
Бу кешелек адым-адым
Чыгар кебек яктылыкка.

Йөрәк белән йөрәкләргә,
Җаннар белән җанга дәшик!
Кеше булу кыен түгел,
Кешелекле булып яшик!



Зәбир
Гыймаев

# КАТОРЖАН*

РОМАН

**Беренче бүлек**

Газраил фәрештә бүген дә килмәде. Оныклар алдында уңайсыз... Кадрия кызы бигрәк борчыла. Доктор кешене авырулары көтәдер. Балаларга мәшәкать ясап, дүртенче ай үлә алмый ята менәтерәк... Йөреп торганда әле ару иде. Аякларның хуты беткәч читен. Шөкер, хәтере чуалмаган. Күңел хөҗрәсендә казынып, көне уза...

И, бирсә дә бирә икән гомерне Ходай. Тәкъдирендә язган булып, көнесәгате җитсен иде инде, хәере белән. Үлемнән курыкмый ла ул. Каушата барыбер... Уйландыра...

– Ихластан әйтәм, син кушканча яшәргә тырыштым, Ходай, – дип уйлады ул. Күңел төпкеленнән үкенүгә охшаш хис баш калкытты. – Бигүк барып чыкмады бугай... Хозурыңа килгәч, кая юллама бирергә икәнен үзең карарсың тагын: тәмугка озатырсыңмы, оҗмах ишекләрен ачарсыңмы...

– Дәү эти, укол...

– Кирәкмәс иде, кызым.

Беләген черки тешләп алгандай гына итте. И, даруга калган гомер...

– Дәү эти, чәй эчеп аласыңмы?

– Әйе, кызым.

Аркасына мендәр салып торгызып утырттылар. Авызы тәм югалтмаган икән әле: балы – баллы, кагы – әчкелтем. Бер чынаяк чәен бик тәмләп эчте.

– Рәхмәт, балалар. Хушландым.

– Саф һавада йөреп керәбезме, бабакай? – Гаяз оныгы эндәшә. «Әйе» дисәң, инвалид арбасына җилтерәтеп утырта да һава суларга алып чыгып китә.

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан 2023 елда уздырылган татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсының «Роман» номинациясендә өченче урынны алган әсәр.

Зәбир ГЫЙМАЕВ (1951) *– язучы, укытучы; «Яңа татар пьесасы» конкурсы, «Казан утлары» журналы үткәргән әдәби конкурслар җиңүчесе. Түбән Камада яши.*

– Юк, улым. Бераз утырып торыйм. Сез эшегезне карагыз. Хәлем әйбәтләнде, шөкер.

– И балалар... Мин китеп баргач, икәү генә каласыз бит... Бер-берегезгә терәк булып яшәсәгез иде!.. Нәсел агачын корытмасагыз иде!..

Бу дөньяларда бала кайгысы күрмә икән. Хәсрәт тустаганын төбенә кадәр эчсен диденме, Ходаем? Сиңа бер үпкәм юк минем... Сорыйсым гына килә: улым Гыйлемханның гомерен берничек тә саклап калып булмый идеме? Гомере бигрәк аянычлы: юл һәлакәтендә өзелде ләбаса.

Килене Зәрия ирен югалту кайгысын күтәрә алмады. Тумрап торган хатын, ире үлгәч, чиргә сабышты. Врачлар тырыштылар анысы... Үлем тырнагыннан алып кына кала алмадылар. Сары-сары саргаеп, ике сабыен ятим калдырып, кырык яшен дә тутырмый китте дә барды балакай.

Газраил фәрештәңне тизрәк җибәрсәң иде, Ходаем! Балалар алдында уңайсыз миңа. Күреп торасыңдыр, бик бетеренәләр. Карчыгым янына урнаштырып, кырыгымны үткәрсәләр, тынычланып калырлар иде алар да...

Газраил! Сиңа эндәшәм. Син, давай, кунак кызы кебек ялындырып торма! Кызык... Төс-кыяфәтең ниндирәк булыр инде? Фани дөньяда изге эш-гамәлләр кылып яшәгән адәмне гүзәлләрдән дә гүзәл фәрештә алырга килә, имеш... Яман юлда йөргәннәрнең фәрештәсе ямьсезләрнең дә ямьсезе икән... Юк сүздер... Кем белә?..

Чү!.. Нинди тавышлар ишетелә? Кемнәр болар?..

***

– Аллаһ әкбәр!.. Аллаһ әкбәр!..

Тәкбир әйткән тавыш авылны сискәндерде.

– Молчать, контра! – дип акырды ярсу атка атланган җайдак, ачуыннан кара көеп.

Җайдакның башында кызыл йолдызлы фуражка, өстендә зәңгәр гимнастёрка, галифе чалбар, аягында ялтыравык күнитекләр; киеме, шадра йөзендә чагылган тәвәккәллек аның гади җир кешесе түгеллеген, бәлки власть өчен яратылган адәм икәнен әллә кайдан «кычкырып» торалар иде.

Бәдри (тулы исеме Бәдретдин) – авылда партячейка секретаре. Бүгенге чара өчен ул җаваплы. Шуңа да иртә таңнан Камали байның Кара айгырын иярләде. Атлаган саен йөгәнен тарткалап торгангамы, менгән аты холыксызлана: вак-вак атлап, артка чигә-чигә биеп китә; танау тишекләрен киереп пошкыра, күзләрен алартып, авызлыгын чәйни, авызыннан канлы күбекләр оча... Әмма җайдак иярдә нык утыра, тезген тоткан кулы каты...

– Аллаһ әкбәр! Аллаһ әкбәр!.. – Китүчеләргә картлар кушылды.

– Молча-а-ть! – Партячейка секретаре, чыгырыннан чыгып, айгырга камчы белән орды. Хуҗасының йомшак таләпчән тавышына күнеккән хайван моны көтмәгән иде. Авызлыгын тешләп, ул кинәт сикерде; ал аякларына төшеп, арт санын чөеп җибәрде. Ярсып кешнәде. Сыртында шулкадәр ипсез утырган адәм ияреннән мәтәлеп төшкәч, тояк тупырдатып чабып китте.

Бәдри шактый вакыт сыны катып тора алмый ятты. Бар дөньясына нәфрәтләнде. Берсе-бер килеп ярдәм итмәде. Хәлен сорамады. Аягына басуга, үтереп тубыгы сызлый башлады. Тешен кысып сүгенде. Аксый-туксый, авыл Советы урнашкан Камали бай йортына титаклады.

***

Авыл биш кулак гаиләсен сөрергә тиеш иде. Югарыда азсындылар. Районнан вәкил килде. Вәкил сүзен кыска тотты: авыл зур, сыйнфый дошман аз. Бу нинди сәяси томаналык?! Моны ничек бәяләргә?! Партия сызган юлдан читкә тайпылу дипме?!

Авыл Советы рәисе иптәш Имаметдинов, партячейка секретаре иптәш Гобәйдуллин, комсомол оешмасын җитәкләгән яшь егет иптәш Зәйдуллин һәм Таллыяр авылының дүрт-биш активисты уйга калдылар.

– Сыйнфый сизгерлегегезне югалттыгызмы, иптәшләр? – диде вәкил, түземе төкәнеп. Сыйнфый сизгерлекне югалтырга ярамый иде!

Исемлекне яңабаштан карап чыктылар. Яңа кандидатуралар тәкъдим ителде. Тавышка куяр вакыт җиткәч, активистлар Курбашев Нурисламны яклап чыктылар: нинди кулак булсын ул, урта хәлле крестьян! Мәсьәләгә аерым тукталып, мал-мөлкәтен янә бер кат инә күзеннән үткәрделәр.

Алты почмаклы калай түбәле йорт. Мунча. Коеп куйган каралты-кура. Мал-туары: ат, сыер, башмак тана, унике баш сарык, бер оя каз, тавык-чебеш... Хезмәтче тотмады.

Нурисламны җибәрәселәре килми иде. Алтын куллы адәм. Шуңа да ил-көндә абруе зур.

Бәлки, алып та калырлар иде, Бәдри «Зингер» тегү машинасын исләренә төшерде.

– Чыкылдап торган кулак! – диде вәкил, өстәл сугып. «Тавышка куябыз!» – партячейка секретаре, кулын күтәреп, активистларга күз йөртеп чыкты. Бер-бер артлы куллар күтәрелде...

Сөрделәр... Урманга җиткәч, ат менеп озата баручы милиционер җилкәсеннән мылтыгын алды. Олауларның берсендә җиде яшьлек малай елады. «Балакаем!» – дип өзгәләнде әнисе. «Егет кешегә елап утыру бер дә килешми», – диде әтисе. «Нургали, телисеңме, мин сиңа үземнең буяу карандашларымны бирәм», – диде апасы, энесен юатырга теләп.

Манарасы киселгән мәчет янында картлар гәпләште:

– Дөнья Бәдри ишеләр кулына калыр микәнни? – диде берсе.

– Калды инде, кордаш, – диде икенчесе.

– Туфрак учласа, алтын итә торган ирләрне сөрдек. Алтабан ничек яшәргә уйлыйлардыр, – дип көрсенде өченчесе.

***

Юл газабы гүр газабы шул. Гүр газабы-ы!.. Таш амбарга ябып, район үзәгендә ике көн тоттылар. Өченче көнне тирә-як авыллардан да җыелган бәхетсезләр белән пристаньга кудылар. Пристаньнан ак пароход Казанга юл алды.

Башкалада мәхшәр: елаш, кычкырыш, чәбәләнеп, этләр өрә... Сүз таралды: балигъ булмаган балаларны алып калачаклар! Сабыйлар балалар йортында тәрбияләнәчәк, имеш. Әнисе күз алдында сызды: күзләре генә утырып калды.

Бу шомлы хәбәр тынарга өлгермәде, икенчесе сискәндерде: Комсомольск-на-Амуре каласына китәчәкләр. Анда зур төзелеш башланып килә, эшче көчләр бик кирәк икән. Китәсе җирнең җәһәннәм тишегендә булуы төн йокыларын качырды. Соңрак килештеләр тагын... Булсын! Балалардан гына аермасыннар.

Ниһаять, ачыкланды: Березники каласында химия комбинаты төзелә, боларны шунда җибәрәчәкләр. Пермь краенда гына бит бу! И, сөенделәр: туган илләрдән кошлар очып җитмәслек еракта түгел, ләбаса!

***

Такта ярыгыннан дөньяны күзәтеп бару шулкадәр кызык. Өйләр, урман-кырлар, кешеләр күренеп кала. Җәлт-җәлт чакрым баганалары йөгерә. Бер көйгә вагон тәгәрмәчләре тукылдый. Сузып кына паровоз кычкыртып ала.

Туктый-туктый, менә өченче тәүлек баралар... Алган ризык, никадәр саклап тотсаң да, тел очына салырлык кына калды. Тәүлегенә ике чиләк су бирәләр. Кеше башына бер кружка тия микән? Вагоннан чыгармыйлар.

Андрей исемле рус малае белән танышып-аралашып киттеләр. Аралашып дию бигүк дөрес булмас: сөйләшергә тел юк. Исемнәрен әйтеп, зурлар кебек кул кысыштылар.

– Драстуй, знакум, – диде Нургали. Урыс малае да җавапка нәрсәдер әйтте. Сүзсез калдылар. Андрейның Наташа исемле сеңлесе бар икән. Зәңгәр күзләрен төймәләндереп, Нургалигә карап утыра.

– Драстуй, знакум, – диде малай, аңа да кул биреп.

– Вот дурачок! – дип көлде кыз...

– Әйдәгез, «очты-очты» уенын уйныйбыз, балалар, – диде әтисе.

– Ура! – дип кычкырды Нургали. Әтисе тәрҗемәләре белән татарча-русча ун сүз әйтте. Сүзләрнең кайсылары «оча», кайсылары – юк. Ике командага бүленделәр: Андрей-Наташа, Нургали-Галимә апасы. Җиңелсәң, җәза: кызларның чәчләреннән тартыш, малайларның борынына чиертәчәкләр.

– Я начну! – диде Андрей, уен дәртенә бирелеп.

– Башла, – диде әтисе.

– Летели, летели, гуси полетели! – дип кычкырды Андрей.

Һи, шуны да белмәскә! Безнең өчен бу ике тиен – бер акча!..

– Летели, летели, утки полетели!

Куллар янә күтәрелде.

– Летели, летели, коровы полетели!

Апасы икеләнеп калды, Нургали кулын югары чөйде.

Борынга чиертәләр каһәрләр!.. Сыерның корова икәнен белмәсәң, шулай ул!

Уенның кызыгы алда булган икән әле. Чират Нургалигә җиткәч, әби-бабайлар да очар кошка әверелде. Борының гына чыдасын, Андрей дус! Наташаның толымыннан тарту күңелгә аеруча рәхәтлек бирә.

Күпме вакыт узгандыр, гел ялгышмый башладылар. Әтисе тагын ун сүз өстәде. Бик мавыктыргыч уен булып чыкты бу! Ашыйсы да килмәсә... Чит җирдә тамак үзәкләрне өзеп ача икән. Кич җиткәч, әнисе, юка гына кисеп, бер телем ипи бирәчәк. Бүген апасы белән икесенә бер пешкән күкәй тәтер микән? Ярты кружка су.

– Бисмиллагызны әйтеп ашасагыз, тамагыгыз туяр, – ди әтисе. Бисмилласын кат-кат әйтә дә бит...

***

Паровоз сузып кычкыртты да, әкренәя барып, туктап калды. Иңбашына мылтык аскан солдат вагон ишеген ачып җибәрде. Күгәргән тавышы белән сөрән салып кычкырды:

– Выходи!

Вагонда ыгы-зыгы китте. Солдат, сүгенеп, кешеләрне ашыктыра торды. Яңа боерык яңгырады:

– Строиться!

Тезелешеп бастылар.

Кешеләр алдына карсак буйлы, тук чырайлы, кара эшләпәсен күзләренә кадәр батырып кигән адәм чыкты. Тавышы таш яра үзенең:

– Партиянең, иптәш Сталинның зирәк карарын тормышка ашыру йөзеннән бүген илебездә иң зур химия комбинатының нигез ташлары салына! Иртәгә патша заманында эт тә белмәгән Березники бистәсе якты киләчәгебезгә юл күрсәтеп торучы эре сәнәгать үзәгенә әйләнәчәк! – Чак кына «ура, иптәшләр!» дип кычкырмады (менә бит: чир китә – гадәт китми дигәннәре хактыр). Маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты. Зиһенен хәвефле уй өтеп алды: ялгыш кычкырган булса?! Үзен кулга алып: – Сүз иптәш Семёнов Егор Потапычка бирелә, – дип, кыска гына нотыгын йомгаклый алды.

«Потапыч» дигәне авызында эт балалата торган адәм булып чыкты. Алай да өсләренә ташкын булып ургылган буш, мәгънәсез янау-сүгенү сүзләреннән кирәген аралап алдылар: төзелешкә агач кирәк, болар урман кисәчәкләр.

Егор Потапыч сәясәткә дә кагылып узды:

– Иптәш Сталин, партия сезгә олы ышаныч күрсәтте. Зур төзелешләрдә кайнап, чын совет кешесе булып тәрбияләнергә мөмкинчелек бирде. Әгәр дә сез, контралар, иптәш Сталинның, партиянең ышанычын акламыйсыз икән, без Совет власте дошманнары белән нишләргә икәнен белербез! Безнең куллар калтырамас! Эленке-салынкы йөрергә өметләнмәгез. Норма бар, паёк бар. Норманы үтәмәсәгез, паёк яртылаш киселә. И баста! Туклану – ашханәдә. Яшәү – баракта. Килүегезгә барак салып куйдык. Балаларыгыз, яшенә карап, яслегә йөрер, мәктәптә укыр. Илгә укымышлы кешеләр кирәк. Бөтен сораулар белән миңа мөрәҗәгать итә аласыз. Бүгенге көннән мин сезнең Аллагыз да, муллагыз да! Сораулар бармы? Сораулар булмаска тиеш, чөнки мин бөтенесен ачык, аңлаешлы сөйләдем! – Егор Потапычның шулкадәр «матур» сөйләвенә үзенең дә күңеле булды, күрәсең, авызын басу капкасыдай ачып боерды: – Налево! В барак, шагом марш!

Баракны күргәч, тагын бер кат уш-акыллары китте. Монда ничек яшәмәк кирәк?!

Әштер-өштер бурап салынган зур гына абзар дисәң... Җүнле хуҗаның абзары да болай булмас. Бүрәнә араларында кул яссуы сыярлык ярык. Түбәгә карап, йолдыз саный аласың. Кары-яңгыры өстеңдә булачак.

Барак эче такталар белән «кетәклек»ләргә бүленгән. Эчендә – өстәл, сәке, ике урындык. Идәне юк. Куллары җитмәгән. Үзеңә җәясе.

Уртада – зур кызыл мич. Бөтен баракны җылытырга исәпләнелгән. Егор Потапыч, аты-юлы белән сүгенеп: «Ягып карадык. Төтен кайтара», – диде.

Кешеләр югалып калдылар. Ничек яшәрләр алар монда?! Ничек көн күрерләр?! Тиздән салкыннар башланачак. Зәмһәрир суыклары белән кыш җитәр...

Ирләр башларын түбән иде. Хатын-кызлар арасында елау-сыктау тавышлары ишетелде: «Ходаем, ник безне бу җәбер-золымнарга дучар иттең?.. Нинди гөнаһларыбыз өчен?..»

Кайсыдыр иптәш Калининга язарга кирәк диде. Аны хупладылар. Кыюсыз гына, менә сүнәм-менә сүнәм дип, өмет уты кабынды.

– Беркая да язарга кирәкми, җәмәгать! Әйдәгез, уйлашыйк... Салкыннарга кадәр вакыт бар. Барак эчендә җил уйный дисезме? Тайгада мүк беткәнме? Мүкләрбез! Түбәдән яңгыр үтәр дисезме? Түбә ябучылар юкмыни арабызда? Ә мичне сүтеп яңадан чыгарабыз. Үзем алынам. Яхшы мичсез булмый, туганнар! – диде әтисе.

– Акбур табып, мичне акшарлап та җибәрсәк! Кунак кызы кебек булыр, менәтрәк! – дип, әтисенең сүзен җөпләде әнисе.

Кешеләр елмайдылар. Бар борчулар бер адым артка чигенде. Яшәрләр! Җан биргәнгә җүн биргәнсеңдер әле, Ходаем!..

Салкыннар башланганда, тишек-тошыклар мүкләнгән, түбә ябылган, сүтеп, яңадан чыгарылган мич акшарланган; әнисе әйтмешли: «кунак кызы кебек булган» иде.

***

Гасырлар дәвамында тынлык саклый тайга... Бары күк күкрәп явып үткән яңгыр шавы, су чылтыравы, йөзьяшәр агачларның җилдә чайкалуы, кошлар тавышы, нәсел калдырырга хак даулаган киек-җанварларның сугышчан чакыру авазы гына боза ул тынлыкны...

Тайгага кешеләр килде. Алар күп иде. Пычкылар чыжлады, балталар тукылдады. Тынлыкны сискәндереп, агачлар ауды. Ят тавышлар, төтен исе киек-җанварларны хәвефкә салды. Төймә күзләрен елтыратып, агачлар арасыннан аю карады. Башын чайкап, ризасызлыгын белдергәч, тайга хуҗасы бу тирәдән ераккарак китүне мәгъкуль күрде. Кабан дуңгызлары килеп чыкты. Болар озак мыркылдаштылар, мөгаен, йөриләр шунда, тынычлыгыбызны алып диюләре булгандыр; аннан, дәррәү кузгалып, агачлар ешлыгында күздән югалдылар. Пошилар бу вакыйганы тынычрак кабул иттеләр бугай. Бүреләр күренде. Өер башы, арт тәпиләренә чүгә төшеп, һаваны иснәде. Бугазыннан усал ырылдау авазы бәреп чыкты. Тәне буйлап, сырт йоннарын кабартып, калтыравык дулкын йөгереп узды. Ачның ачуы яман шул. Һай, яман!.. Сасы селәүчәннәр җитмәгән, биләмәне бу адәми затлар белән дә бүлешергәме?! Юк! Ау! Тик нинди көч аны бу адымнан тыеп тора соң? Өер башы Күккә карап улап җибәрде. Һәм Күкләрдән җавап килде: табу. Аның ыруы соңгы чикне үтмичә дә яшәргә һәм нәсел калдырырга сәләтле. Табу...

Баш бүре, урман кисүчеләрне уратып узып, бөтенләй икенче тарафка китеп барды. Өер аның артыннан иярде.

***

Апасы чирли... Галимә апасы ут яна. Әти-әнисе – эштә, авыру апасы Нургали тәрбиясендә.

Доктор килде. «Салкын тидергән. Үпкәсе шешкән», – дип, ниндидер порошок, төймәләр бирде. Даруларны кайчан, ничек эчәргә кирәген әйтте. Авыруны хастаханәгә салу турында сүз кузгатмады. Нургали нәкъ доктор кушканча эшләде. Апасының хәле җиңеләймәде. Бер әби кипкән дару үләннәре китерде. Үләннәрнең сихәте тигән кебек булды. Чир чигенде. Әйләнеп кайтып, апасының бугазыннан алды; суларга ирек бирмәде. Хәле авырайгач, апасы гел

саташты: «Энем, быел җәй авылга кайткач, Какылы тауга җиләккә барырбыз, яме!.. Анда җил-ә-ә-к!.. Җыеп бетермәле түгел, белсәң! Чур!.. Минем алдан җыйма!.. Монда җиләк күп икән, аю-бүре юк икән...»

Кышның зәмһәрир салкын көнендә Какылы тауда җиләк җыйганда үлеп китте Галимә апасы...

***

Ходай бала кайгысын бирмәсен икән. Әтисенең киң җилкәләре салынып төште, төз гәүдәсе алга сөрлекте. Авыр эшне сытып эшләгәндә дә зарланмаган әнисе гөл чәчәгедәй сулды. Хәтере начарайды. Мәрхүмә баласының киемнәрен барлап утыру көндәлек шөгыленә әйләнде. Ике иратына күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып еш елады.

Бала кайгысы өстенә дөнья тагын бер четерекле ягы белән ачылды: яшь калада мөселман зираты юк икән. Вакыт бара. Мәетне җир куенына иңдерү кирәк.

Нурислам Башкарма комитетның ишеген шакыды.

***

Түрә бүген ачулы иде. Бер сәгать элек Мәскәүдән чылтыраттылар. Наркомның тавышы җанын өшетте: «Ты что там, вредительством занимаешься?! Ты мне план давай! План! Учти: ходом строительства интересовался сам Хозяин!»

Монда ниндидер мужик. Үтенече зиһененә барып җиткәч, ачуы ташып түгелде: «Какого чёрта! На общее кладбище!»

Чыгып китүдән башка чара калмады. Нурислам Башкарма комитет урнашкан бина каршындагы мәйданда туктады.

Кая барырга? Кемнән ярдәм сорарга? Мәйданга кешеләр җыела башлады. Берсе килде... икенчесе... өченчесе... Бер сәгатьтән төркем хасил булды. Бар сөйләшүләре хәл-әхвәл сорашудан узмады. Кешеләр, Башкарма комитет урнашкан бинаның зур тәрәзәсенә карап, тыныч кына басып тордылар.

Халыкның болай җыелуы түрәнең тынычлыгын алды. Боларның уенда ни икәнен кем белә?! Чылтыратты. Милициядән тиз килеп җиттеләр. Кешеләрне куып таратмакчы булдылар. Беркем китмәде. Кешеләр элеккечә тынлык сакладылар. Ник бер сүгенү, янау сүзе ишетелсен. Әллә нинди шомлы тынлык иде бу! Курку, тирәннән күтәрелеп, маңгаена салкын тир булып бәреп чыкты. Секретарена боерды: «Пиши приказ. Выделить участок земли для мусульманского кладбища. – Өстәл сугып җикерде: – Территорию огородить!»

***

Мөселман зиратында беренче кабер калкып чыкты. Җеназа намазы укылды. Апасын соңгы юлга озатырга кеше байтак килгән иде. Малай бөтенләй белмәгән чит-ят кешеләр... Юк, нишләп чит-ят булсын?! Туганнары!

Халык таралгач, йөрәге телгәләнде: апасы менә шушы кар баскан басуда япа-ялгыз каламы?!

Өйгә кайткач та, йөрәк әрнүе басылмады, киресенчә, көчәя генә төште. Апасы анда ялгыз... Ялгыз! Әти-әнисе йоклап киткәч, мыштым гына торып киенде. Шыпырт кына бaрактан чыкты.

Күк йөзе аязган: ай урагы күренә, йолдызлар чекрәеп яна... Ае да булгач, бер дә куркыныч түгел иде.

Апасының кабере өстенә кар яуган. «Менә килдем әле, апа. Таңга кадәр утырыйм янында», – диде. Карга утырсаң, салкын тидерүең бар, килгәндә, нарат-чыршы ботаклары сындыргалаган иде – җайлап кына шулар өстенә чүмәште. Яңалыклар шөйлә күп җыелган икән: түкми-чәчми апасына сөйләде. Авызы бер дә тик тормады инде. Юк, бер тамчы курыкмады.

Кемнеңдер тере, кызыксынучан күз карашы аңа төбәлгән... Кемдер аны күзәтә... Ул моны бөтен тәне белән тойды бугай... Беркавым башын күтәреп карарга йөрәге җитми утырды. Ул арада Айны болыт каплады. Басу караңгылыкка чумды. Астыртын гына, күз кырые белән генә карап алырга дип, башын күтәрде. Кырда 30-35 адым читтәрәк яшькелт утлар яна иде. Менә ул утлар хәрәкәткә килде. Якынайдылар. Бүреләр! Бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Аяк-кулларын тыелгысыз калтырау алды. Зиһенендә өмет чаткысы кабынып алды да сүнде: болардан берничек тә качып-котылып булмаячак!..

Малайның каршысына тугыз бүре килә иде. Өер ике тәүлек бер пошины эзәрлекләде. Поши карт, авыру иде. Тояк эзләрендә сакланган ис, усак кәүсәсенә сыланып калган селәгәе дә шуны раслый иде. Алай да корбаннарын озак кудылар. Ниһаять, өер пошины уйсу җиргә кысрыклап кертә алды. Монда кар тирән иде. Поши корсагына кадәр кар көртенә батты. Аңа хәзер бүреләрне чөеп кенә ташлый алган авыр тояклары ярдәм итә алмаячак иде.

Өер башы, җаен туры китереп, пошиның бугазына сикерде. Бүреләр җылы ит, кан исенә исереп, көне буе сыйландылар. Боларның тәмам авыраеп «мәҗлес»тән кайтып килүләре иде. Кем әйтмешли: тамак тук, өс бөтен.

Бүреләр, тагын да якынрак килеп, кар өстенә яттылар. Колакларын торгызып, малайга текәлделәр. Күрәсең, кызыксыну ерткыч хайваннар өчен дә ят сыйфат түгел. Ара-тирә ырлап яисә чәңгелдәп өреп куйгаладылар. Малайның тавышына үтәли сеңгән әрнү бүреләрнең дә тынычлыгын ала иде булса кирәк.

Сәер Җан Иясе калтыравык тавыш белән сөйли иде: «Килдегез дә яттыгыз... «Нишләп йөри икән бу малай?» дип уйлыйсыздыр инде... Апамны җирләдек бүген... Төнгелеккә ялгызын калдырмыйм, дидем... Әнием бик кайгыра... Кайгы казык башыннан йөрми, адәм башыннан йөри шул. Без бу якларга еraklardan килеп чыктык. Юк, авылдан үз теләгебез белән китмәдек. Безне усал абыйлар өебездән куып чыгардылар... Бер дә китәсебез килмәгән иде...» – Сүз буасы бер ерылгач, күңел төене чишелде дә китте... Күз яшен сыпырып ташлап, башын күтәрде. Бүреләр, тезелешеп, урманга кереп баралар иде. Бүреләр, бик азын булса да, малайның кайгысын үзләре белән алып киттеләр...

Шәрифулла агай, баракта тәмәке тартырга уңайсызланып, тышка чыкты. Яңа яуган карда бала-чага итеге калдырган эзләрне күрде. Эзләр зиратка алып килде.

Нургали йокыга китеп бара, тирә-юнь бүре эзләре белән чуарланып беткән иде.

Әтисе ачуланды. Әнисе улын кочып елады. Үзе чирләп тә ятмады.

***

Урман кисү әкрен-әкрен җелегеңне суыра. Көне буена авыр эштә ватылган тән бер төндә кабат көч җыярга өлгерми. Ару астыртын гына үз эшен эшли: кеше битараф, карусыз бер мәхлуккa әйләнә...

Ашханәдә туклананалар. Бер миски кәбестә ашы. Ярты миски ботка.

Ике телем ипи. Бер стакан чәй яисә компот. Үтер, суй – дуңгыз итеннән әзерләнгән ризык йөрәккә ятмый.

Кешеләр күләгәгә охшап калдылар. Күпләрнең тешләре төшә, уртлары каный... Дәвасы бар икән: ылыс кайнатып эчәләр. Файдасы тия.

Норманы эшли алмыйлар. Җан тиреңне түгеп тырышсаң да, үтәп булмый көндәлек норманы. Үтәрлек тә түгел: җан башына – 2 кубометр. Бер кубометры – кәүсәсенә карап, 5-7 киселгән агач. Кисү белән генә эш бетми: ботагын чабасы, бүрәнәне тиешле озынлыкта турап, әрдәнәләп өясе дә бар.

Егор Потапыч кызык адәм: идарәдә сүгеп җибәрсәләр, әтисе янына керә дә җитә. Әнә бүген дә өстәл артында утыра. Чыраена буран йөгерткән, авызындагысын эт җыймас:

– Сез нәрсә, контралар, ял йортына килдегезме? Саботажниклар! Урман кисәргә теләмәсәгез, Магаданга алтын юарга китәрсез! Мин сезнең ише дошман элементлар белән нишләргә белермен! Тотып атарга кирәк сезне! Бүтәннәргә гыйбрәт булсынга! – дип, дөньяга сыймый.

– Кызма әле син, Егор Потапыч! Сүгенүдән бер мәгънә дә юк бит. Безне тотып атудан урман үзеннән-үзе киселмәс. Синең дә башыңнан сыйпамаслар. Бергә-бергә бу катлаулы хәлдән чыгу юлын эзләргә кирәк, – диде әтисе.

– Син тәкъдимеңне әйт, контра! Мине телең белән юмалама! – диде Потапыч, сүрелә төшеп.

– Ни өчен норманы үти алмыйбыз? Сәбәбе нәрсәдә? Синең шул турыда уйлаганың булдымы, Егор Потапыч?

– Саботажниклар, кабер тактагызны! Сезнең белән икенче төрле сөйләшергә кирәк!

– Урман кисү – авыр эш, Егор Потапыч. Бу эштә җегәр кирәк. – Әтисе сабырлыгын саклады. – Димәк, ашау да әйбәт булырга тиеш. Тамак туярлык. Күреп торасың, кешеләр тәмам хәлсезләнделәр бит...

– Дәүләт тарафыннан билгеләнгән паёкны аласыз!

– Безнең авызга кергәнче күпмесе урланадыр әле ул ризыкның, – диде әтисе, авыр сулап. – Йә, ярый, сүзем ул хакта түгел. Пошилар күренгәли монда. Син безгә ауга йөрергә рөхсәт ит, Егор Потапыч.

– Ничек ауга йөрмәкче буласың син? Сез контраларга мылтык бирергә рөхсәт юк!

– Безгә мылтык кирәкми, Егор Потапыч. Пошиларга тозак куймакчы булам мин. Кабан дуңгызы эләксә – сиңа! Без, мөселманнар, дуңгыз ите ашамыйбыз бит.

– Ай, хәйләкәр басурман! Миңа һавадагы торнаны вәгъдә итә!

– Кулда песнәге дә бар, Егор Потапыч! – диде әтисе, киез итеге эченнән бер шешә самогон, тәрәзә төбеннән гәҗиткә төрелгән бер калҗа сало алып. Бу «байлык»ны ул базарда җылы оекбашына алыштырып кайткан иде.

– Син нәрсә?! Мине, партиянең тугры солдатын, үзең ише контрреволюцион элемент белән бер өстәл артында эчеп утырыр дип уйлыйсыңмы? – Әйтерсең, давыл алдыннан күк күкрәде, яшен атты.

– Ихтирам йөзеннән, Егор Потапыч... Халык сине бик хөрмәт итә бит, – диде әтисе, партия солдатын саламга сөяп.

– Ә-ә... Шулай дисеңме? – Әллә ышанды тагын?..

Ул арада, «син – кем дә мин – кем» дигәндәй кукыраеп, өстәл уртасына

«шайтан малае» менеп кунаклады; янәшәсендә кайнар бәрәңге, тигез телемнәргә киселгән сало, кара ипи, бер баш сарымсак урын алды.

– Тотып ату да аз сине, контра! – диде чакырылмаган кунак, кырыслыгын әз генә дә җуярга теләмичә.

– Син туныңны салып утыр, Егор Потапыч, – диде әтисе.

Икенче чәркәдән соң Егор Потапыч бөтенләй дә киң күңелле адәмгә әйләнде.

– Ярый, куй тозагыңны! Миннән рөхсәт. Ну, быел кыш кабан дуңгызыннан авыз иттерәсең. Йөр ауга, басурман, күз йомармын. Кирәк чакта ачармын да! Бер шарт үтәлергә тиеш: ауга киткәндә, миңа әйтеп китәсез. Көнендә кайтып җитәргә! Югыйсә мин кая хәбәр итәргә кирәген белермен! Аңладыңмы?

– Аңладым, – диде әтисе.

***

Ауга өчәү чыктылар: әтисе, Шәрифулла агай, ул. «Арырсың бит, улым», – дип, әтисенең аласы килмәгән иде. Малае бик ялваргач, ризалашты тагын.

Озак бардылар. Бер тамчы арымады. Түгәрәк бер алан читендә туктадылар. Тирә-юньдә поши эзләре күренә. Җәен, мөгаен, бу аланда пошилар утлап йөргәннәрдер. Кышын усак кайрысы кимерергә киләләр.

Ир-атлар яшь усакларны кистеләр. Ул ботак чапты. Бер ара җирне киртәләп алдылар. Алан яклап капка калдырдылар. Шәрифулла агай, каян юнәткәндер, күгәннәр урынына иске покрышка кисәкләре кадаклады. Капканы киереп ачты, кулыңны җибәрсәң шапылдап ябыла, рәхмәт төшкере! Ябылмас өчен чөй әмәлләделәр. Аран түренә, бауга чорнап, үзләре белән алып килгән хуш исле печәнне ташладылар. Бауның бер очын капканы ачык тоткан чөйгә бәйләделәр. Аучылар уйлавынча, эш тәртибе болай: аранга поши керә, тарткалап-йолыккалап печән утларга керешә. Капка баганасына беркетелгән чөй ычкынып китә, һәм поши тозакта!

***

Убыр авыз икән кяфер: тозакка кабан дуңгызы керде. Печән дә ашамый югыйсә... Кызыксынучан хайван шул. «Егор Потапыч, без дуңгызны суя да, эш итә дә белмибез. Син үзеңә кара инде», – диде әтисе.

«Ярый, ярый, мужиклар белән хәл итәм мин аны! Син, давай, бу эшне дәвам ит. Мин күз йомармын. Кирәк чакта ача да белермен!» – диде тегесе, хәер-фатихасын яңартып.

Бер атнадан тозакка поши керде.

Ул көнне ашханәдә поши итеннән аш пеште. Хатын-кызлар өй токмачы кистеләр. Итле-токмачлы аш ашадылар. Ул йөрәкләренә ятты. Күңелләр хушланды. Туган илләр искә төште.

Әтисе җырлады. Әтисенә Шәрифулла агай кушылды. Сабит агай... Нуретдин абый... Җыр баракка сыймады. Җыр, күкләргә күтәрелеп, тайга өстеннән еракларга очты...

> Кара да гына урман, караңгы төн,
> Яхшы атлар кирәк лә үтәргә... –

дип җырлый татар агае.

Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк гомер итәргә, –

дип нәтиҗә ясый. Юк, зарланмый татар.

«Яхшы атың, дусларың булсын. Яшәрбез!» –

ди.

Ә менә мәхәббәтсез гомер итүләре бигрәк читен икән!.. Апалар җырлый:

Энҗе дә мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы...

Малай боларны үсә төшкәч аңлар. Авылдан сөргәндә, бик күп әйберне алырга рөхсәт итмәделәр. Җырны тартып алып булмый икән...

Бу поши соңгысы булмады. Итле-токмачлы аш кешеләргә хәл кертте. Пычкылар җитезрәк тартылды, балталар дәртлерәк тукылдады.

***

Кояш язга борылды. Көннәр җылынды. Тамчылар тамды. Кошлар килде.

Беренче Май бәйрәме алдыннан соң гына, инде йокларга җыенып йөргәндә, баракка Егор Потапыч килеп керде. Иртәнге якта: «Идарәгә тантаналы җыелышка барам», – дип киткән иде. Кайтып җиткән. Кәефе күтәренке. Авызы ерык. Әлбәттә, салмыш.

– Анагызны сатыйм, басурманнар, социалистик ярышта сез җиңеп чыктыгыз бит! – диде. Кучмә кызыл вымпелны барак түренә элде, кожан кесәсеннән самогонын чыгарды. – Ә хәзер гулять будем!

– Иртәгә ял итәбезме? – дип сорады кемдер кыюсыз гына.

– Беренче Май бәйрәмен без хезмәт фронтында яңадан-яңа җиңүләр белән билгеләп үтәчәкбез! – диде Егор Потапыч, бу кадәр килештереп әйтә белүенә канәгать калып. Бер чәркә самогонын «җилпеп» куйгач, сүзен йомгаклады: – Мин сез контралардан совет кешесе тәрбияләргә тиеш. Партия минем алга әнә шундый конкрет бурыч куйды. – Өстәл сугып, тавышын күтәрде: – Һәм тәрбияләрмен дә!

Беркем бәхәсләшмәде.

Аның белән кәеф-сафа корып утырырга теләүчеләр табылды. Төн уртасы җиткәнче утырдылар. Тавышландылар. Бәхәсләштеләр. Җырладылар. Авызларында җүнле сүз булмады.

***

Кызыл вымпел артельдән китәргә теләмәде. Беразга югалып тора да янә әйләнеп кайта. Һәм бу чак кына күңелсезлек белән тәмамланмады.

Урман кисүчеләр эштән кайткан: күбесе, арыган тәннәренә ял биреп, йокыга изрәгән, кайсылары, бик аз эләккән ял сәгатьләренең кадерен белеп, тыныч кына сөйләшеп утыралар иде.

Кинәт баракка таныш түгел кешеләр бәреп керде. Алар күп иде. Һәммәсенең кулында балта. Битен сакал-мыек баскан, күзләре усал елтыраган пәһлеван гәүдәле ир-ат гырылдап кычкырды:

– Кто старшой?

Баракта зыңлап торган тынлык урнашты.

– Йә, – диде этисе.

– Вам что, больше всех надо, татарва?!

– Не понял. – Көтелмәгән сораудан этисе югалып калды.

– Мы столько добивались! А вы рекорд за рекордом ставите! Чего вам не хватает?!

– Да что с ними разговаривать?!

– Зарубим! – Кайсыдыр эшәке итеп сүгенде.

– Объясните толком, мужики! – диде этисе, тавышын күтәрә төшеп.

– Чего тут объяснять?! Норму не выполним! И баста! – диде пәһлеван гәүдәле.

– И начальство будет вынуждено снизить норму! – дип, иптәшенең сүзен куәтләде яңагы-яңакка ябышкан чандыр ир-ат.

– Все жилы тянут, суки! – диде телен бал-май белән авызландырмаган караңгы чырайлысы.

– Заблуждение. Ошибаетесь, мужики! Не мы устанавливаем норму вырубки леса. Норма вырубки леса утверждается на самом верху. Наши начальники – лишь исполнители...

Әтисен тын да алмый тыңладылар. Әтисенең сүзләре кешеләрне ышандырды. Ахырда пәһлеван гәүдәле ир-ат: «А ведь ты прав, Нурислам!» – дип, әтисенең кулын кысты.

Кунак ашы – кара-каршы. Егор Потапычка бу юлы тозакка кабан дуңгызы кергәнен әйтмәделәр. Күрәсең, «убыр авыз»га насыйп ризык булмагандыр. Чучка үзләренә тәтегәч, буза куптарырга килгәннәрнең күңеле булды: «Давайте жить дружно, мужики!» – дип киттеләр.

Нургали үзе ир-егет булгач, бер нәрсәне аңлады: әтисе гаҗәеп сыйфатка ия булган икән. Тавышын беркайчан да күтәрмәс, кешене түбәнсетмәс, тыныч кына, сабыр гына үзенең хаклы икәнен дәлилли белер. Баш бирми азып-тузып йөргән адәмнәрне дә иманга кайтара ала иде әтисе...

***

1955 елның җәе матур килде. Вакытында күк күкрәп, яңгыр яуды. Җылы нурларын сибеп, кояш карады. Мул уңыш вәгъдә итеп, басуда игеннәр башакка тулышты. Болында чалгы тыккысыз булып, печәне күтәрелде.

Төш җитәрәк, авыл юлында елкылдап торган кара төстәге «ЗИС» машинасы күренде. Басу капкасын узып, сиртмәле коега җитәрәк, «ЗИС» аръяк урамга борылды; калай түбәле, тәрәзә йөзлекләре бизәкләп-сырлап эшләнгән йортның капка төбендә туктап калды.

Машинадан куе зәңгәр төстәге һәйбәт бостон костюм-чалбардан, башына мул булып чал төшкән 60 яшьләр тирәсендәге ир-ат һәм изүе ачык аксыл күлмәгенең җиңнәрен сызганып җибәргән, типсә – тимер, басса бакыр изәрлек утыз яшьләрдәге ир-егет төштеләр.

Болар озак кына каршыдагы йортка карап тордылар. Өлкәне, ике тапкыр кулъяулыгын алып, күзләренә китерде. Яше, чак каударланып, папиросына ут элде (моңарчы әтисенә күрсәтеп тартканы юк иде).

Өлкәне җилкапканы ачып:

– Хуҗалар өйдәме? – дип кычкырып сорады. Җавап бирүче булмагач, багажниктан искерәк чемодан, кыска саплы көрәк алды. «Гаеп итмәсләр әле», – дип, бакчага узды. Як-ягына каранып алгач, бөрчек-бөрчек кара туфракны чемоданына тутыра башлады. Янә, читкә борылып, кулъяулыгын күзләренә китерде. Яше, чемоданны җиңел генә күтәреп чыгып, багажникка урнаштырды.

– Зиратка меник, улым, – диде ир-атларның өлкәне. Зират авыл читендә калкурак җирдә, авыл халкы «зиратка менәбез» дип сөйләшә иде.

Мәрхүм булган авылдашларына, туганнарга сәлам биреп, зиратка керделәр.

Өлкәне Коръән укыды; яше үзе белгән дога сүзләрен ихластан кабатлап, әтисе кырында басып торды.

– Күңелем булды, улым. Сиңа рәхмәт. Сине мәшәкатьләдем... – диде әтисе, зираттан чыкканда.

– Нинди мәшәкатьләү, ди, әти! – диде улы.

Зират капкасын япкач, әтисе әйтте:

– Зәкинур туганым, синең баш очыңда дога укый алмадым. Кабереӊ – Псков каласында... Мирхәбиб энем, синең кабереӊ тагын даерактарак – Польша җирендә. Миргалим, синең кабереӊ бөтенләй дә билгесез... Укыган догаларым сезнең рухыгызга да барып ирешсен иде.

Чишмәгә туктадылар. Картлачның бөтенесе алдан уйланылган икән: суын эчеп, изүен чишеп, битен-кулын юганнан соң, ун литр сыйдырышлы флягасына су тутырды.

Какылы тау итәгендә җиләк җыйдылар. Шунда ук тамак ялгап алдылар. Пешкән тавык, пәрәмәчләргә кагылмадылар диярлек; чишмә суы эчеп, кара ипи белән җиләккә басым ясадылар.

– Кайтыр юлга кузгалабызмы, әти? – диде улы, күңелләр хушлангач.

– Бәдрине күреп китәсем килә, улым. Эчтәге бер корт тынгы бирми, – диде әтисе гаепле кеше сыман.

– Проблема түгел, әти!

«ЗИС» сиртмәле кое янына җитеп туктады.

Ир-атларның өлкәне озак кына каршысындагы йортка карап утырды. Сәер халәт кичерә иде ул...

Мунчадан чак зуррак өй. Җир төсенә кергән салам түбә.

Каралты-курага ир-ат кулы тимәгәне күзгә ташлана. Капка баганасы бер якка авышкан. Шул капкадан, җаның түзеп, ничек көн саен үтеп йөрмәк кирәк?!

Бары тәрәзәләрдә ак пәрдәләр генә бу нигезгә азмы-күпме ямь биреп тора. Ир-ат кулы сизелми. Бәдри сугышта һәлак булды микәнни? Шулайдыр... Күпләр кайтмады яу кырыннан... Кичер, солдат!..Мин монда әллә ниләр уйлап утырам... (Нурислам ялгыша иде. Бәдрине сугышка алмадылар. Камали байның Кара айгырыннан егылып төшеп, ул аягын имгәтте. Гомере буе аксап йөрде. Авыл тарихына «Чатан Бәдри» булып кереп калды).

Капкадан буй җиткән кыз чыкты.

– Әтине көтсәгез, ул өйдә юк. Эш белән районга китте. Тиз генә кайтмас, – диде.

Кызны күргәч, өлкән яшьтәге ир-атка нидер булды. Югалып калдымы соң?.. Моңарчы Бәдригә: «Кеше талап йөрдең, үзеңә бер дә кот кунмаган икән», – диясе, үзагенә үтәрлек авыр сүзләр әйтәсе килгән иде...

Бар әйтергә теләгәне, бер дә кирәкмәгән пүчтәк сүз булып, артка чикте. Улы алдында кыз бик уңайсызланды. Яшьләр бит... Кызның өстендә сизрәп беткән соры күлмәк, аягында иске галушлар иде. Юк, өй арасында да җитү кызлар болай ук фәкыйрь киенеп йөрми. Кызыйның мин-минлегенә кагылмыйча гына ярдәм итәсе килде. Аның да бит, матур күлмәк, яңа туфли киеп, кичке уенга чыгасы киләдер... Бәлки, күз төшереп йөргән егете дә бардыр әле...

– Сеңлем, сабыр итсәңче!..

Янчыгыннан күлмәк-туфлилек акча санап алып, кыз янына ашыкты.

– Нәзер әйткән идем, сеңлем...

– Нәзер? – Кыз, гаҗәпләнеп, аңа карады.

– Әйе. Балык тотканда, көймәм әйләнеп капланды да... Ярга йөзеп чыга алсам, юлымда очраган беренче чибәр кызга матур күлмәк алып бирермен дип, нәзер әйткән идем. Тагын туфлиләр... Онытканмын. Исән калу шатлыгыннандыр инде... Кисәк исемә төште. Мин аңлыйм: моңа ышану бик кыен. Миннән – акча. Ә күлмәк-туфлине үзең аласың. Килештекме?

– Чын сөйлисезме, абый?

– Соң минем яшьтә алдашып сүз сөйлиләрме?!

– Рәхмәт, абый! – Кызның күз-керфекләре яшькә чыланды. Кулының эш белүенә мактанасы килепме: – И ситсысы булса, үзем дә тегәр идем әле. «Зингер» тегү машинабыз бар безнең, – диде.

Алдашты. Гомергә балыкка йөргәне юк. Ярый соң... Ул кадәр кичерә алмаслык гөнаһ түгел ләбаса.

Кыз, акчасын күкрәкчәсенә яшереп, лапаска керде.

– Төш, әти. Киттеләр.

– Күрәм. – Сәндерәдән Бәдри төшеп килә иде.

***

– Хенде хох! Стой! Шартлатам, чурту-матыр!

Юлга күзләрен акайтып, кызурак табигатьле икәне чыраена ук чыккан бер адәм йөгереп чыкты.

Тормозлар чыелдады. Көтелмәгән хәлдән ал тәрәзәне «сөзә» язып туктап калдылар.

Ул арада машина алдына ук килеп баскан юлбасар кулын югары күтәреп акырды: «Иманыңны укы, дошман!» Кулында граната түгелме соң моның? Әйе шул, немец гранатасы! Юктыр ла... Каян килеп?..

Ир-атларның өлкәне елмаеп, ике кулын алга сузып, машинадан төште.

– Күрешик, туган...

– Сезне күрер көннәр дә бар икән, авылдашлар...

Куллар кысышып, җилкәләренә шап-шоп суккалап күрештеләр.

– Куркыттың, – диде әтисе, көлеп. – Сугыш «күчтәнәче»ме әллә? Гранатаңны әйтәм.

– Соң! Берлин каласын фашистлардан азат иткәндә, аккурат минем аяк астына килеп төште ул «күчтәнәч!» Шартламады! Беркавым аптырап басып тордым да юл капчыгына алып салдым. Кирәге чыгар, мин әйтәм!

– Чыктымы соң?

– Күрсәтеп кенә алам – шыр җибәрәләр!

– Төсмерлим дә кебек үзеңне... Танып бетерә алмыйм, – диде әтисе.

– Разрешите представиться: өлкән сержант Галәветдин Әүхәдиев! Җавап бирегез, зимагорлар: сез туган авылыгызга кайтып, безгә кермәенчә китәргә уйладыгызмы?

Әтисенең йөзенә күләгә төште.

– Уңайсызландык. Без керербез дә бит... Хуҗаларны читен хәлдә калдырмабызмы?..

– Нинди читен хәлдә калдыру ул?! Вәт дивана башлар!

– Үзең беләсең, туган: сөрелгәннәр без...

– Дөньялар үзгәрә бит, Нурислам агай!

– Ай-һай, кояшы тиз генә чыгар микән?

– Ярый, күп сүз – чүп сүз! Бор рульне безнең якка, егет! – дип, кырт кисте гранаталы юлбасар, бәхәскә чик куеп.

Галәветдиндә кунак булып, мунча чабынып, авыл өендә изрәп йоклаганнан соң икенче көнне иртәнге якта юлга кузгалдылар.

***

Машина туган якларны артта калдырып, Березники каласына чаба... Юл ерак, уйларның очына чыкмалы түгел.

Кайтып төшү белән аны таныганнар: мәҗлескә авылдашларының әле берсе, әле икенчесе керде. Тыенкы гына исәнләштеләр. Хәл-әхвәл сораштылар. Киң күңелле хуҗа кунакларның һәммәсен өстәл артына утыртты. Тик менә табындашлар булсалар да, әңгәмә җанланып китә алмады. Йөрәге әрнеп, ачы хакыйкатькә төшенде: кешеләрнең калебенә курку сеңгән... Үзендә дә шул каһәр суккан курку яши.

Авылдашлары белән ачылып сөйләшмәде шул. Акылы белән аңлый: аларның гаебе юк! Күңел төпкелендә юшкын булып утырып калган үпкә-рәнҗүе баш калкытты: сөрделәр бит, сөрделәр!..

– Кайтып җитәбез, әти.

Улы әнә чит-ят шәһәргә «кайтып җитәбез» ди...

***

Таллыяр авылында аларның кайтуын берара телдән төшерми сөйләделәр. Авыл өчен бу зур вакыйга булды. «Кая таба генераллар утырып йөри торган машинада кайткан. Зур түрәдер», – дип фаразладылар. Соңрак күңелгә шик төште: түрәме – юкмы? Ул кадәресен төпченеп сораштырмаганнар икән. Үзе әйтмәде.

Бостон костюм аерым сөйләшүгә лаек булды. «Игътибар иттегезме: кәчтүменең ал ягы кыскаракмы, артымы?» – дип сорады Галәветдин. «Причум монда кәчтүм озынлыгы?» – диделәр авылдашлары. «А притум, кәчтүменең ал ягы кыскарак икән – түрә була, арты кыскарса – рабучий класс!» – дип җаваплады тегесе. Аңламассың бу Галәүне! Сүзендә хаклык та бар шикелле...

Кәчтүменә дә игътибар итмәгәннәр булып чыкты.

Күрәсез, сораулар калды. Ачыклык кертик.

Фаразларга килсәк... Нурислам – урман кисүчеләр бригадиры, улы Нургали – шәһәрнең автотранспорт хуҗалыгында механик.

«ЗИС» машинасы турында сөйли китсәм, сабыр канатларыгыз талмасмы? Тәвәккәллим...

Нургалине, яше җитеп, кырык өченче елны сугышка алдылар. Икенче Белоруссия фронтының унҗиденче армия командующиен йөртте солдат.

Кырык дүртенче елның июнь аенда «Багратион» операциясе башланды. Безнең гаскәрләр, немецны тукмый-тукмый, алга китте, тылда чолганышта калган, чигенергә өлгермәгән яисә теләмәгән дошман частьлары калды. Әнә шул «калдык»ларның берсе аулак урман юлында командующийның машинасы каршысына килеп чыкты...

Немец солдатлары төялгән йөк машинасы борылыштан көтмәгәндә күренде. Бик тиз хәрәкәт итәргә кирәк иде! Тупас йолкып, генералны утыргыч артына сеңдерде. Кисәк тормозга басып, машинасын кырт туктатты да, коралын эләктереп, юл читенә сикерде. Сикергән шәптән, дошманга төбәп, автоматыннан озын чират бирде. Шул сулышта гранатасын томырды. Обоймада патроны беткәч, кыргый мәче җитезлеге белән рульгә укталды; ыргылып кузгалды: кулы икенче, өченче тизлекне кушты; аягы соң чиккәчә газ педаленә басты... Ис-акылын җыеп, артына борылып карады: алты-җиде дошман солдаты әйләнеп төшкән, йөк машинасы кара төтен чыгарып яна иде.

Штабка кайтып җитәрәк генералның тавышын ишетте:

– Выходит, ты мне жизнь спас, солдат. Спасибо. Большое человеческое спасибо тебе. В долгу не останусь. Как говорили в старину: долг платежом красен. К ордену представлю. Отпуск не дам. Мне хорошие водители нужны. Есть ещё какие пожелания?

Югалды да калды. Генералга ни дип җавап бирергә? Ык-мык итеп торуы озаккарак сузылды, ахры, генерал елмаеп сорады:

– А мечта есть у тебя, солдат?

– Есть... Как без мечты жить-то?.. – дип, авыз эченнән ботка пешереп алды ул.

– Какая же? – дип тынычлана белмәде генерал.

– Скорее разгромить врага! – дип чатнатып җавап кайтарды Нургали.

– Это само-собой. А вот личная мечта есть у тебя?

– И такая есть, товарищ генерал.

– Ну, колись, солдат!

– Я, товарищ генерал, после войны мечтаю вернуться к своей невесте вот на этом «ЗИС»е. Да, я понимаю... Виноват!

– О как! – Генерал гаҗәпләнде.

– Больно с гонором она у меня, – дип, мәсьәләгә ачыклык кертте Нургали.

Генерал шаулатып көлде:

– А ты вот так, значит: с ходу хочешь брать крепость?

– Так точно, товарищ генерал!

Күкрәгенә орден такканда, штаб офицерлары чын күңелдәнме, командующийга ярарга тырышыпмы: «Герой! Золотой Звезды достоин парень!» – диештеләр. Нургали аңламады: нинди герой булсын ул?! Немецларны күргәч, шыр җибәрде. Курку бик тиз уйларга, җитез хәрәкәт итәргә этәргәндер, мөгаен. Паникага бирелмәде анысы... Калтырап төшмәде. Шуңа исән калдылар. Әнисе бу хәлне: «Ходай саклаган сезне, улым, – дип үзенчә аңлатыр иде.

Саклагандыр да... Машинаның карарлыгы калмаган: кая карама ядрә

эзе, ал як тәрәзәдән иләк ясап ташлаганнар... Радиаторны да алыштырырга туры килде.

Җиңүдән соң Нургали өч ел хезмәт итте. Хезмәт срогын тутырып, өйгә кайту мәшәкате белән йөргәндә, штабка чакыртып алдылар. Полк командиры сейфыннан машина ачкычын, документларын алды. Ачыклык кертте: «Машина в гараже. Правда, не на ходу. Отремонтируешь. И счастливого пути домой, солдат!»

Сөенечтән башы әйләнеп китте. Генерал! Онытмаган! Бу кадәр кече күңелле кеше булыр икән!

Бер ай гараждан чыкмады. «ЗИС» фронт юлларын күп айкаган, сугыштан соң да, төрле кеше кулына калып, нык таушалган, кыскасы, гамәлдән сызып ташлар вакыты бик җиткән иде. Полк командирының хуҗалык эшләре буенча урынбасарына мең рәхмәт: кирәкле запчастьлар табарга ул булышты.

Бер айдан үз гомерендә иң күңелле сәяхәткә кузгалды. Кайгыртучан куллар бөртекләп сүтеп-җыйган техника озын юлда сынатмады.

Ниһаять, каршысында Березники каласы! Машинасын сабынлап юды. Корытып сөртте. Гимнастёркасына ап-ак яка текте. Итегендә кояш нуры уйнады. Дулкынланды. Сүз дә юк, ике арада хатлар йөреп торды... Кем белә бит... Кемнәр белеп бетергән?! Арада – еллар... Кызлар күңеле иләс-миләс... Ничек күрешерләр?.. Хыялы матур күренеш тудырды... Бер егет ярсу атлар җигелгән матур тарантаста кыз янына килә дә әйтә: «Карета подана, моя королева!» – ди. Әйе, укыды... Китапның исемен генә хәтерләми. Хәер, анысы мөһим түгел.

Тәвәккәлләде. Урамнан үткәндә елкылдап торган кап-кара «ЗИС» машинасы артыннан этләре өреп, бала-чагасы кызыгып, тузаны тузып калды... Кыз яшәгән баракның баскыч төбенә килеп туктады. Нәкъ каршысында – кыз тәрәзәсе! Хаталану мөмкин түгел! Сигнал бирде. Ашыкмый-кабаланмый гына машинадан чыкты. Орден-медальле күкрәк тагын да киерелә төште. «Гөлт» итеп зажигалкасын кабызды. Вәкарьлекне нык саклаган хәлдә «Казбек»ка ут элде. Папиросын тирән суырып, һавага төтен алкалары очырды. Ул арада тәрәзәдән Гөлҗиһанның нурлы йөзе күренде. Гөлкәе! Көткән! Көткән! Күзләреннән күренеп тора!

Кыз, йөгереп, баскыч төбенә чыгуга, машина ишеген киереп ачып:

– Утырасы килгән кешегә корыта (ят сүзне, авызы ияләнмәгәнгәме, катырак әйтеп ташлады бугай) подана! – диде.

– Аһ! – диде кыз.

Бу кадәр галәмәткә кыз йөрәге ничек чыдасын?!.

***

Әтисенең соңгы сәфәре булды ул кайту. Сугыш яралары озак яшәтмәде фронтовикны...

Әнисе бакчадан алып килгән бер чемодан туфракны чүлмәкләргә бүлде. Чүлмәкләрдә гөл үстерде. Гөлләре янына килеп, гел җырлый торган иде.

***

– Кызым!..

– Тыңлыйм, дәү әти.

– Энеңне өйләндереп, башлы-күзле итү сиңа кала, кызым. Мин

өлгермәдем... Энеңнең яше бар, акылы тупсасына утырып җитмәгән. Син җаваплы – ишетсен колагың!

– И дәү əти! Гаязның туенда да утырырсың, оныкчыкларыңны да сөярсең əле!

– Рәхмәт, кызым. Гомергә тәмле телле булдың. Ә хәзер үзен чакыр...

Соңгы вакытта гел Гаяз онытгы турында уйлый. Чыннан да, егетнең акылы тупсасына утырып җитмәгәнме соң?.. Бүтән бер-бер сәбәп бармы? Соң таш калада үскән малай агрономлыкка укыймы?! Укыды. «Горзеленхоз» оешмасына эшкә урнашты. Эше әйбәт бара, күрәсең, мастер итеп куйдылар үзен. Шәһәр читендәге бакчаларында үстермәгән яшелчәсе, җиләк-җимеше юк. Менә сиңа шәһәр баласы! Туктале... Әллә соң?.. Моңарчы башына килмәгән... Җир кешесе бит бу малай!

– Килдем, бабакай!..

– Улым... Син туган якларга кайт... Таллыярга... Анда безнең асыл Ватаныбыз. Кайт та тамыр җибәр. Йолкып алырлык булмасын. Туфрак учла да алтын ит!.. Апаңны чакыр...

– Мин монда, дәү әти...

– Елама, кызым... Олыгайган көнемдә кадер-хөрмәтегездә яшәдем... Рәхмәт, балалар... Бәхил булыгыз...

Кунак бүлмәсе нурга күмелде. Шул мәлдә өйгә фәрештә иңде. Бәрәч, Гөлҗиһанына охшаган түгелме соң?! Әйе шул! Тач Гөлҗиһанның яшь чагы.

Фәрештә, елмаеп, аны үз янына чакырды. Җаны авыру, карт тәненнән аерылды да, сөенеп, Аллаһ илчесе хозурына очты...

***

Җизнәсенә рәхмәт: машинасы кулында – мулласын да алып килде, илтеп тә куйды. Мәҗлескә җыелган бабайларны да ул йөртте. Рус дип тормады – түбәтәен киде; кеше дога кылганда, ул да бит сыпырып утырды.

Бабаларының кырыгын уздыргач, туганнарга утырып сөйләшер чак җитте.

– Мин кайтырга уйладым, апа, – диде Гаяз.

– Кая? – Апасы кисәк сискәнде.

– Татарстанга. Таллыяр авылына.

– Синең туган җирең монда, энем. Син берничек тә Таллыярга кайта алмыйсың! Син ул авылга китә генә аласың! Ә мин сине җибәрмим! Мин синнән биш яшькә өлкәнрәк. Син мине тыңларга тиеш! – Апасы усал да була белә икән.

– Бабакайның васыяте турында онытма, апа!

– Үлем исереклеге белән карт кеше ни әйтмәс...

– Бабакайның зиһене ачык иде, апа!

– Минем белән киңәшләшмәгәнсең дә... Кайтам, имеш... – Апасының керфекләре яшькә чыланды.

– Гафу ит, апа. Минем фикерем барыбер үзгәрмәс иде.

– Без икәү генә калдык бит, энем... Син – минем бердәнбер туганым. Син китсәң, бөтенләй ялгыз калам бит...

– Ирең бар бит, апа!

– Балабыз юк, – диде апасы, көрсенеп.

– Булыр! Якын киләчәктә балага батачаксың син! Иманым камил!

– Бирсен Ходай! – Апасы яктырып елмайды.

– Чит планетага китмим лә мин! Телефон, Вотсап аша аралашып яшәрбез. Кунакка кайтырсыз. Үзем дә килеп чыгармын.

– Татарстан турында яхшы хәбәрләр генә ишетелеп тора да соң... Белмим инде... Яңа урында тернәкләнеп китү җиңел булмас. Туганнар бар микән соң ул авылда? Дәү этинең сөйләгәне булмадымы?

– Сөйләмәде. Алай да туганнар бардыр дип уйлыйм. Табышырбыз!

– Дәү этинең васыятен йөрәгеңә якын алгансың икән, – диде апасы, уеннан аерыла алмый.

– Якын алдым, апа. Яшермим. Бүтән сәбәпләре дә бар кебек... Ничек яшим соң мин?! Иртән эшкә барам, кич кайтам. Эшемдә, Аллага шөкер, бар да яхшы. Иртәгә дә шулай булачак. Берсекөнгә дә... Бер айдан... бер елдан соң да берни үзгәрмәячәк. Ә минем үзгәртәсе килә! Дулап бер яшәп аласым килә!..

– Азып-тузып йөрмәсәң ярый ла...

– Йөрмәм, апа. Син борчылма.

– Фатирны сатып китәргә уйлыйсыңмы?

– Әйе. Йорт акчасын бүлешәбез: яртысы – сиңа, яртысы – миңа. Шулай гадел булыр дип уйлыйм. Сатып алучы бар.

– Юк, энем. Сиңа яңа урында яшәп китәсе. Акча сиңа кирәгрәк булыр.

– Миңа тернәкләнеп китү өчен фатир саткан акчаның яртысы да җитә. Үземнең азмы-күпме акчам бар. Мин кайтып төпләнәсе төбәктә уты-газы, суы кертелгән авыл өйләре күтәрә алмаслык кыйбат түгел. Кызыксынып торам. Дөнья бүген-иртәгә бетми. Акчаның сезгә дә кирәге чыгар.

– Сүземне кабатларга мәҗбүр итәсең! – диде апасы, ачуланып.

– Да, да... Сестра права! – диде рус җизни, әңгәмәгә кысылып.

– Барыбер синең өлешеңә кагылмыйм, – диде энесе, сүзен бирергә теләмичә.

Апасы мичтән кызарышып пешкән өчпочмаклар алды. Өчәүләп чәй эчтеләр. Җизнәсе өчпочмакларны «урды». Туганнарның тамагыннан аш үтмәде. Икесенә дә бик моңсу иде... Киләчәктә мондый очрашуларның сирәк буласын, күбрәк Вотсап аша аралашырга туры киләчәген икесе дә аңлыйлар иде.

### Икенче бүлек

Әллә нишләп җене кузгалырга гына тора. Сәбәбе дә юк шикелле... Иренә кычкырды:

– Сүндер әле шул телевизорыңны! Тавышы башыма каба!

– Сөйләсен... – Назиф Сибгатович телевизорның тавышын баса төште.

– Эш карар идең бераз. Бакча коймасы аварга тора әнә!

– Эш, үлгәч тә, өч көнлек кала ул, карчык.

Шушы йоннан әвәләгән адәм белән гомерләр узды.

– «Карчык» димә миңа!

– Бәрәч, кем дим?..

– Зыялы гаиләләрдә ир хатынына «ханым» дип эндәшә. Синнән буламы соң!

– Без зыялы гаиләме?

– Син – мәктәп директоры. Мин – авыл җирлеге башлыгы. Кешедән кай җиребез ким?

Ир дигәнең, диваннан күтәрелеп, башын кашыды. Фикерен әйтте:

– Ханымнар каткан халаттан йөрмиләр.

– Өйдә ярамаган тагын!

– Менә өйдә «карчык» булып кал инде син, карчык!

– Әй, сиңа әйткән мин җүләр! Көннәр буе ятар иде шул диванында, ирек куйсаң!

Әрепләшәсе килми иде. Әрепләшми дә торып булмый. Күнегелгән.

Фәгыйлә Моратовна сүзен өскә чыгару өчен әле тагын аз-маз зәһәрен чәчмәкче иде – җилкапка ачылды. Ишегалдына җилкәсенә биштәр аскан ир-ат керде. Кем булыр бу?.. Күк бейсболкасын күзенә үк төшереп кигән. Юк... Альберт улына охшамаган. Буйчанрак та, гәүдәгә дә нык-калын күренә. Кирәк чакта күзлеге кул астында түгел. Каударланып, иренә эндәште:

– Безгә кемдер керә. Бар әле, бар, каршы чык. Йомышы булса, баскыч төбендә генә әйтсен. Өем җыештырылмаган.

– Өеңнең җыештырылган чагы бармы...

– Теленең тәмсезлеге! Үзеңне бел! И адәм хуры!

Назиф Сибгатович мыштырдап чыкканчы, ишек шакыдылар.

– Өйдәләрме?

– Өйдәләр. Әйдәгез, әйдүк, түрдән узыгыз!

Керүче ир-ат башын ия төшеп исәнләште. Яшьләргә хас сабырсызлык күрсәтеп:

– Сез авыл җирлеге башлыгы Гобәйдуллина Фәгыйлә Моратовна буласызмы? Өегезгә килүем өчен гафу итегез. Эш урыныгызда мин сезне озак көттем, – диде.

– Э-э... чирләбрәк тора идем шул бүген... Әйе. Ашыгыч эшегез бар идеме? Иртәгегә кадәр сабыр итә алмыйсыз?..

– Ашыгыч дип... Авылда сатлык өйләр бармы, Фәгыйлә Моратовна?

– Йорт сатып алмакчы буласызмы?

– Әйе.

– Ул йортны дача итеп тотарга уйлыйсыздыр инде? Шәһәр кешесе шулай кылана хәзер.

– Мин авылда яшәргә кайттым.

– Яшәргә кайттыгыз?!

– Яшәргә, – диде егет, елмаеп. Үзеннән күпкә өлкән ханымның чиктән тыш гаҗәпләнүе кызык тоелды, ахры.

– Ерактан кайттыгызмы?

– Березники шәһәреннән. Пермь краенда ул кала.

– Ничек алай кайтырга уйладың соң? – дип сорады Фәгыйлә Моратовна, «син»гә күчеп. Якын-тирә шәһәрдән кайткан түрә-фәлән түгел икән әле. Хәер, түрә булырга яшьрәк. Белмәссең, артыннан этүче булса!

– Ике ай элек Нургали бабам дөнья куйды. Гөлҗиһан әбием инде өч ел гүр иясе. Үләр алдыннан бабам: «Улым, асыл ватаныбызга кайт», – дип, васыять әйтте.

– Әти-әниең каршы килмәделәрме?

– Әтиемнең гомере авариядә өзелде. Әнием авырып вафат булды.

– И Ходаем!.. Урыннары җәннәттә булсын. Олы кайгы кичергәнсез икән... Туганнарың бардыр?

– Апам бар. Врач. Пермьдә яшиләр.

– Авылга кайтып нишләргә уйлыйсың соң? Ничек көн күрмәкче буласың?

Егет йөзендә нур балкытып елмайды.

– Җан биргәнгә җүн бирер дия торган иде Нургали бабам. Яшәрбез!

– Бабаң соң... Бәхет эзләп барып чыкканмы ул якларга?

– 1933 нче елда Нурислам бабамны, «кулак» дип, гаиләсе белән авылдан сөргәннәр. Нургали бабама ул чакта 7 яшь булган.

– Алай икә-ә-н... Үзең генә кайттыңмы? Гаиләң бармы?

Егет янә елмайды.

– Өйләнмәгән әле!..

– Исемеңне дә сорамадым.

– Гаяз.

– Алайса, без болай итик, Гаяз... Хәзер вакыт соң. Иртәгә сәгать тугызларда авыл советына кил. Бөтенесен шунда сөйләшербез. Сатлык өйләр бар.

– Ярый. Рәхмәт. Сау булыгыз.

– Сау бул.

– Чәй эчәргә дә кыстамадың, – диде Назиф Сибгатович, егет артыннан капка ябылгач. – Кеше ерак юлдан кайткан. Хәзер кая бара инде ул?

– Бетмәс! Бөтенесенә чәй эчертә башласаң! – Җене тынычланмады. Әллә егетнең «мин сезне эш урыныгызда озак көттем» дигән сүзе ошамады? Көтәрсең! Әллә кем түгелсең! Беткән, ди, синең ишеләр! Авылда яшәргә кайткан! Бал сөртеп куйганнар, ди, монда! Яшьләр шәһәргә китү ягын карый хәзер! Аларга офисларда эш кирәк! Компьютер төймәсенә генә басып утырсыннар! Альберт улларын институтта укыту, Казанның үзендә эшкә урнаштырып, фатир алып бирүләр күпмегә төште соң?! Ашаган белми, тураган белә. Чак калды лабаса... Пай җирләрен шухыр-мухыр китерә дип, кемдер әләк язган. Ярый әле, тикшерүче акча ярата торган адәм булып чыкты. Алар арасында да төрле кеше бар. Хәзер хәлле кеше баласын Казанга урнаштыру ягын карый. Байлар Казан белән генә дә ваксынмый: балалары Мәскәүдә! Олигарх дигәннәренең чит илдән кайтып керми.

– Сандык ачкычын бир! – Картының тавышыннан сискәнеп китте.

– Өстәл тартмасыннан карап ал үзең. Ни булды? Ут чыккандай кыланасың.

– Авылдан сөрелгән бабасының исемен кем диде әле?.. Әйе! Нурислам! Хәтерлисең микән, яшь чагында авыл тарихын язам, китап чыгарам дип, җүләрләнеп йөргән идем.

– Нигә язмадың соң? Азмы-күпме акчасы булыр иде.

– Акчасы!.. Китап чыгару өчен үз кесәңнең калын булуы кирәк!

– Адәм санына керер идең бераз! Йөрисең! Санга суккан кеше дә юк бит сине!

– Сукмасалар!

– Кайтасың да шул диваныңда түшәм санап ятасың! Менә бүгеннән тотын китап язарга!

– Юк, – диде Назиф Сибгатович, сандыктан кызыл клеёнка тышлы калын дәфтәр алып.

– Нигә?

– Сәбәбе бар.

– Нинди сәбәбе? Шул ялкаулыгың инде.

– Утызынчы еллар аның сәбәбе! Утызынчы еллар! Каргышлы, каһәрле чор! Мәчет манарасын кисеп, кыйбласыз калган авыл! «Кулак» мөһере сугып, хәлле тормышлы авылдашларын таш ата-ата куган халык!..

– Монда синең ни катнашың бар соң? – диде Фәгыйлә Моратовна, иренең кызып китүенә сәерсенеп.

– Бу эшләрнең башында минем Бәдретдин бабам торган! Авылның партячейка секретаре! Синекеләр дә читтә йөрмәгән, иптәш авыл җирлеге башлыгы! Мин шул турыда китап языйммы?! Юк! Бу дәфтәр сандык төбендә ятсын. Авыл тарихын белүче картлар бакыйлыкка күчә тора. Яшьләргә кызык түгел... Бәдретдин бабамны гаепләмим мин. Югарыдан боерганнар – үтәгән! Һәркемгә баш кадерле!

«Фермер» дигән ят сүз килеп керде татар авылына. Фермер мөстәкыйль фикер йөртә белергә тиеш! Крестьянны колхозга куып кертеп, кушканны гына эшләргә өйрәттеләр. Уйламаска өйрәттеләр!

Әллә Фәгыйләсе белән бәхәсләшә, әллә үз-үзе белән сөйләшә иде Назиф Сибгатович...

Тапты. Хөснетдинов Илгизәр сөйләгәннәрдән язып алган. Хәрефләрне сулга авыштыра төшеп, сәйләннәр кебек тезгән. Яшь чагында язуы матур булган икән. Тиз-тиз күз йөртеп чыккач, кычкырып укыды:

«1933 нче елның 30 нчы августында авылдан Нургаян бай Солтанбәковны, Совет властеның явыз дошманы Мусин Искәндәр Галиәхмәт улын, кулаклар сыйныфы вәкиле Курбашев Нурислам Дәүләтгәрәй улын – җәмгысе ун гаиләне сөрдек. Мин ул чагында яшь комсомол, авылның активисты идем. Янымда торган малайларга «канечкечләр!» дип кычкырып, китүчеләр өстенә таш атарга куштым. Ике малай бик теләп ризалаштылар. Соңыннан без аларга комсомол оешмасы исеменнән рәхмәт белдердек. Кулаклар мәктәп турысына җиткәч, укытучы Мөнәвәрә, балаларны тезеп бастырып, «Интернационал» җырлатты. Бик күңелле булды! Басу капкасын чыкканда, дошман элементларның тәкбир әйтеп маташуы комсомол иптәшләргә бер дә ошамады. Сыйнфый сизгерлеген югалткан кайбер хатын-кызлар күз яшьләрен күрсәтеп елап калдылар...»

Кемнәндер каһкаһәләп көләсе килде Назиф Сибгатовичның. Тыелып калды. Алай да зәһәре теленә чыкты:

– Да-а!.. Синең Мөнәвәрә әбиең молодчина! Ничек әле?.. «Кузгал, уян, ләгънәт ителгән коллар һәм ачлар дөньясы»мы?

– Көлмә кешедән! Заманасы шулай булгач!

– «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга!» дигәнме шагыйрь? Көлмим лә мин... Уйландыра барыбер...

– Уйласаң, уйның төбе юк инде аның... – диде Фәгыйләсе.

– Менә бу очракта син хаклы, хатын.

Корбаш нәселе... Заманында ил өстендә иләмән булып йөргән нәсел. Гарасат җилләре боларны нык тузгыткан, әмма тамырлары корымаган! Бу егет Нурислам кулакның оныкчыгы булып чыга түгелме соң? Әйе. Нинди аңлаешсыз халәт кичерә ул? Нигәдер эче поша. Карашы «Зингер» тегү машинасына төште. Кызык... Бәдретдин бабасының өендә торганын хәтерли.

Әтисе йорт җиткезеп керде. Үзе. Һәр өйнең түреннән урын алды шушы тегү машинасы! Утырып, эчке кием дә теккән кеше юк! Ачуы кайнап түгелде:

– Нишләп чыгарып ташламыйсыз шул аламаны?! Кемнең нәрсә теккәне бар бу өйдә?!

– Сиңа ташларга булсын! Ыштансыз! Альберт улыбыз «алып китәм» диде. Антиквариат ул, бик беләсең килсә! Бик кыйммәт бәягә сатып җибәрергә була, ди! – Каршы әйтергә авызы килешкән. Ханым, имеш! Тфү!..

Бер кабарган ачу тиз генә басылмады, һаман бәйләнергә җай эзләп:

– Өйләнергә уйлыймы ул анда, юкмы? – дип сорады.

– Өйләнер! Җүнле кызлары бармыни аның хәзер тормыш итәрлек?! – диде Фәгыйләсе, газиз баласына тел-теш тидергәнне яратмыйча.

– Бәлки, дөнья көтәрдәй егетләрне кырау суккандыр? – диде Назиф Сибгатович, төртмә телләнеп.

– И, әйтер идем шушыңа!.. Әйтми генә торам!

Әллә нишләп пәриләре килешмәде бүген. Әрепләшергә генә торалар.

***

Урманга җитәрәк Гаяз туктады. Кая ашыга ул? Район үзәгенәме? Әйе, анда төн кунып чыгарга түбә табылыр. Соңгы автобусның китүенә биш былтыр. Юлда берәр машина очрамасмы дип өметләнсә генә... Бер төн куну өчен район үзәгенә бару кирәкме соң? Әнә бит кыр тулы печән түкләре. Бер кичкә кер мичкә... Ике түкне янәшә тәгәрәтеп китерде. Менеп кунаклады. Тамак ялгап алды. Курткасын баш астына салып ятты. Рәхәт! Күктә йолдызлар кабына. Ай калка...

Монда урманнар уйдык-уйдык кына икән, кая карама кыр-басулар, сөзәк калкулыклар... Һавасы да бүтән: коры дала җиле өстенлек итә. Җил йөз төрле чәчәк-үлән исен алып килә; ул истән баш әйләнә, күңел тарыга башлый... Ат менеп, шушы ялан-кырлардан чаптырып үтәсе, сөрән салып, бер кычкырасы килә. Сәер халәт...

Егет, үзалдына елмаеп, йокыга талды.

***

Алты почмаклы йорт. Газы-суы кертелгән. Бүрәнәләре таза күренә. Аскы ниргәне җентекләп тикшерде: яңгыр-фәлән үтеп череп ятмаганмы? Юк. Йорт биек нигезгә салынган. Каралып беткән шифер түбә. Профнастилга алыштырырга кирәк булыр. Тәрәзә йөзлекләренең буявы кубып-купшакланып беткән. Вак мәсьәлә. Буяр.

Утыз сутый бәрәңге җире. Ун сутый җиләк-җимеш бакчасы. Ишегалдында футбол уйнарлык. Мунча... Тел-теш тидерерлек түгел. Каралты-кура... Ир-ат кулын көтә.

Бәрәңге җиреннән соң әрәмәлек китә. Болын. Мул гына сулы инеш ага. Балыгына кадәр бар, диләр.

Хәл итте. Ала!

Сатулаштылар. Ул йортка бер бәяне куйды, хуҗа – икенче... Ахырда сатып алучы йөз меңгә менәргә мәҗбүр булды. Йорт сатучы төшмәде.

– Мин мендем, хәзер син төш! – диде Гаяз.

– Юк! – диде тегесе, үҗәт үгез кебек башын чайкап.

– Бер тиен өчен дер калтырап яшисең икән!

– Юк! Дер калтырап яшәмим!

– Нигә төшмисең соң?

– Күршеләрем әйбәт. Шуңа төшмим. Син тыңла, мин сиңа бер хикәят сөйлим. Шуннан үзең аңларсың. Шулай Хуҗа Насретдин өен сата икән. Өе начар инде, төртсәң аварга тора! Әйтәләр Насретдинга: «Әй, Хуҗа абзый, өең бик иске лабаса! Бәясен бик кыйммәт куйгансың!» «Күршеләрем әйбәт минем, күршеләрем! Шуңа күрә йортымның бәясе дә арзан түгел!» – дип җавап биргән Хуҗа.

Вәт хәйләкәр татар! Йортына өстәп, күршесен дә сатмакчы!

– Ярый, егерме бишне төшәсең дә – килештек, – диде Гаяз.

– Килештек, брат!

Кулына бер төргәк акча кергәч, ир-атның авызы ерылды.

– Нигә сөенәсең? Туып-үскән йортыңны саттың. Жәл түгелме?

– Әй, бра-а-т, ничек сөенмисең?! Бу акчага ипотекамны каплыйм мин! Җелеккә төште бурычлы булып яшәү дә... Әтинең гомере кыскарак булды. Инәйне үзебезгә алып килдем. Ялгызы яшәргә авыргарак туры килә хәзер. Гел авылга кайтып йөрү дә мәшәкатьле. Эштән бик бушый алмыйм. Килене белән уртак тел табарлар әле. Өч бүлмәле фатирга сыярлар. Жәл түгелме, дисең син... Жәл, брат! Җиде бала үскән нигез бу... Бәрәкәтле нигез. Үстек тә таралыштык... Мин – төпчек малай. Менә шулай... Өйдә, безгә күрсәтмәскә тырышып, инәй елый. Сизмиләр, ди бугай... Син монда авырткан сөялгә басасың.

– Гафу, туган...

– Ярый, үткәреп җибәрдек. Бу юлы алып кайтасы килмәгән иде үзен. Инәйне дим... Кем әйтмешли: долгие проводы, лишние слёзы. Юк, кайтты! Әле су буйларыннан әйләнеп кайтам дип чыгып киткән иде. Кайда йөри торгандыр бу гомер? Ә... әнә үзе дә кайтып килә...

Капкадан ак яулык ябынган җыйнак кына гәүдәле әбкәй кереп килә иде. Әбкәй кочак тутырып мәтрүшкә, төрледән-төрле үлән, чәчәк җыйган. Үзе сөенеп елмая: аның яшендә урман-кырларны, су буйларын буйлап йөрү алҗытарак төшә икән...Ул әнә шул ерак сәяхәттән кайтып килә, шөкер!..

– Өйне саттым, инәй! Кайда йөрисең? – дип кычкырды малае.

– Ә?! – Әбкәй кинәт сискәнде. Моңарчы бөтен йөзен балкытып торган елмаю сүнде. «Хәере белән булсын!» – дип, кулларын догага күтәрде. Дога кылгач, тынычланып калды. «Сатып алучысы синме, улым?» – дип, Гаязга эндәште.

– Әйе, апа, – диде Гаяз.

– Бу нигездә бәхетең аягыңа уралып йөрсен, улым! Иелеп алырга иренмәссең, – диде әбкәй, нык итеп.

– Рәхмәт, апа.

– Әби дисәң дә ярыйдыр. Яшем җиткән. Үзең соң?.. Йорт кадәр йорт сатып алырга ялгызың килдеңме? Җәмәгатең белән киңәшләшмичә дә соң...

– Өйләнмәгән әле мин!

– Менә сиңа кирәк булса! Өйлән. Гомер буе дуадак каз кебек йөрмәссең! – Кинәт әбкәйнең күзләре нурланып, йөзе яктырып китте. – Ходаем! Бу нигезгә килен төшәселәр бар икән бит! Улым! Илнур! Чормадан көянтәмне, тагын бишекне алып төш! Тиз бул!

– И инәй, чыгарып ташларга кул җитмәде! Шул иске-москыны кузгатмасаңчы! – диде улы.

– Сүземне тыңла, балам!

Көянтәсенең бизәкләре уңып беткән, бишекнең төбе тишек иде. Әбкәйнең куллары, ана сабыен сөйгәндәй йомшак кагылып, әнә шул төбе тишек бишекне, буявы уңган көянтәне сыйпады... Сүз бәясен белеп кенә, бәхәскә урын калдырмаслык итеп, җан җылысы сыенган йомшак-сагышлы тавышы белән күңелен бушатты:

– Көянтәмне калдырам. Чиләкләрем – чоланда. Хәтереңә салып куй, улым: авылыбызда яшь киленгә су юлын күрсәтү йоласы бар. Килен беренче эше итеп чишмәгә барсын! Соңыннан да эчәргә суны чишмәдән алып кайтыгыз. Чишмәбез ерак түгел. Ашка-чәйгә күп кирәкми. Хатының авырга узгач, үзең йөр. Иренмә! Ялкауга-сылтау, таптылар җаен: торба сузып, суны өйгә китерәләр. Соң ул торба вакыт узу белән тутыга бит! Шул тутык торбадан килгән суны эчеп кешеләрнең җаны тутыга! Азмы андыйлар?!

– Ярый инде, инәй!.. Хатыны да юк бит әле аның. Әллә кая эчкәре кереп киттең! – диде улы.

– Тик кенә тор! – диде әнисе. Гаязга карап, сүзен дәвам итте:

– Балаларыгыз бишектә үссен. Төбен бер нык тукыма табып алыштырырсың. Сиртмәсенә чак кына май тидереп ал. Шулай итсәң, бала тибрәткәндә, бишек җырлый. Сиртмәле бишектә үскән бала каты бәгырьле булмый ул. Әнә хәзер каты бәгырьлеләр белән дөнья тулды. Нигә дип уйлыйсың? Чөнки бишектә үсмәгәннәр.

– Кайтыйк инде, инәй, – диде улы.

– Кая кайтыйк?! – Әбкәй янә сискәнде. Беркавым яклаучысыз калган нарасый баладай басып торгач, үзен кулга алып:

– Сез чыга торыгыз, балалар. Мине бер минутка ялгызымны калдырыгыз... Гомер иткән нигезем белән хушлашыйм, – диде.

– Әниеңне кунакка алып кайткала, туган, – диде Гаяз, капкадан чыккач.

– Рәхмәт, брат! – Йорт саткан ир-ат читкә, борылып, күз яшен сыпырып ташлады.

***

Яңа җирдә әйбәт йокланылган. Берара бакчада кош сайраганын тыңлап ятты. Кояш нурлары тәрәзәдән күзенә төшкәч сикереп торды. Юынды. Кофе эчте. Уйга калды.

Шөкер, баш өстендә түбә бар. Бүгенге көндә яшәп торырга бик әйбәт. Гомер буе кеше искесендә яшәмәс, киләчәктә үзе йорт салып керер. Эшне нәрсәдән башларга? Беренче чиратта «тәгәрмәч» кирәк. Машинасыз син адәм түгел. Иң кулае – «Иж-каблук». Бер дигән эш аты. Табадан төшкәненең бәясе «тешләшә». Йөреп торырга булса, бик яхшы. Кулдан алыр. Мотоблок. Эш кораллары: балта, пычкы, кадак-чүкеч... Табак-савыт: кәстрүл, чәйнек, тәлинкә... Урын-җир... Әбиеңнең кыз чаклары диярсең!.. Стоп!

Болар – тормышның вак-төяге. Базарны өйрәнергә кирәк. Менә көн кадагына суга торган мәсьәлә. Интернетта кызыксыну бер хәл. Үзең сәүдә үзәкләрен йөреп чык, кешеләр белән аралаш!

Җыенды да калага китте.

***

Бер атнадан Гаяз янә өстәл янына утырды. Башкарган эшләргә йомгак ясарга, киләчәккә план корырга – гомумән, умарта күчедәй тузгыган уйларын тәртипкә салырга кирәк иде.

Бер атналык эшкә йомгак: ишегалдында «Иж-каблук» – утыр да чап! Мотоблок. Бакчаны сөреп-тырмалап чыкты. Сатасы булгангадыр, берни утыртмаганнар.

Базарга килгәндә... Әйе... Уйларга кирәк. Мул тормышта яши Татарстан! Бар өстенә бар. Җитештергән продукцияңне сату кыенгарак туры килмәгәе. Кесәдәге акча балалап тормый. Кредитка батасы килми: алуы – җиңел, чыгуы бик озак. Күп чыгымнар түкми генә нәрсәдән башлап китәргә соң? Ел әйләнәсендә табыш та китерсен ул эш! Кереп тормаса, акчаның тиз бетә торган начар гадәте бар. Уйла. Суган үстерүдән башласа?.. Бер генә супермаркет, ашханә, кафе-ресторан яхшы сыйфатлы яшел суган кыягыннан баш тартмый бит. Утыз сутыйдан старт ал! Беренче чиратта – теплица. Төзелеш материалына киртә-колга, таяк-торба – һәммәсе бара. Теплицаны җылыту кирәк. Электр белән җылытса, кыйммәткә төшәчәк. Газ белән дә шул ук хәл. Яхшы сыйфатлы яшел суган үстерәм дисәң, кара көздә, кышның зәмһәрир салкыннарында да теплицада 16-18 градус җылы тот син.

Буржуйка! Шәһәрдә йөргәндә күзенә чалынды. Бәясе дә ул кадәр кыйммәт түгел: биш меңлеге бар, җиде меңлеге... Үзе мич чыгарса? Мич чыгарганы юк. Интернеттан карап өйрәнер. Уйларга кирәк.

Утын?.. Ауган агач, корыган ботак-чатак – бар да ярый. Лесник Габделхәй белән уртак тел табарлар.

Яктылык. Гел чыгымнарсыз да булмас: электр үткәрер. Люминесцент лампалар энергияне аз сарыф итә. Кибетләрдә бар.

Күңеле кинәнеп, үзен маяклы юлга чыккан мосафирдай хис итте ул.

***

Теплица төзелешенә ун көн китте. Йокысын алты сәгатькә калдырды. Ходаның хикмәте: йокысы туеп, тәне көч җыеп торды. Вакыты барда ярдәмгә күршесе Илдус кергәләде.

Суган утыртканда, биш хатын-кызны эндәште. Тегеләр бик теләп килделәр. Әмма телләре! «Кайчан өйләнәсең? Туеңа безне чакырырга онытма!» – дип, тәмам теңкәсенә тиделәр. Эшләгәннәре өчен акча бирмәкче иде – алмадылар. «Өмәгә килдек бит!» – диештеләр.

Беренче уңышны җыйганда дулкынланды. Суган түтәлләрен фотога төшереп, интернетта белдерү биргән иде. Сатып алучы икенче көнне үк табылды. Телгә үткен, сүзгә юмарт марҗа түтәй (пекарня хуҗабикәсе): «Мин моннан фәлән кадәр пирог пешерәм бит», – дип, беренче партия суганны сатты да алды. Марҗа түтинең кул арты җиңел булып чыкты. Бер генә кафе-ресторан, ашханә, сәүдә үзәге ул үстергән яшел суганнан баш тартмады. Киресенчә, бик теләп алдылар. Кулга тере акча керде. Күңеле сөенеч белән тулды: бу әле эшнең башы гына...

Киләчәктә – күкрәп утырган яшелчә, җиләк-җимеш бакчасы!

***

– Хозяин дома?

Эш белән мавыгып күрми калган: капка төбендә «джип» туктаган, дүрт ир-ат ишегалдына кереп киләләр иде. Соңгы кергәне артыннан капканы япты. Көньяк кешеләренә охшаганнар. Охшаганнар гына түгел, тәгаен шулар. Алдан килүче сакал-мыек басканы кычкырып исәнләште:

– Здраствуй, дарагой!

– Здравствуйте.

– Какая у тибя злая собака! – диде сакалбай, аяк астында чәңгелдәп йөргән көчеккә елмаеп карап.

– У вас ко мне дело какое?

– Дило, дило, дарагой!

– Я вас слушаю.

– Ты зачэм лук растишь, дарагой?

– Не понял.

Көлештеләр.

– Лук мы растим, дарагой!

– Так выращивайте.

– Ты нам мешаешь, дарагой! Э-э... палку в колёса ставишь!

– Я вам не мешаю. Вы выращивайте на своей земле, я – на своей.

– Не понял! – Сакалбай гаҗәпләнгән булды: – Он нас не понял! Ай-вай-вай!.. Нехороший человек!

Яше, кесәсеннән пәке алып, теплица пленкасына сызып җибәрде. Көлештеләр. Яше тагын сызды...

Аңлашылды. Башта Сакалбайны сугып егарга кирәк. Ул – баш. Калганнары югалып калачаклар. Аннан күз күрер...

Сакалбай, тез буыннары тотрыксызланып, бер-ике адым артка чикте дә чалкан барып төште. Аның артыннан икенчесе... Яше пәке белән ташланды. Пәкеле кулы һавада буталып алды, маңгаена төшкән авыр йодрык чакырылмаган кунакны җиргә сеңдерде. Дүртенчесе, һөҗүм итәргә кыймыйча, читтә басып торды.

Алай да таза, нык егетләр. Берсе дә ятып калмады. Торып, үз телләрендә нидер кычкырып, сугышка ыргылдылар. Ул үзенең ялгышын аңлады: сугып еккач, дошманыңа алагаемга тибәргә дә кирәк! Шул чагында ул тиз генә аяклана алмаячак.

Егылганны тәпәләмиләр!.. Тәпәләмиләр!

Каян башына сеңеп калган канун бу?!

Дүрт ир-ат ялгызыңа күбрәк шул. Кайсыдыр тез астына күсәк белән орды. Каты авыртудан сыгылып төшүгә башына суктылар. Ишегалды, йорт, теплица – һәммәсе каядыр йөзеп китте дә әйләнеп капланды... Ярсып, сүгенеп типкәләргә тотындылар. Егылганны тәпәлиләр шул! Тәпәлиләр!..

Гаяз, бар көчен җыеп, торып басарга тырышты. Аягына басса, боларга каршы тора алыр кебек иде. Күтәрелергә ирек бирмиләр каһәрләр! Хуҗасын яклап, тигезсез көрәшкә ташланган көчекне тибеп очырдылар.

– Алас!..

Тамак ярып, кемдер кычкырды. Шул мизгелдә коймадан Илдус сикереп төште.

– Алас! – дип, тагын бер үкерде күршесе, уң кулын югары күтәреп.

Ә кулында граната иде.

***

Укытучылар кызык халык: Әүхәдиев Илдус турында сүз чыкса, тиз генә туктатырмын димә үзләрен. Әйтерсең лә Таллыяр урта мәктәбендә бер Әүхәдиев укыган, бүтән балалар килеп-китеп кенә йөргәннәр! И, ул малайга бәйле берсеннән-берсе кызыграк хатирәләр... И, ул малайның чиктән ашкан шуклыгы! Кайчак: «Нигә мин дә аның кебек тәртипсез-шук бала булмадым икән? Мине дә сөйләрләр иде», – дип көнләшеп тә куясың. Юк, сөйләмәсләр иде. Аның өчен Илдус булу кирәк. Ник бер укытучы ризасызлыгын белдереп: «И, ул малай агарткан чәчләр инде!» – дисен. Ә бит аз агартмады...

Бәләкәйдән үк үзгәрәк малай булып үсте шул. Әйтик, җен-пәри, Убыр, Шүрәле, Су анасының юклыгын бөтен бала белә. Ышанмый ул аңа! Ә менә Илдус мунчада – пәри, урманда – Шүрәле, инеш буенда Су анасын күрә! Күргәнен сөйли. Авыл баласының күңеленә шик төшә... Бәлкем, чынлап та, бардыр алар?! Бигрәкләр дә ышандырып сөйли бит!

Болары – еракта калган сабый чак хатирәләре. Үсә төшкәч... Ун яшьләр булгандыр малайга.

Авылдан ерак та түгел Чаукалык тавы итәгендә тау куышы, зурдан кубып әйтсәк, мәгарә бар. Авызыннан үрмәләп кермәле, эчтә аягөсте йөри аласың. Күп еллар элек монда бакыр рудасы чыгарганнар икән. Бик әйбәт. Туган төбәгебез нефтькә генә түгел, бакырга да бай булган дип горурланырга җирлек бармы? Бар. Укучыларын экскурсиягә алып килгәндә, укытучы Гөлзифа апалары да шулай уйлагандыр.

Емельян Пугачёвның патша тәхетен дер селкетеп алган фетнәсе бастырылгач, бер төркем баш күтәрүчеләрнең мәгарәдә качып ятуы турында сөйләгәндә, бер укучысының күзләре очкынланып китүен күрде микән укытучы апалары?

Класс сәяхәттән кайткач, авылда сүз таралды: мәгарәдә Пугач патша хәзинәсе яшерелгән икән. Андагы алтын-көмеш, мин сиңа әйтим! Сандыклап, ди, сандыклап!.. Ходаның хикмәте: малайга бер тамчы ышанмыйча, аны елмаеп-көлеп тыңласалар да, бу хәбәр сүнмәде-сүрелмәде, киресенчә, коры үләнгә капкан ут шикелле бөтен авылны ялмап алды. Ахырда сүзнең ун яшьлек малай авызыннан чыкканын оныттылар. Бу мәгълүматны авылның өч сәрхуш ир-аты йөрәкләренә аеруча якын кабул итте. Баш авырта – төзәтергә сәмән юк – искә килә дә төшә Пугач патша хәзинәсе!

Аеруча авыр иртәләрнең берсендә болар тәвәккәлләделәр. Керделәр мәгарәгә үрмәләп, зур өметләр баглап, фонарьларын кабыздылар, тирә-якка карандылар – вакыты җитепме, саксыз кагылдылармы – куыш авызы ишелде дә төште.

Кеше печән кибәнендәге инә түгел, икенче көнне авыл боларның югалуына игътибар итте. Әүвәл: «Эчеп утырган җирләрендә йоклап яталардыр, хәчтерүшләр», – дип уйладылар. Кичкә таба авыл борчыла башлады. Өч тәүлек узгач, полициягә хәбәр иттеләр. Полициядән тиз килеп җиттеләр. Үзләре белән кинологны да алганнар, рәхмәт төшкерләре. Фаразлау буенча тегеләрнең эчеп утырган урыннарын, берсенең күлмәген, икенчесенең чалбарын, өченчесенең кирза итеген иснәткәч, немец

овчаркасы җирәнеп (бүтән сәбәпләре дә булды микән?) этләрчә төчкерде һәм Чаукалык тавына ыргылды. Тау куышына җиткәч, чәбәләнеп өрергә тотынды.

Әсирлектән азат иткәндә, тегеләр зәңгәрләнә башлаганнар иде инде. «Нигә үзегез казып чыгарга тырышмадыгыз?» – дип сорагач, бичараларның күзләре яшьләнде. Казуын бик казыганнар, тик юнәлешне дөрес чамаламаганнар. Күрәсең, каушап калганнардыр. Анысы бер хәл... Егылып китәрлек яңалык: болар «исән чыксак, мәңге эчмәс идек» дип, нәзер әйткәннәр. Ә нәзерең тотса... ай-һай, егет! Ходай язмасын!

Эчмәделәр. Исерек айнымасын, хәерче баемасын икән: сәрхушләр аек баштан Пугач патша хәзинәсе турында сүз беренче кем авызыннан чыкканын исләренә төшерделәр. Әтисенә зарланганнар: тәк и тәк... Синең малай аркасында шушы хәлгә төштек... Әтисе кырыс кеше: каешы шәп, кулы каты – якын киләчәктә атна-ун көн утырып булмаячагы көн кебек ачык иде.

Әмма малай актыгы вакыйганың бу рәвешле борылыш алачагын алдан сизенгән булып чыкты. Печәнлектә үзенә урын әзерләде, су алды, ашау ягын хәстәрләде һәм «партизанлыкка» китте. Төнлә дә куркыныч түгел: тыныч кына сыер күши, сарыкларның мышнаганы ишетелә.

Печәнлектән төшмәс тә иде, әнисе бик борчылды. Әтисе дә элекке уеннан кире кайткан, күтәрелеп бәрелмәде. Башына юк-бар уй кермәсен өчен улын муеннан эшкә күмде. Эштән курыккан юк анысы...

Җиз кыңгырау чыңына күмелеп, балачак артта калды. Мәктәпне тәмамлагач, бөтен күңелен укуга бирде.

Шофёр. Бөтен категорияләр. Тракторчы. Комбайнчы. Техниканы биш бармагыңдай белмәсәң, син адәм түгел. Максат ачык. Ният нык.

Бер дә көтмәгәндә, кулына повестка тоттырдылар. Хәрби комиссар белән сөйләшкәндә, сүздән аркан ишеп тормады: «Иптәш майор, мин дә әти кебек чик буе гаскәрләрендә хезмәт итәргә телим!» – диде. Офицер булачак солдатның үтенечен аяк астына салып таптамады. Әмма, ни кызганыч, исемлек тулы: Чик буе гаскәрләренә бу чакырылышта солдат кирәкми булып чыкты. «Слушай, Әүхәдиев, – диде хәрби комиссар, егеткә сынап карап. – Ватан чикләрен коры җирдә генә сакламыйлар бит. Һавада, диңгездә, хәтта океанда да саклыйлар. ПВО да хезмәт итәргә ризамы? Уйла әле син...»

Океан киңлекләренә чыгып китәсе килми иде, һава чикләрен коры җирдә сакларга ризалыгын бирде.

***

Радиолокация станцияләрен күргәч, егет бөтенләй югалып калды. Бу кадәр катлаулы техниканы кыска гына вакыт эчендә ничек үзләштермәк кирәк?!

Үҗәтлеге белән алдырды. Нәкъ алты айдан 2 нче класслы белгеч (укуны тәмамлаганда, гадәттә, 3 нче класс кына бирәләр) кече сержант Әүхәдиев беренче тапкыр хәрби бурычын үтәргә басты.

Сүз дә юк, дулкынланды. Ничек тыныч каласың?! Күз алдыңа китер: солдатлар команда пункты каршына тезелеп басалар. Тавыш-тынсыз тимер ишек ачыла. Эчтән кизү торучы офицер чыга. Боерык яңгырый:

– Смирно!

Офицер кызыл папкасын ача. Укый:

«...по охране воздушных рубежей Российской Федерации

Приказываю:

оператору радиолокационной станции младшему сержанту Аухадиеву... – бүтән фамилияләр саналып китә – заступить на боевое дежурство!»

Күкрәк горурлык хисе белән тула. Каршында – яшел экран, синең изге бурыч: «цель»не мөмкин кадәр ерактан күреп алып, координаталарын команда пунктына тапшыру. Спутникмы ул, вертолёт, самолёт, ракета, һава шарымы – кыскасы, һәр оча торган предмет хәрбиләр телендә – «цель».

Менә кайдан башлана ул Ватан! Кыскасы! Кече сержант Әүхәдиев дежур торганда, тыныч йоклый аласыз, кызлар!

Чиккә кадәр ике йөз чакрым. Аннан Кытай иле башлана. Болай ике ил арасында мөнәсәбәтләр ару гына... Ару гына түгел, гел яхшыруга бара. Әмма чик сакчысы тәүлекнең һәр минутында уяу булырга тиеш! Кече сержант Әүхәдиев уяу булды.

***

Таң ата да кич була, диярсең... Болай бар да яхшы. Кече сержанттан сержант булды. Үзенә күрә сөенеч бит ул! Күңелсезләнергә сәбәп тә юк шикелле...

Хәрби хезмәт сержант Әүхәдиевне бертөрлелеге белән изде. Соң уйлап карагыз: Ходайның һәр бирмеш көнендә дежур офицер бер нотага көйләнгән эчпошыргыч тавышы белән боерык укый: «...приказываю: оператору радиолокационной станции...»

Юк чик бозучы! Дөрес, кизү торганда оператор тик утырмый. Үз илебездә шәһәрдән шәһәргә пассажир самолётлары оча. Координаталарын команда пунктына тапшырып барасың. Чик буе бит – ни булмас! Аратирә спутнигы, хәрби самолёты-вертолёты очып үткәли. Күңелсезләнеп утырырга вакыты да юк кебек...

Юк чик бозучы! Соң бер тапкыр булса да боз син! Күршеләр бит! Явыз ният белән түгел, болай – ялгышып кына... Тикшереп кара! Россия илендә һава чикләре әйбәт сакланамы – юкмы? Сержант Әүхәдиев дежурда чакта рәхим ит!

Әлбәттә, ул чик бозучы самолётны яшел экранда ерактан ук күреп алыр. Катгый тавыш белән «цель»нең координаталарын команда пунктына тапшырыр.

Полкны тезеп, саф алдында рәхмәт әйтерләр үзенә. Монысы – бәхәссез. Ул: «Служу России!» – дип җавап кайтарыр. Артык эреп төшмәс. Дөньяда була торган хәл ич. Орден бирерләр микән? Сержант Әүхәдиев рәхәт дулкынлану хисе кичерде. Кем белә бит? Рус агае әнә: «Чем чёрт не шутит», – ди!

Чү! Нәрсә бу?! Кытай ягыннан безнең илгә якынлашып килә. Самолёт түгел. Вертолёт?! Юк! Спутник?! Ракета?! Аэростат?! Өч тапкыр юк! Бу – чак шәйләнүче, моңарчы күрелмәгән әллә нинди җәенке тап... Күзенә күренәме? Күзенә күренми. Тап бар. Ул хәрәкәт итә! Нәрсә булырга мөмкин?!

Радиолокация станциясенең эш тәртибе болай: антенна югары көчәнешле радиодулкыннар тарата, әнә шул дулкыннар, объектка бәрелеп, кире кайта һәм экранда якты яшел тап булып чагылыш таба. Нинди объектка бәреләләр соң ул дулкыннар?!

Бәлки?.. Бәлки, шпионлык максаты белән безнең илгә җибәрелгән бер-бер яшерен очкычтыр?! Ә-ә... мине хәйләләмәкче булдыгызмы?! Сержанта Аухадиева голыми руками не возьмёшь!

Команда пунктында бүген капитан Скворцов кизү тора. Вакыт!..

– Товарищ капитан, воздушные рубежи Российской Федерации нарушает неопознанный летающий объект! Передаю координаты...

Минутында аэродромнан истребитель-перехватчик күтәрелде. Бераздан колакчыннарда очучыларның үзара сөйләшүе ишетелде: «На данном квадрате наблюдаю стаю диких гусей, командир. – Очучының тавышы үзгәрде, елмая иде булса кирәк. – На Родину летят!.. Отбой! Возвращайся, лейтенант».

Дөнья бер көлсә, кычкырып көлә икән... Сержантны гаепләмәделәр. Ә менә «Гусь» кушаматы ябышып калды.

***

Бүген әллә нишләп күңеле тарыга. Йөрәк, кысанлык тоеп, ирек даулый. Һәм ямансу... Әллә нишләп ямансу да шул!

Туган якларга кыр казлары кайткандыр... «Дембель»гә дә санаулы көннәр калды. Бер ел үтә дә китә икән. Ә телгә алып сөйләрлек вакыйга юк. Кытай гадәттән тыш тәртипле ил булып чыкты. Ә бит чик бозулар булган! Ничәнче елда икәнен инде беркем төгәл генә әйтеп бирә алмас (һәр буын солдат, хезмәт итеп кайткач, ул вакыйганы «минем баштан кичкән хәл» дип сөйли), безнең бер «кукурузник» Кытай иленә очып киткән. Карап калганнар. Ничек атып төшерәсең, эче тулы кеше! Кытай ягы очучыны һәм пассажирларны шунда ук биргән (халык үзендә дә күп), «кукурузник»ны калдырган.

Соңыннан ачыкланган: болар туйдан кайтучылар булганнар икән. Менә ичмасам туй! Вәт дөньясын сүттергәннәр болар! Ә самолётны бирмәгәннәр. Кытай иленең бу гамәле кискен тәнкыйть утына тотылды: «У-у, каруннар, бер «кукурузник» өчен, гүреңә төшеп, кәфенеңне суяр болар!» – дип, ду килеп алдылар.

Әмма дә туй шәп булган!

– О чём печалишься, Гусь?

Таня икән. Ефрейтор Татьяна Осипова. Планшетист. Калуга кызы. Әүвәл икәү иделәр. Мариясе, авырга узып, Псков егете Анатолий Дудин белән кайтып китте. Усал телләр кызларны армиягә кияүгә чыгар өчен бара дип сөйлиләр. Кем белә инде... Бәхетләре булсын!

Ефрейтор Осипова кияүгә чыгарга ашыкмады...

Кыз, зәңгәр күзләрен, сипкелле йөзен балкытып, егеткә карады. Ап-ак тешләрен җемелдәтеп елмайды. Башын чайкап, җиңел-җитез хәрәкәт белән өлгергән бодай саламыдай якты-сары чәчләрен иңбашына таратып ташлады. Һәрвакыт шат күңелле үзе: әйтерсең лә баш очында көн дими, төн дими, бәхет кошы сайрап тора!

Буй-сыны... Агыйдел камышларын ерактан ук урап узабыз. Күз алдына,

ни сәбәптер, тутырган тавык килә. Һушыңны алырлык чибәр дә түгел югыйсә... Тик ни пычагыма магнит кебек үзенә тарта соң бу кызый?! Сержант Әүхәдиевне генә түгел... Хакыйкатьнең күзенә туры карап, чын дөресен әйтик, егетләр: полкта ир-ат халкының бик күбесе ефрейтор Осиповага битараф түгел – офицер хатыннары Таняны күрәлмыйлар иде...

Татьяна сайланып кына (Ромеолар адым саен!) солдат-офицерларны «җәлли» иде. Ничек җәлләмисең солдатны, әнә бит ул, әнкәсеннән (сөйгән ярыннан да) аерылып, хәрби хезмәткә килгән...

Офицерны ничек кайнар кочагыңа алмыйсың, үз хатынының түшәге гүр туфрагыдай салкын булгач (мәхәббәт учагы җылыткан урын-җирне ташлап, бер ир-ат та «бәхет эзләргә» чыгып китми. Ефрейтор Осипова шулай уйлый).

– Держи хвост пистолетом, сержант! Не грусти! – диде Таня, үз итеп, якын итеп.

– Пожалела бы что ли, Таня! – Әллә шаяртмакчы булды.

– Ух, ты какой! А что?! Приходи сегодня после отбоя. Ох, пожалею я тебя, сержант! Ох, пожалею!.. – Өздереп, бер карады да китте ефрейтор Осипова. Борылып кул изәде: – Буду ждать!

Умыртка баганасын чемердәтеп, ниндидер бөҗәкләр йөгерешеп узды. Аяк астында җир убылды. Әлегә фикер йөртү сәләтен югалтмаган берничә ми күзәнәген бик каты эшләтеп, беркавым каккан казыктай басып торганнан соң, сержант Әүхәдиев бернәрсәне ачык аңлады: чигенү юллары ябык! Үзен кулга алды: артка хут юк икән, димәк, җаныңны бер учка йомарлап, алга!

Көне күңелле мәшәкатьтә узды. Кытайларга рәхмәт: чик бозып бимазаламадылар.

Тәк... Хатын-кыз янына буш кул белән бару егетлек түгел. Шәраб?.. Чәчәкләр?.. Солдатның акчасы да чутлы. Кирәк булса – табасың. Дневальный – үзебезнең егет – күчтәнәчне, вакыты җиткәнче, каптёркага яшерделәр.

Контракт нигезендә хезмәт итүчеләр хәрби шәһәрчекнең төньяк-көнчыгыш читендә: ике подъездлы, ике катлы кызыл кирпеч йортта яшиләр. Ике арада – җиденче пост. Халык телендә – «седьмой сторожевой». Ни шайтаныма куйганнардыр, сакларга бер объект юк. Туктагыз әле, нигә алай дисез? Хәрби шәһәрчеккә төньяк-көнчыгыш тарафтан дошман һөҗүм итсә? Яисә диверсантлар үтеп керергә теләсә?! Усал телләр генә ул монда мылтык тоткан солдатны бастырып куюны полк командирыннан офицер хатыннары таләп иткән икән дип сөйлиләр. Ефрейтор Осипова шул кызыл йортта яши бит. Ул кадәр нечкәлекләрен кем белгән инде? Солдатка белү кирәк тә түгелдер. Без сәхнә артына күз ташлыйк. Әйе, бу, чыннан да, шулай. Әмма... Пуля – дура, штык – молодец! Суворовны беркайчан да онытырга ярамый. Полк командиры онытмады. Часовойның иңендә – автомат, билендә – штык-нож, патроннар бирмәделәр. Ханымнар, әлбәттә, бу хакта белмиләр. Аның каравы җаннары тыныч.

Барыбер дә часовойның күңелен күрергә кирәк.

Ниһаять, отбой. Тәвәккәлләде. Күчтәнәчен алды. Дневальный, Самара малае: «Ни пуха, ни пера, товарищ сержант!» – дип калды.

Китте. Адымнар нык. Йөрәк ярсу! Алда – «седьмой сторожевой»! Төн карасыннан часовойның кырыс тавышы ишетелде:

– Стой! Кто идет?
– Конь в пальто!
– Пароль?
– Кент!
Часовойга «Кент» сигареты алган иде.
– Проходи. – Күчтәнәчтән канәгать калуы тавышына ук чыккан.

***

Ефрейтор Осипова һушыңны алырлык чибәр иде. Күзләре көлә, сипкелләре балкып яна, тәнендә һәр күзәнәге ымсындыргыч дәрт, мәхәббәт, наз белән мөлдерәмә тулышкан иде. Аның өчен, сержант Әүхәдиевка матур күренәсе килеп, бизәнгән-ясанган бит инде ул! Аны көткән!..

Сәясәт, халыкара мөнәсәбәтләр, илләр арасында низаг, чик бозулар – һәммәсе бер дә кирәкмәгән җыен вак-төяк булып артка чиктеләр...

Үзәктә галиҗәнап Хатын-кыз калды!

Аз гына шәрабтан авыз иттеләр. Хәер, ул эчми дә исергән иде.

– Таня!.. Татьяна!.. – Егет ягымлы, иркә, назлы сүзләр пышылдады (Каян табып бетерә диген, бер авыл малае югыйсә!). Хатын, бик теләп, бөтен барлыгы белән ир-атның назына җавап бирде...

Беренче дуамал хисләр басыла төшкәч, күзгә-күз карап сөйләшеп яттылар. Татьяна, кайнар тәне, мул күкрәкләре белән аңа сыенып, тыелгысыз үбә-үбә, иркәләнеп сорады:

– Я у тебя первая женщина, да? Скажи! Ну, скажи! Ведь первая?!

– Да нет, – дип җаваплады ул. Рус теле кызык: «әйе» дисең дә, шунда ук «юк» дип кире кагасың. Теләсәң ничек аңла. Сер бирәсе килми иде.

– Трудолюбивый ты мой! – Хатын, татлы ыңгырашып, егеткә сарылды. Янә дөньяларын оныттылар...

Офыкта шайтан таңы сызылганда, черем итеп алырга уйладылар.

***

Икесе берьюлы, сикереп торып, сәгатькә карадылар бугай. Татьяна аһылдап куйды. Ир-ат кемнеңдер анасын исенә төшерде.

Йоклап яткан солдатны тревога белән кутәрсәләр, ул, 45 секунд эчендә киенеп, сафка басарга тиеш. Бик озак бит бу!

Сержант Әүхәдиев 10 секундта киенде. Дөньяда иң тиз йөгерүче кешенең тизлеге сәгатенә 39 чакрым. Сержант Әүхәдиев ул иртәдә бу рекордны бәреп екты!

Казармага атылып килеп тә керде; дневальный, тавышы белән таш ярып, кычкырып та җибәрде:

– Рота-а! Подъём!

Солдатлар дәррәү сикерешеп тордылар.

Сержант Әүхәдиевнең шат тавышы яңгырады:

– Строиться на зарядку!

Яңгырмы-кармы, эссеме-салкынмы, һәр иртәдә (дежур тормасаң) өч чакрым йөгереп кайтасың.

Турысыннан үткәндә, Татьяна яшәгән бүлмәнең тәрәзәсенә карап-карап алды. Юк, ефрейтор Осипова күренмәде. Башына кисәк уй керде: өнендә

булдымы бу хәл, төшендәме? Өнендә, өнендә!.. Аягүрә саташып йөрмә, егет! Сержант Әүхәдиев бүгенге халәтенә тач килә торган сүзне әлегә тапмады. Бер нәрсәне ачык белә: бу – Вакыйга! Әмма ир-егет бу хакта шапырынып йөрмәс. Туктале... Яшьлегенең бер елы армиядә узды. Телгә алып сөйләр бер истәлек-хатирә дә юкмыни? Кыр казын шпионлык максаты белән җибәрелгән очкыч дип уйлап полкны тревога белән күтәрдем дип авызын ачса – көләчәкләр! Әлеге дә баягы шул «кукурузник» кала...

Спорт мәйданчыгында тән язып, кайтыр якка йөгергәндә, подъезд ишегеннән Татьяна чыкты.

– Шагом!

Атлап баруга күчтеләр.

– Рота, запевай!

Саратов малае Алексей Бобылёв бер дә ялындырмый җыр башлады:

Идет солдат по городу,
по незнакомой улице.
И от улыбок девичьих
вся улица светла...

Таня сипкелләрен балкытып елмайды, кулын чигәсенә күтәреп: «Здравствуйте, товарищи!» – дип кычкырды. «Здравия желаю, товарищ ефрейтор!» – дип гөрселдәде рота.

Кыз чытлыкланып көлде.

Ә син нәрсә көткән идең? Үзеңә аерым игътибармы? Алланың кашка тәкәсе түгелсең.

Ә Кытай чик бозмады. Гадәттән тыш тәртипле ил икән.

***

Кайтса, әтисе «КамАЗ» үзбушаткыч машинасы алып җибәргән. Яңа түгел, иске дип әйтергә дә тел әйләнми. Кредитка чумганнар чумуын. Әмма әтисенең кәефе күтәренке: «Борчылма, улым, ике-өч елда түләп бетерәбез аны!» – ди. Көйлисе җирен көйләп, майлыйсын майлап дигәндәй, аталы-уллы машина тирәсендә кайнаштылар.

Ул арада урып-җыю чоры җитте. Әтисе комбайнга утырды, ул элеваторга ашлык ташыды.

Төзелештә эшнең гомер бетәсе юк: кирәк-ярагын китерә, котлованнан балчык төяп җибәрәләр.

Кышы карлы килде. Рәхәтләнде шәһәр урамнарыннан кар чыгарып! Монысы бигрәк төшемле эш булып чыкты. Әтисе дөрес әйткән: «КамАЗ» үзен аклады! Билен буып, ерак юлга да чыгып киткәләде. Кыскасы, эш бирүчеләр күбәйде. Нишләп күбәймәсен: ягулык – үз кесәңнән, ватылсаң – запчастьны үзең аласың. Хуҗаның башы авыртмый. Ул сиңа акчасын гына түли. Ә «КамАЗ» йөреп тора, рәхмәт яугыры!

«КамАЗ» йөрер ул. Дөньяның хатын-кызлы ягы да бар бит әле...

Кызлар телендә Илдус булды. Төннәрен ничә кыз ап-ак мендәрләрен күз яшенә чылатып елагандыр?.. Бер Ходайга мәгълүм. Елак кызларны санап утыру егет кеше эше түгел. Хәтерендә Галәветдин бабасының сүзләре яңарды. «Улым, – дигән иде бабасы, – гомер уза: миңа хур кызлары янына

барырга вакыт җитте, синең дә борынга кызлар исе керде. Сиңа әйтер сүзем бар: егет була белик! Аңладыңмы?» «Так тучны!» – диде оныгы.

Армиядән кайткан егет бер ел шәп йөри гадәттә. Аннан искерә төшә. Кызлар да аның исемен ул кадәр еш телгә алмыйлар...

Илдус үзе дә аптыраШта иде. «Өйләнәм» дип, беренче очраган кызны ияртеп кайтсынмы? Ике арада нәрсәдер булырга тиештер бит?! Ярый, мәхәббәт дип зурдан кубып әйтми. Кая инде ул безгә – каткан тезгә Таһир, Мәҗнүн кебек гыйшык утында янулар! Алай да, күңел кыллары бер тибрәнеп алмас микәнни?!

Шулай гамь йотып йөргәндә, классташы Гөлгенәне очратты. Классташы гына да түгел – партадашы. Кызый һаман оялчан икән. Юк, кыюлана төшкән. Кыюлана төшмәсә, шулай өздереп карамас иде. Шул караштан йөрәге тарсылдап типте. Шаккатты: моңарчы уңда дип йөри иде, йөрәк күкрәк читлегенең сул ягында икән! Мәхәббәт дигәннәре шушыдыр... Шушыдыр!.. Моңарчы кайда йөргән бу кызый?! Чаллыда йөргән икән. Заводта эшли. Авылны бик сагына.

Сөйләшеп сүзләре бетмәде...

Өйләнми кая барасың!

Гаилә тормышыннан бер күренеш.

Хатын токмач кисә. Ир диванда гәҗит укып ята. Кыз курчак уйный. Ир-ат ара-тирә хатынына карап алгалый. Токмач кисүләре шушының! Ул токмачының тәме! Яулыгын шулкадәр килештереп бәйләмәсә соң! Алсу алма кебек янып торуын әйт! Ир гәҗитен читкә алып куя да әйтә:

– Ачуымны бик китереп торсаң, «уҗым»га чыгып китәрмен! – ди.

– Озак йөрмә. Хәзер аш өлгертәм, – ди хәләл җефете. Ир сикереп тора. Ярсыган! Ну, әйтерие – кирәк чакта сүзе табыламыни аның! Соң, егетләр, мондый хатын белән яшәүләре бик авыр бит! Кайда хисләр ташкыны?! «Ах, син, оятсыз, мәхәббәтебезгә хыянәт итәргә уйладыңмы?!» – дип, йодрык төйнәп кычкыру?! Күз яшьләре?! Кайда башка төшәргә тиеш Кукмара табасы?! Табагачы, уклавы?! Изүеннән алып җилтерәтәем, Шекспир кайда качып йөри?!

Ир ишекне шапылдатып ябып чыгып китә. Барыр юлы ерак түгел: утарга кадәр генә... Тынычлана. Атлар – йөрәккә дәва. Бер айгыр, биш бия, ике тай, өч колын. Ат асрау чыгым сорый. Мәшәкате дә җитәрлек. Ә хатын иренең ат тотуына бер дә каршы түгел! Ни өчен? Хатын-кыз акча колы бит. Әллә бигүк алай түгел микән?.. Гөлгенәсе исә юк кына бәягә совет чорыннан калган инкубатор сатып алды. Аталы-уллы көйләделәр. Матур гына эшләп китте инкубатор. Йомыркадан чебеш чыгарып сату шөйлә төшемле эш булып чыкты. Нинди эшкә тотынмасын, Гөлгенәсе гел табышка эшли. И, хатынның ул сары йомгакларга әйткән назлы-иркә сүзләре! Йөздән бере иргә эләгә микән? Ачуың да килерлек бит! Бер нәрсә күңелне юата: көз җиткәчме?! Бисмилласын әйтеп... Белгәнен укып!.. Пычак – Гали пәкесе. Авыз тутырып, тавык ите ашыйсылар алда әле! Бүгенгесе көндә хәлләр ничек соң? Ир, үз җире булмагач, «КамАЗ»да эшләп тапкан акчасын солы, печән, салам сатып алуга тотып бетерә. Калса каладыр ипи-шикәрлек... Әмма!..

Киләчәктән бер күренеш.

Киң яланны иңләтеп, җир-күкләрне гүләтеп, атлар чаба... Танау тишекләре киерелгән, күзләрендә ялкын шәүләсе, ял-койрык җилдә таралган!.. Эһе-һе-һей, җан кисәккәйләрем!..

Ике бәләкәч сөйләшә:

– Нинди атлар болар? – дип сорый берсе.

– Бәрәч, Илдус абзыйның чабышкыларын белмәскә син! – дип җаваплый икенчесе.

Менә шулай, энекәш... Ә син тавык-чебеш дисең...

Дөньяда Хыял яши!

***

Әнә шул ир-егетебез һич көтмәгәндә дау кырында пәйда булды.

– Носом в землю, несчастные! – дип акырды ул, баш очында гранатасын болгап. Ир-атның ачудан кыйшайган йөзе, күзләрендә янган хәтәр ут аның теләсә нинди адымга барачагына бернинди шик калдырмый иде.

– Латны... – Беренче булып ишегалды чирәменә Сакалбай ятты. Калганнары аның үрнәгенә иярделәр.

– Дошманнарыңны сузып салдым, күрше. Яр, от души!

– Егылганны тәпәләмиләр, күрше.

– Шулай, дисеңме? Сүзләреңдә хаклык та бар шикелле... Хәзерге кырыс заманда олы җанлы булу кирәк микән ул?

– Монда заманның катнашы юк.

– Нигә бәйләнделәр алар сиңа?

– Конкурентлар. Уртак тел тапмадык.

– Китсеннәр, дисеңме?

– Дүрт яклары кыйбла.

– Исчезли, бараны!

Тегеләр, гранатага шикләнеп карап алгалап, тизрәк китү ягын карадылар.

– Канга баткансың. Күлмәгеңне ташла. Юсаң-юмасаң да, кан барыбер бетми. Фельдшер Зәйнәпкә барып кайт. Ямыйсы җиреңне ямап, сыйпыйсы җиреңне сыйпаштырып җибәрсен. Чыраеңны да шактый ук бозганнар, – диде Илдус, киңәш биреп.

– Хатын-кыз күзенә күренсәң, йөз тапкыр арттырып сөйләячәкләр. Зелёнка сөртәм дә куям. Минем тәндә җәрәхәт тиз төзәлә, – диде Гаяз, кул селтәп.

– Үзеңә кара, алайса, – диде күршесе, гранатасын бил каешына эләктереп.

– Каян ул синдә?

– Семейный реликвий. Галәветдин бабам истәлеге. Сугыштан алып кайткан. Үзенең сөйләвенә караганда, Берлинны азат иткәндә, бабамның аяк астына килеп төшкән бу «күчтәнәч». Шартламаган! Моны могҗиза дими, ни дисең? Чөнки дөньяга әле әтинең туасы булган. Әтидән соң минем... Әнә бит ул ничек! Безнең дөньяда яшәвебез үзе үк могҗиза түгелме?!

– Бик саксыз кыланасың. Руслар әнә: «Один раз в год и кочерга стреляет», – диләр.

– Моңарчы шартламаган шартламый инде ул. Менә кирәге чыкты бит!

– Ярдәмгә килгәнең өчен рәхмәт, күрше.

– Ничек килмисең? Күрше хакы – Тәңре хакы!

– Иртәгә-берсекөнгә дип, һаман суза киләм... Синең белән сөйләшәсе сүз бар иде, күрше, – диде Гаяз, ниһаять тәвәккәлләп.

– Сөйләшик, күрше.

– Бик җитди темага...

– Мин пүчтәк сүз сөйләп йөри торган малай түгел!

– Өйләнергә уйладым мин, күрше. Озын сүзнең кыскасы шул.

– Хуш! – Илдус, беренче күргәндәй, күршесенә карап алды. Менә бит! Эт итеп кыйнап ташлаганнар үзен, ә ул өйләнү турында сүз кузгата! Мондый егетне ничек хөрмәт итмисең?!

Күршеләр арасында беренче көннәрдә үк ихтирамлы-кунакчыл мөнәсәбәтләр урнашты. Мунча яксалар: «Әйдә, әйдә, күрше, үзең өчен генә мунча ягып мәшәкатьләнмәссең. Безнекенең әле эссесе дә сүрелмәгән», – дип, Илдус кереп җитә. Таба ашының исе чыкса: «Бәй, бәлеш ашарга кермичә, кайда йөрисең бу гомер?» – дип, Гөлгенәсе шәрран яра.

Уңайсызлана. Кайчак: «Тамагым бик тук», – дип керми калу ягын карый. Тегеләр барыбер тынычланмый: үз туксаннары туксан.

– Кемгә? – дип сорады күршесе.

– Сәгыйдулла абзый кызы Фәйрүзәгә.

– Ну, эләккәнсең, егет! Бүтән сүзем юк!

– Нигә алай дисең?

– Усал кыз бит ул!

– Булсын!

– Гомере буе үз кубызына биетәчәк!

– Биетсен.

– Минем ярдәмем нидән гыйбарәт? Киләчәктә хатынымнан зарланганда, күз яшемне сөртер дип уйлыйсыңмы? Юкка өметләнәсең!

– Кызның ризалыгы юк бит әле, күрше...

– Ничек?

– Шулай. Китапча әйтсәм...

– Китапча кирәкми. Үзебезчә сукала. Тирәннән алдырып!..

– Мин кызны урларга уйладым, күрше. Түзәр әмәлем калмады. Сабыр казаным тулып шартлады! Урлап кайтам да өемнән чыгармыйм. Хәзрәт никахыбызны укыр әле. Үтенечемне аяк астына салып таптамас дип уйлыйм. Өметләнәм!.. Мине җүләргә саныйсыңмы? Ни әйтәсеңне беләм: егерме беренче гасыр!.. Интернет заманы!.. Бу нинди кыргыйлык диярсең!.. Нишлим?! Башыма уй төште: элекке заманнарда татар егете кыз-кыркынга озак ялынып йөрмәгән бит. Урлаган да кайткан! Всё! Җырың җырланды кызый! Бәләкәй чагымда Нургали бабам миңа күп нәрсәләр сөйләде. Минем белмәгәнем юк! Йә, әйт сүзеңне! Авызыңа су капкандай утырасың! Көләсеңме?!

– Көлмим. Сүземне әйтәм: беренче чиратта, мәсьәләне мәҗлескә салып фикер алышу кирәк. Кыз урлау күрше бакчасыннан шалкан чәлдереп чыгу түгел. Бик җаваплы мероприятие!

– Аңлыйм, күрше.

– Аңласаң, хәзер юын. Кыяфәтең йөрәгемә ярамый. Менә шушы алмагач төбендә чәй табыны әзерлә. Кирәк кадәр генә ачы балымны алып, түбәтәемне киеп, мин хәзер кереп җитәрмен. Хатын коймак та пешереп калган иде бугай...

– Нигә түбәтәй, күрше?

– Түбәтәемне кисәм, баш яхшырак эшләп китә минем, күрше («күрше» сүзенең тирән ихтирам белән бик еш әйтелүенә игътибар иткәнсездер).

– Алайса, ки! – диде Гаяз күршесе.

***

Фәйрүзә чая кыз булып үсте. Өч яшеннән сәхнәгә чыгып җырлады. Биш яшендә, конкурста катнашып, лауреат булды. Биегәндә сокланмаган кеше калмады. Аның турында сүз чыкса, авыл карчыклары: «Теле белән судагы шайтанны чыгарып утка кертер бу бала!» – диярләр иде. Укытучылар сәнгать юлыннан китәргә киңәш иттеләр.

Юк. Мәктәпне тәмамлагач, тотты да кулинария көллиятенә укырга керде.

Кулына диплом алгач, икмәк пешерү комбинатының кондитер цехына эшкә урнашты. Кулыннан гөлләр генә таммаган, телгә оста, оештыру сәләтенә дә ия кызны күреп алдылар. Хуҗа яшь дип тормады, лаеклы ялга киткән бригадир урынына Фәйрүзәне тәгаенләде. «Өметле яшь кадрыбыз!» – дип, хәер-фатихасын бирде.

Тик кызның моңа бик исе китмәде бугай. Тел тибрәтеп, беркемгә әйтмәгән, күңел түрендә сер итеп саклаган хыялы бар иде аның...

Бригада кызлары үзара дус-тату яшиләр. Ярый, ярый, килешәм: әз-мәз гайбәт, чүт кенә көнчелек, гаҗәеп оста үрелгән интрига – болары да юк түгел. Тик ул тискәре күренешләр кызларыбызга, тормыш мәшәкатьләреннән арынып, бергә-бергә күңел ачарга, туган көннәрен билгеләп үтәргә һич тә комачауламый бит. Кайда яшьлек, шунда җыр-бию, уен-көлке! Бригадирның үзе пешереп алып килгән «тәмлүшкәләре» генә ни тора! М-м-м!.. Һәркем авыз итә. Бәясен бирә. Күп очракта: «Болай тәмле итеп ничек пешердең?» – дип шаккаталар. Тик эш шул гаҗәпләнүдән ары узмый. Фәйрүзә исә макталган ризыкның рецептын теркәп куя.

Кулинариядә бәхәссез бер хакыйкать бар: бер үк ингредиентлардан ризыкны төрлечә әзерләп була. Кайсын ашыйсың – ләззәт кичерәсең, кайсын... Чү, ризыкны яманламыйк. Әлбәттә, җан җылысын кушып пешерену дә бик мөһим (көлке түгел!). Кызларга рәхмәт: боларның авызлары тәм-том ашап өйрәнгән, әйткән сүзләре гел синең файдага.

Киләчәктә җыелган рецептларны «үзем уйлап таптым» дип, патент алачак ул. Бүтәннәр борын тыкмасын өчен авторлык хокукына да ия булу кирәк. Ул көннәргә ерак калмады инде. Иреннәннән әнкәсе сөте кибеп, азмы-күпме акыл җыйгач, кызыйга гамь керде: булдыклы кеше үз эшен башлап җибәрә бу дөньяда!

Монысы – тормышының эшлекле ягы.

Күңел дөньясы да бар бит әле. Әнә шул дөньяда иң яшерен, иң изге, саф хисләр саклана торган бакча – күңел хөҗрәсе бар.

Чү!.. Сак кагылыйк...

Кыз иртә өлгерде. Егетләр тынгы бирмәде. Аталары алып биргән затлы машиналарда үз-үзләренә нык ышанган мажорлар килде. Кыз йөрәгенә юл тапмагач янадылар: «Син үзеңне кем дип белдең?! Мин синең белән икенче төрле дә сөйләшә белермен!» Курыкмады. Үткен

теле белән кикрикләрен тиз шиңдерде. Кайчак моңсуланды: йөрәген мүк басмагандыр бит?! Юк, юк!

Йөрәк көтә иде...

Ял көннәре җитте исә, сагынып-ашкынып, авылына кайтты. Автовокзалга барып йөрисе килми – ераграк, юллар чатына чыга да авыл ягына кайтучы машиналарга кул күтәрә.

Ул көнне янына иске генә «Иж-каблук» туктады.

– Таллыярга кайтасызмы?

– Әйе! Утырыгыз.

Утырды. «Каблук» хуҗасы сүзгә саран булып чыкты. Саран гына түгел, бөтенләй эндәшми. Авыз эченнән ниндидер җыр мырлап утыра шунда. Егетнең сөйләшмәве чак кына ачуын кузгаттымы соң, минминлегенә кагылып уздымы? Берәү булса, танышырга җай эзләр иде. Телефонын сорап тинтерәтер иде. Егетләрнең бөтенесе бер чыбыктан сөрелгән! Бу эндәшми. Әйтерсең җитмеш яшьлек әбине утырткан. Харап икән! Бик кирәгең бар! Утыр, авызыңа су кабып!

Үзе астыртын гына егетне күзләде. Руль тоткан куллары бигрәк зур. Чәче җиткән, алдырырга вакыт. Кырынып та йөри белми. Фу-у!.. Мыек җибәргән булып аны! Кара мыек. Чокыр ияк. Кара каш. Пумала баш... Шул пумала башка бармак очларын гына тидереп карыйсы килде. Ю-у-к!.. Аллам сакласын!.. Күзләре... Күзләренә карарга батырчылык итмәде. Егет үзенә борылып карагач та, тиз-тиз карашын түбән төшерде.

Кайтып җиткәч, рәхмәт әйтеп төшеп калды.

– Рәхмәтеңә рәхмәт! – диде егет, йөзен нурландырып. Матур елмая икән. Әллә шул елмаюы күңел кылларын тибрәтте?..

Шул егет онытылмый бит!.. Югыйсә нәрсәсе бар инде: ярый, бергә авылга кайттылар... Машинасы машина төсле булса ярар иде. Иске бер «каблук»! Адәм көлкесе!

Җомга кичен чак көтеп җиткерде. Ашкынып, таныш юл чатына чыкты. Янә дә шул иске «каблук» килеп туктады.

– Мине көтәсеңме, Фәйрүзә? Әйдә, утыр!

Күр син аны! Сине көтәләр, ди! Беткән, ди, минем көтәр кешем! «Әйдә, утыр», имеш! Әйтерсең кәттә иномаркасында диңгез буена сәфәргә чакыра! Моңарчы иске машинаңа утырып йөргәнемә рәхмәт әйт!

Кырт борылып басты. Ике секундтан йөгереп килеп утырды. Сөйләшмәделәр. Болай да рәхәт иде. «Каблук» алга чапты. Егет авыз эченнән «мырлап» кайтты. Кыз иләсләнгән күңелендә тәртип урнаштырырга тырышты. Кинәт елыйсы килде. Бу егет аңа битараф түгелме соң?! Би-тараф! Нинди шыксыз, салкын сүз!

Кыз ялгыша иде. Бик нык хаталана иде! Беренче очрашуда ук күзләрен көйрәтеп, егеткә карап алды – очкыны булачак Мәҗнүннең йөрәгенә төшеп калды. Ә очкыннан янгын чыгуы күпләребезгә мәгълүм бит!

Егетебез исә җомга кичен җиткерә алмый иза чигә иде. Көне җиткәч, машинасын ераккарак куеп, кызның юл чатына чыгып басуын көтте. Кыз күренүгә, янына ашыкты. «Гаҗәпләнде»: менә бит, тагын очраштылар – мач килеп торуын әйт син!

Әмма гомер бакый болай дәвам итү мөмкин түгел. Егет тәвәккәлләде.

Күптән кырынмый йөрүенә игътибар итте. Кырынды. Мыегын төзәтте. Үтүкләп, чиста күлмәген киде. Чәч алдырганда, таләпчәнлек күрсәтте: Казан чәчтарашханәләренең берсендә өч оста егет тирәли йөгерешеп йөрделәр. Чәчәк бәйләме сайлаганда, таләпчәнлек тагын да артты. Кызыл һәм ак розаларны гына азсынды. Бу гөлләр мәхәббәтнең төп символы саналсалар да, аның хисләрен бөтен тирәнлегендә ачып бирә алмаслар кебек тоелды. Бик каты уйлагач: «Букетка лалә, хризантема, сирень чәчәкләрен дә өстәгез!» – диде. Чәчәк сатучы кызлар мәш килделәр...

Бисмилласын әйтеп, таныш юл чатына чыкты. Кыз күренде.

– Рәхим ит, Фәйрүзә!

Машина ишеген ачканда, ни сәбәптер, каударланды. Каушады... Кыз аңа сәерсенеп карап алды, алай да эндәшмәде. Егет кулына чәчәк бәйләмен алды.

– Фәйрүзә!.. – Авызы чатнап кипте, сулышы ялкынга әверелде. – Мин...

Кыяфәте бик мәзәк булгандыр, күрәсең, кыз чыркылдап көлде. Машинадан атылып чыкты да көлә-көлә йөгерде. Соңрак елый-елый...

Тукта, и акылсыз кыз бала! Бәхетеңнән качып барасың түгелме?! Туктамады. Елый-елый, көлә-көлә йөгерде!.. Нигә? Куркып калдыңмы? Егет сине ярата! Ярата! Бу сүзне ишетергә әзер түгел идеңме?!

Ап-ак мендәреңне чылатып, төне буе елап чыктың, и мәхәббәтле кыз бала!..

Егет чакырганда, өеннән чыкмады. Телефонына җавап бирмәде...

***

– Миңа мөрәҗәгать итеп, дөрес эшләгәнсең, – диде Илдус күршесе, бер коштабак коймакны табын уртасына куеп.

Ул арада, гөжләп, самавыр кайнап чыкты. Җиде төрле үлән-яфрак кушып чәй пешерелде. Табын янына утырыштылар. Йомрыларга хуш исле чәй ясалды.

– Минем ярдәмем нидән гыйбарәт? – дип сорады Илдус күршесе һәм түбәтәен киде.

– Кичен ялгыз йөрми. Клубка чыкса, иптәш кызы Гөлназ белән кайта. Гөлназны аерып алып, берничә минут сөйләштереп торасы иде. Күреп калса, тавыш куптарачак бит! – дип, үтенечен әйтте Гаяз күрше.

– Ничек кенә куптарачак әле! Участковый Җәмил өеңә минутында килеп җитәчәк! Җәһәннәм астына качып та котыла алмыйсың. Бөтен Татарстан күтәреләчәк! Закон телендә кыз урлау, беләсеңме, ничек атала? «Көч кулланып, шәхесне ирегеннән мәхрүм итү». Менә ничек! Ничәнче статья икәнен белмим, кыз урлап йөргән юк; ну, срокны җәлләми бирәчәкләр! Алай да бик борчылма, сакалың биленә җиткәндә, төрмәдән чыгарсың. Җәмил сине утыртырга нык тырышачак! Заманында Фәйрүзәгә күз атып йөрде ул. Кыз гына карамады. Әле дә өметен өзмәгәнгә охшый егет. Хәлләр шулайрак, күрше. Йә, кире уйламадыңмы?

– Юк.

– Миңа мөрәҗәгать итеп, дөрес эшләгәнсең, – дип кабатлады Илдус. – Ә Гөлназны таңга кадәр сөйләштереп тора алам мин. Хатынга да көнләшергә бер сәбәп булыр. Алайса, гел көнләшми. «Әллә мәхәббәте сүрелде микән?»

дигән шик туа кайчак күңелдә. Темадан читкә киттем бугай. Ярый. Мин Гөлназ белән серләшеп калам. Син нишлисең?

– Нишлисең дип инде... Клубтан кайтканын сагалап торам да, машинама утыртып, өемә алып кайтам. Карышса, бераз көч кулланырга туры килер. Камил хәзрәт никахыбызны укыр дип өметләнәм.

– Дивана! – диде Илдус күршесе, хәйран калып. – Акыл өләшкәндә, абзар артында йоклап калгансыңдыр син! Соң кем иске «каблук»та кыз урларга бара?!

– Җәяү барыйммы? Яңа машина алу әлегә көн кадагына сукмый. Искесе йөреп тора.

– Минем айгырга атланып барасың! Син – принц на белом коне! Үзебезчә әйтсәк, акбүз атка атланган ханзадә! Аңла, дустым: һәр кыз ак атта үз принцын көтә! Аның бу хыялы, кияүгә чыгып, бала чүпрәгенә уралгач та сүрелми. Дөрес, минем айгыр алмачуар. Булса соң! Ак төстән бер дә ким җире юк. Матуррак та әле!

– Уйлыйк әле, күрше...

– Бер савыт ачы бал кертеп, әнә ул карлыган куагы төбенә күләгәгә куйган идем, – диде Илдус күрше. – Игътибар да итмәдең бугай.

– Игътибар иттем.

– Соң берәр йомры күтәреп куйыйк.

Ачы балдан авыз иттеләр.

– Әйбәт! – диде Гаяз күрше, эчемлекнең сыйфатына бәя биреп.

– Шөкер, бал коя беләбез! – дип мактауны кабул итте Илдус күрше.

– Бал коярга мине дә өйрәтерсең, – дип үтенде күршесе.

– Өйрәтермен. Хәзер көнүзәк мәсьәләгә әйләнеп кайтыйк.

– Җиде иләктән үткәрик!

– Акыллы фикер. Әйдә, тәртибе белән, син әйткәнчә, җиде иләктән илибез... Мин Гөлназ белән сөйләшеп калам. Фәйрүзә ялгызы кайтып китә... Урам караңгы... Урам тын... Кеше-кара күренми... Җырдагыча булсын: су буенда учак яна...

– Күктә йолдызлар да яна. Тулган ай балкый, – дип өстәде Гаяз, кыз өчен борчылып.

– Тик кенә утыр! – дип кисәтү ясады күршесе.

– Дөм-караңгы урамда куркыр бит ул...

– Курыкмас! Минә кыз тыкрыкка борыла... Монда – син! Солыдан бушаган зур капчык бирермен. Секундында капчыкны башыннан аяк йөзенә кадәр кидертеп куясың! Чәбәләнмәскә ару булыр. Кызны ияргә ташлыйсың. Айгырга камчы тидерә күрмә, алып биреп китәр, кайда төшеп калганыңны да сизми калырсың. «Һай Алмачуар!» диюең җитә. Капка төбенә кайтып җиткәч, айгырны җибәр. Улагына керә белер. Онытып торам: кызның телефонын ал, элемтәдән мәхрүм ит.

Бик каты торса, авыл көтү куарга торганчы өеңнән чыгарма. Аннан үзе дә китми ул. Ничек китсен, күрше-күлән күрәчәк бит! Ситуацияне әйбәтләп аңлат. Бөртекләп төшендереп бир. Кызның ризалыгын алырга тырыш! Эшебез пешми икән, сохари киптерә башла. Мине дә как соучастника гаепләрләр. Икәүләп зона таптыйсылар алда әле. И Җәмил сөенәчәк! Йә, әйт соңгы сүзеңне, егет!

– Чигенү юллары ябык, күрше!

– Молодец! Үземә охшагансың! Хуш, сине тыңлап карыйк.

– Капчык эчендә һава җитәр микән үзенә? – диде гашыйк җан, кыз өчен борчылып.

– Хатын-кызга чурт булсынмыни?! – дип кырт кискән иде дә, Мәҗнүн сыңарының чын-чынлап хәсрәтләнүен күргәч, күршесе: «Ерак юл түгел, кайтып җиткәнче генә тончыкмас!» – дип, юату сүзләре әйтте.

– Мин атта да йөри белмим, – диде мәхәббәт корбаны, бөтенләй төшенкелеккә бирелеп.

– Ничек белмисең? Бу ни дигән сүз?

– Шәһәр малае бит мин...

– Тәк. Проблема. Чишәргә кирәк. Бер атна срок сиңа. Вакыт кысан. Җәмил йокламый. Калган эшкә кар ява. Бүгеннән тотынабыз. Мин сине ат өстендә йөрергә өйрәтәм! Кеше күзенә чалынмас өчен, көтү кайткач, әрәмәгә төшәбез. Айгыр да сиңа ияләнсен. Кишер ярата. Үз кулың белән сыйларсың.

Берәр йомры күтәреп куйдылар. Хыял күге биегәеп, офыклары тагын да киңәеп китте.

– Чараның икенче өлешенә күчәбез, – диде Илдус күрше. – Монысы күпкә катлаулы һәм бик каты уйлауны таләп итә. «Кыз урлаган идем, хәзрәт, никах укымассыз микән?» дип барсаң, куа да чыгара! Ике дә сөйләшеп тормый. Кремень! Үгетләү-ялынуларның нәтиҗәсе – ноль! Полициягә хәбәр итмәсә әле. Юк, итмәс. Әмма, вәгазь укып, җелегеңә төшәчәк! Нишләргә соң дигән сорау туа...

– Чәйне кайнарлыйм...

– Кайнарла.

Самавыр торбасыннан зәңгәр төтен күтәрелде. Баш очында кош чыркылдады. Карлыган кайнатмасына выжан төшеп батты. Чыга алырмы-юкмы дип икәүләп карап тордылар. Чыкты, рәхмәт төшкере! Бераз авыраеп йөрде дә канат җилпеп очып китте.

Уйлыйм утыз, чыга тугыз, диярсең...

– Татар малайлары яулап алалмаган крепостьлар юк! – диде берсе.

– Булырга тиеш тә түгел! – диде икенчесе.

– Берәр дога беләсеңме? – дип сорады Илдус күрше.

– Бисмилла әйтә беләм.

– Җитми. Бик әйбәтләп бер дога өйрән. Озакка сузма. Шуннан соң хәзрәт янына барырсың. «Хәзрәт, менә дога өйрәнгән идем, дөрес укыйм микән, рәхим итеп тыңлагыз әле», – диярсең. Кояшка куйган балавыздай эри дә төшә! Ә син, моментны тотып алып, төп мәсьәләгә күч! Алай да эш пешми икән, күрше авыл мулласына барам, диген. И, яратмый күрше авыл мулласына йомыш белән йөргәнне. И, яратмый! Кыскасы, бөтенесе үзеңнән тора, егет!..

– Сынатмабыз! – дип, күкрәк киерде Гаяз күрше.

– Афәрин! Йомрыларны мөлдерәмә тутырып сал. Йомгаклап куйыйк.

Йомгаклап куйдылар. Ачы балның килүе бик җиткән иде.

– Бу мәсьәләдә миңа мөрәҗәгать итеп, дөрес эшләгәнсең! – дип, янә бер кабатлады Илдус, Гаяз күршесенә хөрмәт белән карап.

***

Егетнең ничә тапкыр ат сыртыннан мәтәлеп төшкәнен санап ваксынмыйк. Шөкер, аяк-кул сынмады. Егетебез, гәрчә шәһәр җирлегендә туып-үскән булса да, сәләтле укучы булып чыкты. Бер атнадан ул айгырга сикереп атлана; иярдә дә, иярсез дә, юырттырып һәм кушаяклатып чаптырып та, ат өстендә шөйлә ышанычлы йөри иде. Афәрин дими, ни дисең!

Бүген исә бисмилласын әйтеп, мәчеткә юл тотты.

***

Камил хәзрәт койма тота иде. Изүе ачык, җиңе сызганулы, кулында чүкеч, йөзендә нур уйный – бу эшкә кулы ятып торганы күренеп тора. Гаяз яңгыратып сәлам бирде:

– Әссәламегаләйкем, хәзрәт!

Хәзрәтнең нурлы йөзе тагын да нурлана төште.

– Вәгаләйкемәссәлам, Гаязҗан! Әйдә, түрдән уз, дисәм...

– Сезне күргәч, бер мәзәк искә төште, хәзрәт. Сөйлимме?

– Хуш. Тыңлыйм.

– Шулай бер хәзрәт койма тота икән. Ерак та түгел бер малай басып тора. Китми дә китми. «Энем, миңа бер-бер йомышың бармы?» – дип кызыксына хәзрәт. «Юк, мулла абзый», – ди малай. Ярый. Хәзрәт янә эшкә керешә. Малай һаман китми. «Энем, бар, өеңә кайт. Анаң көтәдер», – ди хәзрәт. «Көтми, мулла абзый!» Хуш. Хәзрәт эшен дәвам итә. Китү малайның уенда да юк! Хәзрәт бу хәлгә тәмам аптырап: «Энем, әйт әле чын дөресен, ник монда басып торасың син?» – дип сорый. «Әй, мулла абзый, бармагыңа чүкеч белән суккач, ни әйтерсең икән? Шул сүзне генә ишетәсем килгән иде!» – дип, серен чишә малай.

Камил хәзрәт сакалын югары чөеп көлде:

– Син дә шуның өчен килмәгәнсеңдер бит?

– Юк, хәзрәт. Килүемнең сәбәбе күпкә җитди.

– Хуш. Тыңлыйм йомышыңны!

– «Фатиха» сүрәсен өйрәнгән идем, хәзрәт. Күңелемдә шик туды: сүзләрен дөрес әйтәм микән? Тыңламассызмы?

– Сөбханалла! Сөбханалла! – Әллә күз-керфекләре дә дымланып китте хәзрәтебезнең? – Бөтен дикъкатем синдә, Гаязҗан!..

Егет көйләп укып җибәрде. Остаз дүрт-биш җирдә төзәтте. Кабатлап әйтергә кушты. Үзе укып күрсәтте. Күңеле нечкәреп, баш очында оҗмах кошлары сайрагандай тоелды. Бәй, ничек сөенмисең?! Менә бит ул ничек!.. Яшьләр дә дингә тартыла диген... Бик әйбәт күренеш бит бу!

– Тагын бер йомышым бар иде, хәзрәт, – диде Гаяз, тимерне кызуында сугып.

– Нигә биш түгел?

– Мин өйләнергә уйладым бит әле, хәзрәт. Никахыбызны сез укырсыз дип өметләнәм.

– Бәрәкалла! Бәрәкалла! Фәрештәләрнең «амин» дигән чагына туры килсен ошбу сүзләрең! Хуш, кем кызына!

– Сәгыйдулла абзый кызы Фәйрүзәгә, хәзрәт.

– Ә-ә... Алай икән!.. Кай тарафтан карасаң да, ихтирамга лаек нәсел. Яучы җибәрдеңме? Кызның ата-анасы ризамы?

– Риза булмый кая барсыннар, хәзрәт!
– Ә кыз?..
– Ничек дип әйтим, хәзрәт... Китапча әйтсәм, монысы билгесезлек томаны белән өретелгән...
– Томанны куып тарат, егет! Тиз! Тиз!
– Мин кызны урларга уйладым, хәзрәт!
– Ничек?!
– Шулай! Урлыйм да кайтам! Сез никах укыйсыз. Дөньяда булмаган хәл түгел. Миңа Нургали бабам сөйли торган иде: элекке заманда егетләр кызларга бик ялынып йөрмәгәннәр!
– Шайтан вәсвәсәсенә бирелгәнсең, егет!
– Сабыр савытларым мөлдерәп тулды, хәзрәт!
– Кызның ризалыгы кирәк, егет!
– Бөтен өметем сездә, хәзрәт!
– Кызның ризалыгы юк икән, мин никах укудан баш тартам!
Дөнья кисәк суынып китте. Күктән бар җылысын җуйган кояш карады. Кошлар тынды. Чишмә челтерәп агуыннан туктады. Чәчәкләрне сөеп, җил исмәде. Өмет шәме соңгы тапкыр талпынып алды:
– Ярый, хәзрәт. Борчыганым өчен гафу итегез. Мин күрше авылга киттем. Минем хәлемне аңлаучы мулла табылыр әле җир йөзендә. Бөтенесенең дә йөрәгенә мүк үсмәгәндер! – Китәргә дип кырт борылды. Өч адым атларга өлгермәде, Камил хәзрәтнең кырыс тавышын ишетте:
– Стоп! Беркая бармыйсың! Шул гына җитмәгән ие! Никахыгызны үзем укыйм. Егет булсаң, кызның ризалыгын ал. Шаһитләр кирәк. Визиткамны бирәм. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында шалтырата аласың. Аудиенция тәмам! Хуш иттек!
Ачуы кабарды Камил хәзрәтнең. Күр син аны! Оятсыз! «Кыз урлыйм» дип килгән! Ә ул никах укырга тиеш! Ә кызның ризалыгы юк! Бу нинди тәртипсезлек?! Бу нинди киртә сикерү?! Менә укырмын мин сезгә!
Бераздан ачуын күңел төпкеленнән күтәрелгән сөенү хисе кысрыклап чыгарды. «Кыз урлыйм», диме?! Күр син аны! Үзсүзле егет! Никахны укырбыз, Алла боерса! Вакыты җиткәч, исем кушу мәҗлесенә дә эндәшерләр, рәхмәт яугырлары! Эшләр болай барса, авыл яши! Яшәячәк! Никахын да укырбыз, исемен дә кушарбыз. Ешрак булсын иде андый чакырулар. Шулай бит ул дөнья! Матур бит ул дөнья! Их-ма!.. Бер сугуда эшләпәсенә кадәр батырмакчы иде шушы кадакны... «А-а-ан!..» – Хәзрәт шул, Ходай сабырлык биргәндер, вакытында тыелып калды.

***

Көтелмәгән бер-бер хәл килеп чыкмасын өченгә, вак-төягенә кадәр акыл бизмәнендә кат-кат үлчәп, чарага бик җитди әзерләнделәр шул.
Кая ул каршылык күрсәтү, кыз «аһ» дип аваз салырга да өлгермәде... Тыкрыкка борылуга, каршысына ярсып-уйнаклап килгән аргамакны күрде. Ис-акылын җыярга өлгергәнче, җайдагы кызның башына капчык кидерде, җиңел генә күтәреп, үз янына алды, шуннан соң дөньясы айкала-чайкала башлады, суларга һава җитмәде...
Ниһаять, ат туктады. Үтә дә таныш тавыш: «Араныңа кайт,

Алмачуар!» – диде. Тавыш иясе, аны җилкәсенә салып, каядыр алып китте. Аягына бастырды.

Яктылык, авырттырып, күзләргә бәрде. Кыз беренче эше итеп төчкерде (солыдан бушаган капчыкны кагып кую беркемнең дә башына килмәгән иде). Икенче эше итеп: «Үләм!» – дип кычкырды. Таныш түгел өйне, каршысында аңгыра кыяфәт белән басып торган ир-атны күрде. Таныды!

– Изге сәгатьтә нигеземә аяк бас, Фәйрүзәкәй! – диде Аңгыра кыяфәт чиктән тыш дулкынланган тавыш белән.

– Кайда мин?

– Минем өемдә.

– Чыгарып җибәр мине хәзер үк! – Кыз ишеккә ташланды.

– Ишек бикле, – диде егет.

– Мин полициягә шалтыратам! Хәзер килеп җитәрләр! Төрмәгә алып китәләр сине, белдеңме?! Телефоным кайда минем?!

– Миндә, – диде егет.

– Барыбер китәм! Китәм!

– Фәйрүзәкәй!..

– Якын киләсе булма!

– Тыңлале сүземне, Фәйрүзә!..

– Тыңламыйм!

– Ярый, тыңлама... Тик шуны бел: яратам мин сине! Яратам! Нишлим?! Очрашудан качасың... Телефоныма җавап бирмисең...

– Өемә кайтам!

Егет күңелсезләнде. Беркавым башын иеп эндәшми басып торды. Сүзен әйткәндә, тавышы да сүрелә төшкән кебек иде:

– Ярый. Нишләмәк кирәк?.. Иртәгә көтү куганда китәрсең, – диде.

– Нигә көтү куганда?

– Күршеләрем күрер сине... «Бу кыз егет өендә нишләп йөри икән?» дип уйларлар. Уйласыннар! Бөтен авылга таралсын бу хәбәр!

– Аһ, син оятсыз! Кара, нәрсә уйлый бит, ә!

– Уйлыйм шул. Минем башта гел акыллы фикерләр генә. Кайчак үзем дә гаҗәпләнәм.

Мыскыл иткән була! И суган кыягы!

– Чыгарып җибәр мине! Соңгы тапкыр әйтәм!

– Көтү куганда китәрсең. Мин ике сөйләмим.

– Ү-ү-ү!.. Аңарчы түзалмыйм!

– Нәрсә булды?

– Мин... Мин...

– Нәрсә, кабынмый җәфалаган машина кебек этенеп торасың?! Ни булды дип сорыйм?!

– Әйтергә оялам!.. Ү-ү-ү!.. Үзең бел инде...

– Нәрсәне белергә тиеш мин?!

– Мин... Мин кысталдым!.. Шуны да аңламый! Бу кадәр томана булырсың икән!.. Ү-ү-ү!..

«Чү, улым! Баш ярылып, күз чыкмаган» дияр иде Нургали бабасы. Баш та ярылды, күз дә чыкты, бабакай! Илдус күрше! Без алалмаган крепостьлар юк, имеш!..

Паникага бирелмәскә кирәк. Уйла! Хәйләлиме? Тикшереп карап булмый. Бәлки, дөресен әйтәдер? Тере җан иясе бит... Чыгармый булмый. Янында басып тора алмыйсың. Димәк, качу мөмкинлеге бар. Аяклары җитез!..

– Мин сине көтәрмен, Фәйрүзә! – Тавышына бер чиметем өмет сыенган иде.

Кыз өермә булып ишеккә ташланды. Егетнең борын төбендә шапылдап, ишек ябылды. Мәрхәмәтсез сүзләр мәхәббәтле йөрәккә ук булып кадалды: «Хуш! Дикарь! Каторжан! (Авылда кушаматсыз кеше юк: узган гасырның утызынчы елларында Нурислам бабасы чит-ят җирләргә сөрелгәнгәме, Гаязга «Каторжан» кушаматы чат ябышты). Синнән урлатып торалар, ди!» – Телен күрсәтергә дә онытмады. Ишегалдында, чәңгелдәп, көчек өрде...

Бетте... «Кыз урлау» операциясе тәмам. Бүтән болай җүләрләнеп йөрүләр булмас инде. Ярый, хатынсыз яшәр. Яшьлек мәхәббәтен сагынып... Йә, исәнме, буйдак ир-ат тормышы! Үз сафларыңа тагын бер бәхетсезеңне кабул ит...

***

Туфлиләрен салып, яланаяк, бар көченә йөгерде кыз. Артыннан чәң-чәң өреп, Гаязның көчеге иярде. Ара ерагая барган саен күңеленең бер кылы җәя керешедәй тартылды, өзелеп чыгар дәрәҗәгә җитте; әйтерсең лә ул кылның бер очын егет өенә төенләп бәйләп куйганнар иде.

Туктады. Күз яшьләренә ирек бирде. Елап алгач, тынычлана төште. Кая йөгерә ул?! Син ул егетне яратасың бит! Яратасың! Нигә таныргa теләмисең?!

Көчек (үзенең эт акылы белән өреп кенә эш чыкмас дип уйлады микән?) качкынның итәгеннән каптырып алды, усал ырлап, күзләренә карады. «Җибәр итәкне! Пшол! Кайтам бит!» – дип кычкырды кыз... Ялгыш ишетмәдең. «Кайтам!» – диде.

***

Башын өстәлгә салып утырган. Күтәрелеп тә карамады. Үпкәчел микәнни? Күрәселәр алда икән... «Мин алдаштым... Гафу ит» диясе килде. Тик ул сүзләр урынына усалраклары чәчрәп чыкты: «Иярен мендәр дә сала белмәгән бит ул!»

Аяк очына мендәр очып төште.

– Мендәргә бас! – Тавышы дорфа.

– Нигә? Менә бастым.

Каерып алып, бер кашык бал каптырды.

– Телең балдай татлы булсын!

Каерып алып, бер кашык май каптырды.

– Телең май кебек йомшак булсын!

– Күп каптырдың! – диде кыз.

– Таман!

Егет балын-маен алып куеп:

– Ела! – дип боерды.

– Менә тагын!.. – диде кыз, гаҗәпләнүенең аръягына чыгып. – Нигә мин еларга тиеш? Бер дә елыйсым килеп тормый әле!

– Тәртибе шулай!

– Еламыйм!

Гаязның, мәсьәләнең асылына төшенергә тырышып, бу хакта уйланганы

бар иде. Ата-ана йортыннан аерылып китәсе кызны ахирәтләре елата бугай... Аннан кияүгә чыгасы кыз җырлый. Әбисе сөйләгәннәрдән хәтерендә тоткарланып калганнары шулар. Кемнәр белеп бетергән? Нәрсәдер ябешеп бетми монда... Кыз елыймы, җырлыймы? Бәлки, ул кияүгә чыгарга атлыгып торадыр? Бу очракта күз яшьләре ышандырмый. Ярый, май ботканы бозмас: әүвәл елатыр, аннан җырлатыр. Монысы хәл ителде. Ахирәтләре юк. Димәк, аларның вазифасын үз өстенә алырга туры киләчәк.

Илдус күршесе хаклы: кыз урлау – күрше бакчасыннан шалкан чәлдереп чыгу түгел. Ата-бабадан калган йола бар. Гореф-гадәте...

Күкрәк тутырып сулыш алды. Трагик ноталарны җәлләмәде:

– Әбиең – бабаңа, әнкәң – әткәңә, апаң җизнәңә кияүгә чыккан. Сине караңгы төндә җиде ят урлап китте, и бәхетсез кыз бала!

– Дивана! – диде кыз.

– Газиз әнкәң иртә таңнан торып коймак пешерер. Ул коймаклардан авыз итәргә син булмассың. Тәрәз каршыңда сине сагынып, кошлар сайрар. Ул кошлар да сине юксыныр... Ела, и хәсрәтле кыз бала!

– Ы-ы, менә!.. Хәзер!

– Синең дус кызларың нинди бәхетле! Алар ата-ана йортында гомер итәләр.

– Ат сыртына салып урлап китте дә!..

– Ата-анаңның газиз баласы идең...

– Әйе шул!

Керфек очына яшь тамчысы эленде.

– Бер кайгысыз кыз чакларын үтте дә китте...

– Ачуымны китереп торсаң, елармын да!..

Шөкер, буасы ерылды. Еласын. Тәртибе шулай булгач, нишлисең? Гөлҗиһан әбисе белми сөйләмәгәндер.

– Нигә елатасың мине? Ник юатмыйсың?

Менә сиңа кирәк булса! Монысы көн тәртибендә каралмаган бит. Юатмый да булмас:

– Ирең сине яратыр, кыз бала. Өрмәгән җиргә дә утыртмас.

– Ы-ы, көт үгездән сөт!

– Алмалар кебек тәгәрәшеп, балаларыбыз үсәр! Алар «әнием!» дип янында бөтерелеп йөрерләр!

– Алла бирсә диген!

– Алла бирсә дим. Картаймыш көнебездә без балаларыбыз, оныкларыбыз бәхетенә куанып яшәрбез, и сөйкемле әби!

– Нигә картайтасың мине?! Үзең бабай!

– Йә, тынычлан, кыз бала.

– Тынычланмыйм! Сугышмыйча гына яшәп булмый микәнни бу дөньяларда?!

– Җитте!

– Үзе елатты да...

– Хәзер җырла!

– Менә тагын... Нигә?

– Әйттем бит инде, йоласы шундый. Исемә төште: кыз баланың авыр язмышы турында җырла!

– Язмышым авыр түгел минем!

– Нинди киребеткән кыз син?!

– Ярый! Әбием репертуарыннан... – диде кыз, көтмәгәндә ризалашып. Күзләрен тутырып, егеткә карады. Йомшак кына тамак кырып алды. Битенә алсулык йөгерде. Җырлады:

Тал чыбыктай нечкә була
Кыз баланың билләре;
Кыз бала ничек кайгырмас,
Кала туган илләре.

Күкрәген тибрәтеп, авыр сулады: «И минем бәхетсез башкаем!» җырын дәвам итте:

Ир бала сикереп менә
Атның иярләренә;
Кыз бала тугач ук ята
Хәсрәт мендәрләренә.

Карашын түшәмгә терәп иңрәде: «И, кайгы-хәсрәт күрергә генә туган бала икәнмен!» – Әллә чын күңелдән әйтә бу сүзләрне, әллә кылана? Кыланса, коеп куйган артист! Юк, артист та бу кадәр булдыра алмас.

Сандугачның, мескенкәйнең,
Булмый аның тәхете;
Кыз баланың, бичараның,
Булмый аның бәхете.

Киртәсенә керде, болай булгач! Ярый. Егет сүзен кыска тотты: «Табын әзерлә. Мин Камил хәзрәткә шалтыратып алыйм. Күршеләргә дә хәбәр итми булмас». Шалтыратты. Ике сүз әйтте: «Хәзрәт, көтәбез». Күршеләргә бер сүз: «Керегез!»

Шул хәбәрне генә көтеп торганнар диярсең, күршеләр кереп тә җиттеләр. И гаҗәпләнделәр бу эшкә, и хәйран калдылар! Аеруча Гөлгенәнең ушакыллары китте: «Ходаем! Ничек алай булды соң?! И, башсызлыгы бу Гаязның! Бер дә андый акылсызлык эшләр дип уйламаган идек!» – дип, шаклар катты. Үзенең кулында мичтән яңа чыккан бәлеш. Яулыгына кадәр онытмаган. «Хәзрәт алдында яланбаш йөрмәссең!» – дип бәйләтеп үк куйды. Гаҗәпләнсәң, гел гаҗәпләнеп яшәрлек бу дөнья!

Үз вакытын белеп кенә, Камил хәзрәт килеп җитте.

Бармак бәйләнгән, башта – чалма, өстә – яхшы чапан, күзләр нур чәчә, тавышы кырыс... Һай, кырыс!.. Сорауны кабыргасы белән куя: «Бу ни хәл?! Бу нинди тәртипсезлек?!» – ди. Һәммәсен сискәндереп, кулындагы таягы тукылдап ала.

Гаяз эндәшми. Баш түбән иелгән. Ничек иелмәсен – гаепле! Кыз, битен яулык чите белән каплап, гөлбәчкә үк кереп поскан. Ничек посмасын – оят!

Яшьләр өчен Илдус җавап тота. Тавышы ифрат итагатьле; чыраена баксаң, Ходайның бер тәкъва бәндәсе инде менәтрәк, тәкъва бәндәсе...

– Яшьләр бит, хәзрәт. Ялгышканнардыр... Инде нишләмәк кирәк? Никах укымассыз микән дигән өметтә калабыз, – ди.

– Илдә булмаган хәл! – Һәммәсен сискәндереп, янә таяк тукылдый.

– Нишләп булмасын, хәзрәт, – дип, йомшак кына каршы төшә Гаязның күршесе. – 1913 елны Сәйфетдин атлы егет Зәкәрия бай кызы Бибигөлне урлый. Нуретдин хәзрәт яшьләргә никах укый.

– Каян беләсең син ул вакыйганы? – дип гаҗәпләнә хәзрәт.

– Тарих укытучысы Кәбир абый сөйләгәние. Шул истә калган.

– Кәбир абыеңа мин сөйләдем. Миңа кадәр имамлык иткән муллалар авылда булган кызыклы вә гыйбрәтле хәлләрне мәчет кенәгәсенә теркәп барганнар, рәхмәт төшкерләре!

– Менә күрдегезме, хәзрәт! – дип, тыйнак кына тантана итә Илдус күрше.

– Бу гамәле өчен Гарифҗан ахун Нуретдин хәзрәткә каты шелтә белдергән. Чак указсыз калмаган Нуретдин хәзрәт!

– Ошбу вакыйгадан соң инде бер гасыр вакыт узган. Йөз елга бер кыз урлап тормасак, йолаларыбызны, гореф-гадәтләребезне онытып бетермәбезме, хәзрәт? – ди Илдус күрше, мәсьәләнең кендегенә төшеп.

– Онытабыз! – диде кыз карагы, сүз әйтергә җай чыгуына сөенеп.

– Син тик кенә утыр! – дип, кисәтү ясады күршесе.

– Ат дагалаганда, бака ботын кыстыра! – диде хәзрәт тә, «гаепле»нең җитди әңгәмәгә кысылып утыруын өнәмичә.

– Киләчәктә йолаларсыз, гореф-гадәтләрсез калмабызмы, хәзрәт? – ди Илдус күршесе, «һөҗүм»не алтабан җәелдерү максатыннан оператив киңлеккә чыгып.

– Минемчә, бу – тәртипсезлек. Шәригать тә кыз урлауны хупламый. – Камил хәзрәтнең үз фикере.

– Ай-һай, хәзрәт! Тәртипсезлек кысаларына гына сыеп бетәр микән бу гамәл? – дип, шиген белдерә Илдус күрше.

Сүзсез калалар. Ир-атлар – тирән уйда, хатын-кызлар табын әзерли.

Ниһаять, Камил хәзрәт телгә килә:

– Яшьләрне әйтәм... Гаепләрен таныйлармы соң?

– Таныйлар, хәзрәт. Бик таныйлар! Бүтән гомергә дә алай эшләмәбез, диләр! – дип, чак кына ашыгыбрак җавап бирде Илдус күршесе.

– Йә, утырышыгыз! – диде хәзрәт, анык бер карарга килеп.

Никах Күкләрдә языла, диләр. Күкләрдә языла да, Аллаһы Тәгалә үзе шартлатып мөһерен суга, имеш. Бик мөмкин.

Камил хәзрәт никах укыды. Күңелнең иң нечкә кыллары тибрәнде. Язмышлар бәйләнде. Ике йөрәк бер ритмда типте...

Мин фәкыйрегезгә дә, яшьләргә бәхет теләп, каләмемне алып куяр чак җитте.

## Эпилог

Без Җир шары дип аталган гаҗәеп корабта Галәм буйлап сәяхәт итәбез... «Төн вә көндез Ул йөрәдер: юл бара ят ил карап» дип язган Шагыйрь. «Кайсы юллар, Нинди упкын Тарта безне җан сорап?!» дип кисәткән... Әнә шул сәяхәттә упкыннарны урап узып, җаннарыбызны имгәтмичә саклап кала алсак иде!

Ул корабта татар авылы Таллыяр да бар. Үзгәрәк халык яши монда.

Юк кына вакыйганы да күпертебрәк, чәчәкләп-чуклап (кайчак чама хисен онытып җибәрүләре дә мөмкин), уен-көлкене дә читкә тибәрмичә, ашыкмый гына, үтә дә тәмләп сөйләргә яраталар. Күзгә карап, кырыс хакыйкатьне дә әйтә беләләр.

Без дә әнә шул матур традициядән читтә калмаска тырыштык. Ни галәмәт килеп чыккандыр, анысы укучы хөкемендә.

Сезне, мөгаен, табадан әле генә төшкән яңалыклар кызыксындырадыр?.. Кыскача мәгълүмат биреп үтим.

Каторжан Гаязның кыз урлавы вәйран башларны хәйранга калдырды дисәм, чынбарлыктан шактый ук еракта торуыбыз ачыкланыр. Каторжан Гаязның кыз урлавы авыл кешеләренә аяз көндә яшен суккандай тәэсир итте дип язып куйсам, чамадан чыгу булмасмы? Билгеле булганча, хакыйкать – урталыкта.

Беренче көнне авыл эндәшмәде. Ми күзәнәкләре әле бу мәгълүматны үзләштерә иде. Икенче көнне... И, сөйләделәр! И, әби-чәби рәхәтләнде! Әле һаман тынычланып бетә алганнары юк. Ходай сәламәтлектән аермасын үзләрен.

Участковый Җәмил бик каты кайгыра дип сөйләделәр. Гармунында уйный да җырлый, ди... Тыңлаган кеше күз яшенә манчылып елый, ди... Бер савыт ачы балын күтәреп, Илдус «кайгы уртаклашырга» барган. Шуннан соң гына Җәмил азмы-күпме тынычлана төшкән, имеш.

Гөлгенә көнләшә башлаган: Илдусның маңгаенда Кукмара табасы эзе. Усал телләр ирнең клуб алдында Гөлназ белән сөйләшеп торуын җиткергәннәр. Менә бит ул ничек... Илдусның авызы барыбер ерык. Ничек сөенмәсен – биясе колынлаган!

Фәгыйлә Моратовна төнне йокысыз уздырган. Сәбәбе җитди: теге йомылган «эш»не яңабаштан кузгатмакчылар...

Назиф Сибгатович яшь гаиләгә «Зингер» тегү машинасы бүләк иткән. Кызыксынучыларга: «Тиздән белерсез!» – дип җавап биргән. Соңгы вакытта үзен гел язу өстәле артында күрәләр. Хәерлегә булсын!

Сабырлыгыгызны сынап, иң мөһим яңалыгымны азакка калдырдым. Сүзебез яшь гаиләгә кагыла... Бүгенгесе көндә Фәйрүзә – үзмәшгуль. Ул пешергән бавырсак, чәк-чәк, пирог, тортларны бик теләп алалар. Киләчәккә планнары зурдан. Уңышлар телик!

Хәзрәтнең юраганы юш килде: ел тулар-тулмас бәхетле хатын ир бала тапты. Сабыйга Нургали дип исем куштылар.

Җир шары Кояш тирәли янә бер әйләнде – Нургали атлы малай ишегалды чирәмендә тәүге адымнарын атлады. Егылды. Кычкырып елады. «Балакаем!» – диде әнисе, өзелеп. «Тор, улым! Елап яту егет кеше эше түгел!» – диде әтисе.

Малай торды. Башын күтәреп, зәңгәр күккә карады. Сөенеп елмайды. Күзләр генә тимәсен, янә китте!

Атла, олан!

Хуҗа булып атла.

Бу – синең туган җирең!



Гөлсәрия
Басыйрова

# «АЛТЫН КӨЗ» МИНЕМ ИСЕМ!..*

## Көзге кояш

Күренә дә кояш көзге көндә, юкка чыга аннан кай ара.
Җылысы аз, ләкин үзе һаман җылыткандай булып шаяра.
Күңелемә сыңар нуры җитә, ул җырларга тора шул ара.
Хыял атын бәйдән ычкындыра, дилбегәсен сала, тугара.
Иркенлекне тою рәхәт аңа, ялын болгап, нурга иярә.
Бераз гына кала учым белән көзге Кояшыма тияргә.
...Соры көндә шушы тансык халәт эзли калса күңел җылысын,
Көземдә дә, салкын кышымда да җылытучым бер Син булырсың...

## Очар идем

...Көзге сагыш якынайган икән, сары яфрак төште каршыма.
Агачыннан өзелеп төшсә дә ул, әллә нинди сере бар сыман.
Мин үзем дә очар кебек булам... Әздән генә калам тукталып.
Нигә тыям икән күңелемне, нигә кирәк мондый урталык?
Үз-үземне читтән карап торам, хыялымны шундый кызганып.
Ә карашым кыр казларын саный, очар кебек бергә кузгалып.
Очар идем, артка карый-карый, җеп очында соңгы каз булып,
Бар җаныма җирсү, сагыну тулып, кайтыр идем аннан Яз булып...

***

Сары яфрак килеп кунды яктыртып уйларымны...
Моңланмыйм бүтән, әллә соң моңланып туймадыммы?!
Янып торган миләшләрдән муенса тезеп кидем.
Кызыл-сары тәкыяне көземнең таҗы дидем.
Таҗлы башны кем соң инде моңаеп аска исен?
Үземә килешеп торган «Алтын Көз» минем исем!

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан 2023 елда уздырылган татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсының «Поэма, шигырь» номинациясендә икенче урынны алган шигырьләр.

Гөлсәрия БАСЫЙРОВА (1952) – *шагыйрә. Пермь өлкәсе Барда районында туган. Чаллыда яши.*

***

Үзгәрдем мин. Күзләремдә генә яшәвемнең тәмен татыдым.
Ашыкмакчы була да ул күңел, каршы килә аңа акылым.
Ашык-пошык яшәлгәнгә микән тоймаганмын мизгел тәмнәрен.
Җигелгәнгә тормыш арбасына авыр булды микән хәлләрем?
Учлап-учлап кояш нурын салам, якты булсын димен йөрәктә.
Шул яктыдан табар мине, бәлки, җаннарына җылы кирәкләр.
Көзләр әнә... Алтынсыман көзем... Ашыкканын беләм мин аның –
Күчәреннән чыгарырдай итеп әйләндерә вакыт Дөньяны.

## Минем көзем

Сезнең көзләр дә матурмы? Минем көзем – алтын сары.
Эзләремә яфрак ява, аз гына сагышлы бары.
Ул шундый да назлы сагыш, җырларыма күчә бара.
Җәйләремнән көзләремә әлләни дә түгел ара.
Түгел, түгел... тик нигәдер күңел бик тиз сизә моны.
Кошлар тавышына күчә шул арада көзләр моңы.
Сезнең көзләр дә матурмы? Минем көзем – алтын сары.
Яшәүнең кадере арта, юыла да сагышлары.

***

Көзнең җимешләре татлы диләр,
Әйе, татлы сусыл алмалары.
Моңсулыгын яшерергә тели
Өзелмичә кышка калганнары.

Сагыш саркып торган кебек хәтта
Алмаларның кызгылт-сарысыннан.
Кеше язмышлары күренгәндәй
Өзелмәгән алма арасыннан.

## Саубуллашу

Тол[*] буена пар аккошлар төшкән –
Саубуллашыр өчен киткәндә.
Их, талмаса икән канатлары
Ерак юлны очып үткәндә.

Көч бирсәнә кошкайларга, җилем.
Каршы исмә, зинһар, уңай бул.
Туган якны ташлап китүләре
Болай да бит бигрәк авыр ул.

Аерылу бар... Кайту сөенече...
Үзгәртепләр булмый язмышны.
...Тол буена пар аккошлар төшкән,
Шул яңартты бүген сагышны.

***

Битемне яңгырга куйдым:
И, ява, ява, ява...
Шундый рәхәт, сөенүме,
Әйтерсең җанга дәва.

Шундый рәхәт, сизелми дә
Әллә яшь, әллә яңгыр?

Яшь катыш яңгыр булса да,
Бардыр, сихәте бардыр...

Сафлана җан, иркәләнә,
Чистара күңел көзгем.
Моңсулансам да, барыбер
Мин сине көттем, Көзем!

***

Юл читендә үскән кылганнарның
Нигә микән миңа моңы таныш?
Аңлый алмыйм, нинди серләре бар,
Ник алардан күчә миңа сагыш?

[*] Тол – елга исеме.

Чал башларын эссе җилләр тарый,
Сынагандай кеше язмышларын.
Язмыш та бит кайчак таный, ахры,
Егылды дип уйлап ялгышканын.

Иеләләр, әмма егылмыйлар...
Кылганнарга соклануым көчле.
Җил таратсын авыр уйларымны,
Башны чөйим әле алар төсле...

***

Кояш белән бергә тордым бүген...
Ашыктыммы сине күрергә?
Ашыктыммы әллә үкенмичә
Кул болгарга узган гомергә.
Якты көнгә рәхмәт, иртәләрнең
Һәр нурында назлы сөю бар.

Әллә күңел ашыктыра җанны,
Берни түгел аңа тыюлар.
Кичәге уй бүгенгегә бармый –
Өметлерәк бүген туганы.
Кояш белән бергә тордым әле,
Яратырга тизрәк дөньяны...

## Өмет

Өмет… Кайчак шундый якын да ул,
Кайчак бигрәк ерак күренә.
Ә кайвакыт сүндем-сүндем диеп,
Яшеренә йөрәк түренә.
Сүнми, ләкин көчен биреп тора
Күңел төшкән авыр чакларда.
Менә-менә туктыйм дигән мәлдә
Ярдәм итә тагын атларга.
Канатларым каерылган чакта,
Шифа табып, үзе дәвалый.
Йөрәгемә сүнмәс нурын сала –
Ансыз яшәү миңа ярамый...

## Дусларга

Йөзең нурлы дисез. Белмим, нигә?
Кояш, бәлки, туры баккандыр.
Тормышымның шушы мизгелендә
Җаным, бәлки, чәчәк аткандыр.

Эчемдәге нурым – тышымдадыр.
Тик балкышы сүнә күрмәсен.
Якты дөньяларда яшәгәндә,
Сөенечләр читтә йөрмәсен...

Мин бәхетле, күңелемнең нурын
Сезгә биреп, балкып яшәсәм.
Бәлки әле шуңа нурым арта –
Сөю белән тулы җан-касәм...

## Мин, уйланып, Сиңа карап торам

Мин, уйланып, Сиңа карап торам:
Чигәләрең инде ак көмеш.
Кай арада узган бу гомерләр,
Икебез дә инде карт, имеш...

Әле бәхет, әле михнәт күреп,
Тормыш таганында атындык...
Авырлыкны бергә җиңә-җиңә,
Җанга күчкән хәзер якынлык.

Үткән юл да шундый озын икән,
Күз салам да сагынып тагы бер.
Юл башында тойган назлы караш
Йөзебездә калган барыбер…

## Җиләк тәме

Беренчесен тәмләп кара,
Авыз ит дип, җиләк бирдең.
Кулларыңда җиләк булса,
Күзләреңдә – сөю күрдем.

Иренемдә – җиләк тәме,
Синең кулда – җиләк исе.
Күңелемә сеңеп калды,
Ул мәңге дә бетмәс төсле.

Белеп торам, онытмыйча
Хәтеремдә сакларымны...
...Сагынып куйдым үземнең
Җиләк кебек чакларымны.

***

Яр читендә үскән камышларның
Арасыннан салкын җил йөри.
Җил сәбәпме, ярда ялгыз учак
Бер сүрелә, тагын бер көйри.

Икәү яккан учак булгандыр ла...
Ялгыз калган сүнә башлагач.

Камышлыкта тына адашкан җил,
Эзләгәнен инде тапмагач.

Көзме моңсу? Әллә минме моңсу?
Шул соравым китми уемнан.
Мин генәме? ...Дөнья моңсулыгы
Яр буена төшеп сыенган...

## Үз-үземә

Башкаеңны кырын сал да
Горур басып атла әле!
Дөнья йөген калдырып тор,
Гел җигелеп тартма әле!
Җаның белән сөйләшкәндә,
Гел дә аны битәрләмә!
Җанның яратасы килә,
Риза бит ул көтәргә дә.

Җилгә каршы битең куеп,
Тирән итеп сулыш ал да,
Офыкларда көткән рәшә
Сөюдер ул... Куркып калма!
Башкаеңны өскә чөеп,
Күзләреңне үртә әле!
Ашыкмасын, көтсен бераз –
Соңгы җырга иртә әле...

## Соңгы танго

Кайдан килгән күңелемә бу бунтарьлык?
Һич аңларлык түгел аны алгысына.
Ник очынам болай һаман каударланып?
Биим сыман Пьяццолланың тангосына.

Нәрсә җитми көзләремә атлар өчен?
Югыйсә бит, тынычланып яшә генә.
Кисәк кенә дертләп куям, аңлар өчен
Туктап калам соңгы аккорд аһәңенә...

Соңгы ярсу, соңгы сөю. Соңгы... соңгы-ы-ы...
Ишетелә кайтавазы түзем генә.
Сары яфрак түшәлгән Көз аланында
Соңгы танго... Биючесе – үзем генә.

***

Йолдызларга карап, уйга калдым,
Мин киткәндә кайсы атылыр?
Яктысына әнә күзем төште —
Сайлау, бәлки, кеше хакыдыр.

Аның кебек якты яналдыммы,
Балкыдыммы җылы кирәктә?
Адашканга юл күрсәттем микән,
Өмет уты булып, бигрәк тә?

Миңа атап, җыр яздымы берәү,
Сөюенә түзә алмыйча?
Гөл булдыммы җирдә кемдер өчен,
Сүздә генә булып калмыйча?

Юк, ашыкмыйм! Яшим әле тагын,
Яктылыгым җитү икеле...
Гомеремдә атылганчы яныйм,
Үзем тапкан йолдыз шикелле.

## Һәр көне кадерле гомернең

Язларда ашкынып җырласа,
Күзләрдә моңая күңелем.
Шулай да туймый ул тормыштан,
Һәр көне кадерле гомернең.

Кадерле һәр мизгел, һәр минут,
Гомерем көзләре җиткәндә.
Артымнан уйнаклап җил йөри,
Калды дип яшьлегең үткәндә.

Каерылып эзләмим узганны,
Калса да, яшьлек бит исемдә.
Үз итәм яратып көзләрне,
Ямь табам алтынсу төсендә...

## Ак болытлар

Ак болытлар ага Туган якка,
Карашларым белән иярәм.
Әйтерсең лә алар риза түгел:
«Еш(ы)рак кайт үзең!..» – дияләр.

Кайталмадым, ешрак кайталмадым,
Әнкәй көткән чакта сагынып.
Җиңеләйде кебек хәзер җаным,
Мәшәкатьтән бераз арынып.

Җиңеллекме... Әллә бушлыкмы ул?
Туган якның җыры тулмагач.
Исән чакта еш(ы)рак кайт икән син,
Бер кайтырмын диеп уйлагач...

Ияртегез, зинһар, ак болытлар!
Туган якның сулыйм һавасын.
Бер кайтмасам бер кайтырмын диеп,
Кичегә шул адәм баласы...

## Сагыну төше

Төштә сине сирәк күрәм.
Тынычтыр дим шуңа җаның.
Ә бүген соң ник борчылып
Кердең әле, әни җаным?

Басып торабыз иртәдән,
Имеш, авыл читебездә.
Печән чапкан тауга карап,
Хафаланып икебез дә.

Хәтерең саклый, күрәсең,
Печән өстен... Авыр эшне...
Киң покослар кала иде,
Син чапканда ирләр төсле.

Бер-бер артлы басабыз да –
Ике покос була ишле.
Эше авыр, үзе рәхәт,
Печәне дә җиләк исле.

Ул чагында син бит миңа
Тоела идең шундый көчле.
Ә мин әле яшь-җилкенчәк,
Рәтен белми эшлим эшне.

Сиңа авыр булмасын дип,
Мин дә покосны киң алам.
Ә син сизеп, туктатасың,
«Ашыкмыйча эшлә, балам!..»

...Печән чапкан тау битендә
Ак каенлык инде үскән.
Синең чалгы тавышларың
Сагынуыма, әнә, күчкән.

Төшләремдә сагышланма,
Тыныч бул син минем өчен.
Оҗмахларда йөр син иснәп
Яңа чапкан печән исен...

Әлфис
Гаязов

# КАЙСЫ ЯКТАН ЧЫГА СОҢ БУ КОЯШ?

РОМАН

**46**

Казанлыда Салихны көтәләр. Бар да Хәмиткә киләләр, шунда киңәшләшеп, каршылау хәстәрен бүлешәләр. Киеменең озын итәкләренә бутала-бутала йөрүче Хәниф мулла, вакытлыча барысы белән дә дуслашкан Сәләхетдин, беркайчан да елмаймый торган Хәсән һәм тагын башкалар көне буе Хәмиттән чыкмыйлар. Йорт тулы кеше, йорт алдындагылар анда-монда йөгерә. Хәмит өченче кат бер үк хәбәрне җиткерә:

– Эше күптер инде Салихның, тиз генә кайтып җитә алмый бит! Кичә Ямашка килгәннәр дип әйтәләр иде, Алла бирсә, бүгеннән калмас дип уйлыйм, кайтыр!

Ул өстән генә җыелганнарга карый: куркып та, тетрәп-дерелдәп тә, калтырап та көткән кешенең улы булуы аны горурландыра, борынын чөймәсә дә, ару ук югарыга менәргә мөкинлек бирә.

Эчкә кереп баткан күзләрен йөгертеп, әллә нинди югары тавыш белән башкаларны үгетләгәндәй, Хәниф мулла сөйли:

– Кайтыр, бирсен Ходай, кайтыр! Көткәнгә озак күренә инде ул. Аллага шөкер, үзебезнең мөселман кешесе килә безгә.

Боларны сөйләсә дә, мулланың башында бөтенләй икенче уйлар, ул тагын үткән заманнар кире кайтуына шатлана, ә үткән елларда ул Казанлыда гына түгел, бөтен төбәктә билгеле, ихтирамлы муллаларның берсе иде бит.

– Ничек, ничек итеп каршы алабыз соң? – Әллә икенче, әллә өченче тапкыр сорый Хәсән.

– Җыен җыярга кирәк, без генә түгел, халык каршы алсын. Әйдәгез, үгезме, әллә башка эре малны суеп, дога укыйбыз. Кешеләрен өй борынча урнаштырыйк. Волость бинасында штаблары булыр. Шунда ял итсеннәр.

– Дөрес, дөрес! – дип шаулашып алдылар. – Син, Сәләхетдин, бик дөрес сүзләр әйттең.

Кемдер бу акыллы сүзләрне әйтергә зиһене җитмәгәнгә кайгырды, кемдер көнләште. Ничек кенә булмасын, карар кабул ителде. Тагын бер карар читкә китмәде – килгән атлыларны күз дә каш карап тору өчен яшь егетләрне волость бинасы түбәсенә менгереп җибәрделәр.

Халык шунда гына таралды.

---

*Ахыры. Башы 7, 8 нче саннарда.*

* * *

Соры көнне караңгы кич белән тоташтырып, җиргә томан сыланды. Җәй төсен югалткан кояш акрын гына күк читендәге болытларга кереп адашты, ысылдап, шул яклардан салкын җил исте. Бары тик авыл башында үскән өянке һәм, бер тамырдан чыгып, болытларга барып тоташкан тупыл агачы гына, усал җилгә җавап итеп, яфраксыз ботакларын ялкау гына кыймылдаттылар. Әйтерсең лә югарыда – өстә бары тик аларга гына билгеле булган, аларга гына аңлаешлы тормыш бар, һәм ул тормыш алар өчен генә, башкалардан биеклеге белән өстенлек алган өянке һәм өч кәүсәле тупыл өчен генә корылган.

Тик алар да кайчак зәһәр җилләрдә шыгырдап, сыкрап елыйлар. Әллә шул чакта алар кешеләрнең ыгы-зыгыда узган тормышына көнләшәләрме, әллә үзләренең әче ялгызлыгына зарланалармы, әллә якынлашып килгән картлыкка кайгыралармы, әллә йөз еллар эчендә калган яшьлекләрен сагыналармы? Кем белә! Кешеләр дә аңлый: биеклек аларга озын гомер бирми, бары тик утлы яшен белән очрашуны гына якынайта. Шундый көенечле чакларында аларга карау сагышлы да, хәсрәтле дә, моңсу да, шул чакта аларның хәсрәте кешеләргә күчкәндәй, кешеләрнең дә аларныкы кебек киң иңбашлары бөгелеп, сыгылып төшә, күзләрендә иге-чиге булмаган хәсрәт чагыла, тавышларында алда көткән картлыктанмы, тормыш авырлыгыннанмы шыгырдау уяна кебек...

Көзге озын, караңгы кич килеп җитте.

Кинәт Чия тау башындагы Каенлык ягыннан ату тавышлары яңгырады. Биектән, йокыга талып барган авыл өстеннән, сызгырып, пулялар очып үтте. Килүчеләрне волость бинасы түбәсеннән карап торырга менгән яшьләр тәгәрәп диярлек җиргә төштеләр.

Ату тавышлары көчәйде.

Нигә кирәк бу ату, кемгә аталар, кемне куркытырга телиләр? Базга төшеп качкан кешеләр аптырады.

Атлыларның кычкырганы, ай-һайлавы ишетелде.

Һәр өйдә, сакланып, тирә-якка карый-карый, бар белгәннәрен исләренә төшереп, дога укыдылар. Тәрәзәләргә үрелгән саксыз балаларның йомшак җиренә күпме җәза төшкәндер бу кичтә...

Атлылар авылга якынлашты.

Авылдагылар, куркып, котлары очып, күкләрне онытып, аларның чабып килүләрен күзәттеләр. Күкләр кайгысы юк иде аларда бу мизгелдә.

Авылга килеп керергә чак кына калды.

Казанлының, башка авылларда яшәүчеләрнең котын алу өчен Салих, авылга кергәндә, берничә залп бирергә боерды. Алда матур озын ял булачагын сизгән солдатлар моны бик тырышып үтәделәр.

Салих бу тамашадан бик канәгать булды. Алда ата йорты, күпмедер ял, үзен зур түрә итеп тою хисе, шулай ук аның кулында гына булган зур власть тойгысы дулкынландыра, исертә, шаштыра иде.

Атлылар авылга очып килеп керделәр.

## 47

Яланга тәмле ылыс исе таратып, үләнгә төтен сылана, күзләрне кытыклый. Учак тирәсендә акрын гына сөйләшеп утырган кешеләр янында бәйләп куелган атлар башларын чайкый, саргайган үләннәрне өзеп ашарга

тырыша. Болытлар артындагы кояш йокларга әзерләнә, җиргә караңгы төшү вакыты якынаю кешеләрне дә йокы турында уйларга мәҗбүр итә. Кайчакта болытлар арасыннан кояш нурлары күренеп кала, алар, җиргә тиклем төшеп, иртәгә көн яңгырлы булчагына ишарә итә.

Ильяс вакыт-вакыт учакка вак утыннар ташлый, күккә күтәрелгән очкыннарны карашлары белән сүнгәнче озатып кала. Сугыш ярасы сулкылдап авыртып ала, ашказаны да бу вакытта кичке аш ашау гадәте барлыгын искә төшерә.

Казанлыдан киткәнгә инде ун көн булып килә, Салих аларга каршы чыгарга уйламый да. Шул турыда сөйләшергә, алдагы көннәргә планнар корырга ул Шакирны чакырып алды.

– Бездә мәгълүмат аз, Салихның планнарын белмибез, значитца. Шуннан, Щучье Озеро тирәсендә кызыл отряд аклар белән сугыша. Кемнәр алар? Соңгы вакытта адым саен очрый торган башкисәрләр шайкасымы? Командирлары кем? Нинди партия платформасында? Кешеләрне бер дә юкка сугышка ташлыйсым килми, значитца. Ике кешене разведкага җибәрик. Берсе безнеңчә сөйләшсен, икенчесе – русча.

– Бар андый кешеләр. Алып килермен.

– Значитца, бүгенгә бездә алтмыш бер кеше, авылларда тагын шул тирә бар. Тик кешеләр кайтырга сорый башладылар. Ун көн эшсез урманда яту берсен дә кызыксындырмый. Салихта яхшы коралланган илле кеше. Безнең бәрелешү ни белән тәмамланыры шар ачык. Нигә ул һөҗүм итми, нәрсә көтә ул?

Шакир бер сүз дә әйтми утыра бирде. Ильяс уйлаганын сөйли бара. Әллә үз алдына, әллә Шакир берәр яңа сүз әйтмәсме дип шул уйлаганнарын аңа җиткерәме – моны аңлавы кыен иде.

– Мин нишләр идем Салих урынында, значитца? Иң башта ул килеп кергән шартларга карыйк, ди. Авыл, ул монда туса да, аңа инде таныш түгел. Значитца, бик куркып бармаса да, саклана, урмандагы һәрбер төп башы бүре булып күренә. Авыл кешеләрен, аларның гаярьлеген дә яхшы белә. Авылның һәрбер почмагы – монда яшәгәннәр өчен, кирәк булса, окоптан да уңайлырак каршы тору урыны. Степан отрядының сыйфат ягыннан бәясе сукыр бер тиен, моны ул яхшы аңлый. Шуннан, ул авылда яңа властьның күпме кешесе яшеренеп ятканын да белми бит әле. Значитца, шуңа ул тими тора әлегә безгә. Мондагы хәлләр буенча мәгълүмат җыя, йомшак якларны эзли.

Шакир үзенең фикерен белдерде:

– Мәгълүмат кирәк, монысы дөрес. Ә барлыгы аның өч йөзгә якын солдаты бар. Илле кешесе монда, калганын да станцияләр, разъездлар буйлап бүләргә мәҗбүр. Дезертирлар да аз түгел. Болары – аның йомшак урыннары. Безнең иң йомшак урын – корал җитмәү. Булган корал белән без чыпчык та ата алмыйбыз!

Ильяс учактагы күмергә әйләнгән утынга суккалады. Шунда ук очкыннар һавага күтәрелеп китеп, яланга төшә башлаган томанга кереп югалдылар.

– Минемчә, ул безне урманнан яланга тартып чыгарырга тырыша. Яланга чыксак, аның кораллы солдатларына безне кыйратып ташлау берни түгел. Шуңа утырабыз әлегә монда.

– Мин дә бу турыда гел уйлыйм. Ул салкыннар төшкәнен көтми микән? Боз туңгач, тукмай ягыннан монда тиклем кереп була бит?

– Анысы да бар.

– Димәк, нидер эшләргә кирәк, тик Салихтан алдарак!

– Шуңа ярдәм эзләп йөреп кайтырга кирәк булыр.

– Аңлашылды!

– Шакир, значитца, безнекеләрнең рөхсәтсез китүен туктатырга кирәк. Күпләр төнен авылга кайталар, беләбез. Бу бик начар тәмамланачак. Кемнедер эләктерәчәкләр, значитца, кемнедер харап итәчәкләр. Салих усал, белемле кеше, безнең йомшак якларны да алар аша алырга тырышачак.

Торымбашлар шартлап яна башлады. Шакир урыныннан торыр алдыннан аякларын уыштырып алды.

– Аңладым. Халык белән сөйләшербез. Ә разведкага миңа үземә барырга кирәктер. Бу – бик катлаулы йөкләмә. Иптәшкә кемне алырга – уйлармын, иртән чыгып та китәрбез. Дөрес әйтәсең, ул рус егете булырга тиеш, авыллар төрле, кайчакта бөтенләе белән үз кешесенә әйләнергә кирәк булыр. Монысын инде мин халыкның бик сак булуын күз уңында тотып әйтүем.

– Ярар, уйла, алайса. Значитца, иртә белән чыгарга кирәк юлга.

Ильяс Шакирны якында тотарга тырышты. Ул – иң ышанычлы кешеләрнең берсе, авылныкыларны бик яхшы белә, һәрвакыт, һәртөрле хәлләрдә иң дөрес юлны эзләп таба. Әгәр ул эшкә тотынса, көт тә тор, эшне югары сыйфатлы итеп аткарып чыга. Әнә бит, армияның «а» хәрефен дә белмәгән кешеләрдән ару гына сугышчылар ясап ята. Бик авыр булса да, ризалашты ул Шакир белән.

Кыза барган учак эссесен чиләктәге кайнарга куелган су да сизде, төрле тавышлар чыгарып җырлый торгач кайнап та чыкты. Карлыган ботаклары салынган чәй исе бөтен яланга таралды, бар үткән-сүткәне сәбәп табып, монда туктый башлады. Иң беренче булып Әхтәм килеп җитте, Ильяс, аның яшен игътибарга алып, үзенең ярдәмчесе итеп куйды. Әхтәм бу вазифаны зур тырышлык белән үти, кушканны да көтеп тормый – эшкә чума, Ильясның эшен җиңеләйтергә тырыша. Аның беренче соравы да шул теләктән иде:

– Ильяс абый, дозорларны алыштырырга вакыт!

– Вакыт! Бар, Шакир абыеңның исенә төшер.

Әхтәм баскан урынында борылып йөгереп китеп өлгермәде, өч кеше ияртеп килгән Шакирны күрде.

– И, соңладым! Әнә, алар китеп тә баралар инде!

– Бик әйбәт, әйдә, син утыр, чәй эч!

Кайнар карлыган чәе бу салкында бик әйбәт үтә торган булып чыкты. Партизаннар эчтән дә, тыштан да кулларны да җылыта дип көлде.

– Әхтәм, иртәгә сиңа разведкага барырга туры килер.

– Кая барырга, Ильяс абый?

– Ерак түгел, Кызыл Ярга. Анда беркемгә дә күренмичә, Фәрхулла абыеңны табасың: «Күтәрелү сәгатен алдан хәбәр итәрбез, әзерләнә башлагыз», – дип әйтәсең. Казанлыда базарга кереп, кеше ни сөйләгәнен тыңлыйсың, нинди яңалыклар бар, шуны ишетәсең. Шуннан бирегә кайтасың. Тик Галләм бабаң әйткәндәй, ысматри-матри, бер эшкә дә, бер сүзгә дә тыгылмыйсың. Син безгә исән-сау кирәк! Кирттеңме колагыңа?

– Кирттем, кирттем! Колагым өзелеп төшә язды! Кайчан?

– Иртәгә. Значитца, син бар, өйгә кереп ял ит!

Әхтәм аны ишетми утыруын белде. Аның йөзендә учакның кызыл яктысы уйный, ачык күзләрендә дә очкын чаткылары чагылып ала.

– Әллә йоклап та киттең инде, Әхтәм?

Егет сүз таба алмый туктап калды, тиз генә бу хәлдән чыгарга ашыкты:

– Юк, йоклый ди!

– Кемне болай искә аласың? Бөтенләй онытылып киттең бит!

Бу сораулардан Әхтәм кызарды. Чынлап та, үткән барганда Казанлыда ул Сәрияне очрату бәхетенә иреште. Сокланып карап туя алмады ул аның озын кара чәчләренә, җырда җырланган кебек кыйгач кашларына, күзләренә! Әхтәм, аның белән сөйләшкәндә, тавышының шундый җылы булуын йөрәге белән сизде, ул бу тавышны нәрсә белән чагыштырырга гына белмәде. Чишмә чылтыравы дип әйтү аз булыр, сандугач сайравы белән тиңләшерлек тавыш иде бу. Күреп булмасмы икән аны иртәгә? Менә нинди сорау аны борчый иде. Аһ, бу унҗиде яшьләр, унҗиде яшьләр...

Сизде микән Ильяс каушаганны, күрде микән биттәге кызыллыкны? Юктыр, ахры. Ә Ильясның ниндидер җылы сүз әйтәсе килде бу балага. Икенче тапкыр аны разведкага җибәрә, икесендә дә, дулкынланып, аны көтә. Әхтәм үзе дә бик тиз эшли торган, җитез егет булып чыкты.

– Значитца, син бар, кереп ят, йокла әйбәт итеп, яме. Иртәгә атларга да атларга. Уф Аллам, киемең дә ни әйтерсең, этәч тиресеннән.

– Ә мин бит йөгереп йөрим, Ильяс абый! Өшергә өлгерә алмый калам!

– Шулайдыр, шулайдыр...

Әхтәм, теләр-теләмәс кенә, Томафиның урман өенә кереп китте. Ильяс учакка утын ташлады, бүреген батырып киеп, күпне күргән шинелен каеш белән кысып буып куйды.

– Солдатларга гына түгел, командирларга да салкын икән! – Учакка Мирон Акимович якынлаша иде.

– Бу әлегә салкын түгел, салкынның баласы гына! Алда ничек булыр? Әйдә, чәй эчеп җибәр, җылынырсың!

– Рәхмәт. Көне буе чәй, инде күрәсе дә килми аны. – Мирон, итәкләрен җыеп, шунда яткан утын түмәренә утырды. – Сөйләшәсе бар. Кичә дозордан соң мин тиз генә авылга кайтып килдем.

Ильяс кузгалып куйды.

– Юк-юк! Барысы да әйбәт! Беркем күрмәде, ике сәгать булдыммы-юкмы. Менә нәрсәләр ишеттем. Степан отрядның санын арттыра.

– Күпме инде отрядта?

– Иллеләп. Халык килә, йөздән артыр якын арада. Беренче Аскын полкы дип атаганнар. Командирлары Аркаша Дедухин. Корал турында сүз бара, Степан Дружининога барып йөргән. Штаблары мәктәптә, аннан укытучы Коноваловны тукмап куып чыгарганнар. Бөтен җилкуар, карак, башкисәр аңарда. Дедухинга ярдәмгә булачак киявен – Савелий Чуровны биргән.

– Нина кияүгә чыгамыни? – Ильяс Гәрәйнең хыялларын белә иде.

– Чыгадырмы, юкмы, Степан Савканы үзенә якынайтырга тырыша. Ладно, монысы ничек булыр, Алла гына белә. Степан кешеләре безнең хатыннарга яный башлаган – кайда ирләрегез дип. Менә бусы куркыныч!

– Монысы, чыннан да, начар хәбәр. – Ильясның йөзенә болыт

төште. – Салих белән очрашмаганмы Степан? Татулашырлармы алар? Салихка барыбер, ә менә Степанга...

– Степанмы? Кая барсын ул? Татулашырлар! Тик татулашу – бер эш, ә менә гафу итү... Монысы булмас!

Ильясның уйлары бу сүзләрне дәвам итте.

– Значитца, әгәр алар килешсәләр, бергәләп безгә каршы чыгачаклар. Монысы да бик начар эш.

– Аларның коралы юк! Сәнәк беләнме?

– Сәнәк белән дә бик хәвефле инде шул тиклем кеше.

Мирон урыныннан торды.

– Значитца, Мирон Акимович, син башка кайтып йөрмә авылга әлегә. Степанның бар эшләре дә шома гына бармыйдыр. Аркашаны мин беләм, бергә үстек. Бик усал кеше. Тотып алсалар, бернинди сүз үтмәячәк.

Мирон бераз дәшми торды да ниндидер эчке тавыш белән җавап бирде:

– Рәхмәт, Ильяс, бу сүзләреңә. Кайтмый торырмын. Саграк та булырмын, Бирсен Ходай!

**48**

Партизаннарны юк итү уе Салихның бөтен барлыгын яулап алды. Урыннары да билгеле, якын да, тик берничек тә аларга якын барырлык түгел. Бер яктан ат түгел, кеше дә үтә алмаслык Тукмай сазлыгы булса, икенче яктан – сугыш стратегиясе ягыннан урыннары бик җайлы. Тагын да бит аларны халык үз итә, аларның ярдәменнән башка урманда яшәрлек түгел. Әйе, берничек тә якын килерлек түгел шул. Башка төрле булырга тиеш бу төенне чишү, башка төрле... Хәйлә белән алдырырга. Тик нинди хәйлә?

Шул чакта Салихның инде бөтенләй үк юлбасарлар өеренә әйләнгән банданың башлыгы наганлы Сафа мулла исенә төште. Ул иярченнәре белән кеше талап көн күрә, аның өчен кеше гомере берни түгел, станциядән кайтучылар аның табышына әверелде. Менә кем кирәк Салихка, менә кем киңәш бирә алыр. Шунда ук ул Сафа янына солдатларын җибәрде, табып алып килергә боерды.

Кичкә табан таптылар Сафаны, чакырып алып та килделәр. Ару гына курыккан наганлы мулла үзе белән баштанаяк коралланган юлбасарларын да алды – бусы инде «Сакланганны саклармын!» дигән уйдан. Юл буе догасын укыды, ул-бу була калса, чыгып ычкынырлык юлларны барлады.

Күрештеләр, исәнләштеләр, Салихның штабындагы кешеләрнең тәртибендә бернинди куркыныч күрмәде Сафа. Салих та бик табигый төсле, исәнләшкәч тә, йомышына күчте.

– Күп сүз китапка яхшы диләрме әле? Киңәш кирәк, Сафа абзый. Иншалла, эшләребез әйбәт бара, озакламый котылабыз бу партизаннардан. Алла бирсә, эзләрен дә калдырмыйбыз бу адәм актыкларының. Тик менә Ильясның юлбасарлары Тукмайда качып яталар. Урыннары шул тиклем уңайлы, бер яктан да якын килерлек түгел. Җитмәсә, Каюм мәгарәсе шунда, анда кереп китсәләр, табарлык түгел.

Сафа шунда ук Салихның сүзен бүлдерде:

– Һе, керсеннәр ни тагын шунда! Алар керү белән шартлатырга кирәк. Кһем-кһем! Менә сиңа вәссәлам! – Сафа сакалын сыпырды.

– Аны гына аңлыйлар шул алар, кара мужик булсалар да. Икенче юл

кирәк! Сафа абзый, синең тәҗрибә зур, бир шул киңәшне. Яхшылык онытылмый, беләсең. Шуннан, мин монда бик күп нәрсәгә күзне йомам.

Соңгы сүзләрне нәрсәгә ишарә икәнен икесе дә бик яхшы аңлыйлар, тик игътибар итмәгәнгә салыштылар. Сафаның оятсызлыгы йөзенә чыккан, ул шушы бик уңай булмаган мәлдә дә үз фикерен алга сөрде:

– Кһем-кһем! Без дә бик авыр хәлдәбез, туган! Минем егетләр синең солдатлардан бер дә калышмыйлар, ыжгырып торалар. Тик бар инде бездә дә чишелмәгән мәсьәләләр. Бар шул! Мин бик рәхмәтле булыр идем, ярдәм итсәң.

– Синдә дә бармы чишелмәгән мәсьәләләр? Булмас, Сафа абзый! Син дә шулай сөйләп торгач, башкаларга нишләргә кирәк инде?

– Кем уйласын, Салих туган, башкаларны? Минем үземнеке үземә җиткән, кеше кайгысы юк. Сугыш бара бит, тик кенә утырып булмый, кем, Салих туган. Кһем!

Мулладан чын шайтанга әйләнгән юлбасар! Белеп торалар бит нинди байлыкта йөзгәнен. Ә ничек кылана, хәерче булып күренергә тырыша. Талаудан соң бер кешене дә исән калдырмый торган бүре өере башлыгы бит бу. Тик бүгенгә ул кирәк, тыңлап карыйк, ни җырлар?

Бу уйлар яшен тизлегендә Салихның башыннан үтеп китте. Корал сорар инде, шул. Монысы, әйтмәсә дә, билгеле.

– Әгәр мин ярдәм итәрлек мәсьәлә икән, нигә, мин ярдәм кулын сузарга әзер, Сафа абзый. Бер эшне эшлибез, бу сугышта без бер яктабыз.

– Тиле-миле сугышта, кһем-кһем. Әстәгъфирулла тәүбә! Сугыш дошман белән, үз туганың белән түгел!

Салих көлеп җибәрде.

– Кара әле, Сафа абзый! Син бит большевиклар кебек сөйли башладың!

– Бәлшәүикләрне, беләсең, якын да китермим! Тик... тик дин дә, әдәп тә өнәп бетерми торган эш башладык, туган. Монысы хак! Ахырзаман җитә, Алла сакласын!

– Барыбер синең кебек әфисәр кеше сүзе түгел инде бу, Сафа абзый!

Сафаның саргайган күзләрендә очкыннар кабынып китте.

– Мин бит башкалар кебек укып алмадым әфисәрне! Нимесләр, газ җибәреп, фронтны кыса башлагач, безнекеләр куркышып тарала башлады. Кһем-кһем! – Дулкынлану ярамый Сафага, монысы күренеп тора, ул тагын буылып ютәлләп алды. Шул газның әле дә үтмәгән, бәлки, мәңге үтмәячәк бәласе инде аның бу ютәле. – Шунда аларны туктатып, алгы сызыкны кабат үзебезгә кайтара алдым. Шунда ук әфисәрне биреп ташладылар. Шулай булгач, мин – окоп әфисәре, парадтан парадка йөргән гарнизон күсесе түгел!

Салих йомшак кына итеп үз сүзен кыстырды:

– Ул күсе дип мине атамыйсыңдыр бит?

– Юк-юк, туган! Юк! Әфисәрнең ниндие дә кирәк замандабыз. Ачуланма, күсенең кем икәнен яхшы беләбез син дә, мин дә! Менә мин шул сугышта кулланган ярман хлорыннан бетмәс ютәл вә сары күзләр генә алып чыктым. Ә ул күселәр... – Сафа сөйләп тормады, кулын гына селтәде. – Йә, ярый, исән булсыннар, әйдә. Ходай барысын да күрә ул!

Аңламассың моны. Ничек сөйли! Көндез мендәрдә дога кылып утыра, төнлә – бар уе, бар эше ерткычлыкта. Бөтен очракта да судан коры чыкмакчы.

– Менә элекке дөньяны торгызабыз, Алла боерса, кабаттан. Шуннан сугыш та туктар.

Курка, курка Сафа закон нигезендә эшләгән дәүләттән! Менә нәрсәдән коты оча! Сафа тагын үзенең әллә кайда яшерелгән хәйләкәрлеген күрсәтте.

– Ярар, түрәләр беләләрдер инде.

– Сафа абзый, сәясәткә бик тирән кереп киттек. Мин үземнең йомышыма синең акыллы киңәшеңне, җавапны көтәм. Нишлибез Ильяс белән?

Шайтанның да шайтаны! Үз туксаны туксан, ә! Тик бу юлы да чишелмәде наганлы мулла, Салихны ишетмәгәндәй, үз туксанын алга сөрде.

– Кем, әфәндем, корал кирәк безгә. Патроннар аз. Ярдәмгә – ярдәм! Гранаталар булса шәп булыр иде. Рәсәйне сакларга, якларга чыктык, ә кулда – сәнәк, балта, искереп беткән сунар мылтыклары.

Анысы бар инде. Каян алсыннар, ди, шушы шайтан бозаулаган тискәре якта әйбәт винтовканы?

– Аңлыйм. Ярдәм итә алам. Күпмерәк инде?

– Иң аз дигәндә, унбиш винтовка. Берничә мең патрон, бер-ике әрҗә граната.

Салихка боларны табу берни дә тормый торуын. Тик бу җирлектә аның батальоны белән янәшәдә яхшы коралланган тагын бер гаскәр булуы бер дә шатландырмый, аның планнарына да керми иде.

– Болай ук булмас. Яртысы. Җиде... Әйдә, ун Мосин винтовкасы, мең патрон, ун граната. Чернушкадан үзегез барып алыгыз. Миннән – каптенармуска, цейхгауз хуҗасына – боерык, сездән – аны майлау-җайлау.

– Авызыңа бал да май, Салих туган. Иншалла, болай булгач, безнең эшләр алга китәр. Сүз болайга борылгач, Салих туган, синнән кош теледәй язу да кирәктер теге каптенармуска.

Салих, өстәлдә яткан кәгазьләрдән бер кисәк ертып алып, нидер язды да аны Сафага сузды.

Сафа, зур гәүдәсе белән алга иелеп, кулын сузып, язуны эләктерде. Әллә инде җавапсыз гына чыгып китәргә тора башлады инде урыныннан шайтан? Салихның бу уйларын сизгәндәй, Сафа сүзен дәвам итте:

– Синең мәшәкатькә бер генә ярдәм – Ильясның бичәсен тотып ябарга. Әманәт итеп.

Салих аптырап калды.

– Ә нигә аптырыйсың? Әманәтлек безнең тарихта булган хәл, ул болганышларны туктата торган бердәнбер вә иң уңай ысул.

Салих үз уенда.

– Ул... ул бит.. теге... соңгы айларда дип ишеттем. Баласы туа калса, нишләрбез?

Сафа усал итеп көлде.

– Әйе инде, без – изге кешеләр. Кулларыбыз таза. Кеше каны белән буялмаган. Гөнаһы читтә торсын. – Сафаның болай да усал йөзе җитдиләнде. – Син – хәрби кеше! Хәрбилек барысыннан да азат итә. Әнә, Мөхәммәт пәйгамбәр, саллаллаһу галәйһи вәсәллам, кирәк чакта үзе сугышка чыккан, башкаларга баш булып. Димәк, сугышта сугыштагы кебек!

– Сафа абзый, ичмасам, син мине оялтырга маташма! Кызарырлык бит очы да юк инде бездә! Син бит белмисең минем кайларда йөргәнне, ниләр кылганны... Әллә кайда, читләр белән эш иткәндә, боерык үтәү – бер эш, ә

туган ягыңда, үз кавемеңдә кыргыйлану – икенче эш... – Ни сөйләгәнен аңлап, Салих сискәнеп китте. Төлкедәй хәйләкәр Сафа да тиз генә сүзне читкә борды.

– Ю-юк, туган! Кһем... Гафу ит! Минем әйтүем генә, ә карар синең кулда. – Сафа бер мизгелгә тукталып калды. – Ә нигә аның бер үзен генә ябарга ди әле? Куш тагын бер-ике хатынны. Берсен-берсе карарлар.

Салихның бер кашы югарыга сикерде. Вәт, шайтанның да шайтаны, ә! Дөрес уйлый бит! Тик ул карар кабул итүдә Сафа сүзләрен өстә калдырырга теләмәде.

– Ярар, карарбыз тагы.

– Киләчәк ул, киләчәк бичәсен азат итәргә. Кһем... Тик менә ничек итеп килер? Ачыктан-ачык һөҗүм итәргә базнат итмәс, коралы да юкка тиң, тәҗрибәсе дә юк. Димәк, вак төркемнәр оештырачак. Минем уемча, игътибарны җәлеп итү өчен, бүлдерү өчен нидер эшләячәк. Шул арада тоткыннарны азат итәчәк. Кһем...

Салих көлмичә булдыра алмады.

– Сафа абзый, син бит бөтенләй Кутузов кебек сөйли башладың! Эх, минем батальонда синең кебек дөрес уйлаучылар булса иде ул! Ярар. Рәхмәт, боларын гына уйларбыз инде!

Сафа, озын аякларын кузгатып, чак өстәлне әйләндереп җибәрмәде.

– Кһем... Тагын бер киңәшем бар. Монысы да алтын. Тагын ун винтовкалык булыр монысы.

– Сатулашмыйм. Карап карарбыз. Рәхим ит!

– Матусов тегермәннәре янына кайчан барганың бар?

– О-о, малай чакта су керергә төшкәч микән? Әллә Оренбургта укыганда, ялга кайткачмы?

– Кһем... Димәк, беләсең буаны.

– Соң?

– Ярар, җәфаламыйм. Буа Томафи яланыннан өстәрәк. Димәк...

Салихның исенә келт итеп стратегия һәм тактика фәннәре килеп төште. Укымаган, ә нинди төпле, булдыклы киңәш бирә Сафа! Тагын бер сорау туды Салихта:

– Ә Казанлыны басып китсә?

– Кһем-кһем... Казанлыны соңгы тапкыр Туфан суы гына баскан, бер дә курыкма!

– Суворов! Чын Суворов син, Сафа ага! – Салих, каләмен карага манып алып, тагын бер хат кисәге язды да Сафага тоттырды.

Тиз генә дога кылып, Сафа чыгарга атлады. Ә ишеккә җиткәч, кабат борылды:

– Кһем... Минемчә, буадан алдарак хатынын ябып куярга, аннан соң гына буаны ерырга кирәктер. Салих бичәсен азат итәргә килгәндә. Томафида калган төркемдә командир юк, ыгы-зыгы, паника, салкын. Күзен дә ачмаган песи балалары кебек барысы да суда тончыгалар!

Сафа бу сүзләренең артык икәнен аңлап, туктаган урынында зыр итеп әйләнеп, бусаганы атлады. Аның авыз эченнән мыгырдаганы үз алдынамы, Салих өченме икәнен аңларлык түгел иде:

– Уйлагыз, уйлагыз, туган. Без нәрсә, без – гади җир корты, безнең эш – җир сөрү дә чәчү. Ә сез менә – дөнья тоткалары. Аллаһ үзенең ярдәменнән калдырмасын.

Һәркем үз уенда иде бу мизгелдә.

Атларыннан да төшми Сафаны көтеп торган кешеләр аңа, йөгертеп китереп, тезгенне тоттырдылар. Ашыкмыйча, үз бәясен белеп кенә атланды атына Сафа, алга чыккан ярдәмчесенә теш арасыннан ярты җөмлә сүз әйтте:

– Мартыш тегерменәнә!

Уйлаганча барып чыкса, корал булачак! Корал бар – власть бар, корал бар – син хаклы, корал бар – син көчле. Бу хакыйкатьне әле беркем дә инкарь итә алмаган. Ул каптенармус дигәннәрен азрак кына түгел, күбрәк майласак, бәлки, санын тагын да арттырып булыр коралның? Законлысы – егерме, тагын бер егермене, ә? Бармыни коралның исәбе-хисабы бүген? Хәзер уйлашырбыз тегермәндә. Тагын бер уй миен тишеп үтте Сафаның. Ул коралны бит сатарга да була! Исәбе булмагач, чыннан да, хисабы да юк инде аның!

Зур волость бинасында берүзе утырган Салих та булып үткән сөйләшүнең кайбер урыннарын тагын бер кат барлап чыкты. Ике тәкъдиме дә дөрес. Тик бүгеннән Сәлимәне ябып кую дөрес түгел. Бердән, үзеңә мәшәкать, икенчедән, Салих әлегә әзер түгел. Кульминация килеп җитмәде, менә нәрсә! Шуннан, «җир корты», имеш. Булыр, булыр җир корты! Бүген бу бәндә ни Аллага, ни муллага ярый торган түгел, булганы бер юлбасар. Тик кирәк шул әлегә андый адәм актыклары да, кирәк шул. Дөнья тынычлангач, авылның һәр каены саен асып куярбыз да ул мондыйларны. Тик – иртә, әлегә кирәк алар. Корал – корал җәл түгел, аның саны юк бүген. Әйе, бүген коралның хакы – сукыр бер тиен... Хәер, бүген кешенеке дә...

Ничек кенә булмасын, Салих бу карт төлке – төлке түгел, бүре белән киңәшләшүенә бик шат иде.

**49**

Ризван бик сак кына йөрергә тырышса да, булмады. Ул авылдан чыкканда ук, үзе артыннан ияргән ике кешене күрде һәм аларның кем икәнен, аларны кайда күргәне барын исенә төшерергә тырышып, башын ватты. Бик якынаймыйлар да, артта да калмыйлар, акрын гына Ризван артыннан баралар, бусы инде аларның махсус бу эшкә алынуы турында сөйли. Берничә уй үтеп китте Ризван башыннан. Аның кебек мәргән атучыга бу икенең берсен бәреп төшерү берни түгел. Ә икенчесе атканны көтеп тормый килгән юлыннан артка табан шылачагына ул ышана иде. Тик ул вакытта ул аларның ниятләрен белми калачак. Кем белә, алданиләр көтә аны, бигрәк тә ашлык төягән барканы кайда саклап торалар? Ул ашлыкны кешегә сиздерми генә төяргә тырышсалар да, ун атлык олауны кеше күзеннән ничек яшерәсең? Барыбер төялгән барканың чыгып китүен күрделәр, ул турыда хәбәр таралды. Арттан килгән кешеләрнең Сафаныкылар булуына Ризван шикләнми иде. Болар инде барып чыккан башкисәрләр, алар өчен кешене талап-үтереп китү берни түгел. Аларның уй-фикерләрен алдан ук сизәргә кирәк, нинди дә исәп кирәк болардан котылырга, тик нинди? Бара торгач, буталган фикерләр аның башында бер җайга килә башлады.

Рус гранын үткәч тә, ул, уңга борылып, Чәчрәтке болыннарына кереп китте. Бу җирләрне ул яттан белә, тар гына юлның, Танып елгасының һәрбер борылышын ничә мәртәбә үткәндер, моның саны юк. Алда яткан кичүнең дә үзенчәлекләрен белә: ул гына белгән билгеләрдән читкә тайпылсаң,

чоңгылга төшеп китәсеңне көт тә тор. Батуын батмассың да, ат алып чыга ул кешене, тик мондый салкында муеннан бозлы суга манчылу җиңел эш түгел.

Кичүгә килеп керү белән Ризван ияргә менеп басты. Атны өйрәтәсе юк, ул шунда ук, тояклары белән капшап, каты юлдан язмый, каршы якка чыгып та җитте. Ризван аны эчкәрәк кертеп бәйләп куйды да кичүгә кайтты. Исәп бер: елганың яртысын үткәч, иярдә утырып килгән бу юньсезләрнең атларын куркытып, кичүнең төп юлыннан читкә тайпылдыру. Бу очракта алар муеннан суга батачаклар, аларда кеше кайгысы югала, икесен дә агачка бәйләп куеп, ниятләрен белергә. Атларны куркыту өчен бер ату кирәк булачак.

Шулай килеп тә чыкты. Ризванны күздән югалтудан куркып, болар чабып килгән килеш кичүгә ташландылар. Су атларның корсагына килеп җиткәч, алар, аякларын өзәңгеләрдән ычкындырып, югары күтәрделәр. Елганың яртысын үтүгә, гөрселдәп, ату тавышы яңгырады. Атлар да, кешеләр дә моны көтмәгән иде: беренчеләре, читкә сикереп, аяк астындагы катыны югалтып йөзә башладылар, икенчеләре, өзәңгеләрдән ычкынган аякларын күтәреп, суга егылып төшеп, тезгеннәрдә асылынып калдылар. Ризван тын гына көлеп куйды, шул арада атлар, җайдакларын сөйрәп, ярга килеп тә җиттеләр. Бер мизгел кирәк булды Ризванга алдан әзерләгән бау белән котлары очкан бу мескеннәрне чорнап алырга, атларны бәйләп куярга. Шунда ук ул сорауларын яудыра да башлады:

– Кем сез? Нигә минем арттан күзәтәсез? Ниятләрегез нинди? Дөрес җавап бирмәсәгез, икегезне дә суга батырам!

Чыннан да котлары очкан бу икәү берсен-берсе бүлдереп сөйли дә башлады. Бер караганда, гади авыл кешеләре, Чүпрәледән Сафаның боерыгы буенча ашлык артыннан күзәтергә җибәрелгән булып чыктылар. Ризванның нинди йомыш белән йөрүен кем аша белгәннәрдер, монысы билгесез калды. Боларга куелган бурыч – ашлыкны кая хәтле алып баруны белү, бу яклардан ерак та китмичә, баркадагыларны кырып салып, аны кулга төшерү.

– Алдашмыйсызмы?

Инде нык кына өши башлаган бу икәү бөтен белгән хәбәрләрне ачып салырга әзер иделәр.

– Ю-юк. Юк! Валлаһи! Ипи тотып ант итәбез!

– Ничек тотасың, ди, әле аны? Кулларыгыз бәйләнгән бит, суга төшкән тавыклар!

Олырагы, тынычрак булырга тырышып, Ризванга мөрәҗәгать итте:

– Ризван кордаш, күреп торам, бу сөйләгәннәр сине бик кызыксындырмады. Безнең язмыш синең кулда, монысын аңлыйбыз. Бездә икенче хәбәр дә бар. Монысы – сезгә бик тә кирәклесе. Безне җибәрсәң, шунысын да әйтәбез.

Яшьрәге, «безнең язмыш синең кулда» дигән сүзләрне ишеткәч, бөтенләй калтырый башлады. Ризван битараф булырга тырышып кына әйтеп куйды:

– Йә, сөйлә. Бәлки, кызыксындырыр да мине.

– Иртәгә Чүпрәледән Сафаныкылар корал алырга Чернушкага баралар. Салих безнекеләргә бик күп итеп корал бирә.

– Мин ничек итеп ышанырга тиеш инде сезгә?

– Беркөнне Салих, Сафаны чакырып, бик озак сөйләшеп утырдылар.

Ни турында сөйләшкәннәрдер, барысын да белмим, ә коралны, чынлап та, бирә. Иртәгә таң атканчы ике ат белән станцага чыгалар.

Ризван нишләргә кирәклеген бик тиз билгеләде. Баягы битарафлыкта калгандай булып, боларга соңгы сүзен әйтте:

– Мин сезнең кебек җан кыючы түгел. Җибәрәм. Атларыгыз да кирәкми, әйберләрегез дә. Мылтыкларыгызны алам! – Ул иярләргә беркетелгән ике обрезны алып килде. – Монысы сезгә ышанып бетмәүдән. Бәйләнгән җепләрне чишмим, мин киткәч, үзегез чишәрсез. Әгәр миңа каршы берәр начар эш уйласагыз, икегезне бер агачка асып куям. Минем урман кешесе, табигать кешесе икәнлекне ишеткәнсездер.

Хәйләкәрлеккә килгәндә, бу пешмәгәннәрдән генә Ризван уздырмый тормый инде. Боларны алдар өчен ул Танып агышының өске ягына менеп китте. Монда үлән зур үскән, көз булуга карамастан саргаеп өлгермәгән. Бу ике бәндәнең җепләрне бик тиз чишә алмавын ул белә иде, чөнки төеннәр нык бәйләнгән, җитмәсә, алар юеш тә, көндезге салкында туңа да башлаганнар. Алар малай чактагы «Каз боты» төеннәреннән дә усалрак килеп чыктылар!

Ул, Үгез чишмәне үтеп, Тукмай яланының үзе генә белгән бер урынында атын калдырды, дистә еллар элек урман чыгарырга түшәлгән, инде череп беткән юлдан Томафи болынына килеп тә җитте. Ризванның килеп җитүен беркем сизмәде, аны күргәч, Ильясның беренче соравы бу турыда түгел иде.

– Баркадагыларга берәр нәрсә булдымы әллә?

– Юк-юк, миндә икенче бер яңалык бар. Шуны әйтәм дә, китәм. Мин аларны «ә» дигәнче куып җитәм тагын.

Ризван иртәнге хәлләрне тулысынча сөйләп бирде. Шунда ук иске юлның үтәрлек булуын да әйтте, дозорларны ничек алдый алганын да сөйләп үтте.

Корал турында ишеткәч, Ильяс сикереп торып, яңадан утырды:

– Значитца, тәк! Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына! Ходай биргән коралны тартып алмый калу мөмкин түгел! Көне-сәгате билгеле диярлек. Аллага тапшырабыз, берсүзсез!

Шунда ук бер төркем оештырылды. Ильясның планы бик катлаулы түгел иде: биш кешедән торган атлылар Сафа кешеләрен Кәлтә урманында көтәләр, каршы торуларына карап, аларны йә юк итәләр, йә бәйләп, урманда калдыралар. Атларны алып, төн эчендә Томафи яланына кайтып җитәләр. Калганын урындагы хәлләр күрсәтер. Ризван тагын бер киңәш бирде: берике кешене Кәлтә урманын чыккан җирдә калдырырга, Сафа алдан уйлап куйган булуы мөмкин коралга күзе төшкән кешеләр барлыгын.

Шул арада Ризван юкка да чыкты. Ильяс аңа рәхмәт әйтеп тә өлгермәде. Менә, бар бит җитез кешеләр!

Икенче төркем дә оештырылды. Беренчесе, Кәлтә урманына кергән урында калып, хәвефсезлекне тәэмин итә, икенчесе урман эчендә корал белән кайтып килүче Сафа кешеләрен көтә.

Төнгә каршы алар юлга чыгып та киттеләр.

## 50

Танып буйлап төшү беренче генә булмаса да, бу юлы Гаязетдин башкаларга күрсәтми генә дулкынлана иде. Башкалар ничектер, бу юлның соңгысы булуы да мөмкин икәнен ул алардан тирәнрәк аңлый, бу тиклем ашлык һәркем өчен дә зур байлыкка тиң, әгәр белә калсалар, аны кулга

төшерергә теләүчеләр һәрхәлдә булачак. Шуңа ул барканың су өстеннән күренгән өлешен бәйләмнәргә төрелгән мунчала белән уратып алды. Читтән караганда, барка мунчала алып бара дип уйларга була. Тик күңелне бочыган уйлар да бар. Өчәү алар. Беренчесе – барканың судагы өлеше. Мунчала гына төялгән булса, ул шул кадәр батмас иде. Икенчесе – барканың тизлеген берничек тә арттырып булмау. Болар икесе дә аны кулга төшерүнең бер ни тормавы турында кычкырып тора. Өченчесе, иң мөһиме – мондый барка белән җәй аенда, көзен, су түбән булганда йөрүче аз, монысы инде бу сәфәрнең башкалардан үзгә булган бик кирәкле очрак икәнлеген күрсәтә. Шуңа да Гаязетдин авыл тирәсен караңгыда үтәргә карар итте, тик монысы өстәмә уңайсызлыклар китереп чыгарды. Сай урыннарны белеп булмый, ә инде борыны белән комга төртелгән барканы агым бик тиз борып куя. Әллә ни киң булмаган елгада кабаттан борылу бик җиңелдән түгел.

Иң куркытканы салкыннар төшү, монысы Ходайдан, елга туңа башласа кышка кунарга калуыңны көт тә тор. Ел азагы бит, озакламый Яңа ел җитә, рәхмәт төшкере, әлегә елганы бөреп алырлык салкыннар юк. Яр буенда һәр иртә саен барлыкка килгән көзгедәй боз аптыратырлык түгел, ә менә барканың борынында туңган боз бер көнне шактый борчуга төшерде.

Таныпка якын уңайлы урыннарда Ризванның киң иңбашлары күренеп кала, монысы зур ышаныч өсти. Юлга чыгуга сигезенче көн, озакламый Борай. Ризван шуңа алгарак китте. Әгәр волостьта кызыллар булса, эш җиңеләя, Шәрәфине таба алса, Борайда кызыллар булмаса, ул Казанцевога тиклем барып ураячак. Менә шуларны эшләргә ничә көн үтәр, шуңынчы барканы кайда яшереп тотып булыр?

Берничә мәртәбә ул явыз кешеләрнең баркага һөҗүмен күз алдына китерергә тырышты. Барканың һәр почмагы уч төбендә кебек, берьюлы берничәсе үрмәли башламаса, аларны куып төшерү авыр булмас. Тик озаккамы? Су тизлегендә генә аккан барка ничек кенә карасаң да, явызлар өчен табыш инде ул. Хәтер Гаязетдингә Япон сугышын искә төшерә, «Варяг» крейсеры матрослары дошманга бирелмәс өчен кингстоннарны ачалар. Чит телдән кергән «кингстон» сүзе шул сугышта катнашканнарны милләтенә карамый берләштерү сүзенә әйләнде. Тик юк шул баркада андый клапан! Һәрбер капчыкны чишеп ятып та булмый, Таныпның тирәнлеге дә диңгезнеке түгел.

Барыбер берничә карар кабул итте Гаязетдин. Үзе барканың башына басты, аның белән булган өч кешене ике якка һәм барканың койрыгына урнаштырды. Кеше үтереп гөнаһ алмас өчен, һәрберсенә агачтан бик җайлы чукмар ясап бирде, балтаны барканың төбен чабып тишәргә әзерләп куйды, шунда ук ут төртеп җибәрергә ике шешә керосин да кул астында тора иде.

Танып буйлап төшкәнне ничек кенә сиздермәскә тырышмасыннар, Борайга килеп җитәр алдыннан явыз кешеләр баркага һөҗүм итте. Иртән йокының иң тәмле вакытында барканың койрыгында утырган кеше кычкырып җибәреп, башкаларны уятты. Суда да, барканың кырыйларында да йөзләр күренде. Беренче һөҗүмне кире кага алдылар. Чукмарлар тар гына аралыкта каршы тору өчен иң җайлы корал булып чыкты. Тик Таныпның мондагы иң тар урынын сайлап алган явызлар тагын баркага тартылдылар. Бу юлы алар да озын саплы сәнәкләрен ташлап, балта белән генә коралланганнар һәм йөзләрендә усал ниятне азагына җиткерү теләге яна иде. Әгәр, йөзеп килеп җитеп, барканы чапкалый башласалар, берни

дә коткара алмый, шуңа Гаязетдин егетләренә боларны жәлләмәскә кушты. Бу сүзләрдән соң ул үрнәк тә күрсәтте: якорь урынына йөрткән ташның җебенә асылынган кешенең башына төшкән чукмары бу явызны кабаттан Танып суына озатты. Шул мизгелдә ату тавышы яңгырады, су өстенә яңгыр кебек вак кургаш ядрәсе яуды. Кемдер кычкырып җибәрде, кемдер баркадан ычкынып, ярга таба йөзәргә ашыкты. Бер-бер артлы тагын ату яңгырады. Монысы инде җитдирәк коралдан – винтовкадан ату иде. Шул арада барка урман эченнән яланга очып килеп чыкты, яр өстенә менеп, кирегә урманга йөгергән башкисәрләргә таба тагын бер-ике ату тавышы ишетелде.

Гаязетдинның коткаручының Ризван булуына бер шиге дә юк иде. Ялан буйлап бераз йөзеп баргач, Ризван үзе дә күренде. Барка туктады, тиз генә балта белән чыбылган урынны төзәтеп алдылар. Эш арасында Ризван Борайдагы хәлләрне сөйләп алды.

Анда яз көне бастырылган ихтилалдан соң бар кеше куркып качып ята, халыкка күтәрә алмаслык акчалата контрибуция салынган. Ихтилал башлыклары булган Шәрәфи Хәмитов, беренче Дәүләт Думасы депутаты Сәхипзадә Мәкъсутовлар юкка чыкканнар. Старшина белән сөйләшкән Ризван. Губерна продуправасы үзәккә озатырга ашлык әзерләүне дәвам итә. Казанцевода аны җыю бер көнгә дә тукталмый икән. Казанлы волосте өлешен ике куллап кабул итеп алачаклар. Олау табарга да сүз куелган, тик олаучыларга акча түләү дә, озатып бару да безнекеләрдән. Шунысы шатландырды – борайлылар дүрт винтовка, бераз патрон бирәләр.

Бер нәрсә азрак аптыратты – ничек итеп олаучыларга түләргә? Шунда тагын бер фикер килде Гаязетдин белән Ризванның башына: барканы кирегә Казанлыга алып кайту мөмкин түгел, аны ничек тә булса сатарга кирәк. Монда бай кешеләр күп, алучылар табылыр, мөгаен. Ризван шушы эшләр белән Борайда кала, Гаязетдин башкалар белән Казанцевога юл ала.

Тагын ике көн юлда үтте. Ихтилалны бастырып, кешеләрнең котын алганнар икән шул: юлда берәү дә диярлек очрамады, авылларда өйләр бикле, эчәргә су сорасаң да, бирмиләр, капканы да, ишекне дә ачмыйлар. Хәер, монысы бик әллә ни кирәк тә түгел иде.

Казанцевода да шул ук хәл. Ихтилалны бастыручы Чернядьев белән Вострецов үткән юлның канлы эзләре юылмаган, шуңа да тын калган халык белән бернинди аралашу булмады. Һәр келәт тулы солдатлар. Булган ашлыкны тапшырдылар, аны алганны куәтләгән мөһерле язуларны алдылар да, бер мизгелгә дә туктап тормый, кайтыр юлга ашыктылар. Күпне күргән кешеләрне келәтләрдәге ашлыкның шул тиклем күп булуы аптыратып кына калмады, таң калдырды. Бар икән шул тиклем ашлыкны сыйдырырлык келәтләр, аларны алып китәрлек елга баржалары! Авылда Матусовның баркаларын зур дип сөйлиләр, ә болары нинди була икән? Халык белән сугыша-сугыша җыелган бу игенне тиешле урынына алып барып җиткерә алырлармы? Бармы бу халык авызыннан тартып алынган соңгы кисәк ризыкның төгәл исәбе? Урлаштырып, әрәм-шәрәм итеп бетермәсләрме икән?

Борайда көтеп торган Ризванга иң җылы сүзләр! Ул барканы сатып кына өлгермәгән, калган акчага арбалы бер ат та алып куйган. Волостька кереп рәхмәт әйттеләр, олаучыларны бәхилләттеләр, юллык ашар-эчәр азык, атка солы сатып алдылар, винтовкаларны арба төбенә салып, печәнгә күмделәр.

Шулай итеп планлаштырылган көннәрнең унберенчесе үтеп тә китте,

тагын ике-өч көндә, бирсен Ходай, Яңа ел туган кичтә алар өйдә булырга тиешләр. Ашаган атны юырттырып, күңелләре күтәренке булган ир-ат Казанлыга табан кузгалды.

Юл буе акрын гына җырлап кайтты Гаязетдин. Иптәшләре сорарга кыймадылар, бары кайтып җитәрәк кенә берсе түзмәде, җырның исемен белеште. Татар халкының «Ишкәкче карт» дигән җыры бу, диде Гаязетдин.

Гаязетдинның җырында аның башыннан үткән язмыш борылышлары да, булган шатлык-көенечләре дә, алдагы тормышка булган ышанычлары да, бар да бар иде...

**51**

– Нәрсә, язылами халык безнең полкка?

Канәгатьлектән кулларын уа-уа, көн саен бер үк сорауны бирә Степан Савелийга. Тегесе дә хәйләкәр, булган халык санын арттырып, көн саен бер-ике кешене өсти. Булганы утыздан чак кына өстә, тик икесе дә илледән артык дип сөйлиләр.

– Язылалар, Степан Акинфиевич, ничек кенә әле! Озакламый безгә каршы чыкканнарның бугазларын ертабыз! – Савка, ояты качкан күзләре белән ашардай булып, Степанга карый.

Кай арада эчеп тә алган? Күз алдында бозылып бара бит малай.

Тугач та, әнисез калып, яшьли әтисезлекнең ни икәнен татыган малай агасы Семёнда үсте. Дөньяның иң күңелсез мәлләрен кичерде Савка: Семённың батраклары урынына авыр капчыклар ташыды, йомышка йөгерүче малай хезмәтен дә үтәде, өй җыештыру, мал карау да аның өстендә булды. Әгәр Савкадан балачактан нәрсә хәтерлисең дип сорасалар, җавабы бер булыр иде: ул да булса, тукмалу, кыйнау, җәберләүләр. Кыйналу барысыннан да эләкте: тегермәнченең үзеннән бер дә юкка, аның хатыныннан Семённың кайда икәнлеген әйтмәгән өчен, аның сөяркәләреннән Семён аларның кайсысына ешрак барып йөргәнен сөйләмәгән өчен, аның эшләргә теләмәүче эшчеләреннән алар эшен башкармаган өчен, авыл мужикларыннан бакча талаган өчен... Шул заманнарда аңлады ул бер хакыйкатьне – бары көч көчне ега, бары көчле кеше дөнья тота. Көчле булсаң, җиңү синең якта, көчсез булсаң, барысына да башыңны иясең. Яшьләрен йота-йота түзде, аны җәберләгәннәрнең барысын да каргый-каргый, нинди генә эш эшләмәде Савка. Тик күңеленең, йөрәгенең түрендә, эч-бавырының иң төбендә кешеләргә булган ачу катыш нәфрәт, авыр, ямьсез балачак еллары өчен үч тойгысы җыелып килде, артты, үсте.

Бу хәлләр Савелий унҗиде яшькә җитәрәк кенә үзгәрә башлады. Үзенең балалары булмаячагын аңлаган картаеп баручы Семён байлыкны кемгә калдырырга дигән сораудан курка башлады. Балалары юк, хатынына ышаныч юк, туганнарына эшне дәвам итәрләр дигән өмет юк. Семён үзе дә бит бик түбәннән күтәрелә алган кеше, аның артында ярдәм итүчеләр тормады, ә ярдан этүчеләр генә булды. Аның исеме тарихка кереп калды: Казанлылар аның тегермәнен «Чимон тегермәне», ә тегермән янындагы тау башын «Чимон тау башы» дип атыйлар. Савкада аның нәселенең каны йөри. Нык кына эчкән чагында, берчак ул күз яшьләрен зур йодрыклары белән сөртә-сөртә, Савкага бу карарын җиткерде. Савка ни эшләргә кирәген яхшы аңлады, ул, Семённың аягына егылып, «әти» дип елап җибәрде.

Бу көннән соң Савка шунда ук күпләр өчен Савелий Семёновичка әйләнде. Әле кичә генә аңа кул күтәргән авыл мужиклары аның алдында бүрек сала, аның белән ялагайланып-юмакайланып сөйләшә башладылар.

Балачактан эшләргә өйрәнгән кеше буларак, ул бер эштән дә курыкмый, башкалар белән беррәттән эшли, эшнең рәтен-чиратын белгәч, аны алдап булмый. Табигатьтән бирелгән акылын Савелий Семёнга ярдәм итүгә юнәлтте: тегермән эшенә яңа ысуллар кертеп җибәрде, бина эчендә бәләкәй генә ремонт ясап, андагы эшне җайга салды. Авылныкылар тегермәнгә яңа хуҗа гына түгел, акыллы хуҗа килгәнен күрделәр. Семён, Савкада үзендә булмаган тагын бер сыйфатны күреп, куркуга калды – бу аның чиктән ашкан кансызлыгы булды. Беркемне дә җәлләмәү, әгәр кирәге чыкса, Семённың үзенә табан борылачагын көт тә тор.

Үз сәгате-минуты килеп җитте Савкага: матур итеп киенә башлады, йөрешенә ниндидер бер дәрәҗәлелек керде. Ул авылның бар кешесенә дә якын, ул теләгәнен эшли, ашый, эчә, аның ялгышлары гафу ителә, аңа бөтен нәрсә дә рөхсәт. Егетләр аның артыннан көтү кебек ияреп йөриләр, кызлар аңардан курка, тик шул ук вакытта аның күзләреннән, алтын чәченнән, юка кызыл иреннәреннән күз дә ала алмыйлар. Бары бер кыз – Нина аның белән сөйләшми, аны якын китерми, санга сукмый. Әллә ачудан, әллә башка ниндидер тойгыдан, Савка кызны кулга эләктерүне үзенә максат итеп куйды. Калганын Ходай үзе генә белә, күз күрер.

Шуңа да Степанның тәкъдименә ике куллап риза булды, тәкъдим аңа бу өйнең ишекләрен киң итеп ача иде. Чынлап әйткәндә, аңа сугыш кирәкми дә, мылтык күтәреп, сугышта йөрергә уе юк. Авылда аңа бар да ошый, бар да аның кул астында. Бертуктамый эчүенә караганда, озак калмаган Семёнга. Менә шул чакта ул барысын да үз кулына ала, менә шунда ул авылның гына түгел, төбәкнең иң хәлле кешеләренең берсенә әйләнә, менә шул чакта бик күп кешеләрнең тешен сындырачак әле ул.

Тик Нина хакына ул барысына да түзәргә әзер. Бары аның өчен Степан белән бик ихтирамлы булып сөйләшә, адым саен киңәш сорый, үзенең фикерен әйтә. Белә ул, телиме, теләмиме, Степанның Салих белән очрашасы бар, бу очрашу аны бик кыен хәлгә куя, аның белән сөйләшкәндә, Степан барыбер Савканы да чакырачак. Ә Салих турында биргән сораулары Степанны ниндидер бер эчке киеренкелектә тота, аның шундый халәттә булуы Савканың күңелен күтәрә. Һәм бу сорауны ул көн саен бирми калмый:

– Степан Акинфиевич, Салихны ничек каршылыйбыз соң?

Степанның йөзе караңгыланып китә, кашлары җыерыла. Килми, очрашасы килми кичәге дошманы белән.

– Ничек, ничек... Каршыларбыз әле берәр ничек!

Савелий сүзне читкә бора:

– Ә нигә син иртән сакчыларны өйләренә кайтарып җибәрдең? Миңа синең арттан тикшереп йөрергәме инде?

– Нәрсә булсын инде иртән? Хәвефле чак түгел лә? Безнең кешеләр күбрәк. Шуннан, Ильяс старшина безгә һөҗүм итү турында түгел, үзен саклап калу турында уйлыйдыр.

Савка аптыраудан алтын йөгертелгән кебек сары кашларын югары күтәрде. Әйе, Степан нинди генә акыллы булмасын, бу эшләрдә берни аңламый. Авыр булачак аның белән, авыр! Бөтен ышаныч Дедухинда.

– Юк, Степан Акинфиевич, син ни әйтсәң дә, мин сакны йомшарту белән риза түгел. Без нәрсә, отряд җыябызмы, әллә уен уйныйбызмы? Торсыннар сакта, өлешләренә төшкән көмешләре бит. Шуннан, килгәннәрне язуны туктарырга кушкансың. Монысы нигә инде? Исемлек кирәк! Тагын бер нәрсә: Салихны каршы алырга әзерләнергә кирәк! Ул бит офицер!

Савка бер нәрсәне бик яхшы аңлады – монда да ул беренче, монда да ул өскә чыга. Ә бу кешеләр акрын гына аның кулына килеп керәләр. Кызык та, кызыктыра торган да, кызыксындырырлык та бу яңа вазифа!

**52**

Озакка китте партизаннарның урманда ятуы. Баштагы планнар буенча ике атнага гына дип башланган иде бит, инде ай, Яңа ел да үтте. Салкыны да, ашарга аз булуы да акрын гына сиздерә башлады. Ашарга булмавыннан бик җиңел чыгу юлын таптылар. Урыс граны тирәсендә авылдан чыгып качкан Сәләхетдин байның алынмый яткан бәрәңгесенең бер өлеше калган икән – шуны тиз генә казып алдылар. Шулай итеп яшәрлек бәрәңге булды. Китәргә соңга калган үрдәкләрне атып алу, балык тотарга төрле ау кую, урман җәнлекләренә ауга чыгу да әллә ни авыр түгел иде гомер буе сунарда йөргән кешеләргә.

Ниһаять, кар да ява башлады. Башта вак кына кар бөртекләре һавада әйләнде, соңыннан инде алар, бергә җыелып, ябалак карга әверелделәр. Бар дөнья ап-ак карга чумды. Кая карама – кар. Кар бөртекләре һавада йөзә, биегән шикелле урала, әйләнә, керфекләргә куна, йомшак кына, тып-тын гына җиргә төшәлә, агачларга куна.

Озын-озак яңгырларсыз, җанга тия торган пычраксыз гына кыш килде. Яуган кар авырлыгын күтәрә алмыйча, агачлардан ашыкмый гына яфраклар коела, картлар моңа карап баш чайкый. Бар шундый күзәтүләр: әгәр яфрак коелу өстән башланса – картлар китә, астан булса – яшьләр кырыла, агач уртасы ялангачланса – урта яшьтәгеләр чираты. Быел исә, агачлар бөтен кәүсәсе буйлап яфраксыз кала, димәк, кешеләрне йотучы сугышның очы-кырые юктыр, ахры...

Лагерьда Ильяс кызыл отрядны эзләтеп җибәргән разведчикларның кайтуын көтәләр. Бишенче көн үтеп бара – бер хәбәр дә юк. Аның каравы, авылдан килүчеләрдә бары тик начар хәбәрләр. Салих тузына, кешеләрне адым саен җәберли, сак астына ала, авылларны талап җыйган малны Чернушка ягына озата.

Яшәү шартларын караштырырга туры килде. Томафи карт өенә өстәмә сәндерәләр эшләделәр, ишегалдындагы салкын бүлмәне җылытып, анда да йокларга урыннар булдырдылар. Землянкаларда да урыннар саны артты. Ауган агачларның кипкән, җиңеләйгән кәүсәләреннән, Томафи өенә терәп, җылытылган бүлмә өстәделәр. Менә шулай тормыш җайлана килә. Тик бернигә карамыйча, сугыш һөнәрен өйрәнү дәвам итте.

Җанлылыкны, шаянлыкны югалтмаган халык кичләрен Томафи өенең алдында җыела, беркемнән курыкмыйча учак ягалар, төрле хәлләр сөйлиләр, бер-берсеннән усаллашмый гына шаярып көләләр, көлү иң яше булган Әхтәмгә эләгә мондый чакта. Егет буйга үсеп китте, битен йомшак кына сакал бөртекләре каплый башлады. Шаяруга һәвәс булган олылар шунда ук аңаниләр эшләргә киңәш бирәләр. Әхтәмнең беренче алдануы

«тастымал белән кырыну» булды. Кемдер аңа тастымал белән озак итеп битне ышкысаң, сакал юкка чыга дип өйрәтте. Икенче көнне иртән бар да Әхтәмнең кып-кызыл битен кычкырып көлү белән каршы алдылар. Шуннан картлар аны тәмәке тартырга өйрәттеләр. Махорканы баштан ук тарта алмады Әхтәм. Шуннан аңа мүк төреп тартырга киңәш бирделәр. Монысы инде бик тиз алга китте, төтенне эчкә суырып тарта, шуннан мүккә махорканы да куша башлады. Бу эшләрдә катнашмаган Галләм шаяруның тирәнгә кереп барганын сизде дә кордашларына үпкәсен белдерде. Картлар да үзләренең ялгышын аңладылар:

– Ялгыштык, кордашлар. Начар гадәткә өйрәтәбез малайны, алай ярамый.

– Ялгыш кына, ди, гөнаһ бу! Әйдәгез, тәмәкене ташлату турында уйлыйк.

Киңәшләр аз булмады, берсенә тукталдылар: махоркага аз гына дары кушарга. Кичкә табан, инде җиргә караңгылык төшеп килгәндә, кемдер Әхтәмгә ыспай итеп төрелгән тәмәке сузды. Әхтәм күмерләнгән чыбыктан тәмәкене оста итеп кабызды, тәҗрибәле кеше кебек аны бирүчегә кисәтү ясады:

– Юеш бит махоркаң! Болай булмасын өчен аны бүректә тотарга кирәк! – Һәм тагын тәмәкене авызына якынайтты. Шунда тәмәкедән чыккан чыжылдау, ялтырау, дары янган ут җылылыгы аны урыныннан сикереп торырга мәҗбүр итте.

Моны күргәннәр көлүдән егылып киттеләр.

– Сез... сез нәрсә эшләдегез әле?

Көлүчеләрнең ишеткәннәре генә ишетте моны. Әхтәм, көйгән керфекләрен челт-челт йомып, янган кашларын уйнатып, аларның көлүен туктатырга маташты.

– Син тартуны ташласын өчен. Элек безне шулай туктаталар иде. Менә нәрсә эшләдек без!

Ачуыннан нишләргә белмәде Әхтәм. Яшьләрен йота-йота, җыелганнарга карап кычкырды:

– Ә мин хәзер сезгә үч итеп тартачакмын! Аңладыгызмы?

Туктата алмадылар картлар Әхтәмне. Тәмәке әзерләп кабызыр алдыннан ул аны учыннан учына сала, бик ныклап, зур игътибар белән карап, туракланган тәмәке үләнен бармаклары белән барлап чыга, исни, тикшерә инде үзенчә.

Барып чыкмады картларның тәрбия эше.

Ильясның башыннан борчулы уйлар китми – Әхтәмнең чыгып китүенә икенче көн узып бара. Көн кичкә авышты, ә егет һаман юк. Читтән караганда, бернинди дә шик кузгата торган түгел Әхтәм, андыйлар авыллар арасында күп йөри. Менә инде үзе генә кирәкмәгән эшкә тыгылмаса...

Учак җылысын, җылы сүз эзләп, халык тагын җыелды Томафи өе кырына. Ялан буйлап төтен тарала, учакта урман чәе кайнап чыгып һавага пар очыра, йөзләрдә утның биегәне чагыла. Һәр көндәге кебек, бүген дә Галләм халыкны үзенә караткан.

– Көз матур килде ул елны, быелгы кебек. Әйе, көз. Игенне җыештырып ята идек. Сәриягә ике яшь иде. Алдылар да киттеләр сугышка. Тик барып җитмәдек, Хабаровта туктадык. Полк зур, ике меңләп кеше, әллә өч атна тордык, беркая кузгатмыйлар, безгә бу хәтта ошый, нигә дип әле сугышка ашыгырга? Тик көн буе штык белән карачкыны тишәбез «Коли!» дигән

командага, «айт-двасын» әйтәсе юк, анысы да көн буе. Полкта барыбыз да олылар, резервистлар дип йөрттеләр, армиянең нәрсә икәнен яхшы беләбез. Күрше полкны сугышка җибәрделәр: ни беләндер канәгать булмый плацка чыкмаганнар, патшага каршы язулар тапканнар. Язуларда сугыш турында дөреслек, командирларны тыңламаска өндәү булган, – революционерлар эше инде бу. Безне тезеп аңлаттылар. Резервта яту ошамас, иртәгә үк сугышка. Ысматри-матри! Без, олылар, бер уйда: сугышка барганчы, монда тыныч кына ятарга кирәк, резервистлар бит! Командир шәп кеше иде безнең, төрекләр белән сугышкан, орден тагарга күкрәгендә урын җитми! Зур кеше! Ә тавышы! Хәрби форма ничек килешә иде аңа! «Отцы! Братцы! Герои!» дип кенә сөйләшә безнең белән. Ысматри-матри син!

Галләм читтә яткан ботакларны учакка тартып куйды.

– Без ни, тагын да әйбәтрәк итеп хезмәт итә башладык. Шәһәрдә торгач, тәртип саклауны безнең өскә салдылар, заводларга йөрибез. Эш ташлап, урамга чыкканнарны куып таратабыз.

– Кешеләргә дә аттыгызмы? – Монысы инде этисе белән партизаннарга кушылган Фәтхинең улы соравы.

– Аттык, улым, аттык. Мин өскә аттым атуын, тик төрле кеше бар бит. – Галләм, аягүрә басып, аякларын яздырды да кабаттан утырды. Бу хәлләрне искә төшерү җиңел түгелдер, ахры, бераз тын торды. – Берзаман бездә дә бер агитатор килеп чыкты. Акрын гына үзенекен сөйли, патшаны, хөкүмәтне сүгә, язу тарата. Укып карагач, котлар очты. Ысматри-матри, анда язылганны әйткән өчен генә дә тотып атарлык! Бездән дә олыраклар бу кешене командирларга тотып бирергә карар кылдылар. Безгә матур гына хезмәт итегез, сугыш бетә, өегезгә кайтып китәрсез дип әйттеләр.

Галләм ютәлли башлады, чәй кабып, бераз тын алды да сүзен дәвам итте.

– Шулай! Унбиш ел кыш саен ютәлләтә. Ух, салкын булды кышы шунда. Бераз йөргәч тә, аяк бармаклары туңа, кул бармакларын бөгеп тә булмый иде.

– Шуннан ни булды, Галләм бабай?

Фәтхи, улына карап, башы белән учакка ымлады.

– Күп сөйлисең. Әнә, утын ташла. – Улының акрын гына күтәрелүен күреп, ризасызлык белдерде. – Синең яшьтә кушканны йөгереп эшләргә кирәк!

– Тиргәмә баланы, Фәтхинур. Ысматри-матри, салкын, юньләп йокламаган. – Галләм тагын үзенең сөйләгән юлына кайтты. – Менә шулай язга тиклем хезмәт иттек. Сугыш бик авыр бара, безнекеләр бер дә алга бара алмыйлар. Безне дә сугышка кертергә әзерлиләр, күренеп тора. Командир бер көн иртән барыбызны да тезде дә бик матур хәбәр әйтте. Әйбәт хезмәт итәсез, мин сезне, ди, бүләкләргә булдым. Бүләк – бер кешене кайтарып җибәрәм, ди бу. Ысматри-матри! Үпкәләмәслек булсын өчен жирәбә салыгыз, ди. Без шатланабыз, өметсез гына шайтан бит! Кем белә, бәлки, кайтып та китәрбез? Исемлекне бирделәр аңа, карап та тормый, төртте бу бер исемгә. Карадылар, үзләре көләләр. Ну, бәхетле кеше, чык, ди, тезелгәннәрнең алдына.

Фәтхинең улы тагын түзмәде, Галләмне бүлдерде:

– Син идеңме инде ул бәхетле кеше, бабай?

– Тик үзе суза! «Әйдә, чык, строй алдына!» – ди бу миңа.

Тып-тын гына тыңлап утыручылар арасыннан гөж итеп тавыш үтеп китте.

– Егылып китә яздык шунда. Барыбызның да күз яшьләре ага, сүз әйтерлек түгел. Командир әйтә, бар, кайт, ди, Галлямка, син әйбәт солдат булдың. Яз, чәчү җитте, сине кыр эшләре көтә, ди.

– Кайтып киттеңме шулай, бабай?

– Киттем, ысматри-матри! Өч айдан, сугыш бетте. Тик безнең өчен хурлык булды инде ул сугыш.

* * *

Танып ягыннан чатырдап агач сынган, нидер чупылдап суга төшкән тавыш ишетелде. Дозорлар иң беренче барып җиттеләр яр буена.

– Кем бар анда?

– Мин, мин бу, Әхтәм!

Яр астына сикерделәр. Кемдер елга аркылы яткан агач буйлап үрмәләде.

– Акрын, миндә бар...

– Нәрсә бар? Бир кулыңны!

– Юк, минем кулда капчык бар.

– Бир, алайса, капчыгыңны!

Әхтәм чак тартып чыгарды капчыгын судан. Үзен тартып алгач, берәү шунда ук аны ашыктырды:

– Йөгер, йөгер учак янына!

– Саграк булыгыз, вата күрмәгез!

– Күп сөйләнмә, йөгер!

Юеш киемле Әхтәмнең нидер сөйләргә тырышканын күреп, Ильяс кулын гына селтәде, учакка күбрәк ягарга, җылы киемнәр алып килергә кушты. Җылы кием, кайнар чәй үзенекен итте, Әхтәм җылына башлады. Партизаннар учак яныннан китми, көлешәләр, Әхтәмне җәллиләр.

– Җәл, катырак берни дә юк. Тиз терелтер иде малайны!..

– Әхтәм, ә син нәрсә алып кайттың? – Фәтхи баядан бирле манара кебек калкып утырган капчыкка карый, аны утка табан тартып чишеп җибәрде.

– Егетләр! Монда... монда бит!

Фәтхинең тавышы югалды бу байлыкны күреп: чирекле савыт, аның янында бәләкәйрәге. Фәтхи, тагын нидер көтеп, кулын капчыкка тыкты һәм бер көнбагыш тартып чыгарды. Көлке тантанасы ачылды бугай – бар да Әхтәмне мактый, бар да берсен-берсе тыңламый, нидер сөйли, көлә.

– Афәрин, Әхтәм! Шәп нәрсә алып кайткансың!

– Сөйлә, кайдан, ничек алдың? Сорап алдыңмы, әллә урлапмы?

Бары бер Ильяс кына җитди калды, Әхтәмнең бар курыкканы аның сорауларына җавап бирү иде.

– Сөйлә, кайдан бу кучтәнәч?

– Мин күрше авылга...

– Анда керергә сиңа рөхсәт бар идеме?

Әхтәм башын иде.

– Ярар инде, Ильяс! Бу бәйрәм хакына кичер малайның гаебен!

– Ярар, иртәгә карап карарбыз! Гаеп зур. Таныштыр батырлыгың белән.

Әхтәмнең борыны бөтенләй төшеп китте.

– Авылга мин урман ягыннан кердем. Беркем дә күрмәде. Бер өйдә туй бара. Эчәләр, җырлыйлар. Якынрак килгәч, бер хатынның мунчадан шешәләр тотып өйгә кергәнен күрдем. Мин...

Шартлау тавышыннан ныграк ишетелде көлүнең яңа өлеше.

– Мунчага керденме? Кит! Әгәр тагын берәрсе булса?

– Юк, бер кеше дә юк иде. Анда шешәләр! Бер капчык табып алып, тиз генә салдым икене. Шул чакта мунчага бер ир белән хатын килеп керделәр.

Бу юлы инде Ильяс та чыдый алмады. Күптән өй җылысы күрмәгән партизаннар кычкырып көләләр, күз яшьләрен сөртәләр, җирдә тәгәриләр, хәтта ишетмәгәннәр дә, берни аңламасалар да, көлә башладылар. Ниндидер гомум халәт барысын да үз эченә алды. Ару-талу, күңелдә тупланган башкаларга, үзләренә булган, елга буендагы хәлләргә ачу, салкынга, ачлыкка, тагын әллә нәрсәләргә булган ачу төтен кебек өскә күтәрелә, юкка чыга. Аның урынына бүген барысына да кирәк булган җиңеллек, эшләгән эшләренә, үзләренә ышаныч туа, үсә, бу ышаныч алда барысы да әйбәт булачагына өмет бирә.

Әхтәм генә бу олы һәм житди кешеләрнең көлү сәбәбен аңлый алмый, булган чын хәлләрне дөрес итеп сөйләп биргән сүзләрдә ул бернинди дә көләрлек сәбәп күрми иде. Барысын да аңламаса да, үзенең уналтыдан югары яшьлек тәҗрибәсеннән чыгып, ул нидән көлгәннәрен аңламаслык түгел, тик нигә бүген алар андый хәлләрне искә алалар? Әгәр үзләре шушы хәлдә калсалар, ни эшләрләр иде икән? Кычыткан арасында чак яшеренеп калды бит ул! Сөйләмәскә кирәк булгандыр боларын, сөйләмәскә! Кайчакта аңа бияләй булган авызларын җыя алмаган бу кешеләр килеп чыккан хәлләрдән түгел, ә шушы хәлгә тарыган Әхтәмнең үзеннән көләләр кебек иде. Азрак җылына төшкәч, бүген урманда чыгу юлын эзләп йөргәненә, куак астында куркып утырганына үкенеч үтте, ул инде олыларга да үпкәли алмый иде. Ә бүген булган бу хәл әле бик озак кешеләрнең күңелен күтәрәчәген ул яхшы аңлый.

Озак итеп көлгән кешеләргә атлар күзләренең бәбәген агартып аптырап карыйлар, берни аңламый, башларын селкетәләр.

– Син кайда качып яттың инде?

– Нәрсә эшләделәр инде алар?

– Син карап яттыңмы?

Әхтәм чынлап торып ачуланып кычкырганын сизми дә калды:

– Бернәрсә дә эшләмәделәр алар! Шешәләрне алдылар да өйгә кереп киттеләр!

Әхтәм, яклау эзләп, Ильяска карады:

– Бернәрсә дә булмады, Ильяс абый! – Инде күптән тамарга әзер булган күз яшьләре атылып килеп тә чыктылар. – Бернәрсә дә булмады бит!

Ильяс, шинеленең җиңе белән күзен сөртеп, барысын да туктатты.

– Ярар, Таныпта коенганнан соң алып кайткан көмешкәңне ярты стакан эчеп җибәрәсең дә, значитца, йокларга! Эзтабар!

Тик аның соңгы сүзен тагын дөрес аңламадылар, бусы инде көлүгә тагын бер сәбәп булды.

– Эзтабар! Мунчада...

– Булды, җитте. Сал тизрәк! Алла сакласын, егетне чирләтербез иртәгә!

Бик зур авырлык белән эчте Әхтәм тәмсез көмешкәне. Зәңгәр күзләрен зур ачып, янган керфекләрен челт-челт йомып, бик озак салкын урман һавасы белән тын алды.

– Бәләкәен тигез итеп бүлегез. Берсе калсын, яра-фәләнгә сөртергә. – Монысы Әхтәм ишеткән һәм аңлаган сүзләрнең соңгысы иде.

– Бернәрсә дә булмады бит! – дип кабатлады ул, елмаю чаткылары эленгән йөзләрне урап үтеп, Ильяска тукталды. Шуннан ул Томафи өенә кереп, үз урынына сыенды.

Башка берни дә хәтерләмәс булды аның бер көн эчендә вакыйгаларга бай булган аңы.

**53**

– Марфа, ач, мин!

Пышылдап әйткән сүзгә Марфа уянды һәм тиз генә, тавышсыз гына ишекнең биген күтәрде.

– Ни хәлләр, ничек яшисез? Үзең, балалар? Тиз генә җылы кием җый, мин хәзер үк китәм. Нидер сизенәм! – Мирон эчкә үк үтеп тә тормады, ишек төбендә тукталды.

– Бәлки, сизмәсләр? – Марфа шулай уйласа да, әзерләп куйган төенчекне Миронга тоттырды. – Ашап аласыңмы?

Мирон, алга үтеп, мичтән генә алган кара икмәкне тешләп тә өлгермәде, ишекне типкәли дә башладылар.

– Ач! Тиз бул! Йортны урап, урап алыгыз, юньсезләр!

– Йөгер, йөгер. Бакча аша, өлгерәсең!

– Ачасыңмы-юкмы, җен карчыгы? – Савканың тавышы әллә кая өскә менеп китте.

– Хуш, Марфа, балаларны кара һәм сакла! – Мирон тәрәзәдән уйламыйсизми көтеп торучыларның кочагына сикерде. Биш-алты кеше эләктереп тә алдылар, кулларын бәйләп, Степанга табан алып та киттеләр. Бара торгач, кире уйлап, авыл уртасында мәктәп базына бикләп куйдылар. Мирон идәнетүшәме нык булган бинаның базын карап чыкты, тик чыгып качарлык юл юк иде: тәрәзә алдындагы учак каршында Степан кешеләре ята. Аларга мөрәҗәгать итеп тә карады Мирон: авылдашлар бит, бергә үскәннәр, бергә армиядә хезмәт иткәннәр.

Тиздән борчулы таң да атты. Йокысыз төндә бер нәрсәне аңлады Мирон: бу юлы котылу юк, бу юлы ул башы-аягы белән килеп капты тозакка. Менә бит, ни яшәвенең рәте булмады, үлеме дә кешечә булмаячактыр...

Иртә таңнан мәктәп йорты җанланып китте. Кешеләр йөри башлады, кычкырып сөйләшүләр... Ишеккә дөбердәтеп типтеләр дә таныш булмаган ике кеше килеп керде. Караңгы базга бик озак карап торгач, берсе калын тавыш белән эндәште:

– Синме бу? Әйдә! Чакыралар!

Партасыз калган бер класс бүлмәсендә тирән махмырда бөтен дөньяга усал Дедухин утыра иде. Күзләрен бер ноктага җыя алмый бик озак карап торгач, ниһаять, теш арасыннан берничә сүз кысып чыгарды:

– Нәрсә, Мирон Архипыч, мөселман отрядына барып баш иденме? Дөресме бу сүз?

Юньләп тыңламаган аякларына чак-чак басып торды да, башка бер сүз әйтмичә, йодрыгы белән Миронның йөзенә менеп төште.

– Шулаймы, сатлыкҗан? Безнең дин сиңа инде ярамыймы, басурманнарга тайпылдыңмы? Син кемгә каршы чыктың, адәм актыгы? Нәрсә җитми сиңа?

Бар булган ачуын алды Дедухин Мироннан. Кичәге кичтән җыелган көмешкә парлары чыгып киткәнче, Миронны егылганчы тукмады.

Ишектән кергән Степан идәндә яткан Миронны күреп туктап калды.

– Аркадий Михайлович, нигә аны болай?

– Ничек нигә? Син нәрсә, бүген дөньяга килдеңме? Җебегән! Отряд җыйган була тагын! Ә борын астында эзтабарлар йөри! Акылдан яздыңмы? Бу сиңа сугыш! Ә сугыш уен түгел!

Чыгып бетмәгән усаллыгы Степанга да калган булып чыкты. Степан читкәрәк китеп, нигәдер кулы белән йөзен каплап, гаепле елмаеп тыңлады аны.

– Аңлыйм. Минем уйда икенче нәрсә: нәрсә белә инде бу кара мужик?

– Белә! Ничек кенә белә әле! Безгә аның нинди юл белән Тимофей яланыннан чыкканын белергә кирәк! – Дедухин Миронга борылды. – Тор! Йә, сөйләп җибәр, тагын кайда яшерен юл бар яланнан?

Мирон авырлык белән торып утырды. Сулкылдап башы авырта, аңа кушылып йөрәк чаң суга, иңбашы үз урынына күтәрелми иде.

– Ильяс кайда? Отрядта ничә кеше? Коралыгыз бармы?

Степан, түргә үтеп, укытучы өстәле артына утырды, ә йөзендә шул ук гаепле елмаю чаткылары күренә иде.

– Син җавап бирәсеңме, юкмы?

Мирон эндәшмәде, иреннәрне җыеп сүз әйтү җиңел түгел, моны Дедухин үзе дә күреп тора. Ә нәрсә әйтсен, ди, әле ул? Һәрбер әйтелгән хәбәр урмандагы иптәшләренең аркасына кадалган хәнҗәр бит!

Ишек ачылды, анда бер баш Дедухинга эндәште:

– Аркадий Михайлович, чык әле! Яңалар килде!

Дедухин үтеп барышлый Миронга тибеп чыгып китте. Степан күзләрен аңардан алып, авыр сулап, читкә карады:

– Менә шундый хәлләр, Мирон Акимыч... Менә шулай... Алла барысына да хөкемдар... Син... син мине хөкем итмә. Дөньясы шулай булгач...

Сөйләп бетерә алмады, Аркадий керде.

– Ну, нәрсә? Ачыламы телең?

Дедухинга аның әллә нәрсә сөйләве дә кирәкми. Мирон белгәнне ул да белә, Томафига керә торган юлларны бу як кешеләре күзне йомып үтәргә булдыралар. Аңа икенче нәрсә кирәк иде – үзен зур кеше итеп тою, башкаларны тыңлату, буйсындыру. Аның уенда инде бу кулга төшерелгән гаепләме, түгелме, кешене мәйданга чыгарып асып кую, башкалар алдында Дедухинның бик кырыс командир икәнен күрсәтү. Ә Ильяс отрядының көчен белү кирәк. Монысы – бөтенләй икенче эш.

Мирон авызын ачты:

– Син, Аркадий, мине куркытырга маташма. Мин күпне күргән, ике сугыш сиңа ул, үзең әйткәнчә, уен түгел. Ни сөйләргә кирәклеген мин яхшы беләм. Отрядның кайда икәнен белмәгән кеше юк, әнә, чык та, Тимофей яланына кара, төтеннәрне күрерсең. Ә саны... Безнекеләрнең саны синекеннән күп. Так что, юкка көчәнмә! Шул минем сүзем.

Аркадий шартлый язды. Карчыга кебек Миронга килеп кунды, куллары, аяклары белән суккалап, типкәләп, кычкырырга тотынды:

– Ә мин сине... Ә мин сине... – Аның ачудан тыны кысылды. – Мин башта синең күз алдында балаларыңны, гаиләңне тураклап ташлыйм, хатыныңны, карт әниеңне... Шуннан белерсең сугышның ни икәнен!

Арыды бугай, ишеккә тибеп кычкырды:

– Бикләп куегыз моны!

Степан аңлый башлады кая килеп эләккәнен. Аның башында кайчандыр Уфаның бер мәйданында караган клоуннар театры артистлары уйный, шул уеннан бер өзек искә төшә, сүзләре колагында яңгырый: «Син җенне үзең шешәдән чыгардың!» Әйе, чыгарды бугай шешәдән ул җенне, тик берне генә дә түгел, йөзне... Бу кешеләр бүген – Миронны, иртәгә башканы – берсекөнгә Степанның үзен дә сатарга булдырырлар.

– Степан Акинфиевич, син нәрсә, буй җиткән кыз кебек? Күтәр башыңны! Дөнья бу!

Дедухин, ике тулы стакан тотып, Степан янына килде.

– Башта шулай инде ул. Җәллисең, соңыннан күңел ката.

– Авыр миңа мондый эшләр. Кичә генә ул миндә эшләде, бүген аны кыйныйбыз, асабыз, атабыз дип куркытабыз.

– Ташла бу уйларыңны, Степан Акинфиевич! Бу халыкны бары бер нәрсә – куркыту тота. Шуңа күрә аларны кыйнарга, тукмарга, башкаларга курку булсын өчен асарга да кирәк. Шунсыз тынычлыкны кабат кайтара алмыйбыз. Әнә, атаман Дутов Ырымбур якларында аларны башта шомпол белән мәйданда яра, шуннан асып куя. Элекке Ходай биргән тәртипне бары тик шушы юл белән генә кайтарып алырбыз.

– Кеше бит әле ул да...

– Кеше! Аларның яртысы калса, Рәсәйгә җитәр. Сугыш беткәч туалар алар. Әнә, бичәләр әзер! Аның каравы, тәртип кайта!

Степанның бер сорау бирәсе килә: ә бу дөньяда кешеләр калмагач, ул тәртип кемгә кирәк соң? Тик Степан хыялый түгел, сорау бирүнең чикләре барлыгын аңлый. Дедухин да, аның уйларын сизгәндәй, бөтенләй басынкы тавыш белән стаканын сузды:

– Әйдә, тот...

**54**

Үзенең төлкедән дә хәйләкәррәк икәнен тагын бер кат исбат итте Сафа. Ильясның кешеләре Кәлтә авылында икенче көн корал алырга киткәннәрне көтеп яталар, ә тегеләрнең эзе дә күренми. Бары өченче көнне иртәнгә табан гына килеп чыкты бер ат арбасы. Йөк авыр булгангамы, озата баручыларның икесе генә арбага утырган, ә калган икәве, мышный-мышный, арба артыннан атлауларын беләләр.

Арбадагыларны беренче булып таныдылар – бу Сафаның иң якын ярдәмчеләре. Алар, йомшак печәнгә ятып, дөньядан бик канәгать булып, үзләре генә белгән ниндидер сөйләшү алып баралар, читкә дә, артка да карау юк. Урмандагы иртәнге тынычлык аларның ни сөйләгәнен партизаннарга тулысынча ишеттерә, ямьсез итеп көлүләреннән колакны каплыйсы килә:

– Ул... Юк! Мин ни... Бала-чагамыни мин? Шуннан...

Алдан уйлап куелган иде бу башкисәрләрне эләктерү планы. Кәкре каен гөрселдәп юлга аугач та ташландылар аларга. Арбадагыларның юаны утырган урыныннда сикереп торды, тик башына төшкән күсәк аны җиргә алып ташлады. Икенчесе камчы белән атка кизәнде, камчыны кулына эләктергән партизан аны да арбадан тартып төшерде. Бу хәлне көтмәгән Сафа кешеләре каршылык күрсәтергә дә өлгермәделәр, кулларын бәйләп, ауган каен янына утыртып та куйдылар. Арттагыларның берсе урманга ташланды, аны куып тотып булмаячагын аңлаган партизаннар бу уйдан кире кайттылар.

Курыккан ат, юлның сикәлтәле булуына карамастан, юыртып китте. Шулвакыт кемдер кычкырды:

– Атны, атны карагыз!

Аны Нигъмәт, тезгененнән эләктереп, бик тиз туктатты.

– Ничә винтовка?

Тиз генә санадылар кулга төшкән байлыкны: егерме биш винтовка, ике әрҗә патрон, егерме граната. Чыннан да, зур байлык иде бу.

Нигъмәт Сафаныкыларны якаларыннан тотып, арба кырына бастырды. Тегеләр куркудан бер-берсенә сыендылар, шуннан башкалардан олырак булган юан калтыраган тавыш белән сорау бирде:

– Нишләтәсез инде безне? Атып китәсезме?

– Без – кызыл партизаннар! Сезнең кебек гаепсез кешеләрне талап, үтереп йөрмибез! Карап карарбыз, анысы Ильясның кулында. – Нигъмәт тавышына рәсмилек бирергә тырышты. – Кайда очрашырга тиешсез Сафа белән?

Бәйләнгәннәр бер-берсенә карашып алдылар да, юан кеше, якасы белән башыннан агып төшкән канны сөртеп, тагын сүз алды:

– Сабан ялан чишмәсе кырында көтә ул.

– Нигә болай озак йөрдегез?

– Озак түгел. Ул бит безне Олы елга аша уратып җибәрде. Кайтырга да шуннан кушкан иде, тыңламадык менә.

Икенчесе кушылды:

– Тыңламадык, сезгә килеп эләктек...

Нигъмәт көлми булдыра алмады, аңа башкалар да кушылды.

– Ну хәйләкәр бу Сафа, ә! Ярар, сезгә рәхмәт аны тыңламаганга. Ә беләсезме нишләтә ул сезне моның өчен?

Тегеләр бөрешеп киткән төсле булды.

– Тирегезне салдырып, каеш ясый ул сездән! Шулай булгач, безнең белән тик кенә атлагыз, алай-болай уйласагыз, бездән сезгә вәгъдә – исән калу юк!

Тегеләр «Аңладык!» дип баш иделәр.

– Әлегә тиз генә Урман асты күленә табан төшеп китәбез!

Тик бер кеше дә кузгалмады. Андагы Тукмай сазлыгының начар данын барысы да беләләр иде шул.

– Сез нәрсә? Бер-ике сәгатьтән теге качкан бәндә ярдәмгә башкисәрләре белән Сафаны алып киләчәк!

– Син чынлап ат белән сазга кермәкчесеңме? Аннан үтеп булмый!

Нигъмәт Сафа кешеләрен алгарак алып китәргә кушты, ул сөйләгәннәргә артык колак бер дә кирәкми, бусын барысы да яхшы аңлый.

– Егерме ел элек мин бу сазлыкның аркылысын-буен ничә мәртәбә үткәнмендер. Василий байның маллары югалды. Әле дә хәтердә, өч сыер, кышлаган ике үгезе. Йөри торгач адаштым, өс-баш – су, тамак – ач. Кинәт төтен исен сиздем дә, шуңа таба барып, учакка юлыктым. Шул учак кырында бер кеше йоклап ята, шуннан тагын икәү килеп чыктылар.

Шул чакны искә төшерепме, Нигъмәт бераз туктап торды.

– Каторжаннар булып чыкты алар. Дүртәү булганнар, берсе юк иде инде. Алар да ач-ялангач, көтүдән мал урларга булганнар. Шулай да, авыл кешеләренең соңгы малын аласылары килмәгән. Ә бер көнне Василий килеп, бер дә юкка мине тукмап киткәнен күргәч, аның малларын урманга

алып кереп китәләр. Бер үгезне чалалар, калган маллар шунда ашап йөриләр. – Ул бер мизгелгә тынып калды – Василий кулына нәрсә эләгә, шуның белән кыйный торган иде, ә кулының катылыгы!

Нигъмәтнең тавышына уйчанлык керде.

– Ашаттылар, учак янында киемне киптердем, алар белән дуслашып та киттем. Шунда алар миңа сазлык аша чыга торган юлны күрсәттеләр. Шуңа күрә, егетләр, мин монда гына йөри беләм, курыкмагыз!

– Ни булды инде аларга?

– Бераз хәл алгач, ары киттеләр. Киткәнче, Василийны тотып, кирәген бирделәр. Әллә өч ай тора алмый ятты урын-җирендә...

Урман авызына чыккач, куактан куакка йөгереп, каршы килгән кешеләрне күреп калдылар. Болар качкан кеше кисәткән Сафаныкылар икәне билгеле иде. Партизаннарга булган винтовкаларның маен сөртештереп, бер-ике ату җитте – тегеләр артларына да карамый кирегә чаптылар. Бәйләнгән юан да аларга кушылып йөгереп карады, тик дуслары кырына инде барып җиттем дигәндә генә, усал пуля аны куып җитеп туктатты.

Нигъмәт алып кергән агач түшәлгән юлны инде вак үсентеләр каплап бетерә язган. Партизаннарның арбасыз атлары ул юлдан җиңел генә бардылар, ә арбаны саз суыннан берничә мәртәбә күтәреп диярлек чыгардылар. Мондый авыр эшне башкарып чыгу өчен Сафа кешеләрен дә ычкындырырга туры килде. Болар, көчләрен җәлләми, эшләргә тырыштылар.

Партизаннарның учак утлары күренгәч, бу икәү Нигъмәт янына килделәр.

– Безнең белән ни була инде?

– Монда каласыз, – диде Ильяс. – Әгәр үзегезне әйбәт тотсагыз, барысы да әйбәт булыр. Алай булмаса, үзегезгә үпкәләгез!

Боларның йөзе яктырып китте.

## 55

– Улым, утыр әле, сөйләшик. – Хәмит ничәнче көн инде Салих белән сөйләшергә тырыша, тик ул: «Вакыт юк!» – дип кенә җибәрә. Бу юлы кыенсынды булса кирәк, көрсенеп булса да, утырды Салих өстәл артына.

– Степан белән очрашмыйча булдыра алмассың бит инде, күпме сузсаң да. Нәрсә уйлыйсың? Чакырып аласыңмы?

– Очрашмый булмый. Үзем барам. Курыксын аз булса да бездән.

– Бәлки, шулай да. Тик мин аны әллә ни гаепләмим. Атта да бар, тәртәдә дә. Менә шуны аңлый алмады ул. Шуңа да аның башында бер генә уй – ничек итеп үч алырга?

– Ә мин нишлим соң бу хәлләрдә?

– Битараф булырга тырыш. Аллаһы Тәгалә үзе белә ул тиешен бирергә һәркемгә. Ә барып куркытып килү кирәк! Дөрес уйлыйсың!

– Аңладым, эти! Белербез нишләргә аның белән синең тынычлыкны ашаган өчен. Ә Михайловкага бүген үк барам.

* * *

Мондый кышның әллә кайчаннан булмавына зарланалар картлар. Кар юк, салкыннан туңган җир ярыла, көннәр буена усал җил сары яфраклар куа, әллә кайларда, өстә, кеше куркытып сызгыра, өермәләр әйләндереп, тузанны югарыга алып менеп китә.

Картлар нидер сизеп зарлана:

– Бәлагә бу, кордашлар, бәлагә! Бездән олыларның мондый хәлләрне сөйләгәне булмады...

Картлар авыр сулап ризалашалар.

– Бәлагә бу! Әйе! Казага...

Хәниф мулла вәгазьләрендә бу хәлләрне көн саен кабатлый башлады.

– Дин кардәшләр! Аллаһы Тәгаләнең каргышы төшә безгә. Илдә гасырлар буе яшәп килгән тәртипне бозган өчен, Аллаһыдан читкә тайпылган өчен. Аллаһы Тәгаләгә ышаныч суына, элекке изге кануннар, игътикад-дингә бирелгәнлек югала башлады. Ходай вә кешеләрнең дошманнары – бәлшәвикләр килеп чыкты. Карагыз, ни эшләделәр алар илдә эрвәлүтсәләре белән? Ходайдан курку кирәк, картларны ихтирам итү кирәк! Болай барса, ахырзаманга да ерак калмый! Сәҗдә кылыйк Аллаһыга, юашлык-тыңлаучанлык аша гафу сорыйк!

Сәҗдә кылалар картлар, кайчакта онытылып утыралар: ни өчен Аллаһы Тәгалә дөньяны җинеләйтергә тырышканда гына аларга ачулана икән? Картлар дисәң дә, аларны һәрнәрсәгә берсүзсез ышандырып булмый, алар бит дөнья күргән, ил гизгән, сугышларда булган кешеләр!

– Начар эшләре белән дан казанган бозык кешеләр барлыкка килде, җәмәгать! Каторжаннар! Әнә бит Ильяс ни эшли?

Ильяс нинди каторжан булсын? Үзебез сайлап куйган старшина ул!

– Акны кара диләр, дөреслеккә каршы баралар. Ходайдан куркыгыз! Изге Коръән-Кәримдә язылган, мондый гөнаһ ияләре тәмуг утында яначак!

Шулай булырмы-юкмы, кем яначак бит әле? Халыкны атып-асып, талап йөргәннәрме, әллә халыкның яклаучыларымы?

Ильястан соң сайламый-нитми куелган старшина Зиннәт картаеп китте. Салихның буш дәгъвалары җиләтте, солдатларны урнаштыра-урнаштыра хәле бетте. Монысы инде староста Хәмит эше, тик ул хәзер Салихка таяна. Бер закон калмады – өяз белән бернинди элемтә юк...

Барысы да үз агымы белән бара. Тик кая барадыр. Бары кичәге дошманнарны бергә җыйды бу агым. Бер йолага, гадәткә әйләнеп китте көн саен староста Хәмиттә җыелу, җыелып яңа хәбәрләрне байкау.

Көн саен өй тулы кеше! Моңа җаны көйгән Рәхимә тиргәшә:

– Ничек көн дә бер җирдә җыелып ятып була икән, ә? Әндрәй казнасы бармы әллә монда? Сөйләшергә дип түгел, бушка тыгынырга дип киләләр, җир битләр! Кемнең безне чакырганы бар?

Ул гына да түгел, карап кына тормасаң, куллары әллә кайдан үскән хезмәтчеләр табак-савытны ваталар:

– Нәрсә дип катып калдың? Йөгер, ашны тарат! Аяк астыңа карап атла! Тәлинкәне тагын ватсаң, башыңны мичкә бәреп ярам!

Мөхәммәтҗан һәм аның уллары килми, юкка чыктылар, Гаязетдин урап үтә, байларның берничәсе инде күптән чыгып киттеләр Казанлыдан.

Буш сүзләр, буш вәгъдәләр... Салих та кайчакта кушыла бу сүзләргә, Колчакның Мәскәүгә барып җиткәне турында сөйли. Ничек кенә тыныч булырга тырышмасын, ул үзен куз өстендә биегән кеше итеп тоя. Казанлыда, борын астында партизаннар. Төрле якка солдатларын җибәреп карады – бөтен төбәк алар белән тулы. Болай булса, ни белән тәмамланыр Колчакның эшләре?..

Салихка да яшерен генә китү юлын эзләргә кирәктер. Бәлки, Бөре аша Уфага? Тимер юлга чыгаргамы, партизаннарны ерып?

Айдан артык ачу-нәфрәт белән карый ул Томафи яланыннан күтәрелгән төтенгә. Берничә мәртәбә ул аларны кырып ташларга да әзер иде, тик солдатлар аз, станцияләргә таратып бетергәч, бары утызлап кеше калды. Михайловкадагы халыкка ышаныч юк, анда бары коралсыз мужиклар. Әлбәттә, кирәк булса, ул аларны авангард итеп файдаланыр. Ике яктан ут астында булсалар, әллә нинди ныгытмаларны алырлар ачулы мужиклар.

Чыгу юлларының күз алдында берсе артыннан берсе ябыла... Аш та үтми, су да бармый. Салих, шинелен кулына гына салып, Хәмитнең өеннән ерак булмаган штабка кереп китте. Шулай аптырап утырганда, Сафа килеп керде.

Исәнләшү юк, башкасы юк, шунда ук ачуланып сүз башлады:

– Партизаннар корал алып кайтучыларга һөҗүм иткәннәр, аларны кырып салып, коралны кулга төшергәннәр.

– Ничә винтовка инде хәзер аларда?

Бу гына җитмәгән иде! Сафа егерме биш дип әйтеп каптенармусны шик астына алдырмады, сөйләшенгәнчә җавап бирде:

– Егерме. Ике әрҗә патрон, гранаталар.

Тынып калды Салих. Партизаннар бөтенләй коралсыз утырмаганнардыр бит әлегә тиклем. Димәк, хәзер барысында да нинди дә булса корал бар.

– Кайдан белгәннәр корал турында?

– Ике кешене җибәргән идем тирә-якны караштырырга, Ризванның ниләр кылганын күз уңында тотарга. Тоттың менә, көт тә тор. Ризван аларны салкында Таныпка төшереп, шуннан бәйләп куеп телләрен ачкан.

– Нинди җәзага тарттырдың инде?

– Бакча артында бер тыныч урын бар, шунда чыгарып аттым.

Икесе дә тын калдылар. Салих беренче булып сүзен башлады.

– Менә нәрсә! Мин, Михайловкага барып, Степанның гаскәрен карап кайтам. Синекеләргә ышаныч бармы?

– Алар күп эшләр белән бер-берсенә бәйләнгәннәр. Ышанычтан да бигрәк курку белән.

– Ильясның бу эше минем түземлекнең соңгы тамчысын юкка чыгарды. Иртәгегә мин план төзим. Очрашырбыз. Кайда, ничек, кем, кая – барысын да сөйләшербез иртән.

Сафа өзгәләнеп чыгып китте, Салих тыныч кына штабта торып калды...

**56**

Салих Степанны бер нинди кисәтүсез-нисез Михайловкага чыгып китте. Үзе белән унбишләп солдат алды. Кем белә анда нинди хәлләр көткәнен.

– Ну, Степан Акинфиевич, исәнме, исәнме! Ишеттем, тик ятмыйсың, отряд җыясың икән! Молоток инде, ни әйтәсең!

– Әйдәгез, үтегез! Менә тик ятмыйбыз, җыябыз акрын гына. Безнең җыйган бер тамчыкай Рәсәйне яклар елгага кушылса, файда булыр!

Степан кунакларны өйгә алып керде, өстәл артына чакырды. Шунда ук ашарга-эчәргә чыгарылды.

– Степан Акинфиевич, чынлап та, кыюлыгың башкаларга өлге булырлык.

Молодец! Башка авылларда да шулай итсәләр, бу большевизм дигән йогышлы чирне күптән җиңәр идек.

Күтәрделәр беренче стаканны.

– Әйе, мин сезне шатландырырга теләгән идем отряд белән каршы алып. Барып чыкты бугай? Ә бу минем ярдәмчем, Савелий Чуров. Тәртипле егет, аңлы егет. Ут бөрчәсе!

Салих бу алтын чәчле егетнең үзеннән күз дә алмый караганын әллә кайчан сизде инде.

– Нәрсә әйтим, Акинфиевич, шатмын очрашуга. Безгә бит Рәсәйнең язмышы кыйммәт!

– Шулай, ничек шулай булмасын, ди? Бирсен Ходай, тазартып җибәрербез әле бу большевиклардан!

– Кемдер өйдә йоклапмы, качыпмы ята. Ә сез менә дигән команда җыясыз. Монысы рәхмәт сүзләренә лаек! Битараф түгелсез, менә бит эш нидә! – Салих тозлы кәбестә капты да аны шыгырдатып чәйни башлады. – Ә Дедухин кая булды?

– Аркадий Михайлович Казанлыга кайтып киткән иде. Юлда очрамадымыни?

– Юк!

Бераз кабыштырып алгач, Степан Чуровка исемлекне китерергә кушты.

– Менә, штабс-капитан әфәнде, безнең байлык – алтмыш бер кеше. Болары ныклап безнең белән. Тагын егермеләп безгә ияргәннәре бар. Бер килгәч, күз салып китегез, чиркәү мәйданына җыйдык.

Шул сүзләр белән өйдән чыктылар. Ишектә туктап кала язды Салих – бүлмәнең теге башында Нина күренеп алды. Ачык ишек аша дошман итеп ашардай аңа караган Савканың күзләрен дә күреп өлгерде ул. Кайсыдыр бер арада Рәхимә аңа Гәрәйнең бу кыз белән яшерен генә очрашуы турында сөйләп куйган иде, күз кырые белән булса да, аны бик күрәсе килгән иде. Чынлап та, Гәрәй сайлый белгән, кыз менә дигән. Тик бу тарихның дәвамын гына берничек тә күз алдына китерә алмый иде ул. Үзәкләрдән ерак тискәре яклар, кыргый кагыйдәләр, йолалар, шәригать, әдәп, тагын әллә нәрсәләр... Ярар, бүгенгә бу мөһим түгел. Ә Чуровка бернинди ышаныч юк, торганы бер авыл башкисәре... Ярый әле, исән-сау котылган Гәрәй алардан.

Мәйданда ала-кола киенгән атлы-атсыз кешеләр тезелгән иде. Саф бар да кебек, юк та. Армиядә булганнар үзләрен кирәгенчә тота, яшьләр һәм болай гына килеп басканнар, сафның тәртибен юкка чыгарып, күңелне төшерә. Салих бик күрсәтергә тырышмаса да, иронияле елмаюын яшерә алмыйча, бу төркемгә карап торды. Ниһаять, Салихныкылар килеп кушылгач кына, сафны бер формага китерә алдылар. Исемлекне тикшерә башлагач, биш кешенең бернинди сәбәпсез юклыгы ачыкланды, өч кешенең дозорда булуын аңлаттылар.

Салих, аптырап, карашын Степанга борды:

– Дозор? Нинди дозор? Без авылга кергәндә, бер кешене дә күрмәдек!

Боларын эзләргә кеше җибәрделәр. Шул арада тагын берәү, йөгереп килеп, рөхсәтсез-нисез тезелгән кешеләр арасында юкка чыкты. Савканың власть күрсәтәсе килде:

– Әй, кем ул анда? Нигә соңга калдың?

Теге, алпан-тилпән атлап, Савка янына килде, бүреген кысып тоткан килеш, җавап эзләде.

– Кайда булдың?

– Үземнең эшләр белән читкә киткән идем, Савка...

Тезелгән халык көлә башлады. Савканың чигәләре янып чыкты – ул да бит ояткa калды. Кем алдында бит әле! Салих та – командир, Савка да – командир. Барысы да тигез булырга тиеш! Тыныч булырга, ашыкмаска кирәк, дәрәҗәне саклап эш итәргә!

Шул арада дозорны табып алып килделәр.

– Кайда йөрисез?

Җавап юк.

– Кайдан таптыгыз? – Савканың бу соравы эзләргә җибәрүчегә барып кадалды.

– Авыл читендә... – Ул туктап калды. – Ял, ял итәләр иде!

– Ә-ә, шулаймы әле! – Савка, ачуланып, кыска камчысын күтәрде, Салихның усал елмаюын күреп, кулын төшерде. – Басыгыз сафка!

Салих ачыктан-ачык көлә иде инде. Степан күзен бер аңа, бер Савкага йөртә, ни булырын аңлый алмый.

– Ярар, Савелий, хафаланма. – Салих аңа эндәште. – Өйрәтербез, бик тиз өйрәтербез.

Мәйданда шунда ук «дәресләр» башланды.

Командирлар, өйгә кереп, бик зур эш башкаргандай, тагын өстәл артына утырдылар. Савка да алар артыннан калмады, Салихның игътибарлы күзләре аңа тынгылык бирми иде. Болай булгач, Степан Хәмит белән килешә, эшләнгән усаллыклар юкка чыга, элекке дуслык кабат кайта. Шунда инде ул Гәрәй белән Нинаның язмышын да килешеп бәйләп куярлар. Салих беләдер Гәрәйнең Нина дип янып йөргәнен, аның каравы да шул кызыксынудан, бәя бирүдән. Бәлки, өйләнергә, Степан кире уйлаганчы? Нәрсә ул өйләнү? Нинасыз тора алмау? Юк, андый уй да юк. Мәхәббәт? Ә нәрсә була ул? Гаилә кору хыялымы? Ә нигә кирәк әле ул гаилә, тормыш болай да матур барганда? Алдагы еллар түгел, алдагы көн турында да уйлый белми шул Савка!

Салих, сораулар биреп, Томафига бара торган иске юлны сораштырды:

– Ну, ничек яшәдегез? Партизаннар ничек?

– Партизаннар нигәдер тыныч. Бар иде элек ул юл, тик хәзер түшәлгән агачлары череп беткәндер инде. Кайчангы юл бит, кирәге дә юк, йөрүчесе дә юк. Барган да, күргән дә юк инде аны.

– Корал ягы ничек инде?

– Аз. Алтмыш бер кешегә тугыз винтовка, ике обрез. Берданкаларны җыеп алдык авыллардан. Тапканы унөч булды. Монысы корал түгел инде, хан заманыннан калган мылтыклар.

– Ярдәм итәрбез, кайгырмагыз.

Ашарга әзерләделәр, аш чыгаруны Егорьевна үзенә алды, Нинаны таныш булмаган ир-ат каршысына чыгармадылар. Калган сөйләшү юк-бардан торды. Степанга, күрсәтмәскә тырышса да, авыр иде. Дошманын сыйлый бит! Әйе, дошман да булмасын, ди, барыбер инде дус түгел... Ни эшләсен Степан, түзә тешен кысып, түзә. Җыйды аларны бер төенгә шушы уртак булган авыр йөк, сугыш йөге. Арбадан төшеп калу мөмкинлеге юк, төшеп калсаң, аңламаслар да. Әнә, Савка ашарга гына тора түгелме? Ялгыш булды, аны якынайту кирәк түгел иде. Ялгышты Степан, ялгышты!

Алыпсатарлык белән шөгыльләнү хыялы да күккә очты хәзер. Ә бит нинди планнар корган иде!

Язмыш инде: ә нигә дип монда солдатлар белән Салих кайтты, нигә башка кеше түгел әле? Тик утырып булмый, сөйләшергә кирәк. Йә аңламас. Шуңа Степан шатланып әйтеп салды хәбәрен:

– Ә-ә, безнең арестант бар бит! Партизан. Михайловканыкы. Авылга разведкага кайтканда эләктердек.

– О-о! Ә нигә эндәшмисез дә?

– Бүгенге буталышта бөтенләй онытканбыз.

– Әйдә, алып килегез мәктәпкә, шунда сорау алырбыз.

– Тәк ул бит болай да мәктәптә, базда! Тик бер сүз әйтми, бернәрсәдән дә курыкмый. – Монысын Савканың тик тормаган теле ычкындырды.

– Әйттерербез. Миндә башта сөйләшмиләр, шуннан җырлый башлыйлар!

Тагын бераз утырдылар. Тәмле иде Егорьевнаның ашлары, туйганчы ашадылар. Сүзнең әллә ни рәте булмады, Салих үзенә кирәк мәгълүматны ишетте, колагына салып куйды. Хәзер аны берни дә тотмый иде монда. Тик, утыра торгач, аның башына бер яңа уй килде. Бу очракта әсирлеккә алынганның булуы бик тә яхшы иде. Башта карарга кирәк, бер Алла мескене булса, аның кирәге юк, үз сүзен әйтә белгән кеше кирәк. Шулай уйланылган.

Киттеләр мәктәпкә. Алып керделәр Миронны, Салих каршына бастырып куйдылар. Озак карап торды Салих Миронга, шуннан, бер сүз әйтмичә, аны урап йөри башлады. Баштарак Мирон аның йөргәнен бер күзе белән озата барды, тик бераздан бу эш тәмам арытты, ул аңа карамый да башлады. Ә Салих йөрде-йөрде дә кинәт Миронның кояш үрелмәсенә көчле итеп сугып җибәрде. Бу сугудан ул бөгелеп кенә төште, тын ала алмый, куллары белән һаваны үзенә тарткандай итә иде. Савка куркудан хәтта күзләрен йомды.

– Йә, ата-бабаларын саткан зат, кайда Ильяс? Ничек аның лагерена барып була? Ничек итеп партизаннар отрядын юкка чыгарырга?

Мирон эндәшми генә кан аккан танавын кесәсендә булган чүпрәк белән сөртергә маташа, ә канның туктарга исәбе дә юк.

– Ну? Кайда Ильяс? Ничек аның белән хәбәрләшеп торасыз?

– Ильяска синең кул җитми. Кыска синең куллар! Ә мине куркытырга маташма, барып чыкмас!

– Ә-ә, шулаймы әле? – Салих ашыкмый гына, озак итеп кыйнады Миронны. Савка чыдамады, күзләрен челт-челт йомып чыгып китте. Арып туктагач, солдатларга кычкырды. – Асабыз бу бандитны, алыгыз Казанлыга!

Тынычланды бераздан. Исенә төшерде элек була торган сорау алуларны. Менә шулай итеп бераз тукмагач, барысының да теле кирәк якка ачыла торган иде. Тик Мирон... Бу мужикны болай гына алып булмас, атарга туры килер. Халыкны куркытыр өчен ул асып та куяр иде, тик туган ягына кайтып вәхшилек күрсәтү ярамас. Әти-әниләренең монда яшисе бар бит.

Класс эче тынып калды. Степан, идәнгә тамган канга карап, озак кына сүзсез утырды. Салих та азрак арттырып җибәргәнен аңлады. Соңгы вакытта ул менә шундый хәлләрнең үзенә нык йогынтысы барлыгын тоя башлады. Исертә аны бу хәлләр. Нәрсә бу? Кансызлыкмы, вәхшилекме? Ничек котылырга була бу халәттән? Ә котылып буламы икән соң?

– Ярар, Степан Акинфиевич, ярар. Сугышта боларсыз булмый! Читтән

караганда рәхимсезлек, мәрхәмәтсезлек булып күренәдер. Тик йөреп кара минем кебек сугышларда. Күңел ката шул акрын гына. – Салих бу лирик борылыштан туктарга кирәклеген аңлап алды. – Бер генә сүзем: безнең урында ул булса, алар булсалар? Шулай ук итмәсләр идеме? Э-эх!

Салих кулын селтәде. Степан кая барып эләккәнен тагын бер мәртәбә аңларлык дәлил алды Ходайдан. Нигә барырга кирәк булды икән ярдәм эзләп? Бер көн армиядә булмаган көеңә! Солдат хезмәтенең тозын тәмләп тә карамыйча! Командирмын дип, саф алдында матур атта йөрү генә дип белдеме ул отряд җыюны? Э-эх, тиле, җиңел уйлый адәм баласы!

Озак кына карап торды Салих Степанга. Аның кимсетелгән, бөрешкән гәүдәсе Җиһаншиннарның барлык үчен кайтарып бирде кебек.

– Степан Акинфиевич, элегрәк монда бер революционер сөргендә ята иде. Ул кайда хәзер?

– Никонов Яков Константинович? Ул бит Казанлыда тора. Җәй аенда килеп китә. Монда аның өе бар. Хатыны да бар.

– Нинди хатыны тагын?

– Фатир хуҗасы сугышта һәлак булды. Шуның хатынына өйләнде. – Степан җавапсыз калмады. – Аңа өяздән ризалык алды ул, бар да закон буенча. Авырып ята ул, аяклары йөрми.

– Йөрмәсә тагын! Ул бит революционер! Алардан башланды бар буталыш! – Шуннан, тавышын күтәреп, ишеккә табан кычкырды. – Савелий!

Савка урам белән өй арасын таптый иде. Нина күренмәс микән дигән өмете азайганнан-азая бара, берәр җиргә җибәргәннәр, ахры, Нина юк!

– Монда мин. Ни кирәк тагын?

– Чуров, минем белән Казанлыга!

– Нәрсә югалттым, ди, әле мин анда?

Салих бу тиклем оятсызлыктан аптырап туктап калды.

– Нә-әрсә? Син боерык дигән сүзне белмисеңме әллә? – Салих бер үкчәсендә Степанга борылды. – Болар монда тик ятып азганнар бит! Берсүзсез, алга. Минем арттан.

Шинелен каптыра-каптыра, ишеккә таба зур адымнар белән атлаган Салих артыннан йөгерә-йөгерә барырга туры килде Савкага. Эшне зурга җибәрәсе килми аның, бу шаярмый, урамга алып чыга да шартлатып ата. Бу кешедә иман юк!

Казанлыга бер туктамый чабып килеп керделәр. Атлар өстеннән пар күтәрелә, алар еш-еш тын алалар, кызарынган җайдаклар гына бу юлдан, кышкы матур кичтән, эшләячәк эшләреннән алдан ук канәгатьлек алалар иде.

Салкын кич кояшта уңган күзләре белән йолдызлар исәпли, әллә кайда җил сызгыра, җәяүле буранның беренче карлары биткә килеп бәрелә. Атлар тавышын ишетеп, авыл этләре усаллана башлады, тик кешеләрнең тәвәккәл адымнарын сизеп, тиз генә ояларына кереп кача тордылар.

– Кайсы өй? Мин монда буталып беттем инде! – Салих салкыннан шиненең якаларын торгызып куйды.

– Менә бит! Ут яна өйдә. – Савка да өши башлады. – Һе, нидер яза әле ул!

– Син – тәрәзәгә бар. Син – бакчага бара торган юлны бүл. Сез икәү минем белән ишеккә!

Савка тагын сүз кыстырды:

– Аяксыз ята ул, качмас!

– Син большевикларны белмисең! Алар утта да, суда да юкка чыкмыйлар, торып басалар!

Ишекне бәреп килеп керделәр, бер каршылык күрсәтмәгән Никоновны бәйләп ташладылар. Яков Константинович бу юлы бернәрсә дә коткара алмаячагын аңлый, шуңа да ул гаять тыныч һәм горур иде.

Антонина кычкырып елап җибәрде:

– Нишлисез? Кеше авырып ята! Тыныч кына дөнья куярга ирек бирегез!

– Кит, тиле карчык! – Савка аны күкрәгеннән этеп җибәрде. Антонина, әллә кайларга очып барып, савыт-саба куелган шүрлек белән бергә егылды.

– Ерткычлар! Барысын да тотып ябасыз! Инде урында ятканнарга чират җиттеме?

Ишеккә барып җиткән Салих кинәт туктады.

– Нәрсә дип әйттең әле? Менә мин сине дә шунда илтеп тыга алам! Кирәкме? – Кулындагы камчы белән сызгыртып, Антонинаның юка гына гәүдәсенә сукты.

– Бәхил бул, Антонина! Рәхмәт сиңа барысы өчен дә! – Никонов чак кына «Мишага сәлам!» дип өстәмәде. Монысын әйтсә, Антонинаны да кулга алуларын көт тә тор.

– Ерткычлар! Кеше үтерүчеләр! – Антонинаның тавышы, Казанлыны урап, Чияле тау башына менеп югалды.

Яков Константинович, аксый-аксый барган җиреннән туктап, Антонина белән ничә ел бергә үткәргән өенә, каерып ачылган ишеккә, капкага сөялеп елап калган Антонинага карап алды да, солдатларның этү-төртүенә буйсынып, авырлык белән алга атлады.

Авыл кешеләре, ут кабызмыйча, тәрәзә ярыгыннан урамга карап, куркып кына дога сүзләрен искә төшереп, урамдагы караңгыда кап-кара булып күренгән кешеләрне волостька таба озаттылар.

**57**

Килде, йөгереп килде икенче көнне Сафа. Иртә белән Салих әтисе өеннән чыгып та өлгермәгән иде әле. Ачуы чак кына да кимемәгән, күзләре яна, фронттан алып кайткан немецлар бүләге «кһем-кһем» тагын да арткан кебек, очраган кешеләргә юл да бирми, өсләренә менеп бара, ә юл бирергә уйламаганнары, аның белән бәрелешүдән чәчрәп, читкә очалар.

– Гаеплеләр белән тагын сөйләштем. Таныганнар алар коралны талап алган кешене. Ул – Нигъмәт. Кһем-кһем! Берсүзсез авыл артына чыгарып аттырдым әти-әнисен. Бичәсе, балалары качып калдылар. Иншалла, минем кул озын, табармын! Менә шулай, кызган тимер белән бастырырга кирәк ризасызлыкны! Әманәтлекне кертеп, ихтилалларны юкка чыгарган диярлек бит Ак патша. Юлы күрсәтелгән, файдаланырга гына кирәк!

Бу сүзләрнең күбесе – Салихның бакчасына атылган таш – моны икесе дә аңлый, тик Салих җаваплы эшне фикер аермалыгыннан башлыйсы килми.

– Ярар, Сафа абзый, стратегиядәме, тактикадамы минем ялгышлар – төбенә тарих тоз куяр. Әлегә икенче бурычлар. Кил якынрак менә бу картага. Менә Томафи яланы. Беренче керә торган юл – ат юлы, иң саклана торган юл, турыга бәреп кереп булмый.

– Степанның отрядын җибәрергә кирәк.

– Аларның коралы да ташка үлчим!

– Сиңа алар жәлме?

Сафаны үч кыздыра.

– Сафа абзый, итальяннарда бугай, «Үч салкын килеш кайтарылырга тиеш» дигән әйтем бар. Мине аларның язмышы кызыксындырмый, аларны уйласаң, тик кенә өйдә намазлыктан төшми утырырга гына кала.

Монысы инде кемгә, кай тирәгә төртелгәнен яхшы аңлый Сафа.

– Ярар, әйттем исә кайттым, авызыма су каптым!

– Танып буйлап барып булмый, аркылыга бихисап күп агач егылган. Әлегә шушы хәл. Болай итәбез. Беренче. Мин Тукмай сазлыгы аша түшәлгән иске юлдан, көтелмәгән яктан аларның лагерена чыгам. Анда урыны белән су туңган, боз. Монысы синең нигә ашыкмадык дигәнеңә җавап. Икенче. Степан отрядыннан, чынлап та, турыга Томафига һөҗүм оештырып, игътибарны бүлә торган манёвр эшләттерәбез. Өченче. Сиңа, Сафа абзый, Таныпның теге ягыннан удмуртларның Гыйбадәт тавына чыгарга кирәк. Ул тау астында Каюм мәгарәсе, беләсең. Анда кереп торасы да юк, биш винтовкадан бер-ике залп – и вәссәлам, үзе ишелеп төшәчәк. Башка төрлерәк килеп чыга калса инде, син анда засада оештырырсың.

– Әйбәт кебек тә бу план, әгәр без уйлаганча барып чыкса! Әлегә тиклем нәрсә көтеп яттык соң без?

– Баягы әйтемне исеңә төшерәм. Каршы якта да тиленәр юк. Авыз пешкән инде башкаларны сантыйга санап. Хәзер иң мөһиме: Чернушкада башка станцияләрдән минем солдатларны җыеп алып, резерв командасы әзерлиләр. Бүген-иртәгә килеп җитәчәкләр. Алар килеп җитәр алдыннан Сәлимәне волостька ябабыз. Менә шушында, Сафа ага, сиңа шәхсән йөкләмә. Төнлә аларны сиздерми генә икенче җиргә күчерергә кирәк. Бармы шундый урын?

– Ник булмасын? Данила картның урманда берничә йорты бар сунарчылар өчен. Шуларның берсенә илтеп биклибез.

– Ильяс бар булганын ташлап, Казанлыга аның артыннан киләчәк. Монда эләктерә алмасак, аны шунда урманда кулга төшерәбез.

– Булмаса, мин аларны яндырам!

Салихның мондый кыргый карашлы кешене күргәне юк иде бугай. Үзе указлы мулла булып йөри бит әле! Ярар, капланып китсен, әлегә ул кирәк! Салихның күптән түгел генә уйлаганы исенә төште: килер вакыт, асып куярбыз әле мондый тиле-милеләрне.

– Сафа абзый, төгәл вакытын иртәгә билгеләрбез. Иң җаваплысы. Көтмәс буасын шартлатуның хәстәрен күрдем. Шартлаткычны озаграк көтәргә туры килде, аның бит, җитмәсә, белгән кешесе дә кирәк! Ул да өч көннән килеп җитә. Димәк, барысын да бер ноктага атна башына тупладык. Тышта салкын, димәк, Тукмай сазлыгы туңачак – мин шуны инде ничә атна көтәм бит! – Соңгысын махсус тагын бер кат кабатлады ул.

Барып җитте, ниһаять, Сафага Салихның планнары. Менә нәрсәне көтә икән ул! Ә Сафа аны инде ничәнче кат тәвәккәллек җитмәүдә гаепли. Бу бит инде ничә мәртәбә аларның арасында әйтелеп үткән стратегик һәм тактик карар! Ул шунда ук Салихның сүзләрен хуплады:

– Көннәр салкынаерга тора, Алла бирсә! Туңар, туңар! Салих туган, аңа

тиклем, бәлки, тагын станциягә коралга барып килербез, ә? Минем гаеп бар, тик сугышта гаепнең кайчан, кайдан килеп чыгарын, кем башына төшәрен кем генә белә?

– Ярар, монысы да хак. Әзерлә кешеләреңне, барсыннар. Тик бүген-иртәгә түгел. Мин Михайловкага да корал вәгъдә иттем. – Салих Сафаның йөзе үзгәреп китүен сизми калды. – Да, бер үтенеч: халыкны куркытмый тор әлегә, безгә авылда тынычлык кирәк. Ике фронтка бүләрлек кешебез юк, күреп торасың.

– Аңладым. Бар да тыныч булыр!

– Уйлаштырып йөре әле бу планны, кайда йомшак урыннары бар, кайда уйланып бетмәгән яклары. Син беләсең, план ул – бик камил нәрсә. Ә тормышның үз планы бар.

Сафа торып басты. Тик сөйләшеп бетерә алмадылар, Салихка ашыгыч хәбәр белән кизүдә торган солдат йөгереп килеп керде. Җылы волость бинасында ычкындырган төймәләрен каптыра-каптыра, Салих Сафа белән саубуллашты.

Сафа чыгу белән үзенең егетләренә кирәкле хәбәрләрнең кайберләрен җиткерде, Михайловкага киләчәк коралның көнен, юлын белергә кушты.

* * *

Казанлыга Чернушкадан сигез-тугыз солдат белән яшь кенә бер офицер килгән икән. Ул җитез генә үзе белән таныштыргач, Салихка Зеньковский кул куйган боерыкны сузды. Анда «немедленно приступить к мобилизационным мероприятиям» дип язылган, аны үткәреп, волостьта аз дигәндә илле кешедән торган команда җыеп, станциягә чыгарырга кушылган иде. Икенче таләп – өч көннән Чернушкага кылган эшләр турында җавап тотарга килергә кушылган, үтеп барышлый полковник үзе бу җавапны тыңлаячак.

Алдарсың күпне күргән Салихны. Инспекция түгел инде бу. Ижаудагы җылы урынны ташлап кая барсын Зеньковский? Димәк, эшләр хөрти, кызыллар бастырып киләләр. Фронт тигез түгел, бер җирдә – аклар алда, бер җирдә – кызыллар. Бу боерыкның әйтелмәгән сүзләрендә ул үзенә янаган куркынычны күрә, моннан тизрәк китү планын тормышка ашыра башларга кирәк.

Тик... Ильяснең отрядын тар-мар итми китү юк! Бу хәл аның хәрбилек булмышына, профессиональ осталыгына бәйле иде. Уйламаганда, аны сугышта катнашудан башка бернинди хәрби белеме булмаган кеше узып бара түгелме? Өч көн! Шушы вакыт эчендә ул бу отряд белән эшне Ходайга тапшырырга тиеш.

Ә мобилизацияне Салих күптән көтә инде. Мобилизациясез сугыш булмый, кемдер корал белән сугышта катнашырга тиеш, кемдер шул коралны өйрәнергә тиеш, кемдер яше җиткәнне көтеп торырга тиеш. Мобилизация тәгълиматының нигезләре шул ук, гап-гади. Килгән төркемне да файдаланырга кирәк, болар чын солдатлар, аларга ышанырга була.

Казанлының үзеннән властька айнык караштa булмаган, каршы чыгарга һәрвакыт әзер булган кешеләр исемлеген ул алдан ук әзерләргә боерган иде. Анысы инде әзер. Сафа кешеләренең саны артуын да ул чынлап та теләми, уйламаганда, Михайловкада отряд барлыкка килде, аларның нинди караштa булуын Алла гына белә. Монда килгәнче Зеньковский та-рафыннан төгәл бурычлар куелды, ул бурычларны Салих читкә тайпылмыйча үтәп килә. Дөрес, ике яктан да бер-берсенә каршы кешеләрнең җыелачагын ул

һәрвакыт күз уңында тотты, тик болай ук булып чыгарын уйламаган да иде. Бер төркем – башкисәрләр, икенчесе – үзләрен беренче көннән үк полк дип атаган авыл мужиклары отряды, аларның командирлары Дедухиннан тыш шул ук мужиклар. Дедухинга килгәндә, ул җитди фигура, сугышта булган кеше, ни эшләргә кирәген белә. Төркемдә йөз кеше дисәләр дә, йөз юк, кырык кеше булса булырмы. Аларның да яртысы беренче бәрелештә үк качып китәчәкләр, монысына аның иманы камил, тәҗрибә бар.

Тик кораллары гына юк аларның. Кызык, Салих – монда гамәлдәге армиянең бердәнбер вәкиле, ә ярдәм сорап килүче юк. Сафа тиклем башкисәр Сафа үзенә өлеш чыгартты, ә болары... Ярар инде, еламаган балага имчәк бирмиләр, карап карарбыз алда ни булырын.

Сугыш тәҗрибәсен читкә куеп булмый шул – Салих үзенең тирә-ягында максатлары билгеле булмаган кораллы кешеләр булдырасы килми. Әнә, Казанлыда ышанычлы дип йөргән кешеләр Ильяс белән урманга чыгып китмәдемени? Шуңа да ул Михайловка отрядын тулысы белән мобилизациягә кертте, ә Степанны сызып ташлады, монысы инде авылда аңа булган ышанычны бик түбән төшерәчәк. Степан булмаса, Савелий берни эшли алмый, полк дигәне таралмыйча, Чернушкага барып җитә алса, аны бик тиз тәртипкә утыртачаклар. Ә Ильяс белән ни эшләргә кирәген ул белә, бер-ике көннән күрмәгәнен күрсәтер!

Яшь офицер белән килгән солдатларның берничәсен Салих үз кул астында калдыра. Монысы инде шәп, нәкъ шундый солдатлар кирәк, аларның берсе Степанның ун кешесенә тора.

Казанлыдан да алдан ук әзерләп куелган кешеләрне ул мобилизация исемлегенә кертте. Монысына да ул бик җентекләп әзерләнде, күп кешеләрнең, шул исәптән әти-әнисенең дә фикерен белеште. Исемлекнең башында кайчан да булса алар нәселенә каршы чыккан кешеләр тора, аннан соң Салихның үзенә нинди булса да сүз тидергәннәрне кертте, соңгылары – Ризван кебек азат булып, бер властьны да санга сукмаучылар.

Икегә бүлеп озатырга карар чыгардылар. Иң беренче баш бирми торган Казанлы кешеләрен озату, Ильяс белән алышта артта хәнҗәр тотып торучылардан котылу. Дедухин белән Степанның отрядын шушы алыштан соң җибәрү, Салих үзендә кеше аз булуына бик нык борчыла, бу хәлдән чыгу юлларын эзли иде.

Нинди генә матур сүзләр белән аклансаң да, мобилизация исемлеген төзүнең нигезендә гади генә үчләшү ярылып ята, моны Салих үзе дә аңлый, тик башкача булдыра алмады. Аның кыенсынганын күреп, Хәмит бер сүз белән тынычландырды: «Кемнең кулында – шуның авызында! Синең урында булсалар, башкалар әллә ни эшләрләр иде әле!»

Анысы шулай да ул шулаен...

## 58

Аркадий Дедухин, Салих белән очрашмауның дөрес түгеллеген аңласа да, түзде, бәлки, чакырыр дип тә өмет итте, тик чакырмады аны Салих. Тактика эшләрендә Салихның көчле икәне әллә кайдан күренеп тора, Аркадий бу өстенлекне аңлый һәм таный. Шуннан, Салихның хәрби дәрәҗәсе, аткарган вазифасы да югары, буйсыну баскычларын әле бит беркем дә кире какмаган. Аркадий бик яхшы, күтәренке күңел белән волостька иртән иртүк килеп керде.

Бик җылы исәнләштеләр ике офицер, балачакны җанлы итеп искә алдылар. Салих Дедухинның бу якларда ни эшләгәнен сорап тормады, бусын болай да аңларга була: боларның полкларын кызыллар тар-мар иткән, кем ничек кача алган, шулай үз ягына кайта алган. Монысы да көн кебек ачык.

Иң мөһим сорауга тукталдылар. Дедухин бик начар сүзләр белән Степан җыйган халык төркеменә бәя бирде, Степан көчләп диярлек таккан командир ярдәмчесенең бандиттан бер җире белән дә аерылмавын әйтте. Тәртип бөтенләй юк, теләсәләр киләләр, теләмәсәләр – эзләп табып та булмый. Дедухин корал алып булмасмы дип, Бөрегә элемтәгә чыккан, бөреләр аңа вәгъдә биргән. Степан отряды белән чагыштырганда, Аскында оешкан полк күпкә зур. Аның саны дүрт йөзгә җитеп килә, аны инде батальон дип атыйлар, анда тәртип тә икенче, диде Аркадий.

Салих акрын гына Дедухинга мобилизация эшләре турында планын хәбәр итте. Каршы килер дип уйлаган иде, бернинди каршылык та булмады Дедухиннан. Ул тәмам арыган булса кирәк бу ни Аллага, ни муллага булган этрәк-әләм җыеныннан. Салихның бар шартлары белән бер сүзсез килеште ул: Ильяс лагерена һөҗүм турында да, аннан соң бу төркемне Чернушкага мобилизацияләнүчеләр җыела торган урынга чыгару турында да. Ә икенче батальонның монда калуы Дедухинны ашыгыч мобилизациядән коткара, монысы да игътибарга лаек. Дедухин әйткән бер нәрсә генә уйланырга мәҗбүр итте икесен дә: исемлектәге алтмыш бер кешенең яртысын таба алырлар микән мобилизация игълан иткәч? Бер өлеше бар дөньясын ташлап чыгып качачак бит.

– Ярар ла! Безгә бит бары илле кеше табу кирәк. Казанлы зур, монда егермене ничек тә табарбыз, Степаннан кырык кеше. Шуннан, Аркадий Михайлович, аларның командиры итеп калдырыйк Савелийны. Ул малай барысына да әзер, тик күренергә, тик аны күрсеннәр. Без дә тыныч булырбыз Чернушкага алып барып тапшырганчы.

– Ул гынамы! Партизаннарга каршы чыгуны да аңа йөкләргә кирәк!

Чыгасы килми Аркадийның сугышка бер эшкә дә ярамаган команда белән. Бу алдан ук юкка чыгуга бәрабәр, юньләп ата да белмәгән кешеләр белән нинди җиңү булсын, ди, инде! Булган-булмаган сәбәп табып, Бөрегә чыгуы турында да хәбәр итте:

– Бөредә безнең полклар белән кызыксыналар. Ярдәмгә прапорщик Рукавишников киләчәк. Әгәр кеше күп җыелса, полковник Старовны җибәрәчәкләр дигән сөйләшү дә бар. Мине доклад белән чакырдылар. Бүген-иртәгә чыгарга торам.

Салих тиз генә уйларын уйнатып алды башында – алдашумы бу, чыгып качумы? Икенчеседер! Бөре белән араларны бозу килешмәс дип ризалашты.

– Ярар. Сөйләшүнең йомгагы шул. Монда безнең кызу эшләр башланганчы, алдарак казанлыларны озата торырырга кирәк булыр, мин исемлеккә ышанычлы булмаганнарны керттем, чынлап та, безнең артта хәнҗәр тотып торучылар кирәкми. – Сафа белән сөйләшүне исенә төшерде Салих. – Бу – бер. Михайловка тирәсеннән җыелганнарны Ильяска каршы файдаланабыз. Бу – ике. Аларны да шунда ук станциягә озатабыз. Бу – өч!

Дедухин бик канәгать булып чыгып китте. Салих кешеләрнең ничек итеп җаваплылыктан баш тартуларына аптырап утырды да кизү торган солдатка старшина Зиннәтне табарга кушты. Халыкны җыеп, мобилизация турында

белдерү ясарга кирәк, бусы инде старшина эше. Исемлек тә Салихтан түгел, халыкка старшина Зиннәттән җиткерелергә тиеш. Салих монда беркем дә түгел, битарафның да иң битарафы булып күренергә тиеш бу эштә. Адмирал Колчак исеменнән бит мобилизация.

Зиннәт килгәч, бөтен мәшәкатьләрне билгеләделәр. Әллә ни күп сөйләшеп тормадылар мобилизациягә эләккәннәр белән. Иртән үк «призывной лист» тоттырдылар, шунда ук кузгалу сәгатен билгеләделәр. Егерме кешене бернинди матур сүзләрсез, җырсыз-нисез яшь офицер командасы астында озатып та җибәрделәр. Тыныч кына үтте авылда бу юлы мобилизация.

* * *

Бөтенләй югалып калды Ризван. Мобилизациядән түгел, аның менә шулай көтмәгәндә алга килеп төшүеннән. Күпмегә сузылыр ул сугышы, кем белә. Бәлки, сугышыр кешеләрне кырып бетергәнче барыр? Бәлки, аның башы бар, азагы булырга охшамаган?

Гыйльминурны танырлык түгел. Әле генә балалар кайгысы дөньяның бар кызыгын үзе белән алып китте, инде монысы. Әллә чыгып китәргәме күз күргән якка? Кем таба ала Ризванны. Бу турыда сөйләшү булды, тик Ризван аны шунда ук туктатты. Ничек итеп инде ир-егет качып йөрергә тиеш, ди, ил чакырганда? Шул тиклем ихлас итеп әйтте ул бу турыда, шунда ук бу теманы япты да куйды.

Гыйльминур саклап килгән серен чиште Ризванга – бәби көтәләр икән алар. Ризван бар бүлмәләрендә биеп чыкты, аның мондый шат күңелле булганын күптән күргәне юк иде Гыйльминурның...

Төне буе сөйләшеп чыктылар: ниләр эшләргә, кайсы очракта нинди адымнар ясарга, авырлыклар килгәндә, ни эшләргә, бик кирәксә, ниләрне беренче итеп сатарга. Бернинди дә икеләнү юк – Ризван кайтачак, бер ел йөрерме, икеме, әллә күбрәкме. Авыр булса да, түзәргә, алга карап яшәргә!

Иртән, Гыйльминур йоклаганда, Ризван йортын урап чыкты. Яшел наратка килеп, аның кызыл сары кайрысына кулын куеп бик озак торды Ризван. Ниләр уйлады икән шул чакта бу киң, бар дөньяны үзенә сыйдырган күңелле кеше?

Атка утырып киткәч, инде авылны чыгып барганда, Ризван сикереп төште дә Гыйльминур янына йөгереп килде. Әйтелмәгән сүзе калган икән:

– Әгәр кыз туса, Хәмдия дип исем кушарсың. Малай булса... әйдә, аны да минем кебек Ризван дип атарбыз! Хуш!

Арбаны куып җитеп утырды да китте.

Гыйльминурга көн яктылыгы юкка чыккандай булды, кояшның болыт аша караган саран нурлары сүнгәндәй тоелды...

Ерактан Ризванның көчле тавышы араларны юк итеп, озатучыларга килеп җитте, йөрәкләрне бораулап үтеп керде:

Кычкырма ла, кәккүк, ай, каршымда,
Кычкырсана агач башында.
Талдин талга, тал тибрәтеп,
Сайрый сары сандугач.
Җырлау түгел, еларсың да
Өзелеп-өзелеп сагынгач.

**59**

Иртәгә булачак җәзаны үткәрү тынгылык бирми Салихка. Озак уйлады ул бу турыда. Ул аны махсус рәвештә мобилизациягә эләккәннәрне җибәргәннең икенче көненә калдырды. Куркытырга кирәк халыкны. Тыңламасагыз, бер генә юл бар. Ә ул юл кая алып барганын бар да күрергә тиеш. Бу – бер. Тагын бер ягы бар бу эшнең. Кулга алынганнарның икесе дә рус кешесе. Шулай килеп чыкты инде менә. Әгәр ул берүзе генә бу эшне башкарып йөрсә, ике милләтне каршы куюы була. Шунда ук әйтәчәкләр, Салих килеп, русларны кырып китте дип. Кеше бит белми иртәгә Ильяс отряды белән ни булачагын. Шуңа да ул Степан белән Савкага иртән үк килеп җитәргә әмер бирде.

Әсирләр белән эшне тизрәк тәмамларга кирәк.

* * *

Салкын, аксу томанлы таң атты. Бер-берсенә ябышып диярлек торган соры болытлар, томан белән кушылып, җиргә тиклем төшәләр, ә усал җил караңгы чырайлы кешеләрне камчылый, агачларның ботакларын җиргә тиклем иеп, нидер сөйли дә сөйли иде.

Базар мәйданына елаган әби-чәбине, хатын-кызларны, аларга тотынып атлаган бала-чаганы, йөзләре болытлардан да кара булган ирләрне куып китерделәр.

Салих, Степан, Савка атта, мәйданның бер ягыннан икенче ягына йөреп торалар, халыкны ашыктырып бер җиргә туплыйлар. Салих атында берни булмагандай матур итеп утыра, аның төз аркасы теләр-теләмәстән ихтирам уята. Степан җилдә яшьләнгән күзләрен кул аркасы белән сөртә, аларның яшьле булуы башкаларның күзенә караудан азат итүе өчен ул шат та иде бугай. Савка өчен бу хәлләр бер уен, аларның җитдилеген ул аңлап та бетерми иде әлегә.

Әсирләрне алып килделәр, иске зират ягыннан мәйдандагы халык алдына бастырып куйдылар. Никоновның ике аягы да аксый, авыз чите белән генә елмаеп, башын горур күтәреп, халыкка карый. Аннан хәтта сорау алып та тормадылар. Салих кулын гына селтәде: «Нәрсәгә? Революционер булуы да җиткән! Әйбәт кешене Мәскәүдән бу караңгы почмакка сөрмиләр!» Бер нәрсәне аңламый Салих. Шушы революционер мондагы бик күпләрнең күзен ачты Рәсәйдә барган хәлләргә, аңа килеп киңәш алалар, аның сүзе, аңлатмалары бу болганчык заманда кояш нуры кебек юлны яктырта. Асылынып төшкән сынган кулбашын икенче кулы белән тотып, кичәге кыйнаудан һушына да кайтып өлгермәгән Мирон бар дөньяга битараф булып атлый, бөтен халык өстенә караш ташлап, якыннарын эзли. Башка килер кеше калмаганын аңлап, Салих сүз алды:

– Җәмәгать! Сез беләсез, безнең яклар элек-электән югары властька терәк һәм таяныч булган. Ничә кешебез сугышларда Рәсәй өчен башын салды, илгә, патшага тугры булдылар. Көчле ике дин безне тотып килә, бу яктан да бер нинди каршылык юк. Ничек итеп без шушы көнгә калдык? Ничек итеп безнең изге җирләрдә халыкны икегә бүләрлек көчләр барлыкка килде?

Сөйли белә Салих. Җиңел генә бер телдән икенчесенә күчә, кешеләрнең күзләренә карый, алардагы сүнеп барган өмет чаткыларын җанландырырга тырыша.

– Бүген сезнең каршыгызда ике Алласыз басып тора. Берсен ничәнче мәртәбә Мәскәүдән сөргенгә җибәрәләр, инде монда килеп, халыкны аздырып ята. Икенчесе, безнең авыл егете Ильяс котыртып төзегән отрядка кереп, безгә каршы сугыш әзерләп ята. Шушы бәндәләр аркасында кан коябыз, туган туганны үтерә. Күптән, күптән асып куярга кирәк иде аларны, бу эшләрнең башында торганнарны. И повесим! Шул чакта мондый сугышлар да булмас!

Озак сөйләде Салих. Тик бераздан шинель якасы ышыгыннан чыккан бер колагының өшүен сизде, ә күпмедер вакыт узгач, бу сизү юкка чыкты. Тотып, бармак белән ышкып җибәрәсе дә соң, кая ул! Горурлык бирми! Бер генә юл – тизрәк эшне тәмамларга.

– Адмирал Колчак тарафыннан бирелгән власть нигезендә, сугыш вакытында дошманнарны хөкем итү буенча миңа бирелгән вәкаләтләрдән файдаланып, бу кешеләр атарга хөкем ителде. Так будет со всеми врагами! Мин сезгә мөрәҗәгать итәм, җыелганнар: әйтегез, кайтсыннар Ильяска алданып киткәннәр. Бүген гафу итәрбез. Тик иртәгә соң булачак!

Халык арасыннан хатын-кыз кычкыруы ишетелде:

– Нигә җәфалыйсыз аларны? Ерткычлар! Җибәрегез!

Кешегә күрсәтми генә колагын ышкыган Салих башын күтәрде:

– Нәрсә булды? Кем бу?

Кем бу дигәне алга табарак чыгарга тырышкан Антонина иде. Тик аны җибәрмәделәр. Шунда ук әлегә бер ни аңламаган балалары белән Марфа басып тора иде. Балалар, әниләренә сыенып, әтисенә карыйлар, ә Марфа якын-тирәдәгеләр ишетерлек итеп кенә пышылдый:

– Мирон! Нәрсә эшләттеләр сине, ә?! Ни өчен? Кем? Алла каргаган тормыш! Ни өчен безгә бу җәза, ә? – Кинәт аның тавышы күтәрелеп китте, ул алга омтылды.

Шул вакытта көтелмәгән хәл: бөтен мәйдан кычкырып елый башлады. Башта олыраклар, аннан балалар. Салих, аптырап, юлдашларына карады. Степан, башын иеп, ияргә чумып утыруын белде, Савканың иреннәрендә мыскыллы көлүне күреп, Салих тиз генә солдатларына боерык бирде.

Болытлар бер мизгелгә кояшны ачып җибәрделәр. Яков Константинович, хәтерләп каласы килгәндәй, күзен йоммый да аңа карады. «Өч мәртәбә дар агачы тия язып яннан үтеп китте, ике дистәгә якын ел төрмәләр, сөрген. Димәк, үлем шуннандыр, бу юлы башкасы юк!» Винтовкалар йөрәгенә төзәлгәнче, ул халыкка бер-ике сүз әйтеп өлгерде:

– Кешеләр! Курыкмагыз, көрәшегез! Без җиңәрбез! Көрәшегез! Яшәсен революция! – Мылтыктан очып чыккан утлы пуляның йөрәген тишеп үткәнен ул сизде. Тик йөзендә калган елмаю, ул егылганда, тагын болытлар арасыннан килеп чыккан кояшта тып-тыныч булып күренде...

Кичкелеккә авылда беркем дә ут кабызмады. Бары тик шәмнәрнең саран яктылыгы гына аларның кырыс йөзләрен яктырта иде, диварларга төшкән шәүләләрдә төенле-тамырлы зур куллар тамарга әзер булган яшьләрне йодрыклары белән сөртәләр иде.

**60**

Бик озак мәйданны урап йөрделәр Марфа белән Антонина. Атылганнарга якын җибәрмәде солдатлар. Төштән соң килеп алырсыз диделәр. Көн салкынайта, Марфаның балалары туңа башладылар, ашау-эчү онытылды.

Аптырагач, Антонина Марфаны ияртеп, өенә кайтып китте. Алар кайтуга күршеләр ишекне урынына куеп ныгытканнар, мичне ягып җибәргәннәр. Күрше хатыннары, аларны күреп, булган ашамлыкларын җәймәгә төреп алып, йөгереп кереп җиттеләр, балаларны чишендереп ашарга утырттылар.

Бернәрсәгә дә кулы бармый иде Антонинаның. Авыр атлап килеп утырды Яков Константиновичның өстәл янындагы яраткан урындыгына. Өстәлдә аның язулары... Шулвакыт аның әйткәне келт итеп искә төште: минем белән ул-бу булса, Андрейга тапшырырсың аларны. Алда ни буласын белгән бит...

«Сиңа тагын бер хат, Андрей. Илдә нинди хәлләр булып ята, күрәсең дә, беләсең дә. Мәскәү кайныйдыр инде. Эх, бер күрәсе иде шуны! Ышанычым арта көннән-көн: мин дә читтә булмадым зур эшләрне китереп чыгарган әзерләнүләрдән. Егерме елдан артык бит! Юкка чыкмады мин керткән өлеш!

Минем күзлектән чыгып караганда, Казанлыны зур үзгәрешләр көтә. Былтыр минем янга сугыштан кайткан бер егет килеп керде. Күп нәрсә турында сөйләштек, Казанны, Мәскәүне искә алдык. Бу егеттә эчке бер көч, сөйләшү иплелеге бар. Авылда да, волостьта да аны ихтирам итәләр. Ул гына да түгел, акыллы, белемле, Уфада данлыклы «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаган. Кышларын укыган, җәйләрен Уралда шахтада эшләп, дөнья күргән. Эшче дип әйтергә була. Безнең Плеханов эшчеләр сыйныфының алга чыгачагын фараз иткән, ә соңрак Ленин моны тәгълиматтан гамәлияткә күчерә. Менә бит, эшчеләр дөньяны дер селкетәләр бүген.

Казанлыда Салих. Аса, ата. Михайловкада Степан белән Савка Чуров котыралар. Минемчә, Чуров монда Степаннан зуррак командир булып китте. Степан йомшак кеше, аңа Савкада булган ерткычлык җитешми. Ә тегесендәме? Кайдан аладыр ул аны яшь кенә көенә!

Хәзер Мәскәүне бик еш искә алам. Гаиләдә мин артык кеше булдым. Университетта сәясиләр белән дуслашуны әти кабул итмәде, мине өйдән куып чыгарды. Ул мине гафу үтенер дип уйлаган иде бугай. Тик миндә ул вакытта ук революцион тугрылык бар иде шул...

Көзен атылган йолдыз кебек беренче мәхәббәт үтеп китте. Ул да революционерка, туйга таба бара иде безнең эшләр. Тик мине кулга алдылар, өч көннән – аны. Шулай итеп иң бәхетле буласы көнебез иң кара көнгә әйләнде. Бер елдан аңа рөхсәт бирделәр минем кырга килергә. Озын Себерне үткәндә, салкыннарда ул бик тиз китеп барды...

Моны ишеткәч, мин карда-бозда аунадым, аның кебек салкын тисен дип, яшисем килми иде. Иң якын кешемне югалтканымны аңладым, ничек итеп дөньядан китүне сайлый башладым. Чернышевский белән таныш бер революционер ярдәм итте, яшәргә өйрәтте. Шуннан гына азрак суынды янган йөрәк, тормышның алдагы утлары күренә башлады.

Бу сүзне дәвам итеп, шуны да әйтәм. Яшисе килү миңа бары монда килгәч кенә тулысынча кайтты. Аның сәбәпчесе булып, синең әниең Антонина торды. Ул булмаса, мин белмим, ничек яшәр идем икән монда? Кечкенә адымнар белән мин бу дөньяга кайта алдым, минем өчен дә дөньяның төсләре яңарды, миндә дә өмет уянды. Рәхмәт Антонинага, яраткан кешемә!

Монысы тарих, үткән заман!

Көрәш, нинди генә булмасын ул, җиңел түгел, бик күп көч, үзеңне аямауны таләп итә. Без моңардан курыкмадык, курыкмыйбыз да.

Шуннан, мин артык кайгырып та бармыйм эшләргә өлгермәгәннәргә. Мин әле дә изгелек-игелек сибәм киң кырларга. Минем горурлыгым – минем эшләрем. Мин әллә кайчан уемнан чыгарып ташладым «кирәк булганнармы алар» дигәнне. Кирәк, кирәк булган алар, Андрейка! Тамчыдан су җыела, тамчы таш тишә! Тагын фикерне өзгәләп, бернинди бәйләнешсез яза башладым бугай. Аңларсың дип уйлыйм, мин бит тик синең белән генә сөйләшәм. Картлар шундый инде, сәер кешеләр, сөйләргә яраталар. Кемгәдер бу ошамыйдыр, тик син мине аңларсың, улым (кара, мин сине инде улым дип рәттән икенче хатта атадым!). Без әле синең белән бу эшләр турында бик җентекләп сөйләшербез, бирсен Ходай! Сугыш беткәч, тын бакчада, әниең ясаган тәмле чәйне эчкәндә. Ерак түгел инде ул көннәр, түз!

Дулкынлана башлыйм мин алдагы көннәрне уйласам. Ул көннәр якты һәм иң матуры булачак! Якын инде алар.

Күрербез, күрер...»

Бу сүзләрдән соң кәгазь битендә инде кибә башлаган куе кызыл кан табы ята иде.

**61**

Кичкә таба килеп житте Томафига Казанлыда булып яткан хәлләр турында күңелсез хәбәр. Партизаннар һәрбер учак кырында җәзаланган ике көрәштәшләрен искә алалар, үч алу теләге аларның бармакларын бер төенгә төенли. Сөйләшүләрнең төбе бер – Яков Константинович һәм Миронның фаҗигале язмышы. Фаразлар күп.

– Ходай гафу итсен бу сүзләрем өчен. Мирон – сугышчы, партизан, ул безнең белән. Ә нинди гаебе бар Никоновның?

– Никонов бит ул большевик та түгел! Аның нинди катнашы бар шушы туган белән туган арасында барган сугышта?

– Нигә суд та юк, башка да юк?

– Икесе дә жәл инде, жәл...

– Никонов авырып ята инде икенче ел, аягына да баса алмый. Аны ату – бу зур гөнаһ. Аллаһы алдында да, кешеләр алдында да.

Төйнәлә йодрыклар, эшчән куллар матур итеп дошманга берне сыларга ук-җәя кереше кебек тартыла. Кайчандыр язылып китәргә тиеш бит инде бу кереш? Беркем дә шул язылу астына эләгергә теләми иде, аһ, теләми иде.

Ильясның отряды үзе дә менә шул керешне хәтерләтә иде бүген.

Караңгы төшүгә, Томафи карт өе алдына бар халыкны җыеп алды Ильяс. Бик авыр сөйләшү көтә иде кешеләр белән.

– Иптәшләр! Безнең хәлләр, күреп торасыз, җиңелдән түгел. Халык салкыннан авырый башлады, ачлык та бүген-иртәгә бугаздан алырга тора. Тагын ике яктан Салих белән Степан кысып алырга әзер. Нәрсә эшли алабыз да нәрсә эшләргә тиешбез бу очракта? Исән каласы килсә, җиңеп чыгарга уйласак, менә нәрсә турында уйларга тиешбез.

Ильяс җыелган халыкка күз йөртеп чыкты.

– Әлегә нәрсә бар бездә? Һәр адым саен сизгерлекне югалтабыз. Кичә өстәмә сакны тикшерергә чыктык. Кайда йөри, ди, ул сак? Күрше удмурт авылына киткән яртысы. Кайда Катнаш отрядның командиры?

Катнаш дип төрле авылдан җыелган отрядны атыйлар, аннан башка

Казанлыдан беренче, икенче, Михайловка отрядлары бар. Ялан уртасыннан урта яшьләрдәге мыеклы кеше, Ильяс янына килеп, усал итеп ике сүз әйтте:

– Ә нәрсә, гаеплеләр икән, җәзаларга кирәк.

– Әйе, сиңа җиңел генә болай дип әйтү. Безнең турыда уйладыңмы син?

– Айдан артык монда ятабыз.

– Ә нигә үзебез һөҗүм итмибез? Салихның чыкканын көтеп ятабызмы?

Туктатты бу бәхәсне Ильяс.

– Барыбыз да беләбез ачлык, салкын турында. Без моңа әзер идек түгелме, партизаннар булып китеп барганда?

– Барысына да әзер идек. Тик Томафида кыш чыгарга түгел.

Ильяс чыдамады, тавышын күтәрде.

– Кем әле ул безнең шундый батыр?

Тынычлык урнашты. Бары өстә җил уйнаганы ишетелде, озын төз чыршылар ыңгырашып атынып алдылар, учактан, көлтә булып, очкыннар күтәрелеп китте. Куера башлаган караңгыда учактан төшкән кызыллык Ильясның кырыс йөзен тагын да усалрак итеп күрсәтте.

– Мин, мин әйттем моны. – Кешеләр тавышка борылдылар. Тун төймәләрен эләктерә-эләктерә, Мостафа карт торып басты. – Мин әйттем. Дөрес түгелме әллә? Сүз синдә генә түгел, Ильяс. Үзебез гаепле килеп чыккан салкын тиюгә, ачлыкта да үзебез гаепле. Нигә дип урманга килдек? Берәр күрше авылга гына китеп булмадымыни? Бәрелеш барыбер булачак, шулай түгелмени, кордашлар?

Халык шаулашып алды. Алар ышанычлы, бер-берсен бар да яхшы белә, йә туган, йә күрше. Шуңа Ильяс барысын да турыга әйтергә булды.

– Сезгә җиткермәгән бер-ике сүзем бар иде. Без монда тик яту берничә нәрсә белән бәйләнгән. Сез Салихта көч, корал күбрәк икәнен, Степан да кеше җыйганын беләсез. Үзебез генә чыгып җиңә алмаячагыбызны аңлыйсыз. Тимер юл буенда берничә кызыл партизаннар отряды бар. Шулар белән бәйләнешкә керү өчен мин кешеләр җибәрдем. Бүген-иртәгә алар кайта. Шул партизаннар белән бер булып чыгабыз тагын бер-ике көннән. Кемнәр ни эшләячәк, командирларга җиткерермен. Алар кайткач.

Аңлады халык. Шунда ук карар кабул иттеләр: тәртипне көчәйтергә, дозорны еш алыштырырга, аларны гел тикшереп торырга.

Ильяс учак янында утырып калды. Эрегән кар учакны түгәрәк булып урап алган, эссе көл, карны учактан тагын да ерагайтып, су юлы ясый.

Китәргә йә бәрелешергә! Әгәр кызыл отряд белән хәбәрләшеп булса, партизаннар бергә чыгарга әзер.

* * *

Сүнеп баручы учакның көлгә әйләнеп яткан кисәүләре караңгы төнне яктырта алмасалар да, лагерь буйлап йөргән сакчылар төркеменә билге булып хезмәт итәләр. Урман эчендә тынлык: кара-яшел чыршыларны тибрәтүче җил дә юк. Ара-тирә атларның пошкырган ишетелә. Алар тартылып киткән, атларга ашарга җитми. Кар яумагач, үлән таба алалар әлегә, имән, каен, юкә яфраклары да ярап куя.

Башта төрле уйлар кайный. Казанлыда Сәлимә, бәби көтүнең соңгы атналарын үткәрә. Мирон, Яков Константинович өчен үч тойгысы кыза. Ильяс шинелен киде дә һәр төндәгечә лагерь буйлап китте. Нәрсә эшләргә? Чигенергәме? Әллә һөҗүм итәргәме? Кайда сез, Шакир белән Митька?

Вакыт тар, вакыт кыса! Сездән җавап булса, болай ук авыр да булмас иде бер карар кабул итәргә.

Сакчыларның тавышы коры иде:

– Кем килә?

– Үзебезнекеләр!

Караңгыдан ике кеше, Галләм белән Карам чыктылар.

– Ә, Ильяс! Йокламыйсыңмы?

– Юк, бабай. Йокы бөтенләй качты әле.

– Өлешеңә төшкән көмешең, энекәш! Кешеләр белән җитәкчелек итү җиңелдән түгел!

Ильяс бабайның үзгәреп киткән йөзенә карады. Аның түгәрәк ак сакаллы битендә учакның ялкыннары биеп ала, хәтта шул арада картның суырылып киткәне ачык күренә иде. Түзә Галләм карт, түзә. Беренче көннән үк Ильяс белән, бер адымга да читкә китми, ярдәм кулы һәрчак сузылган.

– Чигенү турында уйламыйсыңдыр бит?

Ильяс, иелеп, учак күмереннән озаклап тәмәке кабызды.

– Юк, Галләм бабай, юк. Сугышып алмыйча, беркая да китмибез. Казанлыны алардан чистартмый торып тынычланырга урын юк. Шуннан. Монда килеп урнаштык, бер айдан артык өшеп-туңып ятабыз. Иптәшләребезне югалтабыз. Кичә генә Яков Константинович Никоновны һәм Миронны атканнар. Бөтен каршы булган кешеләрне мобилизация дип сугышка озатканнар. Оят! Отряд бар, корал бар. Иртәгәдән соңга кузгалабыз. Син ничек уйлыйсың, әгәр бер төркем Чияле тау ягыннан, Рәхимә ерымына чыгып, атышуны башлый. Ә без, Тукмай сазлыгын чыгып, аларга аркадан һөҗүм итсәк?

– Булырдай кебек тә ул. Тик сазны чыгу – ай-һай, булырмы икән?

– Сиңа ышанам инде! Син юлны беләсең, анда булганың бар. Эх, Ризван өйдә булсамы... – Ильяс бер мизгелгә туктап калды. – Әгәр Тукмайны Танып яры буйлап үтеп, Чана чыгыш аша Көтмәс елгасын кичсәк, аннан Чияле тауга күтәрелеп, Рәхимә ерымына урнашсак, авыл уч төбендәге кебек була бит.

Галләм баягы сүзләрен кабатлады:

– Матри, ә! Начар түгел, начар түгел! Бу бит бөтенләй яңа юл һөҗүм өчен! Моңа тиклем аны уйлаган да, караган да булмады. Ә мин алып чыгармын төркемне, кайгырма!

Урманда тыныч, җил дә юк, бер тавыш та юк. Йоклаганнар йоклый, кемдер, үзенә генә шәм кабызып, кирәкле эшләрен аткара.

Ильяс Карамга борылды да елмаюын сакал эченә яшереп эндәште:

– Нәрсә, Карам, өйгә, җылыга кайтасы килмиме?

Карам да елмайды.

– Юк! Көтәрләр, беркая да китмәсләр өйдәгеләр. Тик балаларны күрәсе килә дә ул...

– Күрерсең, күрерсең, Карам. Озак калмады, Алла бирсә!

Шунда аерылды юллары Ильяснең сакчылар белән. Күңелдә җиңел булып калды. Карар инде әзер! Иртәгә төркемнәргә бүлеп, бурычларны аңлатырга һәм Аллага тапшырырга! Аз, әлбәттә, халык. Тик корал юнәттек, кешеләр әзер. Салихта да әллә ни күп түгел кеше. Степанның кешеләренә ышаныч зур түгел, анда сугышыр кеше юк. Төбәктә кем хуҗа икәнен күрсәтергә кирәк халыкка. Һәм бу хуҗа алар түгел, ә безнекеләр!

Тормышка ашырылачак план күз алдына бербөтен булып килеп басты. Зур булмаган беренче төркем, Рәхимә ерымына чыгып, акларның башын бутап, ялган һөҗүм оештыра. Икенче, төп төркем, Үгез чишмә ягыннан урап үтеп, Казанлыга волость бинасы ягыннан бәреп керә – салкын, сазда су туңа башлаган. Әгәр кызыл Тауштан партизаннар килеп җитешсә, алар Чернушка юлы белән Казанлыга керәләр. Бу яктан Салих һөҗүмне көтә, шуңа аларга каршы пулемёт куелган, окоплар чылбыры ике-өч катлы. Вакытын билгелисе калды, тик анысын Тауштан киләчәк партизаннар белән бәйләргә кирәк. Аларсыз авыр булачак, аларсыз чыгу дөрес түгел. Салих ягында әзерләнгән солдатлар, сугыш алып бару кануннарын һәм кагыйдәләрен югары дәрәҗәдә белү, аның яклы булган, партизаннарга аяк чалырга әзер булган бихисап күп куштаннар, Михайловка отряды, коралның күп булуы, тиз итеп күчеп йөрүче атлы кече төркемнәр, арттан һәрвакыт этлек ясарга әзер булган Сафа башкисәрләре, алар ягында көннән-көн салкынаеп барган һава торышы.

Кызганыч, партизаннар ягында болар юк. Димәк, җиңү – батырлыкта, Салихныкыннан үзгә булган план булуда, аның уңышлы килеп чыгуында.

Инде ничәнче көн бу уйлар йоклатмыйлар Ильясны.

Караңгыда берничә мәртәбә егыла язып барып җитте ул яр буена. Ильяс Әхтәм белән яр буенда җиргә казып эшләнгән урынга күчкән иде күптән түгел. Җылысы да бар – кемдер, каршы як таудан ташлар алып чыгып, мич тә чыгарып куйган. Анда кайтып хуш исле чыршы ботакларына башын салу белән ул йокыга талды.

Салкын суда коенганнан соң тирән йокыдан инде терелгән Әхтәм, тәмләп-тәмләп, авызын чапылдатты, йокы аралаш үзе генә белгән телдә нидер сөйләп алды, көрсенеп куйды да тагын тынып калды.

Иртәне көтеп, дөнья тынды.

**62**

Хәмитнең ике өе арасында күбәләк кебек очып йөргән Сәрия каршында кинәт эчеп алган Салих пәйда булды.

– Ә-ә, күрше кызы! Сәрия! Нәрсә эшлисең болай йөгереп?

– Суга... барам... – Куркып кына җавап бирде Сәрия, ишеккә таба чигенеп.

– Ә нигә керегә киттең? Әйдә, үт алга! – Калтыранган тавыш белән тагын эндәште Салих.

Сәрия туктап калды. Кинәт Салих алга атлады, Сәрияне беленнән эләктереп, мунчага таба тартты. Көянтә һәм буш чиләкләр дөбердәп, идән буйлап тәгәрәп киттеләр.

– Җибәр, Салих абый, нишлисең?

– Эшләмим, берни дә эшләмим!

– Кычкырам бит хәзер! Җибәр! – Сәрия ишек яңагына тотынды. Салих җиңел генә аның кулын ычкындырды, мунча ишеген ябып бикләп куйды.

– Әллә кайчаннан бирле карыйм мин сиңа, кызыкай! Менә син минем кулда!

– Җибәр, җибәр дим! Ярдәм...

– Беркем дә юк монда. Беркем дә ярдәм итмәс! Шаулама!

* * *

Өйгә кайтты да егылды Сәрия. Нәгыймә нидер булганын сизеп, аның янына йөгереп килде:

– Нәрсә булды, кызым?

Бер сүз әйтми елады да елады Сәрия. Нәгыймәнең йөрәгенә уклар кадалды, инде сиздe ана эшнең нидә икәнен.

– Салих... көч... – Сулкылдавы сүзен бүлде Сәриянең.

– Әй Аллам! Монысын да күрәсем бармыни соң? – Хәлдән таеп, әнисе кызы янына бөгелеп төште...

* * *

Акрын гына тынычланды тормыш Нәгыймәнең өендә. Сәриянең элек йөзеннән төшмәгән елмаюы гына юк иде хәзер. Сәлимә белән алар аерылмаслык ахирәткә әйләнделәр, Сәриянең дөньяга яңадан кайтуында Сәлимәнең урыны бәяләп бетергесез. Нинди генә хәлләр турында алар сөйләшмиләр, алдагы көннәргә нинди кенә планнар кормыйлар, йә булмаса кичләрен икесе бергә, кочаклашып, бер-берсен тыштан гына түгел, йөрәк түреннән җылытып утыралар, үзгәргән һава торышына дулаучы бәләкәй кешенең хәрәкәтләрен тыңлап, көләләр. Сәрия шул вакытта акрын гына җырлый башлый, тик ул яраткан җырының азаккы дүртьюллыгын гына җырлый әлегә... Тирән җан яралары тиз генә төзәлмиләр шул!

Иртә дә генә торам, юлга чыгам,
Курай кисеп алам камыштан.
Нигә моңлы син, дип сорамагыз,
Моңлы бала булдым тумыштан.

Нәгыймә дә үзгәрде, ул инде кайчандыр булган тыныч, юаш, кыюсыз, изелгән кеше түгел. Рәхимә эшкә чакырып карады, тик файдасыз, кая ул! Әйләнеп тә карамады Нәгыймә. Тиргәшә, әйтмәгән сүзләре калмады Рәхимәнең, бар тырышканы мыскыл итү һәм рәнҗетү:

– Хәерче! Кыланышына үләрсең! Ничек ашатырга уйлыйсың кырык балаңны? Шулмы синең рәхмәтең мин күрсәткән игелекләремә? Исеңә төшәр әле бу игелек хәер сорашканда! Аягың да булмасын минем өйдә, хәерче!

– Булмас, булмас, кайгырма! Синнән файда күргән булмады, тиешлесен түләмәдең, биргәне – юньле кеше этенә дә бирми торганы!

– Әле син шулай дисеңме тагын?

– Менә синең малаең да шундый оятсызлардан, Алла каргасын аны! – Нәгыймәнең тавышы калтырап китте. – Кызымны харап итте!

Рәхимәнең күзләре майлы ояларыннан бәрелеп килеп чыктылар.

– Минем улым? Син... син ничек оялмый сөйлисең бу сүзләреңне? Әфисәр улым турында! Кем ул сиңа? Карарга кирәк иде азгын кызыңны! Минем улым әфисәр, ул андый түгел!

– Шундый булып чыкты, бел! Беркайчан да онытмабыз аның бу оятсызлыгын, безнең башка төшкән бу кайгыны! Ярар, ярар, безнең урамда да бәйрәм булыр әле, Алла бирсә! Барысы да алда!

Рәхимә калтыранып елый башлады, ишеккә карап, кычкырып-кычкырып, ярдәмгә чакырды:

– Хәмит! Хәмит! Кайда син? Нәрсә сөйли бу хәерче? Салих улым!

Нәгыймә аның гаҗизлегенә карап елмаеп тора бирде. Өйдән матур хәрби киемдә Салих чыкты.

– Нәрсә булды? Әни? Нәрсә?

Рәхимә аның янына ашыкты, бармаклары, куллары белән Нәгыймәгә күрсәтеп:

– Ул.. ул... сине... Син бит андый түгел, улым? Сәрия, ди...

– Нәрсә булды? Нигә елыйсың?

Салих Нәгыймәгә карады да бер мизгелдә аның йөзе кызыл төскә керде.

– Менә ул... ул рәнҗетте! Синең улың кызымны җәберләде, ди! – Рәхимә кычкырып елый башлады һәм һәрвакыттагыча үзенекенә иреште. Салих, ачуланып, Нәгыймәгә таба атлады.

– Син нәрсә сөйлисең, карт тиле? – Кулындагы камчы ярымай ясап, Нәгыймәнең битенә тиде. – Марш бу йорттан!

Тагын сугарга дип күтәргән кулы шул көе калды. Суга алмады Салих кабаттан. Яшь бөртеген күзендә кысып тотып, аңа гадел әниләр карашы белән Нәгыймә карап тора иде. Һәм бу карашка каршы берни эшли алмады макталган әфисәр, чөнки бу караштa нәфрәт тә, җирәнү дә, өстенлек белән көлемсерәү дә, кайгы-сагыш та бар.

Рәхимә чырылдавын дәвам итте:

– Нәрсә эшләп торасың инде? Ку! Куып чыгар!

– Кит! Чыгып кит! – дип ысылдады да Салих, камчысын ташлап, башын түбән иеп, өйгә кереп китте.

Нәгыймә шул ук карашы белән аны озатып калды, кул аркасы белән битендәге канлы эзне сөртеп, үз өенә таба атлады. Каршыга Сәрия йөгереп чыкты.

– Нинди кычкырыш анда? Шул симез чучка белән сүзгә килештегезме? Кан? Кем сукты? Кем, әни? Әйт! – Сәриянең күз яшьләре атылып чыкты. – Хәер, әйтмәсәң дә беләм! Нигә шулар белән сөйләшәсең инде?

– Ярар, балам, кайгырма. Барысы да әйбәт! Ә ул үләчәк, озакламый дөмегәчәк! – Аның тавышында шул тиклем өмет, ышаныч бар иде, Сәрия аны бүлдерергә дә, кабатлап сорарга да батырчылык итмәде. – Тиздән, тиздән, кызым! Азган Аждаһаны болыт алып китә Каф тау артына. Ә моны безнекеләр юк итәчәкләр. Ильяс һәм аның дуслары! Безнекеләр!

Нәгыймә, елмаеп, көне-төне эшләп кытыршыланып беткән куллары белән Сәриянең башыннан сыйпады.

**63**

Кереп килүчеләргә зур эт ташланды. Аның өрүе, урманны урап, авылга кайта, чылбырын өзәрдәй булып тартыла, аякка тиклем килеп җитә яза, кызыл канга баткан күзләрен уйната – бар кануннар буенча да ул кешеләрне куркытырга тиеш кебек иде. Тик курыкмады Митька: эткә иелеп, аның күзенә карамыйча гына нидер әйтте, тегесе шунда ук басыла да башлады.

– Ну, булды, булды сиңа! Үзебезнекеләрне танымыйсың! Бар, бар, булдырдың, ял ит!

Эт, елап, зарланып, оясына кереп китте. Яшелчә бакчасыннан чыккан хуҗа, сәнәккә таянып, кунакларга карап тора иде.

– Нихәл, хуҗа абзый?

Әллә ни ышаныч белдермичә, хуҗа игътибар белән боларга каравын белде.

– Исән-сау әлегә, Аллага шөкер! Үзегез ничек? Кая барасыз төнгә каршы?

– Шуңа да кердек инде? Йоклап чыгарга рөхсәт итмәссезме?

Тагын бер мәртәбә күз йөртеп чыккач, хуҗа җавап бирде:

– Әйдә, үтегез! – Ишегалдында мышнап-мышнап, аяк киемен салдылар, өйгә үттеләр. Түшәмгә асылган бишек янында биш-алты яшьлек кызыкай йөри, ул ят кешеләрне күргәч чыгып китте.

Кунакларны утырткач, хуҗа сорау бирә башлады:

– Мин Иван булам. Сез кайсы яклардан?

– Без Казанлыдан.

– Ә-ә, ерактан икән.

Барып чыкмый сөйләшү, ике як та бик сак. Шакир һәрвакытта да булган сорауларга турыдан-туры җавап эзләргә өйрәнгән кеше буларак, хуҗаның күзләренә туры карап ярды да салды:

– Менә нәрсә, хуҗа! Без сиңа шаярырга дип килмәдек, син үзең дә моны сиздең бугай инде. Казанлыда аклар, алар бик күп. Партизаннар отрядын оештырдык, әлегә урманда ятабыз. Командир безне башка партизаннар белән бәйләнеш урнаштырырга җибәрде. Сездә күптән түгел генә булып киткән отряд белән. Бөтен ышаныч синдә, туган! Әгәр сезнең яктан ярдәм тапмасак, аклар безне кырачак.

Митя да сүз кушты:

– Безгә ашыгыч рәвештә ярдәм кирәк. Ул булмаса, эшләр хәтәр! Акларда солдатлар күп, корал җитәрлек. Без урманда, халык авырый башлады.

Яшь кенә хуҗабикә самовар алып керде, кунакларга карап алды да чыгып китте.

– Син, әлбәттә, безгә ышанмассың да. Башка ышандырырлык бер дәлил дә юк. Берәү бар, тик ул синең безне кабул итү-итмәвеңнән тора.

– Шикләнмә, туган!

Тын гына утырган хуҗа башын күтәрде:

– Туктагыз әле! Мин нәрсә, мужик түгелмени, үзебезнекеләрне танымаска? Ял итегез. Ашап алыйк. Әнә мунча әзер, анысы да кирәктер. Әйдә, өстәл артына!

Шакир бер карарга килде: әгәр болар аклар ягыннан булсалар, инде күптән бикләп куярлар иде. Шуңа ул хуҗага Ильяс язган хатны күрсәтте, шуннан соң тегенең күңеле бөтенләй күтәрелеп китте.

Юынып та чыктылар. Өстәлдә көзнең бар булган күчтәнәчләре елмаеп чакыралар иде: берсе – салкынлыгы белән, икенчесе – күтәрелгән пары белән, өченчесе – тамакны кытыклаган тоз-борыч тәме белән...

– Булдылар өч атна элек бездә партизаннар. Павел Иванович Деткин үзе түгел, икенче полк... Биш көн тордылар да Трун ягына киттеләр. Бар якын-тирәдән мәгълүмат җыялар. Сезнең турында беләбез. Җиһаншин да билгеле кеше, Яңаулдан Красноуфимскига тиклем тимер юлын саклый. Сезне эзләтеп, кешеләр җибәргән идек, Салихныкылар тотып алганнар да юк иткәннәр. Аның көчен беләбез, шуңа каршы чыгарга җөрьәт итмәдек аз көч белән.

Кунаклар, күптән җылы аш күрмәгән кешеләр, кыстаганны көтмичә, майлы кисәкләрне җылы шулпа белән кушып ашауны белделәр.

– Кызганыч, без боларның барысын да белмәдек шул. Партизаннар барлыгы билгеле, ә бәйләнеш юк. – Шакир кулындагы йомшак икмәкне өстәлгә куйды. – Ике отряд барлыгы да билгеле безгә.

– Алар отряд түгел, ике полк. Берсе Лысая горада тора, командиры Титов.

Кызык килеп чыкты. Отрядлар берсе артыннан берсе йөргәндәй, ә очрашып булмады. Титов кешеләре Казанлыга килә, тик аларны сизми калганнар.

Урамда караңгы төшә, зәңгәр күк төннең салкын булачагы турында сөйли. Өйләрдә кызыл утлар күренде, бала-чага тавышы акрынлап тына башлады. Шакир хуҗага эндәште.

– Бер полк Трунда тора, дисең. Трунга тиклем утыз-утыз биш чакрым. Икенчесе Лысая горада. Унбиш-егерме чакрым. Мин менә нәрсә тәкъдим итәм. Митя монда кала, каршы булмасагыз. Мин беренче полкны эзләп чыгам төнлә. Күп булса, бер көндә әйләнермен дип уйлыйм, әгәр барысы да без уйлаганча барып чыкса.

Хуҗа бик кирәкле фикере белән бүлеште:

– Мин бит монда бәйләнешкә калдырылган кеше. Ат бирәм, кирәксә. Шуннан иртәгегә пароль бар, аны да әйтәм.

Шакир тора да башлады.

– Син нәрсә, хәзер үкмени?

– Көн елны туйдыра, сәгате көнне саклый. Мин кузгалыр идем, Иван?

– Ялсызмыни? Азрак йоклап ал, иртән чыгарсың? Ә юлны табарсыңмы?

– Юк, рәхмәт! Табам, мин монда күп йөрдем яшь чакта. Юлларны яттан беләм. Вакыт! Беләсеңме, ничек көтәләр безне анда? Һәр сәгате исәптә, соңгысы да булуы мөмкин. Шуңа мин – юлга. – Шакир маңгай тирен сөртте. Кинәт аның бу кешеләргә азрак кызып алганнан түгел, ә урманда калган иптәшләргә ярдәм итү теләгеннән ашыгып юлга чыгуын аңлатасы килде. Тик вакыты түгел шул! – Әйдә, Иван, атны әзерлә!

– Ярар, алай булгач! Тоткарламыйм. Әйдә!

Тирә-якка җәелеп үскән биек чыршының очында ай урагы кагып куелган кебек, аның янында йолдызлар бер-берсенә сыенышкан. Салкын төннең эре йолдызлары елмаешып җемелдиләр. Менә кемнең бер мәшәкате юк галәмдә!

– Иртәгә төштән дә калмый монда булам, Алла бирсә! Шуннан турыга Казанлыга. Һәр мизгел кадерле!

Капкадан озатып калдылар да Шакирны, хуҗа белән Митя өйгә үттеләр. Бер кеше күзен дә йоммыйча Митяны көтә – бу Пашка иде. Йокларга урын әзерләгәнче ике дус тагын туйганчы гәпләшеп алдылар. Хуҗа белән хуҗабикә елмаеп, бик озак карап тордылар аларга, чын күңелдән көлделәр аларның бик мөһим итеп сөйләшкән сүзләрен тыңлап.

**64**

Кыш үзенең төп вазифаларын үти башлады. Бер көнне салкыннары белән өтә, икенче көнне, азрак сындырып, өченче көнне буранлап карлары ява. Бүген дә иртәдән бирле ябалак кар ява, бу якларда аны «чабата кар» диләр. Ябалагы аның йомшак булуыннан килсә, чабатасы кар бөртекләре үргән чабатаны хәтерләтүеннән.

Сәлимә бәби көтә. Әбиләр әйтүенчә, бәби бүген-иртәгә дөньяга оран салырга тиеш. Кендек әбисе авылның икенче ерак башында торганга, кайтып тормый өенә, кунарга кала. Бүген иртән хәлне бәяләп, кайтып урарга булды, өс киемнәрен алыштырырга, башка өй вак-төякләрен караштырырга.

Кичкә таба күтәргә, кирәк-яракларны әзерләп, бер урынга җыеп торырга кушты. Алар арасында иң мөһиме – әтисенең күлмәге, баланы, тугач та, әтисенең күлмәгенә төрергә кирәк, бу инде аны бөтен ыруы-кавеме белән бәйли торган йола. Инде күптән барысы да әзер, теләгән теләк бары берәү: дүрт саны төгәл, исән-сау булып, бәхете белән тусын!

Авыл дөньясы ниндидер тыныч булмаган чакны кичерә. Төне буе сирәк-саяк, иртән бер туктаусыз атыш, анда-монда йөгереш. Халык андый хәлләргә күнегеп бетсә дә, тынычлыкны боза торган һәрбер нәрсә борчылуга сәбәп була. Тәрәзә пыялаларының туңмый калган читеннән карап озатып калалар йөгерүчеләрне, «Алла сакласын! Илаһым, үзең сакла!» телдән төшми торган сүзләргә әйләнде.

Иртән хәл белергә Әминә керде. Аның сөйләвенә караганда, югары очта, урман буенда атыш вакытында ике як та кешеләрен югалткан. «Аклар ягыннан да, партизаннар ягыннан яраланган һәм мәрхүм булган кешеләр күп икән», – диде Әминә. Балалар ятим кала инде менә диештеләр сөйләшүчеләр.

Кинәт капка ачылды, анда таныш булмаган өч кеше күренде, шул арада алар өйгә үк үттеләр. Солдатлар түгел, тик кораллылар. Авыл кешеләре, тик кайсы авылныкылар? Сөйләшүләре бу якныкы кебек тә... Исәнләшеп тә тормыйча, барысына да тиз генә җыенырга куштылар. Нәгыймә бу сүзләрне үзенә генә юнәлгән дип уйлаган иде. Тегеләр боерыкны тагын кабатладылар:

– Өчегез дә җыенасыз. Шуннан безнең белән!

– Кая? Ни өчен? Бүген-иртәгә туарга торган баланың әнисен кая алып китмәкчесез?

– Безгә сезне волостька, арестантлар бүлмәсенә илтеп ябарга кушылды.

– Корсагы борынына җиткән хатынныммы? Сез нәрсә, акылдан яздыгызмы? – Әминә килүчеләргә күзләре белән тишәрдәй итеп карады. – Әллә кендек әбинең вазифаларын башкара беләсезме?

Килгәннәрнең берсенең башкаларга сүзе үтә, шунда ук аларны туктатты.

– Буш сүзләр кирәкми. Безнең ике юл: йә үз аягыгыз белән аны-моны аласыз да кушкан җиргә барасыз, йә бәйләп алып барабыз. Тагын бер юл бар – тыңламасагыз, сезне юк итәргә. Тәк ышту, тиз генә җыеныгыз да киттек!

Чынлап та, бәхәсләшеп торуның файдасы юк, болар барысына да сәләтле. Нәгыймә Сәлимәгә карый: түзәрме ул бу сынауларга? Сәлимә бу бирелмәгән сорауны аңлады булса кирәк, аңа җавап бирде:

– Курыкма, әни! Мин әзер. Берүзем түгелмен, сезнең белән. Барысы да әйбәт булыр, Алла бирсә!

Теге кешеләр тик тормадылар, сорауларын бирә тордылар:

– Өйдә тагын берәрсе бармы?

Нәгыймә ашыгып җаваплады:

– Юк-юк! Кем булсын мондый чакта? Бәби көтәбез бит!

Үзе тиз генә йокыдан торып өлгермәгән Сәрия өстенә мендәрләрне, юрганнарны ташлап, урынны җыештырып та куйды.

Әминә җылырак әйберләр алырга тәкъдим итте, бәби әйберләрен төреп алды. Шуннан калын шәлгә уранып, урамга чыктылар. Нәгыймә ишектән чыкканда, арттарак калып, Сәриягә пышылдады:

– Азрактан, тавыш-тын беткәч, Гаязетдин абзыеңа йөгер, анда кун! Өйгә кайтасы булма!

Волостька тиклем барган озын урамда бер кеше юк. Бары иртән ягылган мич җылысыннан әле эреп өлгермәгән тәрәзәдәге күзләр аларны озатып калды. Бераз вакыт үткәч, җылы киенеп, биленә балтасын кыстырып, бәләкәй чанасын өстерәп, урманга утынга чыгып баручы Гаян картка беркем дә игътибар итмәде.

* * *

Волостьның арестантлар бүлмәсе салкын, бинасында мичләр ягылмаган булып чыкты. Әминә бу хәлдән чыгу юлларын җайлауны үз өстенә алды. Башта, әллә нинди үзе генә белгән усал сүзләрне әйтеп, озатып килүчеләрдән утын һәм бер чиләк су алып керттерде, мич янагындагы куыштан шырпы табып, аны ягып җибәрде, өстәлдә торган казанчыкка су салып кайнарга куйды, ә чиләкне суы җылынсын дип, мич авызына урнаштырды. Утыра торгач, салкынлык ныгый төште, мич ягуның бик вакытлы булуын алар тиз аңлады. Сакчылар, аларның качып китәрлек хәлләре булмавын күреп, ишекне бикләп тормадылар. Әминә ачык булган бүлмәләрне урап чыгып, волостьта кизү торучылар бүлмәсеннән иске толып табып алып килде, шунда ук болын чәе салынган бер ватык савыт табып, аларны да үзләре торган бүлмәгә күчерде. Бу әйберләрнең иң кирәклесе, әлбәттә, толып иде, Сәлимәне толыпка төреп утыртып куйдылар.

Шулай итеп кыска көн үтеп тә китте. Ярыйсы гына җылынган бүлмәдә авыздан чыккан пар инде күренми иде. Бар уңайлыклар булмаса да, Ильяс килеп азат иткәнче, бер-ике көн түзәрлек шартлар булдырылды. Ә аның шул бер-ике көн эчендә азат итәчәгенә беркем дә шикләнми иде.

Тик дөньялар тагын үзгәреп китте. Караңгы төшкәндә, волостьның икенче ягындагы капкадан чаналы ат килеп керде, аннан өч кеше төшеп, хатын-кызларны төяделәр дә билгесез якка алып чыгып та киттеләр. Әминә, килүчеләр белән тиргәшә-тиргәшә, толыпны чанага чыгарып салды, теге савыт белән казанчыкны эләктерде. Чиләге тишек булып чыкты, мич алдында утырганда, аның суы акрынлап агып беткән иде.

Килгәннәрнең берсе волостьта торып калды.

**65**

Салих кешеләрне чиктән уздырып куркыту өчен ике мәрхүмне дә җирләргә рөхсәт бирмәде. Сакчы солдатлар алар янына ике көн беркемне якын җибәрмәделәр, тик саклап кала алмадылар. Юкка чыкты атылганнарның җәсәдләре. Шул ук төнне Степанның бер исән тәрәзәсе калмады, Хәмитнең бакча очында елга буендагы мунчасына, Семённың тегермәненә ут төрттеләр. Степан белән Савка, төн карасыннан кара булып, гаепплеләрне эзлиләр, тик таба алмыйлар. Бар дөньяга ачуланып, өстәл артына утыралар һәм эчәләр. Степан һәрвакыттагыча зарын сөйли башлый:

– Әйт әле, Савелий, нәрсәгә кирәк иде бу отрядны җыю безгә, ә? Менә дигән итеп, тыныч кына яшәп ята идек. Юк, маҗаралар кирәк булды! Бу кешеләрнең берсендә дә өмет юк, арттан пуля көт тә тор... Әнә, акыллы кешеләр сату итеп баеп ята, бернинди отряд кирәкми аларга!

Савканың да баштагы батырлыгы акрын гына югала башлады. Болай булыр дип уйламаган иде ул. Ярар иде сугышы булса: атлар чаба, кылычлар ялтырый, бер, ике һәм менә сиңа җиңү. Матур атта кылыч тагып кайтып

керә ул авылга, Нина ничек итеп аның белән сөйләшергә җай эзли... Ә нәрсә килеп чыкты?

– Кара әле, Степан Акимович, ничек ул безнең өстән җитәкчелек итә? Ә без кем? Без бит бар яктан да мөстәкыйль отряд! Без халыкны җыйганда, ул кайда булган? – Савка ямьсез итеп сүгенеп алды. – Тыңламыйм мин аны, менә нәрсә! Миңа ул кирәкми!

Степан көлемсерәп утырды.

– Ну әйттең син, Савелий! Бер башлагач, артка юл юк! Алай-болай булса, безне бер язмыш көтә, алар белән генә безгә яшәү бирелгән. Кызыллар җиңсә, Степан «Прости, Господи!» дип чукынды, – безгә берәр ярлыкау булыр дип өмет итәсеңме? Кем атты Никоновны? Кем тотты, тукмады һәм атып үтерде Миронны? Бу сиңа, браток, бет үтерү түгел!

Чуров кычкырып җибәрде:

– Ә кем мине бу булмаган эшкә китереп тыкты? Син түгелме ул кеше, Степан Акимович? Миңа кирәк идеме бу? Синең дә башыңнан сыйпамаслар. Барлык гөнаһыңны миңа ташларга уйлама тагы! Мин... мин сине хәзер... белермен нишләтергә!

Степан торып басты.

– Син... Кемгә яныйсың, көчек?

Усал тынлык урнашты. Күрше бүлмәдә аяк тавышы, ютәлләгән тавыш ишетелде. Бераз басып торгач, командирлар утырдылар.

– Ярар, Савка! Булды! Кызып киттек. – Степан теләмичә генә сүзләрен чәйнәде. – Мин нәрсә турында сөйлим соң, атаң башы! Безгә башка юл юк, тик алар белән! – Степан бөтенләй пышылдауга күчте. – Син миңа җиңел дип уйлыйсыңмы әллә? Йөрәктә, белсәң, таш! Кемне сыйлыйм, кем белән дус булып йөрим? Салих, аның этисе Хәмит – минем дошманнар бит! Хәтерлисеңме, былтыр болын өчен урамга урам сугыштык? Ә-ә, белмисең! Ул бит минем иң шәп печәнлекне тартып, талап алды. Ә мин нишләргә тиеш, ә?

Савка уйга калды, калтыраган куллары белән лампадан тәмәке кабызды.

– Гафу ит, тиле баланы, Степан Акимович! Яшибез әле без синең белән, о-о, яшибез! Туганлашып та китәрбез!

– Өлгерербез, өлгерербез, Сава. – Степан беренче мәртәбә аны этиләрчә йомшак итеп исеме белән атады. – Хәзер башланган эшне без азагына илтеп җиткерергә тиешбез. Ни генә әйтсәң дә, кендек аша әнисенә бәйләнгән бала кебек нык итеп, үзебезне бәйләп куйдык бу эшкә. Өзеп булмый инде. Ә өзә калсак, бары канга батып, канга тузып.

– Дөрес әйтәсең, Степан Акимович! Башка юл безгә юк... Дозорларны тикшерергә кирәк. Зират ягына барып кил әле, авыр булмаса. Синнән барысы да курка. Тагын теге көмешкәчегә кереп киткәннәрдер.

Икесе дә басты.

– Ә син ни эшләмәкче буласың?

– Минме? – Савка аксыл кашларын җыерды. – Исемлекне барлап чыгам, тагын икәү качканнар. Казанлыдан ике чана килергә тиеш, корал белән. Салих ышандырды.

Степан кадактан тунын алды. «Алдаша, күзгә карап алдаша бит. Вәт, эт баласы! Ярар, тикшерербез сине» – аның башын бора башлаган шушы уй башкалар арасында беренче урынга чыгып туктады.

– Ярар, көт аларны. Сатулашма! Ал барысын да, соңыннан ни эшләргә белербез. Кулда корал булса, сөйләшергә җиңелрәк булыр.

Чуров маңгаена төшкән чәчләрен, башын кагып, артка очырды да күренер-күренмәс соклану белән Степанга әйтте:

– Ну баш үзеңдә, Степан Акимович, хак сүз! Ә мин уйламаган да идем!

Степан, төлке тиресеннән тегелгән зур бүреген киеп, бер тавышсыз чыгып китте. Ә Савка аны күзләре белән капкага тиклем озатты да икенче бүлмәгә төртелде.

– Нина!

Бервакытта да аның эндәшүенә җавап бирми торган иде Нина. Чыкты бу юлы нигәдер. Әллә кистереп әйтәсе килдеме, йөрмә минем арттан дип, әллә оялтырмын дип уйладымы, үзе дә аңламады.

– Нина, нигә син мине куасың? Якын да китермисең! Яратмыйсыңмы? – Арыган кеше кыяфәтен чыгарып, талгын назлы күзләре белән Нинага баштанаяк карап, сүз башлады Савка. Белә, белә ничек күзләрен берьюлы ягымлы да, моңсу да итәргә ул кирәк чакта!

Нина эндәшми генә тыңлады.

– Ничәнче ел синең арттан йөрим. Ә син? Бөтенләй ошамыйммыни сиңа? Әйт, Гәрәйдән кайсы җирем ким? Нәрсә эшләргә миңа, ничек төзәтергә ошамаган якларымны? – Савканың сүзләре шундый җылы булып агалар, аларда шул тиклем наз, хәтта Нинаның йөрәге ешрак тибә башлады. – Мин сиңа әйбәт тормыш иптәше булырмын. Телисеңме, ташлыйм мин бу сугыш эшен? Тик син Гәрәйне ташла! Беләсең бит, беркем дә сине аңа бирмәячәк! Дин, иман икенче! Әгәр өйләнешсәгез, авылда яшәргә бирмиләр сезгә! – Савка туктап, сүзләренең кызга нинди тәэсир ясаганын күзәтә. Әлегә ул бик канәгать иде. – Нәрсә, ну нәрсә таптың син шул такыр башлы малайда?

Нина тыңлый. Савканың соңгы сүзләрен ишеткәч, айнып киткәндәй булды. Һәрвакыт, һәрчак, хәтта этисенә дә каршы чыга ул, әгәр берәрсе аның алдында Гәрәй турында начар сүз әйтсә. Дулкынланудан чигәләре кызып китте:

– Син! Син! Алай сөйләмә аның турында! Ул андый түгел!

– Ха! Юк инде ул! Царицында бугай, эчәкләрен таратканнар инде аның. Ышанмыйсыңмы?

– Юк! Юк! Юк!

Савканың күзләре, лампа утында янып, яшькелт төскә керделәр.

– Мин барыбер үземнекенә ирешәчәкмен! Минем сүз өстә булачак! Степан Акимовичны күндерәм, ул хәзер минсез беркем дә түгел! Аның тормышы тулысынча минем белән бәйле, ул минем алда бурычлы! – Монысын Савка арттырып җибәрә. – Ул әйтер сиңа нәрсә эшләргә! Йә көч белән алам! Аңладыңмы, юләр?

Нина артка атлады.

– Бервакытта да сиңа карамаячакмын, ишетәсеңме? Гәрәй исән, исән!

– Ах, менә син ничек!

Тычкан аулаган мәче кебек күз иярмәслек тизлектә Савка Нинага таба сикерде һәм аны почмакка өстери башлады.

– Син шулаймы әле? Син миңа каршы әйтергә батырчылык иттеңме?

– Әти-и!

Шул вакытта ишек ачылды һәм Степан килеп керде...

**66**

Шакир тирә-ягына игътибарын югалтмый Митяга тагын эндәште:

– Менә мин сиңа барысын да сөйләдем, син тик бер сүзне дә оныта күрмә. Кайткач түкми-чәчми Ильяска сөйләрсең. Яктыга тиклем Казанлыны үтеп китәргә кирәк.

– Аңладым да ул. Тик отрядта бергә булабыз бит. Үзең сөйләрсең, – дип, Шакирның җиңеннән тарта Митька.

– Ярар, ярар! Бел дә тик кенә тор! Тартма минем җиңнән, шәбрәк атла. – Шакир ачуланып китте.

– Ярар ла. Миңа нәрсә... – Шакирның ачулы чагы икәнен аңлап, Митька да сөйләшмәс булды.

Алдагы караңгылыкта Гыйльманша мөәзиннең тегермәне кап-кара булып утыра, ак сулы буа йөзендә ул хәтта караңгы төндә дә кара сызыклары белән аерылып тора. Башта озак кына тыңлап тордылар. Улаклардан аккан су тавышы башка тавышларны басып китә, шуңа берни аңлый алмадылар.

– Бәлки бар көчкә йөгереп үтеп китәрбез? Сизми дә калырлар?

– Кем белә... Су тавышында бернәрсә ишетелми! Кеше юк кебек.

Ике адым да ясап өлгермәделәр, ату тавышлары яңгырады. Шакир буш кулы белән Митьканы екты:

– Ят!

Шакир мылтык тавышы килгән яктан монда табан йөгерүчеләрне шәйләде һәм аларга төзәп ата башлады. Кинәт, колак янын җылытып кан ага башлаганын тойгач, бүрегеннән язу алып, Митьканың кулына тоттырды.

– Йөгер! Тау башына табан! Мин аларны тоткарлыйм бераз!

– Бергә! Китмим!

– Ну-ка! Йөгер! Язуны югалтма! Тау башына!

Бер кулы белән револьверын күтәреп, якынлашып килүчеләргә тагын ата башлады.

– Тиз бул, йөгер! Нәрсә көтәсең? Тагын. Кәлтәдә очрашасы отрядның винтовкаларында кызыл чүпрәк булыр. Йөгер!

Ни эшләргә белмәгән Митька тагын бер мәртәбә Шакирга карады да елга буйлап сузылган тауга йөгереп менеп китте. Яктыра башлаган иртәдә ул тагын борылды. Берничә кеше Шакир өстенә егылдылар, шуннан ул аларны алып ташлады, шулчак берсе аңа терәп диярлек атып җибәрде.

Чияле тауга менеп җиткәч, хәлдән таеп егылды Митька. Тик бер мизгел дә ятмады, булган көчен җыеп, урманга табан тагын йөгерде. Куып килүчеләр, яктырудан файдаланып, аңа төзәп ата башладылар. Баш очында пулялар оча, күздән яшьләр ага, кош баласыныкы кебек дулап типкән йөрәк йөгерергә комачаулый, эчкә кинәт килеп чыккан кату һәрбер адымны газапка әйләндерә...

Көтмәгәндә алга килеп баскан куаклар Митьканы арттан куып килүчеләрдән яшерделәр.

***

Туктый-туктый, Томафи яланына йөгергән кешене әллә кайдан күрделәр сакта торучылар. Уйнагандай иттеләрме Салихныкылар: ул күтәрелеп йөгерә башласа, алар ата башлыйлар, егыла калса, ул егылган урынны тишеп пулялар кар тузаны күтәрә. Алгарак үтеп, сакта торган партизаннар

аларга каршы ата башлагач кына, Митя Танып белән тау арасындагы иң тар урынны исән-сау үтеп китә алды.

Бераздан ул инде Ильяс алдында иде.

– Боерыкны үтәдек, иптәш командир!

– Маладис, егет! Ә Шакир кайда?

Митя ни әйтергә белми туктап калды.

– Нәрсә телеңне йоттың? Ни булды?

– Шакир һәлак булды. Иртән көтмәгәндә поскынга тап булдык...

Ильяснең тезләре калтырап китте. Бер сүз әйтмичә, башыннан бүреген тартып төшерде. Бик озак басып торды ул, бүректән чыккан пар туктагач кына, аны яңадан киде.

– Ничек? Кайчан? Кем?

– Бүген... Иртән... Гыйльманша мөэзиннең тегермәне янында.

– Син... Син ничек котыла алдың соң?

– Ул мине куып җибәрде. Боерык диде. Кулбашы яраланды, тегермәннән тагын солдатлар килеп чыккач, ул миңа: «Беги, сынок! Я задержу их!», – дип кычкырды...

Тирә-якта кырыс йөзле партизаннар саны артты, алар, бер сүз әйтмичә, Митяны тыңлыйлар иде.

– «Беги!» Мин тыңламый булдыра алмадым. Чөнки ул миңа менә шушы кәгазьне бирде. «Берүк саклан һәм аны сакла! Ильяснең үз кулына тапшыр», – диде. – Митька күлмәк эченә тыгылган төргәкне чыгарып, Ильяска тоттырды. – Озак кудылар мине алар. Соңрак үзем дә адаштым, чак кайтып җитә алдым.

Ильяс кәгазь төргәкне ашыгып ертты, карга вак хәрефләр белән язылган хат килеп төште. Ильяс аны алып укый да башлады.

«Тов. Ягафаров! Поговорили с вашим разведчиком о положении отр. Оно, к сожал., незавидное, у Зиганшина много средств, чтоб напасть. Но этого мы не допустим. Ваша просьба рассмотрена в штабе Бирск. партизанск. бриг., ком. П.И.Деткин приказал мне идти с утра на соединение с вами. К обеду встретимся с Шакиром у ручья после Кальт. лесов. Передайте время выступления и наши направления. Ком. втор. полка Бирск. бр. А.В.Титов»

Җыелган партизаннар Ильяска карап тын калдылар.

– Шакир юк... Кем, кем бара ала хәзер Кәлтә урманына? Кем партизаннарны белә?

Бар да уйда, беркем бер сүз әйтмичә, бу хәлдән чыгу юлын эзли. Шунда Митя чәчрәп килеп чыкты:

– Мин! Мин барам! Күрүен күрмәдем, тик партизаннарны башкалардан аера торган билгене Шакир әйтеп өлгерде.

– Соң син бит төнен йокламадың, җитмәсә, яралысың да. Атта ике-өч сәгать барырга кирәк. Булдыра алырсыңмы?

– Булдырам, иптәш командир! Булдырам!

Башка юл чынлап та юк. Ә егетнең берүзен чыгару дөрес булмас.

– Ярар! Тик берүзең түгел. Синең белән бара... Синең белән бара... Фәхри абзый, син барасың. Вакыт бик кысан, хәзер үк китәргә кирәк. Митяны ашатыгыз да юлга!

– Мин ашарга үзем белән алам, бара-бара ашармын!

Кемдер шаярып алды:

– Ашны кесәгә саласыңмы?

Көлми булдыра алмадылар. Ахыргы сүзне Ильяс әйтте.

– Ашны ашыйсың, калганын үзең белән алсаң да ярый. – Шуннан партизаннарга борылып өстәде. – Иптәшләр, чыгабыз! Әзерләнегез, коралларны карагыз. Командирлар, минем янга!

***

Гаян сакчыларның беренче рәт окопларына килеп җиткәндә, кояш шактый күтәрелгән иде. Командирлар белән киңәшмәдә утырган Ильяс кырына ул тиз үтте, сакчылар аның яңалыклар алып килгәнен белә. Тәмәке төтене баскан Томафи өендә сүзләр тәмамланып ята иде. Исәнләшеп-нитеп тормый, карт хәлне сөйләп бирде. Төсе үзгәреп киткән Ильяс иптәшләренә борылды:

– Нишлибез?

Галләм карт шунда ук Салихның уйларының төбенә төште:

– Ул бит Ильясны моннан тартып чыгарырга маташа, ысматри-матри! Димәк, көтәләр шунда!

– Әллә ни яңалык түгел түгеллеккә. Без мондый хәл килеп чыгуын күз уңында тоткан идек тә ул.

– Яңа шартлар барлыкка китереп, ул безнең һөҗүмне тоткарларга маташа. Значитца, алар безгә каршы чыгарга әзер. Бүген төнен без аларны узып башларга тиешбез ул һөҗүмне.

– Титов килеп җитәр микән? Аларсыз бик җиңел булмаячак.

– Җитәр. Бик җитди кешеләргә охшаганнар. Ярты ел эчендә партизан бригадасы оештырып җибәрә алгач, уен түгел инде бу сиңа!

Командирлар Ильясны иртәнгә тиклем түзеп торуның кирәклегенә шик белдерделәр. Гаян карт әйтүенчә, Сәлимә берүзе түгел, аның янында Нәгыймә белән Әминә, төрле хәлдә дә алар баш бирмәячәкләр. Шунда ук һөҗүм барышында волость бинасына бара торган кечкенә бер төркем оештырылды, аның бурычы – каравыл бүлмәсендә ятучыларны азат итү.

Ильяс инде икенче көн үзенә урын тапмый үрсәләнде. Менә нәрсәгә булган икән бу көю! Беренче сәбәбе. Тик икенчесе дә бар бит әле. Ул эшнең монда гына түгеллеген башкаларга караганда тирәнрәк аңлый. Матусов утарыннан килгән кешеләр буа кырында кешеләр йөрүен, бөянең астын-өстен тикшерүләрен җиткерде. Димәк, шартлату көн тәртибендә, вакыты гына билгесез. Ә бозы туңып килгән елгага өстәмә су бирү туфан суына тиң булачак. Баштагы фаразлар елганың туңмаган вакытына карыйлар иде, ә бүген хәлләр икенче. Әгәр Сәлимәне бикләп кую, буа кырында кешеләр йөрүе белән Салихның башка эшләрен тәңгәлләп карасаң, һөҗүм бүген йә иртәгә иртән башланачак. Боз өстенә су китсә, һөҗүмнең иң ышанып торган ике юнәлеше юкка чыгачак.

Ильяс командирларның һәрберсенә бирелгән әмерләрен барлап чыкты да аларга үзгәрешләр кертте. Беренче үзгәреш – Карам җитәкчелегендәге Беренче Казанлы төркеме, юл күрсәтүче Галләм карт белән сөйләшенгәнчә, хәзер үк Чияле тауга карап юлга чыга. Михайловка төркеме, икенче Казанлы төркеме Ильясның үзе җитәкчелегендә, Тукмай сазлыгы аша Үгез чишмәгә чыгып, иртән волость ягыннан авылга керә. Болар барысы да җәяү, атсыз. Атлар лагерьда кала, ә Катнаш төркем, аларны Таныпның теге ягына чыгарып тын гына Каюм мәгарәсе аша үткәрә. Катнаш төркем, һөҗүм башлангач, Салихныкыларның тәмам башларын катыру өчен бу яктан авылга карап ут ача.

Бер сорау булды. Нигә монда кунып, иртән генә чыкмыйбыз дип сорады кемдер. Ильяс тыныч кына хәлләрнең кайсы якка борылу мөмкинлеген аңлатты, ашыгырга кушты. Башка сораулар юк иде, барысы да үз эшенә тотынды. Һөҗүмнең башы – буаны шартлату тавышы булачак, диде Ильяс, үзенең ышанычын башкаларга җиткереп. Әгәр ул караңгы чакта булса, бераз көтәргә, изге Китапта әйтелгәнчә, ак җепне карадан аера алу мөмкин булганчы.

Иң башта, Гаян картка утын төяп, урманнан чыгарып озатып куйдылар.

Бераздан Томафи яланында аяк-кул бармаклары белән санарлык кына кеше калды.

**67**

Салихның бөтен курыкканы Ильясның һөҗүмне бүген башлавы, үзенең буаны шартлатып өлгерә алмавы булды. Матусов буасын кырык кат урадылар аның кешеләре, бөянең йомшак урыннарын табарга уйлап. Тик табарлык түгел, җитмәсә, җирне, калын булмаса да, кар каплап алган, ә яр буенда чылтырап, ватылып-кырылып, уалып торган пыяла кебек боз. Шартлаткыч җитәрлек, тик аны суга салып булмый бит инде, аңа хәтле бикфорд җебе янып барырга тиеш. Ә бөянең үзен казырлык түгел, урыны белән туңып та өлгергән.

Утарда бер кеше юк. Хуҗа чыгып киткәннән бирле бер корылмасы да эшләми, утарда ара-тирә күренүче каравылчылардан башка кешеләр булганга охшамаган. Шаулап-гөрләп торган тормыш сүнгән инде бу җирдә. Халыкның Матусовка булган ихтирамы шаккатыра: бернинди урлау-талау юк, вату-кыру күренми. Әйтерсең бер көнгә эшне туктатканнар да, барысы да җыелып, нидер аткаралар, ә ул тәмамлангач та, иртәгә корылмалар гөрләп эшли башлаячаклар... Әллә шуңа да күңелсезлек, сагыш урап алган бар тирә-якны.

Матусов елга үзәненең табигый рәсемен бик уңышлы файдаланган, бөянең озынлыгы бары дүрт-биш сажин, биеклеге дә шуннан артык түгел. Озын елга буена җыелган су әллә ни киң җәелмәсә дә, кирәкле куәтне җыя ала, тегермәннең һәм такта яргычның тәгәрмәчләрен гөрләтеп әйләндерә. Шул тиклем бөтен игы да килгән бөяне эшли алган кеше аны һәрвакыт тикшереп тору уңаен дә күз алдында тоткандыр бит? Сорар кеше дә юк Матусов утарында, бары каравылга куйганнар гына йөри. Әллә Салих кешеләренең тел төбен аңлап, әллә башка сәбәптән Петькаларның икесе дә юкка чыктылар, эзләтеп тә карадылар, тик таба алмадылар. Ике Петькасыз бу мәсьәләне чишеп булмый дисәләр дә, җаен таптылар. Таулы авылыннан Матусовка эшләгән бер кеше акчага аның серен сатты. Аның утарындагы түгәрәк күлгә су алыр өчен җир астыннан канау казылган икән. Эзли торгач, таптылар. Тирәнлеге тиешенчә, шартлаткычны төшерү уңайлы. Ә шуның елга буендагы өлеше ярга җитмәс борын бөя кырында аска төшеп китә. Ул урын һәркемгә күренеп, игътибар җәлеп итеп тормасын өчен өстенә таш өеменнән пирамида корганнар. Читтән караганда гади таш өеме, башка бернинди дә фараз юк. Эшли белгәннәр элек, ни әйтерсең. Моны Екатеринбургтан чакыртып алдырылган шартлату буенча оста кеше дә тел шартлатып куәтләп торды.

Канау үзе, су җибәргәнче, коры, чөнки ул буаның аскы ягында. Оста сайлап алынган ике ярдәмче солдатка эш тәртибен аңлатты. Иң башта,

булган ташларны аска ташлап, тигез коры урын әзерлибез. Шуннан беренче бикфорд җебен яндырып карап, икенчесен кайчан яндырырга кирәкле вакытны беләбез. Шуннан, вакыты җиткәч – монысы инде Салих кушуы буенча иртәнгә таба – шартлаткычларны төшерәбез дә җепләргә ут төртәбез. Бу кеше шаярырга да өлгерә: җепкә ут төрткәч, бар булган көчкә ерактa торган атларга тиклем чабарга, алай булмаса, Иделгә тиклем су астыннан җәеннәргә утырып бару төшә һәркемгә.

Беренче төшергәне ул-бу булып шартламаса да, икенче әрҗәсе шартлаганда, детонация барлыкка килеп, аны шартлата, азакта буаны ерып җибәрә дип аңлатты ул. «Канауда бераз дым бар инде барын, анысын шартлаткычны тиз генә төшерү белән бәхилләтеп була», – диде оста.

Оста солдатларга тәмәке тартмаска кушты. Ә үзе бер дә курыкмый, якындагы шартлаткыч әрҗәләренә игътибар да итми төтенләвен белде. Моңа аптыраган икәүгә болай дип аңлатты ул:

– Сез җилгә карамыйсыз, бар дөньягызны онытып, шартлаткычка якын килүегез бар. Бер курку чирканчыгы алмагач, аны бар дип тә белмисез. Ә миңа боларны сугыш хәтергә уеп салып куйды. Ни генә шартлатырга туры килмәде анда! Рәнҗемәгез, якын килмәсәгез, исән булырсыз. Менә мин иртәгә карармын әле йөзегезгә безнең эш тәмам булгач!

– Ә хәзер нишлибез?

– Көтәбез.

Оста түш кесәсеннән зур сәгать тартып чыгарды, колагына куеп аны тыңлап алып, ниндидер тәгәрмәчен кетердәтеп борды.

– Әле сәгать ун. Шартлау алтыда булачак. Сигез сәгать ял безгә. Шартлаткычны әлегә төшермибез, ул дым тарта, җилләп торсын. Тик аны саксыз калдыру ярамый, шулай булгач, бераз туңарга туры килер сезгә, егетләр. Бу эшне уникедә башлыйбыз. Анда инде бик тиз була. Шартлагач та, без кайтып китәбез. Белмим, сезгә ничек тәэсир итәр, мин сезгә ахырзаманның ничек буларын күрсәтергә вәгъдә итәм!

Ниһаять, әйтелгән вакытта бу яклар өчен ахырзаман хәбәре булган шартлау тавышы яңгырады. Ничә кеше уянгандыр Казанлыда һәм күрше авылларда, догаларын кабатлый-кабатлый йөгереп килгәннәрдер пыялалары чыңлаган тәрәзәләргә.

Иртәнге караңгылыкта әллә ни күренми иде буада нәрсәләр булып ятканы. Тик моны күзаллавы читен түгел.

Шартлаудан соң ничә еллар су басымын җиңеп җибәрми торган бөянең яртысы күккә күтәрелде дә гөрселдәп суга төште. Ул төшкәнче ташкын буаның калган өлешен ашый башлаган иде, ә вак кына кисәкләрдән торган бөя балчыгы үкереп аккан суга кушылып агып та китте. Бөя урынында хәрәкәткә килгән су агымы кайный, ыргыла, боргалана, сикерә, әйләнә, томан булып күккә менә, яңгыр булып су өстенә тама. Әллә кайдан килеп чыккан иректән нишләргә белми елга упкын ясап бөтерелә. Бу үкерүгә тегермән һәм такта яргыч биналарының диварлары дөбердәп җимерелгән тавышы кушылды, алар әллә нинди көч белән бөянең калган өлешенә килеп бәреләләр, шул бәрелүдә зур-зур кисәкләрне йолкып алып калган суга юл ачалар. Буаның суы яр буена сызык итеп сызган тигезлектән кызу итеп төшә башлады, аның өстендә яткан агачлар, такта кисәкләре, бәйләре өзелгән көймәләр һәм башка бик күп чүп-чар, акрын гына

хәрәкәткә килеп, бер заман тота алмаслык тизлектә бөянең ерылган урынына ташланалар.

Буаның аскы ягында бөтен дөньяны басып алырлык судан биек дивар барлыкка килде. Иң беренче ул, Гәвенгә кереп, җәйдән башлап тик утырып, беренче суыкларда җиргә ябышып туңган ике барканы йолкып алып су белән күмеп китте. Баркалар күтәрелеп, Гәвеннән чыгар юл эзләп, әле бер ярга, әле икенчесенә барып төртелделәр, шуннан агым көченә буйсынып, Танып буйлап китә башладылар, тик әлегә су югары булмагач, бозларны ватып, аларның арасына кереп кысылдылар. Шунда ук су, җирдә яткан бүрәнәләрне җыеп, Танып үзәненең бозына ташлады. Һәм китте бу табигать диварының боз өстендә биюе! Танып Салихны туктатырга дип, егылган агачларны шырпы бөртеген сындырган кебек сындырып, бөкләп ташлый, юлда булган башкаларын борып алып китә, яр өстенә сикереп менеп, тирә-якны үз астында калдыра, урап-урап кире кайтып, бер буш урынны да калдырмый су белән тутыра – менә нәрсә бу кыш көнендә су ташуы...

Җитмәсә, чиксез туфан суы, агачтан агачка сикереп, боз өстеннән уйнап ыргыла, элек буш булган урыннарны күмеп җилү белән генә чикләнми, авылның көтүлегенә, авыл читендәге беренче өйләргә таба чаба.

***

Шартлау тавышын иң беренче булып сакчылар ишетте һәм чаң кактылар. Берничә көн өйрәнгәннән соң, Ильяс лагеренда һәркем ни эшләргә тиешлеген белә иде. Иң беренче – чыгарып өлгермәгән атларны тынычландыру һәм аларны Танып аша үткәрү, икенчесе – бер тавышсыз Каюм мәгарәсенә керү һәм аның аша үтеп удмурт җирләренә чыгу. Боларны беркем дә уйлап чыгармаган, беркем дә әллә нинди китапларны укып тапмаган, – барысы да халыкның гомум акылында булган һәм сакланып килгән хәвефсезлекне хәстәрләү кагыйдәләре һәм Ильясның шуларга карап бирелгән боерыгы.

Су якынлашканнан-якынлаша, ә чыгарасы атлар бар гына. Эшне тизләтү өчен янәшәгә тагын ике бүрәнә салдылар. Бусы инде атларны саклап калдык дигән сүз булды. Беркем дә шәхси әйберләр турындагы уйны башына да кертмәде. Ильяс кушканча, мәгарәгә башта ике кешене кертеп җибәрделәр ул-бу юклыгын тикшерү өчен. Монысы да дөрес карар булган – теге башта Сафаның өч-дүрт башкисәре аларны сагалап утырганнар икән. Аларның бернидән курыкмыйча, учак кырында җылынып утырулары аптыратты партизаннарны. Ильясның мәгарә кырында, аның эчендә атарга ярамый дигән сүзләрен искә төшереп, аларны егып та салдылар, өчесен өч агачка урап бәйләп тә куйдылар. Тик берсе генә мылтыгын ташлап йөгереп качып котылды.

Тау куышына берәмләп керү өчен чират көтеп торганда, күз иярмәслек тизлек белән биек су диварының килгәне күренде. Биш аршиннан биек булган бу диварның бозлы елга үзәне буйлап үкереп килүендә әллә нинди дәһшәт барлыгы сизелә иде. Бер мизгел эчендә килеп җитеп, Томафи карт йортын туздырып ташлады, алырга өлгермәгән әйберләрне туздырып узды да китте. Ә дивар артыннан чиксез су диңгезе дөньяны басып алды.

Шунда гына аңладылар алар Ильясның боерыгының бик вакытлы

булуын. Әгәр су килгәндә, халык лагерьда булса, берәүнең дә исән калмаячагын алдан күргән бит ул!

Буадагы шартлау җир астыннан да йөгереп үткән, күрәсең. Тау куышында бер-ике җимерелгән урын да бар иде, тиз генә аларны да чыгарып ташладылар. Атлар бу урыннан куркалар, алга бармый артка чигенәләр. Куыш эчендәге караңгылык шулай куркыта аларны. Сафа башкисәрләренең учагыннан торымбашлар алып, юлны яктырткач кына, алар бик зур шик белән, пошкыра-пошкыра, алга атладылар.

Бер нәрсә уйланылмаган булып чыкты. Томафины су басып китсә, Катнаш төркем ни эшләргә тиеш? Бик озак уйлап тормадылар бу турыда. Биш кешене атларны сакларга калдырдылар, калганнар белән Таныпның биек ярлы ягыннан Казанлыга юл тоттылар.

Теге өч башкисәрне дә, бәйләп, үзләре белән алырга туры килде.

Кемдер шунда Таныпның үкерүенә игътибар итте. Катнаш төркемнең командир ярдәмчесе Мәрдән карт аңлатты нигә икәнен:

– Салихныкылар башына үкерә ул бу юлы!

**68**

Мобилизацияләнгәннәрне станциядә ашык-пошык киендерделәр дә, теплушкаларга төяп, каядыр озаттылар. Бары иртән кояшның кайсы яктан чыгуына карап, Ризван көнчыгышка китеп барганнарын башкаларга җиткерде. Станцияләрдә бар да составның теплушкаларында элекке тәртипнең булмавына игътибар иттеләр. Командирлар күренми, туктаган саен нәрсәдер төйиләр, беркемгә дә беркем дә кирәкми.

Теплушкага илдә булып яткан хәбәрләр дә килеп кергәли. Беренче хәбәр кызылларның Казан ягында бик уңышлы операцияләр үткәргәне турында, күп шәһәрләрнең кызыллар кулына төшүе турында. Боларны инде яшереп тотып булмый, ачыктан-ачык сөйли башладылар. Шулай булгач, бу составны Екатеринбург ягына кууның кирәклеге бер дә аңлашылмый иде. Каршы торасы, каршы барасы урынга бар да көнчыгышка карап китеп баруны белә. Монысы нинди стратегиядер, уйлаучы бармы икән шул турыда? Ашауның да рәте юк, беркем кереп тикшереп тә йөрми. Берничә мәртәбә Ризванның башына качып китәргә кирәктер дигән уй килде. Төш тә кал, аннан урман буйлап кайт та кит. Кем, кем, ул урманда югала торган кеше түгел, ашарына да табар иде. Тик кием... Кием, чыннан да, әтәч тиресеннән шул! Моның белән урманда түгел, теплушкада өшеп-туңып баралар бит әнә. Болай киткәндә, авыллар аша барырга кирәк булачак, ә бу инде иртәмесоңмы барыбер аклар, йә булмаса, кызыллар кулына эләгәсеңне көт тә тор. Шуңа Екатеринбургка җиткәнче түзәргә булды ул. Төзелеп бетмәгән юлларда урап йөри торгач, аңа да барып җиттеләр, тик зур шәһәргә кереп тормадылар, состав тагын алга китте. Камышлов станциясенә килеп җиткәч кенә, яңа солдатларны, теплушкалардан куып төшереп, салкын җилдә тезеп куйдылар. Ачлы-туклы солдатлар монда ашатырлар дип көттеләр. Тик оныттылар, ахры, аларның дөньяда барлыгын. Сәгатькә якын басып торгач, тезелгән саф таралды, беразы станция буйлап ашарга эзләп киттеләр, беразы үзләренә урын табып, җиргә, шунда яткан агачлар өстенә утырдылар. Тагын бераз вакыт үткәч кенә, исләренә төште бугай монда солдатлар барлыгы, йөгереп чыгып, сафны яңадан җыя башладылар. Монысы бик

озакка сузылды, таралган халыкны көчкә җыеп, сафка бастыра алдылар. Шунда ук аларны, өчкә бүлеп, бәләкәй генә шәһәрчекнең өч ягына алып та киттеләр. Ризван төркемен станциядә комендатура солдатлары вазифасын башкарырга калдырдылар.

Комендатураның вазифалары бер эшкә кайтып кала – ул да булса дезертирларны, ялгыз йөрүче солдатларны тотып, бер җиргә җыеп, кем икәнен ачыклау, алардан хәрби төркемнәр оештырып, фронтка озату. Тик алай йөрүчеләр дә тәҗрибәле, бер дә тотылып бармыйлар, кечкенә шәһәрчекнең бар урамнарын, йортларын беләләр, кирәк булса шунда ук юкка чыгалар. Аларның күбесе кораллы, сугыш яланнарында җыелган тәҗрибәне кулланып, каршы тора беләләр. Әгәр алар качып йөрү белән генә чикләнсәләр, әллә ни игътибар да таләп итмәсләр иде. Тик бик еш була башлаган урлашу, кеше талау очраклары бу оешкан башкисәр төркемнәре белән көрәшергә мәҗбүр итте, аларны сугыш заманы кануннарына ярашлы рәвештә юк итүне көн тәртибенә чыгарды.

Тимер юлы буендагы зур амбарларга һөҗүм иткән шундый төркем белән бик җитди бәрелеш булды бер көн. Барысы да алдан уйланылган иде бу эшнең. Вакыты – ике поезд очрашкан вакыт, ыгы-зыгы, буталыш. Юллары – бары ике юл калдырып, калганнарында баррикада кору. Кешеләре – кем нәрсә эшләргә тиешлеген яхшы белү, кайда нәрсә ятканыннан хәбәрдар булу. Тагын бер нәрсә – бандитларның күбесе, кызылларга охшатып, бүрекләренә кызыл тасма такканнар иде.

Җиңделәр җиңүен. Тик ике яктан да яралылар, һәлак булганнарның саны зур иде. Кулга алынганнарны озатып килгәндә, Ризван ике кешегә игътибар итте. Болар – якташлар, Казанлы ягыннан иде. Икесе дә башкисәрләр төркеменә кичә генә килеп кушылган, кемнең кем икәнен белмәгән дезертирлар. Боларның язмышы билгеле – бернинди тикшерүсез аларны атачаклар.

Ялгышты бугай һәрчак бик сак булган Ризван. Якташларны җәлләү тойгысы өскә чыкты, шәһәрчекнең тар гына урамнарын үткәндә, ул аларга йөгерергә кушты. Тегеләргә шул гына кирәк, шунда ук юкка чыктылар. Башка кулга алынганнар, нидер сизенеп, Ризванга ялыналар, ә иң усаллары аның бу эшен өскә, түрәләргә җиткерәбез дип яный да башладылар. Бу янауларны игътибарга алырга кирәк булгандыр да соң...

Комендатурада арестантларны алар өчен тиз-тиләмән эшләнгән бүлмәгә ябып куйгач та, саттылар Ризванны теге усаллар.

Алай гына да түгел, үзләренә ирек даулап, алар Ризван өстенә әллә нинди гаепләр өеп куйганнар, бу гаепләрнең чиксез, тозсыз, мәгънәсез булуын аңлау беркемгә дә кирәк түгел, аларны тикшерерлек, аларның агын карадан аерырлык кешеләре дә юк иде.

Ризванны да идән астына ябып куйдылар. Командирның әйтмәгән сүзе калмады, шунда ук таш диварга терәү белән куркытты. Ризван мисалында бөтенләй төшеп барган тәртипне ныгыту иде аның башында. Боерык боерык инде, ул тулысынча үтәлергә тиеш, шулай булмаса, армия булмаячак. Монысы да дөрестер, тик... Ялгышу бар, кешеләр тойгыларга бай, кайчакта халыкның аскы катламнары чынынданиләр булганын өстәгеләргә караганда әйбәтрәк белә бит!

Белсә ни.

**69**

Сәгатенә карый-карый, волость бинасында, Салих бөтерелә. Ниһаять, күк күкрәгәннән дә көчлерәк булып шартлау тавышы яңгырады. Көчле су агымының тавышы хәтта монда да ишетелде. Барысы да уйлаганча, Салих, бик канәгать булып, тамагын кырып куйды. Әлегә караңгы, берни эшләп булмый, көтәргә кирәк! Монысын уйлап та өлгермәде, хәбәрче солдат йөгереп килеп керде:

– Капитан әфәнде, корал белән Михайловкага барган олауны талаганнар, өч кеше үлгән, икесе юкка чыккан!

– Ә?

Солдат хәбәрен кабатлады.

– Җый барысын да! Тревога!

Урындык өстендә яткан шинелен эләктереп, Салих ишеккә атлады. Шул арада икенче солдат атылып килеп керде.

– Чияле таудан, тегермән ягыннан һөҗүм башланды!

– Кем?

– Белмим!

– Күпме кеше?

– Белмим!

– Дур-рак! Бел!

Салих волость алдына йөгереп чыкты һәм тыныч кына тиешле боерыкларын бирә башлады:

– Пулемётны кырыйдагы өйгә! Тиз! Калганнар – алдан сайланган позицияләргә!

Үзе лапас астында торган атына таба йөгерде.

Бу вакытта авыл урамында калган кешеләр дә йөгерешә башладылар. Сәрия Рәфыйга апасы белән көлә-көлә карап тордылар Гаязетдин өеннән бу бик дәрәҗәле һәм тәкәббер булып йөргән кешеләрнең ыгы-зыгы килүенә: чапанын бер кулы белән тотып, Хәниф мулла йөгерә, юан Фазылҗан, вак-вак атлап, артына карый-карый, киртә буйлап чаба, старшина, ике аягына да аксап, юл уртасында туктап калды...

Елганың теге ягында пулемёт ата башлады. Урамның бер теге башында, бер бу башында Салихның нык, көр тавышы яңгырый:

– Михайловкадагы отрядны алып килергә! Нәрсә аптырап торасың?

– Яраландым! Аталар!

– Шуннан нәрсә? Сугыш бу! Корал тота аласыңмы? Соңыннан яраларны бәйләрбез! Пулемётка ни булды?

Озак еллар хәрбилек тәҗрибәсе бу бар яктан да уңышсыз булган юнәлешнең игътибарны читкә алып китәргә тырышып эшләнгәнен Салих аңлый. Шуңа күрә дә ул бу якка әллә ни күп кеше дә куеп тормады, әлегә аның бөтен булган игътибары волостька туп-туры чыга торган Үгез чишмә юлы. Әгәр Тукмай сазлыгын боз өстеннән үтә алсалар, әгәр Танып суы басып китмәсә, бу юнәлеш һөҗүмнең төп юнәлеше булачак. Игътибарны үзендә тоткан икенче юл – станция юлы, моннан көтмәгәндә ярдәм килеп җитүе ихтимал. Моны ул, планнарын корганда ук, колакка киртеп куйган иде, анда поскын оештырды.

Шуңа да ул үзенең боерыгында солдатларга бик артык күзгә күренмәскә, бары тик окоплардан һәм ышыктан баш күтәрмәслек итеп партизаннарны утта тотарга кушты. Хәрби әзерлек ягыннан аның

солдатлары Ильяснықыннан күпкә югары, монысы бәхәссез, аларга тиешле, уйланылган боерык кына кирәк. Алар урындагы булачак бәрелеш мәйданының үзенчәлекләре белән яхшы таныштылар, чигенгән очракта да кайда, ничек, кайчан җыелырга икәнен беләләр. Корал алдан карап куелган, башка сугыш кирәк-яраклары җитәрлек. Һәркем үз урынын яхшы белә, үз эшен беренче мәртәбә генә башкармый. Кешеләре күп булмаса да, Салих бер төркемне резервка да чыгара алды. Степан төркемен сугышка кертүнең, әгәр ул кирәксә, берничә төрен дә уйлап куйды. Нигездә, алар кеше куркыту өчен: саранча болытыдай чабып килгән атлылар сугышта чәчләрне үрә торгыза торган куркыныч күренеш ул – моның дөреслеген сугышта казаклар да, шул ук «Кыргый дивизия» сугышчылары да мең мәртәбә исбатладылар.

Планның ныклыгын, дөреслеген тикшерергә вакыты булды, берәм-берәм һәрбер урамны, һәрбер тыкрыкны, йортны урап чыкты Салих, җайлы урыннарга ут ачу нокталарын урнаштырды, уңайсызларына игътибар итеп тә тормады. Тагын да каршылык күрсәтерлек итеп табигать тарафыннан булдырылган урыннар да аз түгел: елгалар, чокырлар, калкулыклар, аларга өстәп, кешеләр тарафыннан булдырылганнары – буалар, күперләр, өйләр, киртәләр, таш кибетләр.

Бернәрсә дә калмаган кебек иде Салихның очлы күзләреннән. Тик бәрелеш аның бер ялгышын китереп чыгарды, һәм бу ялгышлык, бу хата, үз чиратында, бәрелешнең барышын үзгәртеп җибәрде.

**70**

– Син... – Степан тын ала алмый төелде. – Син... нәрсә эшлисең, эт баласы? Ә?

Степан, усал карап, Савкага табан атлады. Нина аңардан ычкынып, бүлмәдән чыгып йөгерде.

– Син нәрсә уйладың, хайван?

Савка куркудан ап-ак булды, татулашырга тырышып, аңа сүз кушты:

– Ә син нәрсә, Степан Акинфиевич? Әтәч кебек кунарга әзерсең! Бәлки син мине кызларга кагылудан тыярсың?

– Кагыл, сүзем юк, тик Нинага түгел! Әгәр алай тупас итеп тотынганыңны күрсәм, сугып үтерәм, бел! Гөнаһка барып җитсәм җитәрмен, кызымны мыскыл итәргә бирмәм!

Савка, усал итеп елмаеп, теш арасыннан сыгып чыгарды:

– Әйе инде, синең кыз – дворянка! Кая инде безгә, кара мужикларга аңа тиклем!

– Ну! – Степан тилерә язып кычкырып җибәрде. – Үтерәм, кабахәт! – Ул ишек янында эленеп торган винтовканы эләктерде.

Чуров, тиз генә борылып, ишек буендагы сәкегә карады – винтовка анда ята, тик ерак, өлгермәячәк. Ә бу өлгерә, ничек тә өлгерә.

– Ярар инде, Степан Акинфиевич. Мин бит шаярып кына! Син нәрсә инде тагын? Ну, гафу ит тилене, ә? Ну, гаепле, шаярам дип уйлап, уеннан уймак чыгара яздым! Мин бит аны... – Савка театраль пауза ясады. – я-яратам!

Савканың тавышы йомшак итеп, калтырап яңгырады. Степан күтәрелгән винтовкасын акрын гына төшерде, ачуын баса-баса, Савкага эндәште:

– Син... кем белән уйнагыңны белеп уйна! Нина бала-чага түгел,

җиткән кыз, минем бердәнбер, яраткан кызым! – Һәм үкенеч, шелтә белән тәмамлады. – Ә мин сине кияү булырсың дип уйлаган идем бит! Ә син? Э-эх, егет!

Тик сөйләп бетерә алмады, ишекләрне дөбердәтеп ачып-ябып, Казанлыдан йомышчы солдат йөгереп килеп керде.

– Казанлыга һөҗүм!

– Кем?

– Билгесез! Мин приказ алып килдем.

Чуров астыртын итеп елмайды.

– Приказ? Исенә төште тагын!

Солдат кәгазь кисәген сузды. Степан, тырышып, аны укып чыкты: «Приказываю немедленно выступить в Казанлы. Наступают с двух сторон. Немедленно! Шт.-капитан С.Х.Зиганшин».

Степан һәм Савка бер-берсенә карашып алдылар.

– Бар, Савка! Шулай кирәк!

– Ә нигә мин? Син бит командир!

Пулялар астына керәсе килми иде Савканың, ох, килми! Шул гына җитми әле! Барсын, әнә, Степан!

– Ярар, әйдә, алайса, бергә!

– Ә нигә әле ул безгә боерык бирә? Кем булган әле ул?

– Минем өчен әллә кем булсын! Бер Аллага хезмәт итәбез дә! – Степан тәрәзә кырында таптанып йөргән сакчыга эндәште. – Әй! Җый барысын да тиз генә мәйданга!

– Барыбер безгә анда чабудан файда юк! Ул бит әфисәр, укыган кеше, җиңсен, әйдә, җиңәлсә! – Савканың тавышы калтырый иде.

Килгән солдат, көлемсерәп, командирлардан җавап көтә. Степан чыгырдан чыгып китте, ачуланып, тавышын күтәрде:

– Син ни сөйлисең, малайка? Ну-ка, киен тиз генә! Син нәрсә, сугышны кызларга ябышып яту дип уйлый идеңме? Чүбек чәйнәп утырма монда!

– Шуннан, мин бит авырып торам. Атта йөри алмыйм. Үзең дә күргәнсеңдер, гел җәяү йөрим!

– Алай булгач, җәяү барырсың! – Степан егетнең мактауга килүен исенә төшереп дәвам итте – Миңа синең кызу, булдыклы башың кирәк анда. Синсез булмый! Шулай булгач, әйдә, Савелий. Бергә башладык, бергә тәмам итик!

– Тәмам? Нинди тәмам ди әле? – Савка, куркудан калтырап, кычкырып җибәрде. – Нинди тәмам? Мин куркам! Минем үләсем килми! Те-лә-мим!

Степан көлеп җибәрде.

– Кем сине үлемгә куа? Нәрсә хатын-кыз кебек яшь түгәсең? Марш!

Ишеккә сакчы какты.

– Степан Акинфиевич, җыелдык!

– Күпме?

– Кырык тирәсе.

Степан белән Савка урамга атладылар. Егорьевна нидер әйтергә тырышып карады, тик Степан этеп җибәргәч, читкә тайпылды.

Тиз генә бурычларны аңлаткач, Степан «Алга!» дип боерды. Бер мизгелдән, кар тузаннарын туздырып, Степан белән янәшә, уйлап чыгарган авыртуларын онытып, бераз тынычланган Савка да атта чаба иде.

## 71

Әллә кайдагы әтәч кычкырып уятты иртәнгә табан йокымсырап киткән Ризванны. Капкачлар белән капланган тәрәзә ярыгыннан адашкан кояш нуры килеп кереп, каршы стенага кунаклады. Иртәнге тынлыкны сирәк ишетелгән ату тавышы, пар күтәргән паровоз пошкыруы гына бүлде.

Ризван идәндә бөкләнеп яткан кешеләргә карады. Ничәсе бүген якты дөнья белән хушлашыр инде? Үзенең дә язмышы ятлар кулында, ни телиләр, шуның белән тәмам булачак. Башны чүкегән сорау – нидер эшләргә кирәк. Төшеп каласы булган вагоннан. Кем эзләр дә кем табар? Ничек кенә булмасын, Ризван аклар ягында тәртип булыр дип уйлаган иде, булмады. Әгәр хөкем карары барысын да атарга дигән булса, үзен дә, башкаларны да азат итәргә тырышып карарга кирәк булыр.

Иске сарай ишегенең тутыгып беткән йозагы шалтырады. Кемдер аны бик тырышып борды, тик ул ачылмады. Гаиләсе белән Олы-Елгага өй күрсәтергә барганнары Ризванның исенә төште: майланган «богау» йозак келт итеп ачылган иде ул чакта. Ризванның башыннан хәтер битләре бер-бер артлы ачылып үтте. «Юк, болай гына бирелмибез әле! Яшисе бар әле!» дигән уй тирәнрәк иде башкаларыннан.

Ниһаять, ишек ачылды, бер подпоручик, ике солдат озатуында аны караңгы baздан яктыга алып чыктылар. Бары яктыга чыгып, азрак күз ачылгач кына, Ризван подпоручикның йөзе таныш булуына игътибар итте, тик бер сүз дә әйтмәде. Йортта солдатлар читкәрәк тайпылдылар, подпоручик Ризванга карап эндәште:

– Ризван абзый, мине таныгансыңдыр инде. Мин бит Гәрәй!

– Таныдым. Тик кеше алдында тануымны күрсәтмәдем, йә сиңа бу зыяны белән чыгар дип уйладым.

– Рәхмәт! Ничек бу хәлләргә тарыдың? Ничек бу таш капчыкка килеп каптың? Безгә тизрәк моннан чыгу юлын табарга кирәк! Әйдә, утырып сөйләшик, – дип, шунда тәгәрәп яткан карлы бүрәнәләргә күрсәтте.

Ризван бер мизгелгә сүзсез генә торды да сөйли башлады.

– Беләсеңме, мин армиядә акыллы командирлар, тәртип бар, кешегә игътибар бар дип уйлаган идем. Шуңа да мобилизациядән башкалар кебек качып калмадым. Минем мөмкинлекләрне беләсең бит, кемне-кемне, мине эт тә таба алмас иде, әгәр теләсәм.

– Беләм. Шулай итәсе булган да бит...

– Шуннан, мин акларын да, кызылларын да якыннан кабул итмәдем. Сугышка, көчләүгә каршы кеше бит мин! – Ризван тагын тынып калды. – Тик соңгы ярты елда әллә ниләр булды минем язмышта. Тәкъдирдер инде, тәкъдир! Ни хәл итәсең! Өч баланы бер-ике көн эчендә югалттым, Олы-Елгадагы өр-яңа өйне яндырдылар, уйнап торган дүрт атымны авылда бары бер атна торган кызыллар талап алды. О, син белмисең аларның бездә ничек ерткычланганын! Алар күзендә без барыбыз да байлар. Димәк, яшәргә бер хокукыбыз юк! Миндә торган солдатлар кайда нәрсә күрә, шуны биштәренә сала, алып китәргә дип яшереп куя. Күтәрә алмаганын ватып-кырып ташлыйлар. Мин нинди бай инде аларга? Менә шулай тәмам җәфа чиктем, чыдар әмәлләрем калмады. Әйттем хуҗаларына, тыегыз бу каракларны дип.

– Тыйдылармы?

– Тыйган ди! Мине волостьның теге бүлмәсенә бикләп куйдылар. Өч көн ач ятканнан соң чыгардылар. Ә кайтсам... Гаиләне абзарга куып чыгарганнар, өйдә япа-ялан, бернәрсә калмаган. Малны суеп ашап бетергәннәр.

– Бер синдә генә түгел бу хәлләр, бөтен Рәсәй буйлап!

– Рәсәй зур! Кеше хәлен кеше белми шул. Үз башына төшмәсә. – Ризван зәңгәр күктә аккан болытларга карап торды. – «Әгәр каршыга бер сүз ишетсәм, – диде командирлары, – гаиләңне җәзага тарттырам, үзеңне базар мәйданында асып куябыз». Түздем инде, түздем тешне кысып.

– Шуннан?

– Шуннан ни, аклар килде. Болары азрак кына тәртиплерәк иде. Әллә талар нәрсә калмагангамы? Синең абыйны танырлык түгел – Салих та бер кансыз-җансыз кешегә әйләнгән. Бу аптыратты барыбызны да. – Ризван тагын туктап калды. – Менә шулай ике якка да ышаныч бетте. Йорт-кураны, өй эчен азрак җыештырдым, көйләштердем. Сөйләшер кеше калмады, бар да бер-берсеннән курка. Кайчакта күрше карт белән генә бәхәсләшәбез.

– Нәрсә турында инде?

– Бер сүз инде, бер сүз. Йә аклар, йә кызыллар килә. Йә берсе талап китә, йә икенчеләре килеп, соңгы бөртегенә тиклем бөтен булган мөлкәтне җыеп ала. Бездә дә, башка җирдә дә шул ук хәл!

Гәрәй беразга тын калды. Туган белән туганнар сугышы, аклар, кызыллар, әллә нинди башкисәрләр, кан коючылар, кеше талаучылар – болары турында ишеткәне генә түгел, инде үзе күпме шул казанда кайный, тик бу хәлләр аның туган ягында булып ятамы? Монысына ышану кыен иде шул.

– Ата улны, инә кызны белми дип әйтергә була бездәге хәлләрне!

– Ә власть ни эшли инде?

– Бездә бертөрле власть юк, бертөрле канун юк! Волость эшләгән була да ул, тик исем өчен. Башта Ибраһим урлашудан башканы белмәде, урыны җәннәттә, әйдә, булсын.

– Аңа ни булды инде?

– Таныпта, Кәлтә урманында таптылар. Аты дулап, күпердән елгага очкан, башы белән нәкъ субайга туры килгән. Мин моңа ышанмыйм. Матусов кешеләре суга салган дип тә сөйләде халык. Монысы дөрестер.

– Алай икән!

– Шуннан Зариф йөргән булды старшина булдым дип. Аны бәреп төшереп, Ильясны куйгач кына, эш башланды. Тик аклар килгәч, аңа партизан булып китәргә туры килде.

Бу теманың бик озын икәнлеген аңлап, икесе дә туктап калдылар.

– Ризван абый, сиңа исән калу өчен үзеңнең җырыңның бугазына басарга туры килер. Командирлар белә, мин алар белән инде сөйләштем.

– Шуннан нәрсә була инде?

Гәрәй тынып калды.

– Полк командиры кулын селтәде, «Пусть повинится, может, и прощу», – диде. Боларга бүген һәрбер солдат кадерле, әйдә, шуның белән файдаланып калыйк, ә? Син моны бик әйбәтләп уйла, бу бер генә юл! «Ялгыштым, гафу итегез, белем юк, авыл кешесе, армиядә бары бер-ике ай, фәлән-төгән...» – шундый булырга

тиеш синең җыр бу хәлләрдә. Мин хәзергә киттем кушылган эшләрне үтәргә. Ә син уйлый тор һәм сөйләшкәнне үтә!

– Иелгән башны кылыч кисми дисең инде?

Киттеләр икесе ике якка: каравыл Ризванны яңадан шул идән астына озатты, ә Гәрәй штабка кереп китте.

***

Нәрсәгә ышангандыр Ризван, хәбәр бирмәде Гәрәйгә командиргa башын иеп бару турында. Һәрвакыт югары торган горур баш бу юлы да, гәрчә үлем куркынычы янаганда да, иелмәде.

Кичкә таба җиде кешене шәһәр кырына алып чыктылар. Алар арасында нык кына ирләр бар иде – Ризван алдан ук атучыларга каршы чыгу планын аларга әйтеп куйды. Беренче калкулыкны үтеп, елгага таба тайгак бозлы юлдан борылганда, алар озатып баручы солдатларга ташландылар.

Гади фетнәче түгел иде Ризван, аны гыйсъянчы дисәң, дөресрәк булыр иде. Үз юлын эзләгән, беркемгә дә, беркайчан да буйсынмаган шәхес. Кешегә бирелгән табигый азатлыкны барыннан да югары куйган, ул кешегә бирелгән шушы азатлыкны басуга каршы чыккан шәхес, горур азат кешене яклап чыккан, тормыш борылышларында үзенең югары кешелек сыйфатларын саклап кала алган романтик шәхес. Бар булмышын дөньяны, тирә-як мохитне өйрәнүгә, табигать белән бер дулкында яшәүгә юнәлткән гаҗәеп, искиткеч Кеше.

Үз кордашларыннан бар ягы белән дә аерылып торган, ун, бәлки, йөз елга алдарак туган Ризванның соңгы минутлары да үзенчә булды...

Өч кеше качып китә алды. Ризван алар арасында юк иде – сакчылар аткан пуляларның берсе аны куып җитеп, каты яралауга карамастан, ул елгага таба шуышты, тик көчләр акрын гына эреп беттеләр. Язгы көннең алдакчы җылысына ышанып чыккан бер елан, артына борылып карый-карый, читкә тайпылды аңардан.

Ризванның соңгы карашы офыкка төшеп барган кып-кызыл, зур кояшта иде...

**72**

Бәрелеш әллә нинди көтелмәгән юнәлешләр ала башлады. Салих таудагы партизаннарга каршы резервын ташлады. Иң зур куркыныч тудырганы авыл башындагы пулемёт иде, ул баш күтәрергә дә ирек бирми. Беренче Казанлы төркеме командиры Карам төрлечә урап үтәргә тырышып карады, тик патроннарны җәлләмәгән Салихныкылар баш күтәрергә дә ирек бирмиләр. Шул вакытта аның кырына партизан Фәтхинең улы Муллануp килде.

– Карам абый, Мута елгасы буйлап боз өстеннән талларга ышыкланып барганда, пулемётка граната ташларга була.

– Кит! Анда боз калын түгел, кешене күтәрми. Яр буенда суы да бар кебек?

– Күтәрә! Мин барып сикергеләп тә карадым. Күтәрә. Ә су юк, инде туңган.

Карам буйга үсеп килгән тал чыбыгы кебек ябык үсмергә бик озак карап торды. Әйе, аны боз күтәрәдер. Тик...

– Ә син гранатаны бәрә беләсеңме?

– Беләм. Үзегез өйрәттегез бит Томафида.

– Менә сиңа граната. Күрсәт, ничек әзерлисең?

Мулланур җиңел генә бар булган юлларын күрсәтте граната ташлауның. Карам егетнең төпле булуыин үзенә билгеләп куйды.

– Ә этиең кайда?

– Яраланды ул. Тегермән артында ята, яраларын бәйләп, шунда калдырдык.

– Ярар, бар, Мулланур. Тик үзеңне сакла, яме. Булмастай булса, борыл да кирегә кайт. Ике граната җитәрме сиңа?

– Җитә!

Юкка да чыкты Мулланур. Чынлап та тегермән буасы кырында биек, юан өянкеләр, таллар, аларның яфраклары булмаса да, бик тыгыз утыргач, алар артында ни булуын бик күрерлек түгел.

Аңлашылмый, нигә Ильяс күренми? Инде килеп чыгарга тиеш бит! Әгәр бер сәгать эчендә алар килеп җитмәсәләр, Карам отрядының язмышы бик аяныч булачак. Ә пулемёт, чынлап та, баш күтәрергә дә мөмкинлек бирми. Ул гына да түгел, Сары саз яланыннан аклар контратака ясарга әзерләнеп яталар. Тагын бер куркыныч нәрсә – әгәр болар өстенә Михайловкадан Степан отряды да килеп һөҗүмгә ташланса, тар-мар итү тулысынча булачак. Карам, берничә партизанны чакырып алып, Мулланурга кайтыр юлны тәэмин итәргә кушты.

Шул вакытта граната шартлады һәм пулемёт тынып калды. Җибәргән кешеләр Мулланурны тартып алдылар. Пуля аның яңагын тишеп үткән, ә иреннәрендә елмаю, күзләрендә яшь тамчылары кысылып калган иде...

Урамда атакага килүчеләрнең «Ура!» тавышы яңгырады – болары инде урманнан чыккан Ильяс отрядыныкы иде. Аның соңлавы волость бинасына турылап чыкмауда булды, ул, авыл башыннан урап, су ярган ерым буйлап авылга килеп керде. Ә Салих аны моннан көтмәгән иде, ул бу хәйләкәрлек кызылларның башына кермәс дип зур хата ясады. Ә партизаннар аның бу хатасыннан бик оста файдалана алды.

Тик аклардан бер кеше дә «ура»дан куркып качмады. Авылның волость янында пулемёт тыкылдый башлады, Ильяс отрядына кем кайда урын таба, шунда җиргә егылырга туры килде. Отрядның хәле күренеп авырлаша башлады, чөнки ул ике яктан кысып килүче Салих кешеләре арасында калды. Патроннар да бетәргә охшаган, авыл өйләре артында яткан акларны куып чыгарырга бер генә юл – өйләрне яндыру, тик Ильясның кышка таба авылдашларның яшәү урынын яндырасы килми. Тагын бер авырлык килеп чыкты: авылның көньягыннан әче итеп сызгырып, ай-һайлап, Степанның атлылары очып килгәне күренде.

Ильяс берничә мәртәбә өмет белән станция ягына киткән юлга карап алды, тик анда Титовның отряды күренми иде әле.

Ниндидер карарга килергә кирәк иде. Урамда яткан партизан чылбыры аша ул барысына да волостька табан чигенергә кушты. Волостьны бераз тотып була, аның карагайдан буралган диварлары бернинди пуляны да үткәрмәслек. Бер куркыныч – Салихның бинага ут төртүе бар. Анысы – соңыннан, әле түгел, әлегә партизаннарны саклап алып калу кирәк. Бер җылы хәбәр – атларны елга аша чыгарырга дип калганнар, авыл очына килеп, Салихның Томафига каршы казылган окопларыннан акларны бәреп чыгарды, волостька килергә тырышкан солдатларны акрын гына

Мосинның озын көпшәсеннән чүпли башлады. Монысы бик кирәкле ярдәм иде, волостька ут төртү турындагы Салихның өметен шунда ук юк итте ул.

Волостька чигенергә дигән карарга Ильяс аңлы рәвештә барды. Әйе, уратып алачаклар, монысы бар. Тик ул барыбер Титовның килеп җитүенә ышана иде һәм аны көтте.

Һәм килде Титов. Матусовның хуҗалыгын карау өчен төзелгән кечкенә Таулы авылы аша башы-азагы булмаган атлылар төркеме чыга башлады. Аларның тизлеге яшен тизлегенә тиң, кышкы салкын, соры көндә кылычлары ялтырап ала. Алар шул ук тизлектә авылга килеп тә керделәр, каршы чыккан акларны турап та салдылар, ә башкалары каршы килергә батырчылык итмәделәр: Степанның исән калган кешеләре Михайловкага җилдерделәр, Салихның солдатлары, корал ташлап, кул күтәреп бирелә башладылар. Шулвакыт җанланып киткән пулемёт оясын бер мизгелдә юк иттеләр.

Титов белән Ильяс кочаклашып очраштылар. Башта сүз дә әйтә алмый карашып тордылар, шуннан нык итеп кул кысыштылар.

– Иптәш Ягафаров! Өлгердек бит! Тау башында борылмага Салих поскын куйган. Без, аны-моны уйламыйча, чак барып кермәдек аларның утлы кочагына. Ярый әле, сугыштан килгән сизгерлек бар, разведка җибәрдек бу урынга. Поскынны кырмый үтә алмадык. Гафу ит соңлаганга.

– Инде була гафу итәргә дә. – Ильяс көлеп җибәрде. – Җиңдек бит. Кырып салдык боларны.

Шул арада Нигъмәт йөгереп килеп җитте.

– Ильяс, Сәлимә волостьта юк. Монда булганнар, тик иртән аларны каядыр алып киткәннәр.

Ильяс болар белән сөйләшкән арада берни аңламаган Титов, нидер сизенеп, тып-тын гына басып торды. Шунда партизаннардан берсе аңа сөйләшүне тәрҗемә итә башлады, хәлне кыскача ачып бирде. Аны тыңлаганда, Титовның кашлары өскә менеп китте, ул, тел шартлатып, башын чайкап тыңлады хәбәрне.

Карам, якасыннан бер кулы белән тотып, өстерәлгән бер бәндәне алып килде алар янына.

– Менә бу белергә тиеш аларның кайда икәнен.

Монысы, куркудан бер сүз әйтә алмый, әллә ни сөйли башлады.

– Ми-ми-ми... бу-бу-бу...

– Хәзер ачам мин аның телен!

Нигъмәт, борылып, бу кешенең борынына берне утыртты да: «Булдымы?» – дип сорады. Тегесе пычрак куллары белән борыныннан аккан канны сөртә-сөртә баш какты.

– Йә, сөйлә, нәрсә беләсең?

– Мин – Сафа кешесе.

– Аңладык, башкисәр.

– Хатыннарны Матусовның елга буендагы урман өенә алып киттеләр. Мине монда, сезне алдап, эз югалту өчен калдырдылар.

Ильяс тиз генә соравын бирде:

– Ә еракмы ул?

– Таныпның теге ягында, моннан җиде-сигез чакрым.

Нигъмәт Ильяска борылды:

– Мин беләм, ахры, ул өйне. Әйдә, Ильяс!

Кемдер тиз генә ат китерде. Эшнең нидә икәнен аңлап алган Титов, кулларын селтәп, «Бар-бар!» дип торып калды. Ун-унбиш коралланган атлы Танып ягына карап чаптылар.

***

Ике сәгатьтән соң Матусовның урман өен таба алмыйча кайттылар. Карт әйткән өйне Танып буендагысын шартлаган буа суы басып киткән, актарып ташланган, анда кеше торганга охшамаган. Тегендә-монда сугылып карадылар, тик таба алмадылар.

Сафа калдырган карт баягы ыгы-зыгыда юкка чыкты. Аның «Мине монда, сезне алдап, эз яздырыр өчен калдырдылар» дигән сүзе барысының да келт итеп исенә төште. Димәк, алдандылар, ә бу хәйләкәр карт, үзен жәлләтеп, Ильясныкыларны төп башына утыртты. Ильяс, картны эзләтеп Чүпрәлегә атлылар җибәрде, Сафа кешеләрен табып алып килергә кушты.

***

Партизаннар арасында хөкем сөргән күтәренкелектән, шатлыклы ыгы-зыгыдан файдаланып, старшинаның озын ат абзарыннан атларын чыгарып, берничә кеше Чернушкага таба ташланды. Беренче атта Салих иде. Алар артыннан куарга җибәрелгән пулялар еракка һәм биеккә очты.

**73**

Бераз вакыттан соң гына сөйләшә алдылар Титов белән Ильяс. Икесе дә хәлнең вакытлыча уңыш булуын яхшы аңлыйлар иде.

Партизаннар командирларны тыгыз кулча булып урап алдылар. Кемнеңдер күзендә яшь тамчылары уйный, кемдер аларны сөртеп тә тормый елый, кемдер шатлыктан көлә, кемдер сугыш кызуыннан суына алмый, «Ура!» дип кычкыра. Тагын бер мәртәбә Ильясның иңбашларыннан кагып, Титов партизаннарга борылды:

– Иптәшләр! Менә безнең отрядлар килеп кушылды. Тик моны мин отрядлар гына түгел, безнең янган йөрәкләр кушылды дип әйтер идем. Бүгеннән башлап без бергә булырбыз, һәрвакыт бергә!

Аңа сөйләгә ирек бирмәделәр, күңелдә ятканнар барысыннан да көчле иде. Күп тавышлы «Ура!», тагын авылны урап чыгып, күккә менеп китте, кемдер атып җибәрде. Бераз тынычланган каргалар, ату тавышлары ишетелә башлагач, биек агачлардан кычкырып күтәрелделәр дә читкә очып киттеләр.

– Ну, нәрсә, Ильяс, булдырдыкмы?

– Барысы да әйбәт. Хәзер, иптәш Титов, киттек минем өйгә...

Шулай дип әйтте дә Ильяс, туктап калды. Өйдә бер кеше дә юк бит! Титов хәлне аңлап тора.

– Теге картны алып килергә күпме вакыт кирәк?

– Сәгать ярым – ике сәгать.

– Болай итәбез. Шушы вакытка ял, яралыларны урнаштырабыз, мәрхүмнәрне җыябыз. Әгәр гаилә турында берәр хәбәр килсә, син шунда ук чыгып китәсең. Шуннан, әйдә, командирларны җыеп сөйләшик. Ни эшлибез?

Берничә минуттан волостька командирлар җыела башлады. Кемдер ярасын бәйләп өлгергән, кемдер нидер чәйни, кемдер коралын сөртә – барысы да бик тиз килеп керделәр. Аларга Титовныкылар да кушылды. Ильяс торып басты.

– Барысы да бит?

Кемдер сузып, «Әйе-е!» диде.

Үзара сөйләшкән тавышлар тына башлады. Титов белән Ильяс волостьның әле берничә сәгать кенә элек Салих утырган бүлмәсендә тәрәзә каршысында утыралар. Калганнар, кем кайда урын тапкан, шунда урнашкан. Тәрәзәдән ара-тирә кергән кояш нуры тартылып киткән сакаллы йөзләрне яктырта, болытлар кояшны каплаганда, бүлмә бөтенләй караңгыланып кала. Титовка тиклем Ильяс сүз алды.

– Менә нәрсә, иптәшләр! Акларны бәреп чыгардык Казанлыдан. Тик бу тулысынча җиңү түгел икәнен сез аңлыйсыз. Казанлы кебек волость үзәген аклар кире кайтарырга тырышачаклар, көт тә тор. Безгә алда ни эшләрбез, шул турыда уйларга кирәк. Салих исән, күптән түгел Чернушкага чыгып качты. Димәк, ул бүген-иртәгә карательләр белән кайтыр. Әйдәгез, Титов иптәшне тыңлыйк. Аның кем икәнен сөйләп тормыйм, беләсез.

Титов торып басты, бар булган куәтле гәүдәсе белән тәрәзәне каплады.

– Син бит бөтен дөньяны капладың! – Кемдер шаярып алды. – Хәзер безгә урамнан пуля янамый, ничек кенә атсалар да, мишень бер!

Титов үзе дә көлүдән тыела алмады.

– Ярый да, син аның артында утырасың. Әнә Ильяс аның белән янәшә, аны беркем капламый!

Ильяс та сүзсез калмады:

– Шулай булгач, син дә кайгырма, сиңа тимәс!

Арттан үкчәгә басып, үлем йөргән чакта һәркем өчен тормышның башка уйлары күңелне күтәрә, бу күңелсез уйлардан читкә алып китә, кешенең кешеләргә генә хас булган табигый бер халәтенә алып кайта. Әле генә мылтык төзәве аша карап, дошманга җавап бирергә әзер торган кешеләр җанланып китәләр, дөнья икенче төрле икәненә ышаналар, бер-берсенә яңадан карап, бу тормышта адәмчә мөнәсәбәтләр дә бар бит дип уйлыйлар.

Көлү дулкынын уздыргач, Титов сүз башлады.

– Казан – Екатеринбург тимер юлы буйлап бик күп партизан отрядлары хакимлек итә. Без булган җирдә акларның аяк астында ут яна, бер минут та аларны тик тотмыйбыз. Мин үзем Бөре партизан бригадасыннан, бездә – ике полк. Берсе Таушта тора, командиры Воробьёв, мин командир булганы – Лысая Горада. Безнең зур командир Павел Иванович Деткин.

– Әйе, аралар ерак булмаса да, бары тик яңа гына очраштык. Без дә сезнең белән элемтәгә керергә тырышып карадык, сезнекеләр безне ике-өч көн элек килеп таптылар. Тик кайтканда, поскынга эләгеп, Шакир һәлак булган икән...

Бар да тын калдылар.

– Бүген барыбызга да бер сорау тынгы бирми. Салихның отрядын тар-мар итә алдык, Казанлыны азат иттек. Тик күпкәме? Безнең дошман көчле, ул регуляр армиянең бер өлеше. Шулай булгач, соңракмы, әллә бүген-иртәгәме алар монда яхшы коралланган зур команда җибәрәчәкләр. Ә безгә үзебезнең отрядны саклап калырга кирәк!

Титов кешеләргә күз йөгертеп чыкты.

– Сез беләсез, Җиһаншин – Чернушкадан Красноуфимскига тикле тимер юлын саклый торган батальон командиры. Ул, үзенең кешеләрен генә җыеп алса да, бездән көчлерәк команда оештыра ала. Ә ул моны эшләячәк!

Әйе, Кызыл армия дә алга бара. Безнең бригада алдында зур бурыч: тимер юл буйлап чигенүче акларны тоткарларга, мөмкин булса, аларга һөҗүм итәргә, бастырып килүче кызыллардан аларның игътибарын бүлдерергә. Моны без үтәп киләбез. Бу зур ярдәм, кулдан килгәнне генә түгел, килмәгәнен дә эшлибез. Павел Иванович исеменнән сезгә зур рәхмәт. Сездән куркып, Салих батальонының зур гына өлешен бу тирәдә тотты.

Партизаннар канәгатьлек белдереп шаулашып алдылар.

– Әлегә безнең яктан акларның берничә дивизиясе үтәчәк. Казан, Уфа алардан тазартылмаган, әле сугышның кызган мәле. Салих монда гаскәр белән кайтса, сезгә бик авыр туры киләчәк. Шулай булгач, иптәшләр, оешкан рәвештә безгә чигенергә кирәк, безнең зур бригада составына Казанлы полкы булып кереп китәргә.

Бар да тынып калдылар.

– Минем сүз бетте. Бу карар җиңел генә бирелмәс, аңлыйм. Тик ул бердәнбер дөрес карар!

Бераздан барысы да берьюлы сөйли башладылар. Китәргә кирәклеген бар да аңлый, ә монда калганнар белән ни булырын беркем дә әйтә алмый.

Беренче булып Хисаметдин сүз алды.

– Сиңа әйтү җиңелдер, бәлки. Синең монда гаиләң юк. Ә минем алты ачык авызлы бала. Хатын, олы яшьтәге әни. Аларны кем карар да, кем ашатыр, кем яклар? Алар белән нәрсә булыр? Салихныкылар явызлыкларын буаны шартлату белән дә исбат иттеләр бит!

Бар, дөреслек бар бу сүзләрдә.

– Беләбез аларның кыргыйлыгын. Балаларны штыкка кадарга да күп сорамаслар!

– Начарлыктан башка алардан ни көтәрсең! Игелексезләр!

– Ә син игелек көтәсеңме? Тот капчыгыңны!

Ильяс, тынгысызланып, командирларга карады. Карам, Нигъмәт, Тихон ни әйтер? Җыелганнарның күбесе каршы чыкты китүгә.

– Китәргә кирәкми! Кирәк булса, бригада безнең якта. Ярдәм итәрсез бит бүгенге кебек?

– Ну, һәрвакыт алар ярдәм итеп кенә тора алмаслар инде. Алар да ял итеп ятмыйлар бит!

Түзмәде Ильяс.

– Әгәр Салих, гаскәр алып килеп, безне кырып ташласа? Үч алачак бит ул бүгенге җиңелү өчен!

– Әйе, үч. Тик без монда булсак, без моңа каршы да чыгарбыз. Ә без моннан китсәк, ул безнең гаиләләрдән үч алачак!

– Без бер сәгать элек Танып буена барып килдек, сез беләсез. – Ильясның ачудан күзләренә яшьләр килде. – Тик анда элекке Көтмәс, элекке Танып, элекке буалар юк инде. Елга бозы өстендә тубыктан ләм, ярлар җимерелгән. Бар яланнарны су баскан, без яшәгән Томафи карт йортын су таратып ташлаган. Безгә яшәргә урын юк хәзер анда.

Инде барысы да, башларын кашып, тын калдылар. Шулвакыт Карам

белән бер партизан килеп керде, Ильясны чакырып, нидер әйттеләр. Ни булганы аңлашыла иде.

Титов, «Бар! Бар!» дип, Ильяска башын какты.

– Иптәшләр, беразга тәнәфес. Ә иртәгә китәр алдыннан, митинг үткәреп һәлак булганнарны озатырбыз.

Ильяс ашыгып чыгып китте.

**74**

Салих калган командасы белән атларны станциягә тикле җәлләми куды. Ярсыган атларны чак-чак тотып, патрульне туктатып, штабны белештеләр, ә инде анда полковник Зеньковскийның урынын билгеләделәр.

Зеньковский, йөгереп килеп кергән Салихка аптырап, башын күтәрде.

– Ба-а! Җиһаншин! Нигә мондый формада? Нәрсә булды?

Югары, әллә нинди ят тавыш белән кычкырып җибәрде Салих:

– Бетте барысы да! Тар-мар иттеләр безне! Тар-мар! Аңлыйсызмы, тар-мар иттеләр безне!

– Кемне? Тынычланыгыз! Утырыгыз! – Зеньковский үзенең тынычлыгын югалтмый иде.

Салих кечкенә бүлмә буйлап йөгерүен дәвам итте. Ниһаять, Зеньковский да түземлеген югалтты, өстәлгә сугып, тавышын күтәрде:

– О-отставить! Туктат истериканы! Ну-ка, адәмчә, аңлашырлык итеп сөйләп бир хәрбиләрчә!

– Тар-мар иттеләр! Башта якындагы партизаннар, аларга мондагы партизаннар килеп кушылды.

– Казанлыдамы? Нинди партизаннар?

– Казанлыда бер отряд. Аларга ярдәмгә станция ягыннан килеп җиттеләр. Ике йөздән артык кеше. Коралланган!

– Тынычрак, штабс! Мин бит сезне кисәттем, туган якта хезмәт итү икенче дип. Анда туганлык, башка мөнәсәбәтләр. Нигә дип менә монда урнашмадыгыз? Нәрсәгә ышандыгыз, ни көттегез? Кем миңа партизаннар белән мәсьәләне үзем чишәм дип ант итте? Һәм ничек итеп алар сезне тар-мар итеп ташлады?

– Мин дошман солдатлары белән сугышып өйрәнгән, кыргый мужиклар белән түгел!

– Изге булып күренергә тырышмагыз, капитан. Мин сезнең Мәскәүдәге Казандагы батырлыгыгыз турында да хәбәрдар! Аерылганда кем сөйләде пафос белән Туган ил турында, ә? Мин бит сезне... трибуналга!

– Трибуналга? Мине? Бу нәрсә, шаярумы?

– Молчать! Трибунал! Хөкем бер – атарга! Монысы да аз әле сезгә! Коралны өстәлгә, тиз генә!

Салих бик тиз суынды. Зеньковскийның мондый карарын көтмәгән иде ул. Нәрсә эшләргә? Шулай да коралны шапылдатып өстәлгә салды.

– Рәхим итегез! Карагыз, ничек үләргә әзер тугры офицер!

Әлегә кереп килүче солдатларга каршы атлады. Батырлык, офицерлар өчен әзерләнгән бүлмәгә килеп кергәч тә, юкка чыкты. Үкенечтән, үпкә-рәнҗүдән күз яшьләре атылып чыкты. Бик озак утырды ул куллары белән битен каплап. Тәмам тынычлангач, башына көчле бер план килде, ул планны үтәү юллары ачыкланды, кешеләре тәгаенләнде. Ишек төбендәге

юынгычка килеп, кулларын, битен юды, өстен каккалады. Шуннан ишек шакыды. Ишек ачкан солдатка Зеньковскийның аны кабул итәргә мөмкинлеге бармы-юкмы дип сорау бирде һәм, мөмкинлеге булса, әзер булуын әйтте.

Зеньковский өч сәгатьтән кабул итте. Тәҗрибәле, белемле офицер шулай итеп тагын дәрес бирде Салихка. Моны ул бик тиз һәм дөрес итеп аңлады.

– Иң беренчедән, полковник әфәнде, үземнең аңлата алмаслык ямьсез тәртибем өчен гафу үтенәм сезнең алда. – Салих актёрларча пауза ясады, шуннан моңа тикле кырык кат кабатлаган Зеньковскийга ошаячак фикерен әйтте: – Нишлисең, мондый тәҗрибә дә кирәктер кешегә. Бу бит минем беренче җиңелүем!

Чынлап та, ошады бу сүзләр полковникка. Бик ачылып китмәсә дә, ниндидер җылылык бар иде аның алдагы сөйләшүендә.

– Ярар! Бөтен бөек гаскәр башлыклары да моның аша үтә! – Аның тавышында тирән ирония, ул аны яшерергә дә теләми шикелле. – Шуннан нәрсә? Наполеон да сезнең кебек Мәскәүне калдырып качкан! Нинди планнар?

Салихның башына Мәскәүне башта Кутузов калдырган дигән уй килде, тик ул аны әйтмәде. Нинди көч, тырышлык белән кайтарылып ятучы ышанычны җимерергә бер сүз җиткәнен ул бик ачык аңлый иде.

– Таралган кешеләрне җыеп алырга. Алар мондый очракта кая барырга беләләр, мин алар белән бер мәртәбә генә түгел, бик күп өйрәнү үткәрдем. Менә ул авыл – Чүпрәле. Анда безнең яклы отряд бар.

– Күпме кеше инде анда солдатлардан?

– Казанлыда минем белән егерме биш кеше генә иде бит. Шуларның ким дигәндә унбише анда булырга тиеш.

Салих махсус рәвештә солдатларның санын аз итеп күрсәтте. Полковник берни әйтмичә дәвам итәргә кушты.

– Якынрак ике станциядән каравылларга зыян китермичә унар кеше алырга була. Шуннан Михайловка дигән авылда утыз-утыз биш кеше ярдәмче отрядта. Барлыгы илле тирәсе.

– Алар ышанычлымы?

– Ышанычлы. Үзләрен әйбәт күрсәттеләр алар. Шушындый тактика тәкъдим итәм: мондагы тәҗрибәдән чыгып, кечкенә очып йөрүче төркемнәр оештырабыз.

Полковник бүлдерде:

– Сезнең ул летучий төркемнәрнең эффектлы булуына командующий да игътибар итте! Это да!

– Бер-бер артлы баручы өч отряд булачак. Беренчесе бәрелешне башлап җибәрә, калганнары төрле яктан кушылып китә.

– Яхшы! Болар сезнең төп эшкә комачауларга тиеш түгел! Мөмкинлек чыккан саен миңа хәбәр!

Зеньковский өстәлдә яткан коралга ымлады. Салих аны бик тиз үтәде – корал бер-ике секундта үз урынын алды.

– Китәргә рөхсәтме?

– Рөхсәт!

Бу юлы кул биреп тормады. Кофе да юк, кәефе дә.

***

Тышта көткән солдатлар йөгертеп кенә атны китереп бирделәр.

Менә шулай, бер минутлык төшенкелеккә бирелеп, бөтен булганын югалтырга була. Арудан бу, арудан. Сугыш башланганнан бирле ял күргән юк, булыр сиңа истерика. Ә Казанлыны хәзер яшәргә өйрәтәбез. Ялгышлык – йомшак булуда. Гаебе бармы, юкмы, чыгарып атарга. Курыксын кеше, бары курыккан кеше генә тып-тын булып кирәген эшли. Михайловкалардан бернинди файда булмады, бер рәт чыкмады, бәрелешкә катнашмыйча, качып беттеләр. Теге малайканы, Савканы, тотып атаргамы әллә? Командир булып китте бөтенләй! Мобилизация үтәлмәде. Хәер, монысының аңлатырлык сәбәпләре бар инде. Барыбер аларны мобилизация дип куркытырга. Да, бик урынлы була да бу мобилизация: Савканы, тагын берничә баш бирмәгәннәрне җибәрергә шуңардан файдаланып! Булды! Сафа калды... Сафага күпме ярдәм булды, киңәшләреннән башка ни файда? Ә ул киңәшләре файдалы булып чыктымы ахырда? Карап карарбыз. Менә Ильясның гаиләсен юк итә алдымы? Алмаса, аңа да икенче караш. Шуннан Ильяста командир булып йөргәннәрнең гаиләсен җәһәннәмгә җибәрергә. Муллалар бер сүз әйтмичә өйләрендә яталар. Вәгазьләрен ташка үлчим. Ни файда алардан?

Ильясны табарга, тотарга, бөтен халык алдында асарга. Мондый оятны бер мәртәбә күргән булмады, менә ул оят! Кемнән бит әле ул!

Бер сүз белән әйткәндә, Зеньковский алдында да, командирлар алдында да ихтирамны кайтарып алырга башка бер юл да юк.

Казанлылар, сезгә кансызлык, шәфкатьсезлек кирәк идеме? Димәк, булыр, булыр барысы да! Елар көннәрегез алда әле, якташлар! Монысына инде Зеньковскийның ирониясен алды Салих.

Шул арада атлар Герасимның өе алдына килеп туктадылар. Өйдән аю кебек уйнаклап, хуҗа үзе дә килеп чыкты.

**75**

Ильяс йөгереп тышка чыкканда, аның өч-дүрт атлысы волость алдында биеп тора иде. Шунда ук теге карт – аңа ару гына эләккән бугай егетләрдән, бертуктаусыз канаган танавын тарта. Бер генә сорау бирде Ильяс:

– Нигә алдадың әле син безне? Монда бит вакытның һәр мизгеле кадерле. Әгәр бала туып, аның белән ул-бу булса, суга салам мин сине!

– Алдамадым, валлаһи! Икмәк тотып ант итәм! Аяк астымда җир убылсын менә! Сез мине ялгыш аңлагансыз!

Ильяс иптәшләренә карады. Нигъмәт картны ашыктырды:

– Сөйлә тизрәк!

– Сез Көтмәс буасыннан аска киткәнсез. Анда да урман өе бар. Тик анысы түгел. Су буйлап өскә менәргә кирәк иде бит!

– Ничә чакрым?

– Буадан биш тирәсе.

Ильяс сикереп атка менде. Иптәшләренә карап, сорау бирде:

– Нәрсә, бу юлы акыллырак булабызмы? – Картка карап сүзен дәвам итте. – Безнең белән барасың. Анда юл бармы соң?

Карт болардан көләргә тырышты. Шуны да аңламагач ни инде!

– Бар, әлбәттә! Соң, ничек кереп йөрмәк кирәк өйгә хәтле, юл булмаса?

– Атта бара аласыңдыр бит?

– Барам! Без бит ялга ябышып үскән малайлар.

Шунда ук чабып китеп тә бардылар. Азрак соңлап, алар артыннан тагын атлылар иярде.

Ильясның күңелсез уйлары иңбашларга гер булып бастылар. Буага ике чакрым булсын, ди, аннан урман эченнән биш тирәсе. Көн кичкә авыша, караңгылык та озак көттермәс. Сугышта чакта бер уй җылыта иде җанны: бетә бу сугыш, кайтабыз исән-сау, Алла бирсә, өйләнәбез, балалар үстерәбез шатланып. Юк, әллә ниләр булды заманага, әллә ниләр булды дөньяга. Без теләгәнчә, без уйлаганча барып чыкмады. Аллаһы Тәгалә яратканны сынармын дигән. Әгәр ул яратканы мин булсам, сынаулары да, бирсен Ходай, уңышлы тәмам булачактыр бит? Чыдыйбыз, түзәбез! Китермәс ул яратканына авырлык. Күңелле булып китте шушы уйлардан соң Ильяска. Иншалла, шулай булсын да, исән генә булсыннар бәләкәй кеше, Сәлимә, әнисе, Әминә апа! Ул бит аның малаймы, кызмы икәнен дә белми! Кем булса да риза, кочакларын җәеп, үзенә тартып алачак ул, кайда гына булмасыннар! Нинди оятсызлык, кешелек сыйфатларын югалту бит бу йөкле хатынга кул күтәрү, тумаган балага хәвеф-хәтәр китерү. Ильясның йөрәге тагын жу итеп китә, шушыларны искә төшереп. Мәрхәмәтсезлек!

Буаны тизлекне акрынайтмый гына узып киттеләр. Күптән түгел яуган карда ярылып, өр-яңа эзләр ята. Болары кайдан? Кичә төнлә алып киткәннәр, ә бүген нигә барганнар анда? Әллә... Ильяс атын ашыктыра, башкаларга да ашыгырга куша.

Алар җиргә сеңеп баручы өй утырган яланга килеп чыкканда, андагы ике кеше ашыгып, атларына сикерделәр дә урман эченә чаптылар. Ильяс тун чабуына абына-сөртенә йөгергән кешеләрнең берсен таныды һәм бар көчен, бар әрнүен җан ачуына салып кычкырып җибәрде:

– Сафа-а-а! Кан дошманым син бүгеннән! Ишетәсеңме, җирбит? Дошман син! Барыбер табармын, дөнья белән хушлаша тор, бәдбәхет! Үлем сиңа!

Тегеләр урманга карап чаптылар. Артларыннан атып та карады, тик куе агачлар, ерак ара, аларга тидерерлек түгел. Иң начары – өй өстендә сызылып кына төтен агымы күтәрелә башлаган иде.

Ильяс урман өенә килеп җиткәндә, ул чытырдап яна, аның бер башындагы ялкын инде якындагы чыршыларны ялмап югарыга үрмәли башлаган, эчтән буылып ютәлләгән, ыңгырашкан тавышлар ишетелә иде. Ишектәге зур йозакны ачарлык бер нәрсә дә юк, каерып ачарга тырышкан агачлар шартлап сына бара. Вакыт үтә, икенче юл кирәк, эчтә инде тавышлар да тына башлады. Ильяс өйнең почмагына ышыкланып, револьверын йозакка төзәп атып җибәрде. Соңгы патрон, барып чыкмаса, эшләр хәтәр... Йозакның икегә сынып агачларга таба очканын шәйләп калды ул.

Бар көче белән тартып, Ильяс ишекне урыныннан суырып чыгарды. Калганы, акрынайтылган хәрәкәтләр тезмәсе булып, аның исендә калды: ишек ачылганда, өйнең түшәме дөрләп яна иде; беренче булып ишек кырында яткан Сәлимә аңа чүпрәккә төрелгән баланы сузды; Ильясның кулына тотынып, тышка атлады; төтеннән дулаган ютәлен туктата алмый, ул, баланы алып, өй эченә ымлады; Ильяс шинелен Сәлимәнең иңбашына салып эчкә ташланды; Сәлимә, баланы күкрәгенә кысып, янган өйдән читкәрәк атлады; ишектән бер-ике адымда хәлдән тайган ике кеше чүгәләп утырганнар иде; ул аларны көчләп урыныннан торгызды; бер мизгелдән өйдән бер-берсенә тотынып Ильяс, Нәгыймә, Әминә чыктылар.

Шул вакытта өйнең кыегы, түшәме күккә очкыннар туздырып җимерелеп тә төште. Ут янында эссе, урман ягыннан үзәкләргә үтә торган салкын өрә, биш кеше бер-берсенә сыенып, кочаклашып, берничә минут тын ала алмый тордылар. Ильяс, тиз генә гимнастёркасын салып, бәбине төрде, хатын-кызларга карап эндәште:

– Аллага шөкер, өлгердем! Барыбыз да исән-саубыз! Кая, Сәлимә, карыйм әле балама!

– Улыма! Улыма дип әйт!

Шул вакытта гына хатын-кызлар барысы да берьюлы кычкырып елап җибәрделәр. Кичерелгән хәлнең киеренкелеге шул тиклем зур булуы аларны башта тынычлыкның бер тигезлегендә тотты, ә инде аннан кинәт котылу елгадай күз яшьләренә ирек бирде. Ильяс акрын гына баланың битен ачты. Бәби тирә-якны карап чыкты да әтисенең йөзендә тукталды:

– Мин бу, мин бу, әтиең, улым! Син берүк ачуланма, өйдә туасы урынга менә шулай булды, менә ничек туры килде бит, ачуланма, яме?

Йөгереп, Әхтәм белән Нигъмәт килеп җиттелер. Мондагы хәлләрне күреп, дулкынланудан Нигъмәт җиргә утырды, калтыранган куллары белән өстендәге киемен чишеп, хатын-кызларга сузды, аның артыннан Әхтәм дә шуны ук эшләде. Нигъмәт Әхтәмгә борылып эндәште:

– Бар, йөгер безнекеләргә. Кирәкмәгәнгә атуны туктатсыннар – монда бәби йоклый! Зур кеше йоклый! – Аның тавышы мизгелнең мәгънәсен, әһәмиятен күтәреп җибәрде. – Һәм тизрәк җылы киемнәр җыйсыннар.

Ике әйткәнне көтмәде Әхтәм, юкка да чыкты. Нигъмәт, әле янып яткан торымбашларны җыеп, урман ягыннан озын ярым ай кебек итеп учак корды, шунда ук салкында өши башлаганнарга җылы кереп китте.

Ильяс улы белән сөйләшүен дәвам итте:


– Мин сине дә, әниеңне дә башкача бер адымга да үземнән калдырмам, яме! Дөнья үзгәрде, хәзер яңача яши башлыйбыз, Алла бирсә!

Әллә ни ерак та булмаган урман артында кызыл атлыларның җыры яңгырады. Кай арада сүзләрен өйрәнеп өлгергәннәр бит, ә?

Гармунчының осталыгына караганда, бу, һичшиксез, сукыр Ногман кебек уйнаучы Әхтәм булырга тиеш. Әхтәм, бу көннәр-атналарда булган хәлләрне үзенеке итеп, эченнән-бавырыннан, йөрәгеннән үткәрде. Ильяс, партизаннар, аклар, Сәлимә, Нәгыймә, Әминә апалар, шушындый шартлардан курыкмыйча бүген генә дөньяга килгән батыр егет – барысы да бер төенгә төенләнде, алар арасында Әхтәмнең дә урыны бар. Бу урында ул берүзе түгел, аның белән бергә Сәрия дә бара. Ә Сәриянең дә шул уйларда булуына ул тулысынча ышана.

Ә җыр шул тикле матур, тигез булып яңгырады ки, әгәр аны дошманнар ишетсә, җиңеләчәкләрен берсүзсез аңларлар иде!

Чылтыр-чылтыр ник чылтырый
Ат өстендә ыңгырчак та
Ат өстендә ыңгырчак.
Без җырламый кем җырласын?
Безнең самый җырлар чак та
Безнең самый җырлар чак!



Рәшит
Бәшәр

# ҖӘЙНЕҢ СОҢГЫ АЛКЫШЫ...

## Җәлил һәйкәле

*Тик булса иде ирек...*
М.Җәлил

Казанына карап тора Җәлил,
Тараталмый җилләр томанны.
Көтә шагыйрь Казан томаннарын
Ләйсән яңгырлары юганны.
Карурманнар кичеп килеп җиттем
Бүгенгемә бала чагымнан.
Ишетелә, керә колагыма:
«Тамырыңа балта чабылган».
Синең дәвам – синең оныклар да
Яһүдтер дә, Җәлил, урыстыр.
Асты өскә килде дөньяларның,
Заманалар артык кырыстыр.
Кулларыңны һәм тәнеңне кисә
Чәнечкеле тимерчыбыклар.
Чәнечкеле тимерчыбыкларга
Килеп куна әрсез чыпчыклар.
Ак диварда вакыт саный сәгать,
Шуып-шуып үтә күләгә.
Кулларыңны чишеп, шагыйрь, сине
Бастырасым килә үләнгә.
Җәяр идем авылың туфракларын
Кызыл гөлләр үскән түтәлгә.
Уяныр быз бер көн таң белән үк,
Баштан сыйпар Аллаһ безләрне.
Күксел томаннарны эретәчәк,
Ачтырачак кояш күзләрне.

---

Рәшит БӘШӘР (1949) – *шагыйрь һәм прозаик; А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Сандугачлы бишек», «Ачык капка», «Былбыл оясы» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Ерак төбәлгәнсең, ни күрәсең,
Биек таумы алда, киң даламы?
Сай елгамы? Әллә Иделме?..
Күрәсеңдер, шагыйрь, ышанам мин,
Күрәсеңдер нурлы илеңне!

## Татар фаҗигасе

Бик күпләрне иблис саташтырды,
Оныттырды нәсел, ыруны.
Муса Дядюшкин булса бабасы,
Иван Ильич бүген туруны.

Инде тәмам телсез калганның да
Гаярь татарлыгы канда бар.
Килер бер көн: сүз каргышы төшәр,
Тел каргышы сугар, бәндәләр.

## Сары моң

Чуар төскә төрә көз,
Елга өсте – пәрәвез.
Сайрап уянмый таллар –
Былбылсыз ата таңнар.
Рәхәт оета җанны
Шарлаган су тавышы.

Япа-ялгыз карт имән
Ботагында – ау кошы.
Тын күкләр сарылланган –
Сары яфрак балкышы.
Исеп куя җылы җил –
Җәйнең соңгы алкышы.

## Яфрак өзелә

Көзләр быел иртә килде бик,
Берөзлексез яфрак коела.
Гомер көннәрем дә ашыгып
Коеладыр кебек тоела.
Тын һаваны сулап ятадыр
Кое төбендәге тын сулар.
Гөмбәзеннән йолдыз өзелсә,
Авыр итеп янә төн сулар.
Бөтерелеп төшкән яфраккай
Кое бурасына куна да:

«Таңга кадәр ял итимче бер,
Җилләр йоклый!» – диеп куана.
Белми лә ул карт агачына
Очып менеп кабат кунмасын,
Үлән арасында саргаеп,
Әкрен-әкрен туфрак буласын.
Өзелешеп төшәр яфраклар,
Авыр итеп янә төн сулар.
Яфрак кыштырдавын ишетә
Кое төбендәге тын сулар.

## Их...

Соң туылган.
«Болгар», «Амур»ларда
Тукайны да күреп булмады.
Чатларында Печән базарының
«Барабыз»лар көтеп туңмадым.
Шәрык клубында «Кисекбаш»ны
Мин тыңламый калыр идемме?
...Янды еллар. Заман актарылды,
Кисекбашлар басты илемне.
Күккә ашты «Болгар», тузан булып,
Дерелдәми ялкын чырагта.
Көпшәкләнә илнең нигезе, их,
Нәрсә икән инде чиратта?
Кабызыгыз шәмдәл! Өши бәгырь.

Төннәр – корым, көннәр сорырак.
Күрмәс өчен шушы көннәрне, дим,
Туасы ла булган соң(ы)рак,
Туасы ла булган соң(ы)рак...

## Халәт

Аһ, нинди илдер бу, аһ, нинди җирдер бу?
Тап-такыр кырдыр бу, өзелгән җырдыр бу.

Нәрсәдер көтелгән һәм өмет ителгән.
Гомерем юллары йомгактай сүтелгән.

Хыяллар кителгән, буыннар биртелгән.
Бәхетләр иленнән читләтеп үтелгән.

Исәпсез борчулар чаларган башымда.
...Йөгереп чыгам мин яңа көн каршына.

Халкымның әрнүен, шатлыгын, күз яшен
Сыйдыра йөрәгем. Димәк ки, мин яшим,

Бар әле кирәгем.
Былбыллар тибрәтә гомерем тирәген.

## Читлек

Утыра ул, баш иеп, үз иткән дә тозагын.
Читлекнең ничә гасыр ача алмый йозагын.

Күрми күкнең биеген, оныткан ирек тәмен.
Корсак кайгысы гына белгән уен, гамен.

Бөтен тәне лычма су, әйтерсең лә парникта.
Бөркү зоопаркта утырудан гарык ла.

Ачылыр ишекләре, чыгар гөл арасына.
Кояш нурлары кунар күзләре карасына.

Шулай булыр, ышанам.
Тышта көннәр барыбер аязырга охшаган.

## Үзгәрде ил

Әллә кайчан күптән бер булган идем сездә бер.
Гайрәтле иде халык, чирле иде йөзгә бер.

Тау күле – йөзек кашы, таулар бик биек иде.
Тау битендә, үзәндә чуп-чуар киек иде.

Әллә кайчан күптән бер сезнең илгә килдем бер.
Болытларга ышкылып, тау күленә мендем бер.

Учак яктым, ялкыны йолдызларга тигәндер.
Тау күленә үзәннән аккош очып менгәндер.

...Тагын килдем шул илгә: күк биек, кеше боек,
Өй иске, түбә кыек.

Тау ишелгән – чүл инде, учак сүнгән – көл инде.
Шиңәр-шиңмәс гөл инде, яктыралмый көн инде.

Иле нык чирле инде, аккошлар үле инде.
Мин үзем дә үзгәрдем, элекке түгел инде.

## Заман

**1**

Кемдер әләк сөйләп, кемнәрдер жалу язган замандыр бу,
Адәмнәрнең бер кадәре акылыннан язган замандыр бу.
Бер җылытып, бер суытып бик тә туңдырган замандыр бу,
Куштан түрә халык малын читкә шудырган замандыр бу.
Һәрбер хәсис, түргә менеп, нидер боерган замандыр бу,
Бәндәләрне бер-бер артлы упкынга орган замандыр бу.
Буш вәгъдәләр, алдашулар тәмам туйдырган замандыр бу,
Ил өстендә кара болыт яман куерган замандыр бу.

**2**

Кабих заман адәмнәргә йодрыклап суга тора:
Тел агачы корый тора, туйралар сула тора.

Иблис күсәге – кара кан, тарала, бетә илләр.
Илләрне дә, телләрне дә күмә дә китә силләр.

Мин йокысыз, чал башымда күпме уем, ваем бар.
...Чит туфракта ут тергезә илсез калган кавемнәр.

## Кирәк!

Ойый гәүдә, кан куера тәндә...
Йокламасын дисәң хәлсез йөрәк,
Аяк-кулны азат итү кирәк,
Зынҗырларны кисеп ату кирәк.
Көйле типсен дисәң хәлсез йөрәк,
Башны азат итү кирәк элек,
Элмәкләрне өзеп ташлау кирәк,
Ирек кирәк җанга, ирек кирәк.
Ябалдашын җәеп, ак җиһанда
Шыбырдасын дисәң җилдә тирәк,
Тамырлар нык, имин булсын өчен
Тирәккә дә якты киңлек кирәк!



Ландыш
Әбүдәрова

# ОЛАБЫЙ

ХИКӘЯ

Җил ниндидер бер ашыгычлык белән салкын тәрәзәгә килеп бәрелде. Аңа ияреп килгән эремчек кебек шадра кар бөртекләре шыбыр-шыбыр тәрәзә төбенә коелды да җил, аларны җыеп, янә очыртып алып китте. Агач өй бүрәнәләрен сынагандай шыгырдап куйды. Нык иде әле бүрәнәләре.

Шуңа да өй эчендә дә җылы. Мичтә биешкән ялкын телләре дә, чытыр-чытыр килеп янган коры утын да, мич алдына төшкән яктылык та тәнгә генә түгел, җанга бер рәхәтлек биреп тора.

– Сёмага дигән кыстыбыйларны ныграк майла, аңа тагын берне өстәсәң дә ярый. – Муса агай, хатынына шулай дия-дия, шкафтан муенлы свитерын алып киде. Үзе йомшак, үзе җылы шушы свитерны шактый еллар элек хатыны Җиһан бәйләгән иде. Яшьрәк чагында ук. Бәйләргә өйрәнәсе килә дип, әллә каян гына юнәтеп, өч төсле җеп алып кайтты да бәйләм инәләренә күз җыярга өйрәнүгә шушы свитерга тотынды. Гади булса да, үзенчә матур килеп чыкты. Һәрхәлдә хәләле сүз белән үтереп мактамаса да, бер кадерле әйбере итеп саклап тота. Көзгә кергәч алып кия, яз җиткәч, янә хатынына салып бирә. Җиһан апа аны, хуш исле сабынны җебетеп, йомшак җылымса суда юып киптерә дә киләсе елга кадәр дип төреп алып куя. Елдан ел шулай: свитер искерми дә, тузмый да, җылысын да югалтмый.

– Сёмага дигәнен дә, сиңа дигәнен дә майлыйм. Үзең турында уйла син, төне буе керфек тә какмый, каравылда сиңа торасы. Сёма ул, ичмасам, син алып килгән кыстыбыйларны ялт иттерер дә кикерә-кикерә, корсагын кашып яткач, гырлый-гырлый йокы симертер. – Җиһан апа иренең гадәтен белсә дә, уендагысын әйтми калмый. Хәер, Муса агай өч көнгә бер каравылга киткән саен шул сүзләрне кабатлый, әмма ире кушканны

Ландыш ӘБҮДӘРОВА (1980) *– язучы; «Мандариннар», «Октябрь һәм бәләкәй тылсымчы» дигән китаплар авторы. Казанда яши.*

җиген җиккә китереп эшләп куя. Эшләми кая барсын, Мусасы барыбер үз дигәнен итә инде аның.

– Ноябрьгә кергәндә, безнеке кебек шартларда яшәүче кешеләрнең каны, кыш киләсен сизеп, салкынга әзерләнә башлый. Кан йөреше әкренәя, йокы баса, күбрәк майлы ризык ашыйсы килә. Бу безнең бик борынгы заманнарда яшәгән бабаларыбыздан ук килә торган гадәтләр. Без генә түгел, бөтен җан иясе кышка әзерләнә. Кайсыдыр кышка ризык җыя, оя кора, кайсыдыр мамык үстерә, тун алыштыра...

Муса агай сукбай Сёмага карата аеруча хәерхаһлы. Берәүдән дә, хәтта станция начальнигыннан да сүз әйттерми. Тегесенең станция тирәсендә еш йөрүен өнәми яңа начальник, шуңа да Муса агай аны алай итеп тә, болай итеп тә хәйләли, тәки йолып кала. Тел-теш тидертми, җил-яңгырдан саклый. Җил-яңгырдан дигәндә, туры мәгънәсендә саклый: үзенең сменасы туры килгән төннәрдә каравылчы бүлмәсендә кундырып чыгара, шунда ашата-эчертә. Әле шул рәвешле кайгыртуын ничектер башкалардан, хәтта Сёмадан да яшерергә теләгәндәй, үзеннән-үзе шулай килеп чыккандай итеп күрсәткән була. Менә бу юлы да «Сёмага күбрәк, майлырак ашарга кирәк» диясе урында карчыгының ике ятып, бер төшенә дә кермәгән фәлсәфәләр сөйләп ташлады.

– Аңа кыш ни дә, җәй ни. – Җиһан апа барыбер үзенекен кыстыра. Һәм шул сүзе белән йомшак тастымалга төреп, эшкә йөри торган биштәргә салган кайнар кыстыбыйларны иренә тоттыра.

– Ишекне үзем бикләп чыгармын, иртән эштән кайтуга сине уятып торасы булмас, – ди Муса агай, җавап итеп. – Кышка таба таң йокысы аеруча тәмле була ул...

***

Гадәттәгечә, сөйләшә-сөйләшә, дөресрәге, сукбайның соңгы ике-өч көн эчендә күргәннәрен тыңлый-тыңлый, әле суынырга өлгермәгән кыстыбыйларны ашап куйгач, станциянең һәркем тарафыннан диярлек сөекле мәчесе Мырауны да сыйлап, аның мыекларын пөхтәләп юганын сүзсез генә кинәнеп карап утыргач, һәм шушы ике мәхлук үзләренең дөньядагы иң бәхетле җан иканлекләренә инанып, тар сәкегә ятып, мес-мес килеп, йокыга талгач, Муса агай, төнге поездны каршы алып озатып калырга дип, перронга чыкты.

Кыш булып уйнарга яратучан ноябрь эремчек карын кая куярга белмәгәндәй, анда-монда сибереп йөртүеннән туктаган, төнен тагын да суытырга итеп, томан төшереп килә. Кайчандыр өяз шәһәре булганда, XIX гасырда ук салынган тимер юл станциясенең перроны да әллә ни үзгәрешләр кичермәгән иде. Патша заманыннан калган иске фонарьларының да сары уты томаннан качарга теләгәндәй тыгызланып, йомарлам гына булып калган. Алай да дөм караңгы түгел, шәүләләрне азмы-күпме аерырлык кына булып ай яктысы, тәрәзәләрдән электр уты төшеп тора. Әнә, рельслар телгә килеп, поездның якынлашуын хәбәр итте. Күп тә үтмәде, тәгәрмәчләрен газиз бер ритмга салып көйләтә-көйләтә, поезд күренде һәм, рельсларны сызгырта-сызгырта, үзе белән ниндидер бер тантаналы ыгы-зыгы алып килде. Ничек тиз башланса,

станциядәге ыгы-зыгы шулай ук итеп кинәт тынып калды. Ике-өч минут эчендә биредә каласы пассажирларын төшереп, яңаларын алды да тепловоз, томан эченә җылы төтенен өреп, вагоннарын сөйрәп китеп тә барды. Озакламый поезд тәмам күздән югалды, төтене таралып, тирә-як элеккечә бәләкәй шәһәрләрдә генә була торган салмак гүләү тавышына күмелде. Муса агай бусын да озаттым, бар да тәртиптә дип, тыныч күңел белән керү ягына таба борылганда, кырый күзе белән генә күреп алды да инде аны.

Дөресрәге, иң элек перрондагы соңгы фонарьның саран яктысында аның озын шәүләсе күзгә чалынды. Шәүлә селкенми иде, Муса агай да шып туктап калды һәм чекерәебрәк караса, аның кеше икәнен чамалап алды. Поездда төшүенә каршы алырга килүчесе соңга калган, ахрысы, дип уйлады тимер юл станциясе аша үтеп йөрүче пассажирларның холкын тәмам өйрәнеп бетергән Муса агай. Күрәсең, беренче килүе, кая барырга белми аптырап калгандыр дип, гадәтенчә, теге кеше янына ашыкты. Каршында озын какча буйлы, әллә картлыгыннан, әллә куркуыннан, әллә өшүеннән муенын алгарак сузып, иңнәрен җыерып, бөкерәеп басып торган, бәләкәй генә төенчеген ике куллап күкрәгенә кыскан, ничек кенә җылы итеп киенсәң дә, үзәкләргә үтә торган юеш салкын көнне юп-юка пәлтәдән, бары бер кат яулыктан, җыерчык баскан ак йөзенә караганда, 80 белән 90 яшь чамасындагы бер карчыкны күреп имәнеп китте. «Ходай бәндәсе, нишләп йөрүең инде?» – дип куйды ул үз-үзенә, эшнең нидә икәнен чамалап, чөнки кемнеңдер кеме – берәүнең кадерлесе шушы яшьтә төн уртасында мондый кыяфәттә юлга чыкмавын бер караштан аңларлык кына тормыш тәҗрибәсе Муса агайда тулып ашкан иде.

Ә Ходай бәндәсенең каян килүе, кая юл тотуы, хәтта исемен дә төгәл генә белмәве ачыклангач, Муса агайга карар кабул итәр өчен тирән итеп бер сулыш алырлык вакыт кирәк булды: иң элек әбине җылыга алып керергә, кайнар чәй эчерергә, иртәнгә кадәр ял иттерергә кирәк иде. Аннан соң күз күрер...

***

– Менә сиңа авырткан башка тимер таяк! Башка проблемаң юкмы әллә? Тот та полициягә тапшыр, алар аны кая куярга икәнлекне бик тиз хәл итә. Ә болай үзеңә мәшәкать кенә, – дип акыл сатты Муса агайга Сёма, әбинең, күзләрен тутырып, аңа карап торуыннан да тарсынмыйча. Аның болай да вакытлы-вакытсыз йокысыннан уянырга, әле җитмәсә төн уртасында нәрсәдер хәл итеп утырырга мәҗбүр булуы, алай гына да түгел, үзенә дә сирәк эләгә торган җылы урынын кем беләндер бүлешергә туры килүе өчен ачуы чыккан иде, шуңа да бу әллә хәтерен югалткан, әллә бөтенләй зиһенен җуйган карчыктан тизрәк котыласы килә иде.

– Аларны чакырырга беркайчан да соң түгел... Рәшәткәле машинада кунак итәргә алып китмиләр. Хәер, үзең дә беләсең анда ничек каршы алганнарын, – диде Муса агай Сёманың канәгатьсезлегенә каршы. – Ә хәзер тор, әйдә, әбине утырт. Күрмисеңмени, көзге яфрак кебек калтырап тора...

Сёма теләмичә генә бәләкәй сәкенең аяк очына торып утырды. Тагын

да ныграк жәлләтер өченме, янындагы мәчене алып, куенына салды. Аның балаларча кылануы, күрәсең, әбигә дә тәэсир итте. Ул да, җәһәт кенә Сёма янына килеп, аны тынычландырырга ашыкты:

– Улым, менә безнең якка кайтучы берәрсе табылса, бергә кайтырбыз, яме? Җае чыгуга кайтырбыз, озакламабыз, – дигән булды.

Сёма әбигә кырын күз белән генә карап алды да мәчесен тагын да ныграк кочагына кысты һәм:

– Кая кайтасын беләме соң ул? Каян килгән? Чакыр дим бит тиешле кешеләрне, әби белән берәр хәл булса, башыңнан сыйпамаслар. Ә болай үзеңә проблемалар гына әзерлисең – дип, Муса агайны тагын үгетләргә тотынды.

Муса агай әбигә чәй әзерли иде, ул сукбай киңәшен ишетмәгәндәй, бер сүз дә җавап кайтармады, май ягып, өстенә сыр телеме дә кисеп куелган бутербродларын биштәреннән алып, тәлинкәгә тезде.

Аның каравы әби, үзенең кем икәнен белмәсә дә, колакка сизгер, сүзгә оста, җор телле булып чыкты.

– Алар килсә, иң элек мине түгел, сине алып китә. Үз гомеремдә энә дә урлаган кеше түгелмен, шулай булгач, монда син – карак! Үз гаебеңне миңа аударырга утырма, – дип, Сёманың авызын япты.

– Минме карак? – дип, нахакка рәнҗетелгән кеше кебек яклау эзләп, Муса агайга күзләрен мөлдерәтте Сёма һәм акланган кебек күңелен бушата башлады:

– Тоталар да бөтен караклыкны миннән күрәләр, маңгаема карак дип язып куйганнармыни? Әллә минем энә урлаганым бармы? Менә, Муса агай, син мине кайчаннан бирле беләсең? Караклыкта тотылганым бармы? Урлаша белсәм, монда утырмас идем әле. Үз вакытында урлашырга намусым кушмады, шул вакытта өйрәнгән булсам, бүген монда балавыз сыгарга калыр идемме? – дип, тавышын бөтенләй җебетеп агызды сукбай. Муса агай исә Сёманың гадәтен белгәнгә, аңа «ә» дә димәде, «җә» дә димәде, сүзен әйтеп бетерергә мөмкинлек кенә бирде. Бүлмәдә хисләр куеруын сизгән әби исә Сёманы жәлләп елап җибәрде.

– Менә, безнең авылга кайтучылар булса, шуларга ияреп кайтырбыз. Син дә безгә кайтырсың, кунак булырсың, анда бөтен кешегә дә урын җитәрлек, – дип, үзенчә юаткан булды.

Төн әнә шулайрак үтте.

***

Икенче көнне үк Муса агай, әбине машинасына утыртып, аның туганнарын, йә булмаса торган җирен эзләп китте. Иртә белән Җиһанын уятмас өчен өй ачкычын үзе белән алса да, чакырылмаган кунак белән кайткач, дәшми булдыра алмады. Киңәш-табыш кирәк. Җиһан киңәше белән башлаган эшнең ахыры һәрвакытта да хәерле була – Муса агай моны әллә кайчан белә инде.

Иң элек әби утырган поезд килгән якка станцияләр буйлап йөреп чыгарга кирәк дип хәл иттеләр. Хәтер дигәне бөтенләй булмаса да, энә түгел, кеше кадәр кеше бит ул! Бәлки әле кемнеңдер кадерлеседер дә.

Һичшиксез, шулай. Аны югалтучылар бардыр бу дөньяда. Һичшиксез, бардыр. Аларны эзләп табып, кулларына исән-сау килеш тапшырырга кирәк әбине... Һичшиксез, кирәк...

Беренче килгән җирләрендә үк машина туктауга, әби сикереп тә төште, кая барасын төгәл белгән кеше кебек төенчеген култык астына кыстырып, артыннан сәйлән кебек вак-вак эзләр генә калдырып, туп-туры китеп тә барды. Муса агай бер мәлгә генә дөрес килгәнбез, әбинең акыл хәтере бөтенләй булмаса да, аяк хәтере бар икән әле дип сөенеп куйды. Әмма әби: «Әниләргә кайтабыз, көтә торгандыр инде, бу бала нишләп кайтмый йөри дип ачулана торгандыр, безнең өй күперне чыккач та уң якта, өянкеләр астында», – дип сөйләнә башлауга, ялгышуын тиз аңлады. Икенче, өченче, дүртенче һәм тагын бик күп авылларда йөргәндә дә, нәкъ шулай итеп, күпер янындагы өянкеләр астында утырган өйне эзләде ул.

Ә Муса агай ару-талуны белмичә йөртте дә йөртте аны. Җиһан апа әбине сабыр гына кабул итте, тәрбияләп карады, иренә ничек тә ярдәм итәргә тырышты. Шәһәр газеталарын алып, югалган кешене эзләүчеләр юкмы дип караштырды, телевизордан эзләүчеләр игълан бирмәгәнме дип көтте. Ләкин якын-тирә авылларда әбине танучылар табылмады.

Кайвакытта ераккарак киткәндә, бик соңга калып кайтырга яисә куна калырга туры килгәндә, Муса агай Сёманың ай-ваена карамыйча үгетләп, аны үзе урынына төнге каравылда торырга күндерә иде. «Син нәрсә? Акылыңнан яздыңмы әллә? Сәлимыч белсә... Мин ул тәртип саклаучы дип атала торган кавем белән алыш-бирешне өздем, алардан ераграк йөрергә тырышам, ә син, күрәләтә торып, мине шулар авызына илтеп тыкмакчы. Менә ни өчен кулгаияләштергәнсең икән син мине», – дип, бик карышса да, Муса агай күп сүзле дустының җаен тапты. «Сәлимычтан курыкма, андый-мондый белә калса, үзем сөйләшермен», – диде. Тегесе: «Мин төнге салкында чыгып йөрергә тиешме?» – дип, тагын да бәясен күтәрә башлагач, Җиһан апа бәйләгән теге свитерны да салып бирергә туры килде. Сёма бик кызыга иде инде шуңа, кыш чыгарга әйбәт свитер, миндә мондый булса, салкыннарга эһ тә итмәс идем дип торып-торып мактап куя торган иде.

Иртән станция начальнигы эшкә килгәндә, гадәттә, Муса агай территорияне әйләнеп керергә чыккан була. Менә шул вакытта алар ерактан торып исәнләшә. Сёмага төнне исән-имин үткәреп, Муса агайга охшатып, ягъни чын-чынлап хәл-әхвәл белешеп исәнләшергә генә кирәк. Менә монысы аеруча катлаулы: аның Сәлимычта һичкайчан эше булмады, алар, гомумән, үзе әйтмешли, Евклид геометриясендәге ике параллель. Кырынып, юынып, чәчен алдырып килсә, килеш-килбәте ягыннан Муса агай белән бер-берсенә охшап торалар анысы. Аның каравылга гына кия торган кышкы курткасының изүен ачып, свитерның муенын да күтәребрәк куйса... Шулай иттеләр дә. Сәлимыч бер исәнләште – сизмәде бугай, ә икенчесендә шикләнепме, әллә Муса агайга берәр йомышы төшеп, сөйләшеп торыр өченме, туп-туры каравылчы янына килә башлады. Бөтен караклыкны, Сёма уйлаганча, дөньядагы бөтен явызлыкның башын шушы сукбайдан күргән станция начальнигының үзенә таба үтәли тишәрдәй

булып карый-карый якынлашуын күргәч, ул йөз еллык теге фонарьларга карап «Нигә фонарь булып тумадым икән?» дип уйларга гына өлгерде. Эшнең нидә икәнен белгәч, ни гаҗәп – Сёма өчен бу гомерлек сер булып калачак – Азат Сәлим улы полиция чакыртмады, каршында үзен түгел, ә бик күп кагыйдәләрне, эш тәртибен, хәтта ки Хезмәт кодексын бозган Муса агайны намусын яклаган кебек очына-очына яклаган сукбайга бик озак итеп, сүзсез генә карап торды да шулай ук дәшмичә генә борылып китеп барды. Ә бераздан сукбайның бөтен дөньясын астын-өскә китергән бер гаҗәп хәл булды. Ул инде сменасын тапшырып, Җиһан апага төннең тыныч узуы, станция начальнигының аны күреп тә, бер сүз әйтмичә китеп баруы турында түкми-чәчми хисап тотарга дип барырга җыенганда, аның янына идән юучы Мәликә түти килеп керде. Кулында бер стакан кайнар чәй белән ике телем бутерброд. «Сәлимыч бирде. Сиңа!» – диде ул, әйберләрен кечкенә өстәлгә тезеп куйгач. Һәм «Ничек булгандыр бу хәл! Үзем дә берни аңламыйм!» дигәнне белдереп, гаҗәпләнүеннән кулларын җәеп җибәрде...

***

Озакламый Сёма җылы курткасын тагын да ныграк бөркәнеп, муенын җылы свитерга ныграк батырып, Муса агайларга китеп бара иде. Ноябрьнең кышка авышканлыгын белдереп, уйнаклый-уйнаклый төшеп торган карлар аның битенә, чәчләренә куна, әмма ул аларга игътибар итми, җил белән сөзешкәндәй, башын ия төшеп, йөгерә генә. Үзе күңеленнән генә Муса агайга Сәлимычның нинди әйбәт кеше икәнлеген сөйли. Ә Муса агайларда исә хәбәрнең тагын да олырагы көтә. Нинди хәбәр булсын инде – әбинең улы белән килене табылган иде.



*Соңгы елларда Балтач төбәге әдәби мәйданга яңа буын иҗатчыларын китерүдә, мөгаен, иң алдынгысыдыр. Берничә ел эчендә «Казан утлары»ның «Яңа исемнәр» рубрикасында шигырьләре дөнья күргән Гүзәлә, Миләүшә Гафурова, Алмаз Әхмәтгалиев, Зөһрә Рамазанова, Гөлзилә Фәхретдинова, Гөлинә Шәйхи, яше олырак булса да, проза өлкәсендә активлык күрсәтүче Рәҗәп Бәдретдинов кебек авторларның исемен атарга мөмкин. Эльвира Һади, Резеда Гобәева кебек иҗатчыларыбыз да – Балтач кызлары.*

*Шөкер, бу төбәк яшь, өметле каләм ияләре тәрбияләүне әле дә дәвам итә. Сәхифәбезнең бүгенге авторы – Көшкәтбаш авылы тумасы, 2004 елда дөньяга килгән Гөлназ Мәлик кызы Әхмәдиева моңа тагын бер мисал. Алай гына да түгел, Гөлназ – яшь буын иҗатчыларыбызның иң активы һәм күпкырлысы. Ул жанрларның тезмәсе белән дә, чәчмәсе белән дә бердәй эш итә, шул ук вакытта журналистика өлкәсендә дә актив эшли. Казан федераль университетының татар журналистикасы юнәлеше буенча белем ала, ул – «Татарстан – Яңа гасыр» телеканалы хәбәрчесе дә, «Ватаным Татарстан» газетасы һәм «Ялкын» журналы авторы да. 2021, 2022 елларда «Глаголица», «Иделем акчарлагы» кебек әдәби бәйгеләрдә һәм яшь журналистларның «Алтын каләм» фестивалендә Гран-прилар яулауга ирешә, Шәриф Камал һәм Шәүкәт Галиев исемендәге әдәби премияләр белән бүләкләнә. Шигырьләре исә Татарстан китап нәшриятының «Күңелгә илһам кирә» исемле күмәк альманахында басылып чыккан, районның «Хезмәт» газетасы һәм «Ялкын», «Идел» журналлары битләрендә урын ала.*

Гөлназ
Әхмәдиева

# МИН ОЧЫШКА ӘЗЕРЛӘНӘМ...

***

Мин әле күп нәрсә белмимдер.
«Чын» димдер ялганны,
Айларны «ел» димдер.
Мин кемдер – үзем дә белмимен.
Ак күрсәм, «кара» дим,
Караны «ак» димен.

Мин шулай дөньяны күзәтәм.
Туйганчы исним һәм
Тоямын аннан тәм.
Кем ничек – мин шулай күнеккән.
Тормышта һәр нәрсә
Ничек тә береккән.

Белмимен әле мин күбесен.
Шулай да өйрәнәм
Үземә тиешен.
Дөньяны күзәтеп туймам күк:
Чык тулы болыннан
Елмая чиксез күк.

Мин үзем барысын белмәмен.
Җир шары әйләнсен –
Мин аңа бәйләнмәм.
Хисләрем – кемгәдер гади хис,
Шуңа да һәр кеше
Шагыйрә түгел ич.

***

Бер секундка ике тапкыр сулыйм.
Туймыйм яшәп синең белән.
Каләм язмас булып ярат әле –
Иҗат итми шашыйм тәмам.

Тамам яңгыр булып һәр сулышта
Ике тапкыр. Былтыр
Такыр юллы шигырьләрдән
Тапкан идең бугай асыл.

Хәзер бу шигырьдә миннән ары
Берни юк та бугай, бугай бар да.
Мин хисләрдән өстенрәк, әмма
Хисләр барда
Мин – сүз генә.

Үзәгемә үзгә җилләр узсалар да,
Мин тибрәләм танышында.
Канда минем кансызлыгым,
Тоссызлыгым – бары таңда.

Монда мондый юллар булса,
Укырсызмы
Шигыремне тагын-тагын?
Ә мин сулыйм секундына ике тапкыр.
Һәм барыбер сулап туймыйм.

***

Җир яшәрә бара бездән...
Кешеләрдән... җылы сүздән...
Бу тоташ төн, зәңгәр төтен,
Читен хисләр үтә күздән.

Менә тиздән... яз булыр күк:
Яшәргән җир, зәп-зәңгәр күк...
Мин очышка әзерләнәм,
Син канатым турайт берүк!

Чирләп терел янар өчен,
Балкыр өчен башка сүнми.
Ышан бары: тулы җиһан
Күзе белән сине көнли.

Ышан җирнең яшәвенә
Безнең өчен, безне зурлап.
Ә бит, чынлап... кемдер кемгә
Очар өчен бирә канат.

Сынап безне сындыра ул,
Уйнап үчен алыштыра.
Бу сынауда кемдер өчен
Чын йөзеңне алыштырма!

Ачыш шунда: Җир туклана
Сөю белән, җылы белән.
Үзгәрешне башла элек
Яшәвеңне сөюеңнән.

***

Әйдә, яз!
Миңа яз кирәк дип алданма,
Булганда кулыңда каләмең.
Күзләрен мин гел дә беркатлы:
Очына чыгалмыйм хисләрнең.

Яз хәлең!
Ничек син – яхшымы, начармы,
Моңсумы, әллә гел күңелле?
Хисеңне хис кенә дияргә
Телләрең әйләнми түгелме?

Җиңелме
Яшәве бүгендә? Дәшәме
Киләчәк, тартамы үткәнгә?

Чигенмә дип чигәм кырыйга:
Мин бит ул – диңгез дә, җилкән дә...

Күзен дә
Күзгемнән күз алмыйм.
(Югыйсә шашарлык яз түгел!)
Үтенәм, кәтмә яз җитүен,
Хисләрең бүгеннән үк җимер.

Әйдә, яз!
Нигә мин күз генә, яз түгел,
Әз генә булса да шашарга?
Ашыга йөрәгем яшәргә,
Ә хыял – тормышка ашарга.

***

Күптөрлесең.
Сөрттермисең яшьләремне
(елак булып яшим һаман).
Минем дәвам –
дәвамыдыр шигыремнең,
әмма шигырь инде тәмам
дип уйлама!..
Башы гына иҗатымның
һәм азагын күрмим әле.
Яле, еламыйча гына укы!
Шигыремдә – дөнья яме,
Тәме иренеңнең,
яктылыгы кара төннең,
исең синең...
Барлыгымны хәтерләтеп торыр
чишелгән сул җиңең.
Һәр җиңүдән
минем белән җиңелүне
төшерерсең исләреңә.
Хисләремә төкерерсең,
ә аннары...
хисләнерсең үзең генә.
Шигырь аша сагынырмын,
танышырмын өр-яңадан.
Һәм ахырдан...
Онытырмын мәңгелеккә,
чөнки шигырь инде тәмам.



Энҗе
Галиәхмәтова

# МӘРХӘМӘТЛЕ БУЛ, БАЛАМ

хикәя

– Сөенче, сөенче...

Айгөлнең шатланып кычкырган тавышын ишеткән Асия апа кухняда савытлар юган җиреннән юеш кулын күлмәк чабуына сөртә-сөртә, ишегалдына йөгереп чыкты.

– Сөенче, сөенче. Сөенчегә ни бирәсең?

– Хәбәрең изге булса, менә бу алтын алкаларым синеке.

– Чынмы, әнкәй?

– Әйе, балам.

– Айназ абый белән Гөлчәчәк җиңгинең кызлары туды. Минем нәни сеңелкәшем бар хәзер!

Кулларын чәбәкләп, Айгөл биеп-биеп сикереп әйләнде. Асия апаның күзләреннән яшьләре бәреп чыкты. Ни дияргә дә белмәде. Ишегалдындагы болдырга утырды да елап җибәрде.

– Кем әйтте? Каян белдең, кызым?

– Айназ абый шалтыратып хәбәр итте. Сездән сөенче алырга кушты.

Шатлык яшенә күмелгән Асия апаның күңеленнән яшен тизлеге белән бар да үтеп китте: кыз кулын сорарга бару, никах мәҗлесе, дус-туганнар белән бергә зурлап туйлар уздыру. Шатлыкка төренгән яшь пар. Шул шатлык белән бергә табибларның «Сезнең балагыз булмый» дигән җанөшеткеч сүзләре. Күпме күз яше, күпме борчу. Катлы-катлы тикшеренүләр, дәваланулар. Болар бар да куркыныч төш сыман артта калды. Көтеп алган сабыйлары, кызлары бар! Айназ белән Гөлчәчәкнең генә түгел, Шакир белән Асиянең дә түземсезлек белән көтеп алган оныклары.

Ә Айгөл бии дә бии. Аңа шундый рәхәт. Абыйлары сеңелкәш алып кайту белән бергә алтын алкалы да булды. Чөнки сөенчегә бирелгән бүләк бик кадерле була. Дус кызлары янында горурланып тагып йөриячәк. Әнисенең янып торган ул алтын алкаларына бик кызыгып карый иде. Үскәч

шундый алкалар алырга хыялланды. Ә әнисе оныкка шундый шат, хәтта аңа алкалары да кызганыч түгел. Гадәт буенча сөенчегә иң кадерле бүләк бирелә. Менә Айгөлгә дә шундый бүләк насыйп булды.

– Кызым, кил әле бирегә. Әйткән сүз – аткан ук диләр. Алкаларым – сиңа бәби бүләгем. Сөенчегә.

Айгөлнең гади алкаларын салдырып, үзенең алтын алкаларын такты. Шуны гына көткән сыман кызчык урамга чыгып юк та булды. Дусларына бүләген күрсәтеп мактанасы килде аның. Асия апа да өйгә керде. Каян, нигә тотынырга белми, бүлмә уртасында басып торды. Аннан чәй куеп җибәрде, бәйрәм булгач бәйрәм булсын дип, коймак туглады. Шакир төшке ашка кайтырга тиеш. Тәмләп чәйләрләр, сөенечле хәбәрне дә җиткерер.

...Санаулы көннәр бик тиз узып китә. Менә бәбине чыгарыр көн дә җитеп килә. Иртәгә нәни йомгакны өйгә алып кайталар. Айназның түбәсе күккә тигән. Чормадан бишекне дә алып төште.

– Әнкәй, түр якка менә шул бишекне элик әле. Минем кызым да үзем үскән бишектә үссен.

Асия апа моңа бик шат иде. Менә бит, үзебезнең гореф-гадәтләргә таянып үсә балалары. Онытмыйлар иске гадәтләрне.

Бишеккә ал чәчкәләр төшкән матур чаршау тегеп кидерделәр. Яңа каз мамыгыннан нәни мендәр, йон юрган нәнине көтеп тора хәзер. Бәби кайтмыйча бишекне элмәделәр. Бары тик әзерләп кенә куйдылыр. Гадәттә шулай эшлиләр. Бәби булмаганда, бишекне элмиләр, ул буш көенә тирбәлергә тиеш түгел.

Ул көн килеп җитте. Түр якка бишек эленде. Ал бизәкле чаршау-чыбылдыкны ябып куйдылар. Электән калган гадәт буенча шулай эшләнә. Бишек буш чакта чаршауны ябып куярга, җен-пәриләр баласын салып тирбәтмәсен, бала куркып уянмасын өчен эшләнә. Шунда ук мул табын корыла. Табын түрендә иң татлы булган кортлы-май – «Бәби мае» куела. Мулла да чакырыла, бәбигә исем кушыла.

Шаулап-гөрләп, бизәкле шарлар, чәчкә күтәреп, иң алдан капкадан Айгөл йөгереп керде. Аның артыннан куанычлары җиде кат күккә күтәрелгән, нарасыйларын күтәргән яшь әти белән әни килеп керделәр. Ишегалдында шатлыкларын кая куярга белми әби белән бабай көтеп тора иде.

– Төкле аягың белән, кызым, төкле аягың белән! Исән-имин кайтып җиттегезме, балалар? Юлда авыр булмадымы?

Шакир абый белән Асия апа яшьләрнең бер алдына, биш артына төштеләр. Түр якка узган яшьләр, бәбине «бисмилла» әйтеп бишеккә салдылар. Шуны гына көткән Айгөл очып килеп тә җитте.

– Матур апа, карыймчы, күримче нәни сеңелкәшне?

– Чү, кызым. Иң алдан тәпиен күр әле, тотып кара үзен, – дип, әнисе беләүсәдән нәни тәпиләрне чыгарды.

– Ник инде, әнкәй, алдан тәпиен? Минем үзен күрәсем килә.

– Кызым, иң алдан тәпиен карыйлар. Бу нәнине әти-әнисеннән, башка туганнардан көнләмәс өчен эшләнә. Шундый гадәт инде ул.

Өй эченә азан тавышы яңгырады. Мулла абзый азан әйтте. Камәт догасы укып, нәни кызчыкка Айзирә дигән исем куштылар. Исем кушып, мул

табындагы сый-хөрмәттән авыз итеп, бәби чәе эчкәч, яшь әни Айзирәне имезде. Бишеккә салгач, алар янына ут бөрчәсе Айгөл килде.

– Матур апа, бирче, үзем тирбәтәм.

Тиктормас Айгөлгә бар да кызык иде. Аның барысын да беләсе килде. Шуңа да сорау арты сорауны Гөлчәчәккә яудырып кына торды.

– Ә нигә бу чаршау корыла?

Әнисе дә читтә калмый. Кызының сорауларына җавап бирергә кирәк бит.

– Бу, кызым, бәбине чит-ят күзләрдән саклар өчен, күз тимәсен өчен куела. Шулай ук чаршау эчендә һәрвакыт бертөрле генә җылылык. Нәни өшемәсен өчен ул. Бишектән бәбине алуга ябып куярга кирәк. Шулай ук буш бишекне тирбәтергә дә ярамый. Җен-зәхмәт утырып тирбәлмәсен, балага чир салмасын өчен. Элек-электән калган гадәт шундый.

– Бишек читенә элгән бау нигә кирәк?

– Монысы, кызым, әни кешегә ял итәр өчен куела. Төнлә бәби уянып көйсезләнә башласа, торып йөрми генә, яткан җирдән баудан тартып бишекне тирбәтеп җибәрергә. Әйдә, кызым, Айзирәне бишек җырын көйләп йоклатыйк. Әйдә, Гөлчәчәк кызым, син дә кушыл.

– Әнкәй, мин бит бишек җырын белмим. Син миңа аларны өйрәтерсең инде. Айзирә-иркәмне тирбәткәндә җырлар өчен.

– Ярый, кызым, өйрәтәм мин сиңа. Әйдә әле, тыңла да кушыл, бергә җырлыйбыз.

Әлли-бәлли итәргә
Ал бишеге бар аның.
Елама, балам, дияргә
Үз әнкәсе бар аның...

Өй эченә моңлы бишек көе таралды. Анда гына сыеша алмаган көй, якты нур булып, ачык тәрәзәдән урамга чыкты.

Тәүбә-тәүфыйклы, миһербан-шәфкатьле, әти-әниеңә, кешеләргә мәрхәмәтле, иманлы, динебезне, гореф-гадәтләребезне саклаучы булып үс, бала.



*Баһаветдин Әнвәр улы Аджиев (1950) – Дагстанның халык шагыйре, драматург, тәрҗемәче. Кумык телендә иҗат итә.*

Баһаветдин
Аджиев

# ШАГЫЙРЬДӘН СОҢ ИЛДӘ ҖЫРЫ ҖЫРЛАНА

## Таргу тауга менгәндә

Таргу тауның итәгендә мазар.
Ерак заманнардан калганнар –
Каберләрнең тынычлыгын саклап,
Сафка баскан сыннар-балбаллар.

Бормалары гарәп язуының
Саклый нинди тарих серләрен?
Кичкәндер ул ташлар, уылмыйча,
Дәверләрнең хәтәр җилләрен.

Таш улаклар буйлап ярсып ага
Таргу тауның ташкын елгасы.
Теш сындыра торган салкын суын
Кувшин алып ташый тау кызы.

Тирәсендә кумык авыллары –
Казанышы, Эндрей, Кёстеге.
Таргу тауда шушы авылларның
Егетләре бәхет эстәгән.

Таш түбәсен күккә терәп, Таргу
Серен чишә Хазәр-диңгезгә.
Нинди серләр шулай саклыйсың син?
Яшермичә сөйлә син безгә.

Сөйлә безгә кумык авылларын
Яулар өчен килгән ханнарның
Башларына
                    биек Таргу тауның
Түбәсеннән ташлар яуганын.

Стенька Разин атлы башкисәрнең
Яу чапканын сөйлә син безгә.
Ничек итеп аның олакканын
Каеклары белән диңгезгә.

Искә төшә бик еш Шавхал Чопан,
Аның улы батыр Солтанмут.
Таргуның һәр Шавхалы – генерал!
Махти бәге аның – аткан ут!

Таргу – Хәзәр каһанлыгы ядкаре,
Бер бизәге кумык җиренең.
Китаплардан тулыр иде киштә,
Әгәр язсак бөтен сереңне.

* * *

Иҗатчы бүләк иткән
Изге китап ул – гомер.
Кемдер акылга таман
Йә зирәк була кемдер.

Шөһрәт сөйсә, иманы
Бар дип булмый һәркемнең.
Халкы бәхетсез икән,
Бармы бәх(е)те хакимнең?!

Аһ, бу гарип дөньяда,
Шәфкать көтеп догадан,
Курыкмыйча Алладан,
Үзен Алладай күреп,
Әмма Кыямәт көнен
Исенә дә алмаган
Бу кешегә ни дисең?!

## Мин төш күрдем

Мин төш күрдем, мин бер агач, имеш,
Чүл комында тамыр җибәргән.
Ак болытлар керде минем төшкә,
Күрдем якты балачагым язын...
Уянсам – кар ява чигәмдә.

Мин төш күрдем – имеш, мин бер инеш.
Хыялымда – чуму тирәнгә.
Йолдызларга очкын чәч(е)рәтеп,
Акканымны күрдем ташкын булып...
Уянсам – кар ята чигәмдә.

Мин төш күрдем – мин бер диңгез, имеш,
Дулкын ярып йөзә җилкәннәр.
Балачагым кораблары йөзә,
Акчарлаклар суда тирбәлә.
Уянсам – кар ява җилкәмә.

Мин төш күрдем – мин бәхетле идем.
Каян килгән бу чал чигәмдә?
Агач, елга, диңгез, тормыш – бар да –
Ак җилкән дә, томан, болытлар да...
Ак кар ята бөтен тирәмдә.

## Дүртьюллыклар

***

Ташчыдан соң җирдә торып йорт кала,
Шагыйрьдән соң илдә җыры җырлана.
Үлсәң, кем соң дәвам итәр юлыңны,
Беркем белми – улыңмы, оныгыңмы?

***

Кавын өлгергән – авызда эри,
Ә бакчаларда өлгергән йөзем.
Торна чылбыры күктә җилферди.
Бу кайчак дисәң – әлбәттә, көзен.

***

Кешеләр җирдә бөтен нәрсәгә
Икмәк баш диләр борын-борыннан.
Тамагы артык тук бәндә генә
Оныта кайчак Алла турында.

***

Телеңне тот йозакта,
Югыйсә эшең харап.
Язмышыңны бозарсың,
Әйткән сүзеңә карап.

***

Рәхәт җирдә яшәве.
Үз үлемен кем теләр?!
Ләкин никтер җәннәтне
Теге дөньяда диләр.

***

Карунның карны туймас,
Туйса да, туймас күзе.
Әмма капкага сыймас
Әйталган олы сүзе.

***

Ишеттем мин өлкәннәрдән, заманында,
Сөйләделәр дөм-сукыр бер зат турында.
Өйләнгән, ди, дөньяда иң чибәр кызга,
Көн яктысын күрми яшәп бер тапкыр да.

***

Гүзәллекнең очкыны
Тимәсә дә күзенә,
Сукыр да сайлый алган
Чибәр хатын үзенә.

***

«Кунак көне – өч» дигәннәр элек.
Бу тапкыр сүзне әйткәннәр белеп.
Югыйсә чөйгә элгән бүркеңне
Челәннәр китәр күккә алып менеп.

***

Гомереӊ зая үтмәсен дисәң,
Онытма шуны, дустым, беркайчан:
Атланмай күрми яшәрсең, әгәр
Каймак турында гына уйласаң.

***

Һәр сугышның үз чоры,
Үз иле һәркемнең дә.
Тик онытма син шуны –
Ватан була бер генә!

***

Төрле хәлләр булып тора тормышта.
Җәфа күрми яшәмәгән беркем дә.
Иң зур җәфа китерүе мөмкин сиңа
Иң якын дус диеп йөргән кешең дә.

***

Әгәр хөрмәттә яшисең килсә,
Кайгы-хәсрәт күрмичә җирдә,
Сиңа һәрвакыт бәхет теләгән
Атаң-анаңны онытма бер дә.

***

Куркакны белеп була
Карап ике күзеннән.
Синнән куркуын күрсәң,
Син дә курык үзеннән.

# БӘХЕТНЕҢ ДӘ, БӘХЕТСЕЗЛЕКНЕҢ ДӘ СӘБӘПЧЕСЕ…

Вакытында әйтелгән, вакытында ишетелгән кирәкле сүздән дә кадерле нәрсә юктыр кеше өчен. Ул сине тынычландыра, барган яки ниятләгән юлыңның дөреслеген билгели, уйдаш-фикердәшләреңне күрсәтә... Apple компаниясенә нигез салган Стив Джобсның, Тынычлык өчен Нобель премиясе лауреаты Тереза Ананың кешеләргә нәсыйхәт итеп язган сүзләрен укыганым бар. Алар кеше гомере, кешелеклелек, бәхет, яшәүнең мәгънәсе турында. Ләбиб абый Леронның «Кыршау» бәянын да мин шундый фәлсәфи уйланулар дип кабул иттем. Тик алар миңа тагын да якынрак, чөнки бу – минем татарымның дөньясы, мохите, хаталары һәм казанышлары... Монда Мөслимә әбиләр бар – алар безнең Акъәбиләр холкын, табигатен, зирәклеген сеңдергән (алар «улым-балакаем», «тач үзебезнең», «җәшәргә кирәк» дип сөйләшә), монда сукыр рәссам Мөнәвир бар – караңгылыкта да яктылык эзли ул, монда Әкълимә – чит-ят «гуантамера»ларның бәхетле итә алмавын аңлап, үз моңына кайта алган ханым... Һәм монда – әллә параллель, әллә тулаем фон булып торган безнең халкыбыз тарихы. Төп геройлар да – шул зур урманның берничә агачы – нәкъ менә тулаем безне, безнең халык язмышын тасвирлый.

Әсәрдә һәр нәрсәдә сакраль мәгънә бар кебек. Биредә исемнәр дә һавадан алган очраклы исемнәр түгел. Мөнәвир – «яктылык алып килүче», Мөслимә – «ислам динендә, Аллаһка табынучы», Әкълимә – «йомшак, сабыр, мәрхәмәтле». Һәм менә шул геройлар аша татарның төрле сыйфатларын күрсәтә автор – тулаем «без»не сурәтли. Әлбәттә, биредә башка персонажлар да бар, алар да «без»нең чагылышлар (надан укытучылар, чит-ят җирләрдә яшәргә мәҗбүр Вәсилә, мөһаҗир агай һ.б.).

Бәян Мөнәвир Максатовның күргәзмәгә куелган «Хәвеф алдыннан» исемле картинасын карау белән башланып китә. Дөресрәге, Бакый Урманченың «Килер бер көн, /Алда, киләчәктә, /Кичелер бу котсыз, кадерсез төн... Күк капусы ачылып киткән иде, / Теләкләрем әйтеп өлгермәдем...» дигән эпиграф итеп алынган сүзләре белән башлана ул һәм алда бәян ителәчәк хәлләрнең бүгенге вазгыять белән дә, үткәнебез белән дә һәм, әлбәттә, киләчәгебез белән дә бәйле икәнлегенә ишарә ясый. Шул бер картина турында сөйләгәндә генә дә никадәр мәгълүмат! Ачы чынбарлык һәм өмет: айсыз калган, ләкин манаралы мәчет («Алар айны замана зәхмәтеннән саклый алмасалар да, мәчетне дә, манарасын да саклап кала алганнар. Мәчеткә тиздән ай куеласына да өмет бар»). Картинадагы детальләрнең һәрберсе – татар тормышының берәр ягы. Малай башына газетадан ясалган башлык кигән, «стан» язуы күренеп тора («СССР заманында кайбер татарча журналлар һәм газеталар миллион данәдә бастырылып таратыла иде»). Хәтта Татарстанның «стан»га гына калуы да күп нәрсә турында сөйли.

Әсәрдә Мөнәвиргә (димәк, безгә) Мөслимә әби әйткән сүзләр бар: *«Бәхетеңнең дә, бәхетсезлегеңнең дә сәбәпчесе кыршау булыр»*. Кыршау белән бәйле гыйбрәтле тарихны «хахул кияү» белән бәйләп сөйләттерү дә юкка түгел икәнен аңлаган кеше аңлардыр... Тарихның хикмәтен болай төшендерә әби: *«Мичкәне туган ил, ватан дип аңларга кирәктер. Имән такталар – әти-әниләр һәм аларның балалары. Кыршаулар – илне бердәм, тату иткән дус-туганлык. Такталар кыршауда вакытта мичкә барые. Кыршаусыз калгач, бернәмә дә калмады. Дуслык, хөрмәт булганда – барча халык бердәм. Дуслык, хөрмәт бетсә, ил кадәрле ил дә таркала...»* Ә әби зирәк! Һәм әби бик күпләребез кебек ышанучан наив та: *«Сугыш булмас, Аллаһы бирса, безнең патшалар да, гиниралнай сиркиритарлар да гомер-гомергә сугышка каршы булды»*. Нишлисең бит, үзе алдамаган, гадел, намус хезмәт белән яшәгән кеше өстәгеләргә ышана инде ул...

Әсәрдә Бакый Урманче образы да калку. Сукыр Мөнәвир (димәк, ул бөтен нәрсәне аңлап бетерми әле – *«Мин көчсез, зәгыйфь бәндә, үземне бу томанлы дөньяда сукыр*

*бөҗәк... бет итеп хис итәм. Кайчан мине таптап изәрләр, кайчан мине сытып ташларлар икән дип уйлыйм...»)* олпат, гомер кичкән, зыялы-затлы, гыйлемле остазның сүзенә мохтаҗ. Бәянда юкка гына Урманче сүзләре һәм шигырьләре еш телгә алынмый – аларда хикмәтле сүз *(«Күңелеңдә дә, гавәм күгендә дә Бөек Төшенкелек, Зәгыйфь Чарасызлык хөкем сөрә»)*, аларда караңгылыктан чыгу юлы *(«...Бәхетне күңел күзе булганнар гына күрә ала. Бәхет ул – үз кыршавың-гәүдәң эчендә – йөрәгең!..)*.

Мөнәвирнең сукыраюының башы исерек шофёрның бәрдереп китүе белән бәйле. Машина номерын хәтерли малай: бер...биш...биш...ике. Монда инде артык шәрех тә кирәкми. Үзе дә мантымый ул адәм: күпмедер еллардан соң Рублёвка бистәсендә атып үтерәләр ул депутатны. Башка халыкларны санга сукмаучылар да мантымый...

Бәянның эпилогын кабат-кабат, уйлана-уйлана уку лязем. *«Теләкнең канатларын хәйран җәеп, /Өметләр күгенә күтәрелдем...»* – Бакый аганың эпиграфка алынган сүзләре авторның да, безнең дә теләк-өметләргә ачкыч вазифасын үти. Ә авторның тормыш фәлсәфәсе өметләндереп кенә калмый, бәхетле булып яшәүнең юлларын да ача: *«Тудыңмы – яшә, мескен булма, горур бул, абынсаң – егылмаска, егылсаң – еламаска тырыш, һәрчак матурлыкка, биеклеккә омтыл, наданга кушылма, акыллыга тартыл, явызлыкны түгел, яхшылыкны дус ит, буйсынып яшәүгә караганда, ирекле булуга ни җитә, һичкайчан күңелеңдәге өметеңне сүндермә, шул чагында гына теләгәнеңә, максатыңа ирешерсең».*

Бәяндагы Мөнәвир моны аңлады. Ул бөтенләй үк сукыр да түгел, лезвие калынлыгы булса да күрә, өстәвенә күзенә яңа операция дә көтелә; әбисе әйткән хәзинәнең хикмәтенә дә төшенде. Яңа кыршау ясау уе тикмәгә генә килмәде аңа. Һәркемнең үз кыршавы да булырга тиеш бит! Чит кыршауда ирексезләү, үз кыршавыңда бердәмлек, ныклык рухы бар.

**Лилия ФӘТТАХОВА.**

## ЛӘБИБ ЛЕРОННЫҢ ЧӘЧМӘДӘ ЯҢАЧА АЧЫЛУЫ

Шулай дип баш куюым аклана, минемчә: балалар шагыйре булып йә юмор-сатира әсәрләре белән киң танылган әдип, ягъни Ләбиб чәчмәдә (проза жанрында!) яңа сүз әйтә дип уйлыйм мин. «Кыршау» исеменә өстәп, «Мин дөньяны шулай күрәм» дию дә аклана: һәр әсәр әнә шулай яңача күрү, яңача сурәтләү, алымнар белән тәэсир итә дә бит инде. Ә бу әсәрдә жанрлар синтезы да, тормыш – реаль буяулар белән бергә хыял, хәтта виртуаль дөнья да чагыла. Күрәзәлек итү сәләтен, тормыш тәҗрибәсен – туган җир, нигездән, чын фәлсәфи акыллы әбиләрдән алу, димәк ки, үзе сизмичә дә «алтын» кыршау белән бәйләнгән сәләтле бала язмышы. Һәм аның чын иҗат кешесе булуы да кадерле! Сукыраю, шул көе иң газиз тема – элекке авыл, әбисе, хәтта песине дә онытмыйча, гаҗәеп милли картиналар язган рәссам язмышы! Һәм аның аңлаучысы, юлдашына әвереләчәк Әкълимә белән бәйләнеше! Кечкенәдән үк якынаеп, аннан ара өзелгән, аерылган ике йөрәк бергә кавыша. Әйе, татар кызының бәхете дә әллә кайдагы Куба, гарәп илләре, бүген инде Африка илләрендә түгел, үз туган ягы белән бәйле мохиттә, традицияләрдә! Моны хәтта бал кортлары да аңлый: хуҗасын соңгы юлга озатканда, алар күч булып җыелып, аллегорик сурәт буларак, әсәргә яңа мәгънәләр өсти. Бу җәһәттән Ландыш Әбүдәрованың «Умарта» бәяны да искә төшә: Актаныш яклары әллә шундый газиз уй-фикерләр коллизияләре тудырамы?

Миңа әсәрдә авторның олуг сынчыбыз Бакый Урманче шигырен эпиграф итүе дә, аның төшкә кергән колоритлы сурәте һәм шигъри юллары да, әңгәмәдә афоризмга тиң сүзләре дә кадерле. Бу җәһәттән авторның үз күңел биографиясе, иҗади тәҗрибәләре, балачактан ук үз юлын эзләгән үзсүзле шәхес буларак ачылуы да кызыклы. Теле, юморлы ситуацияләре әсәрне укылышлы итә. Җыеп әйткәндә, мин бу әсәрдән соң Коэльолар түгел, ә үз әдипләребезнең дә барлыгына инанам. Ялгышмыйм дип беләм.

**Рәдиф ГАТАШ.**

# СЕБЕР – ҮЗЕБЕЗНЕКЕ?!

*Өркетмәгез Себер белән, –*
*Себер – үзебезнеке!*
Татар халык җыры

Гадел фикер йөртеп, туры сүзлелеге яки гамәле белән хакимият даирәләре канына тоз салган ихлас шәхесләрнең гомере, гадәттә – моны без бигрәк тә патша Россиясендә ачык күрәбез Себергә сөрелү белән тәмамланган. Шәүкәт Гаделша (Сибгатуллин), миңа калса, алдан ук хәстәрле бунтарь заман шагыйрьләре сафына басып, бу эшен дә ятлар кулына калдырырга кирәк тапмаган – тумышы белән үк Себернеке булырга хәл кылган. Үзенә алган тәхәллүсе дә шул хакта сөйли. Иҗатының кайсы аспекты, кайсы төп проблемасына килеп кагылсаң да, биредә стихияле Себер табигатен, кырыс Себер холкын, аның эчкерсез туры фикер йөртү рәвешен, шуларның натураль эстетик чагылышын ачык тоеп торасың. Бу кабатланмас үзенчәлекләрнең автор яшәү рәвешенә, димәк, бөтен әсәрләре тукымасына тумыштан сеңдерелгән булуы күңелдә һич шик уятмый. Укучыларга тәкъдим иткән бер-берсеннән аерылгысыз төп дүрт өлеш-бүлекчәдә дә: шагыйрьнең Себерне мәңгелеккә үз итүен күрсәткән шигырьләрендә, бу төбәкнең тылсымлы табигать дөньясын җанландыруда, Себер холыклы каһарманнарының индивидуаль характерын, шәхес буларак өлгерүен ачуда, Ватан ирегеи, милләт язмышын үзәккә куеп язылган темаларында әлеге принципиаль сыйфат-критерий – игътибар үзәгендә.

Ш.Гаделша – бүгенге чор шагыйре. Аның яңалыгы кыю фән ачышлары, ис-акылыңны җуярлык «айти» техник казанышлары, галәм-җиһанның әлегәчә күрелмәгән киңлекләренә чыгып, башка планета вәкилләре белән перспектив контакт-әңгәмә коруында түгел. Билгеле бер мәгънәдә аны хәтта иске-традицион заман шагыйре дип тә атарга мөмкин булыр иде. Әмма бөтен хикмәт шунда: әдипнең табигый яшәеше, тереклеге – моннан утыз-кырык ел элеккеге – зур өметләр вәгъдә иткән ымсындыргыч-мавыктыргыч, шау-шулы фән-техникага килү юлында түгел, ә бәлки, киресенчә, кешелекнең бу шалтыравык тарихи казанышлар нәтиҗәсеннән күңеле сүрелеп, зур югалтулар белән – гармоник үткәннәргә кире кайтуында. Нишлисең, алга барыр өчен кайчакта – тарихның күзенә-башына берни чалынмаслык дивана сыман кызган вакытында – кемгәдер чигенә белү каһарманлыгына ия булу таланты да бик кирәк.

*Китеп барам туры басып,*
*Табигатьнең тыныч чагы.*
*Марта[1] гына юл башында*
*Авырттырып кулны чакты.*

*Астан, өстән укмашалар*
*Авыртулар йөрәгемдә;*
*И туган як, китүемнең*
*Юктыр бәлки кирәге дә.*

Биредә мавыктыргыч сюжет та, бүгенге көн тәнкыйтьчеләре таләп иткән аяктан егарлык оригиналь метафоралар да күренми. Хәтта лирик герой үзенең әле китү-китмәү теләген дә кистереп әйтерлек халәттә түгел.  Шул булдымы заман шагыйре – эче-тышы билгесезлек, икеләнү, җебеклек. Өстәвенә, бу халәт, шигырьдән-шигырьгә күчеп, төрле нюансларда үсеп бара. Икенче шигырьдә үк тасвир болай дәвам итә: *Сузып-сузып җырладым да, / Тындым көнне тыңларга; / Юк шикелле мохтаҗ булган / Минем җырны тыңларга.*

Чынлап баксаң, тирә-юньдә тормыш үз эзеннән ага бирә, яңа рифмаларга ихтыяҗ

[1] Умарта корты.

һич күренми. Лирик герой котылгысыз кырыс нәтиҗәгә килә: «*Монда шундый кызык заман, / минем моңнар нәрсәгә?»*

Гаепне бары тик үзеңнән, яшәгән чорыңнан эзләргә кала: *«Ә мин киләм, / әйтерсең лә тыныч аккан агымсу. / Кайнап чыккан моңнарымны / кайсы җилгә тагыйм соң?»*

Шулай итеп, ике кыска шигырьдәге мозаик картиналар лирик герой халәтен – аның югары романтик, лирик тойгыларын, кискен өзеп, туган ягы белән яңа алыш-биреш зарурлыгын, иң үткен метафора башкара алмаганнан да уздырып, бик тиз төшендереп бирә: халәт-кичереш тә, логик нәтиҗә дә – күз алдында! «Акрын барсаң – морадыңа җитәрсең!» дигәндәй, зур тормыш серләрен өйрәнәм дип, каядыр еракка ашкынасы, ашыгасы, чит купшы-ялтыравык шигъри тәгъбирләр эзләп кабаланасы юк – шагыйрьнең төп яшәү-иҗат юлы – үз төбәгендә, югалту-табышлары – үз туган йортында, мәңгелеккә дип калдырасы сүзләре – үз халкы каршында, барыр юлы, тотыласы вакыты, сүтеләсе гомер йомгагы Себернең бүгенгедән шаулы меңъеллыкларына барып тоташа!

***

Шәүкәт Гаделша (Шәүкәт Гаделша улы Сибгатуллин) 1949 елның 16 сентябрендә Төмән өлкәсенең Түбән Тәүде районы Киндерле авылында дөньяга килә. Туган авылында сигезьеллык мәктәптә укыганда ук шигырьләр яза, районда русча чыга торган газетада кыска лирик парчаларын, хәбәрче язмаларын бастыра. Мәктәптән соң 1967 елда һөнәр училищесын тәмамлый. Ике ел туган авылында электромонтёр булып эшли. Салехардка китеп, эшен балык комбинатында дәвам итә. 1970 елда ул, шигырьләрен туплап, юлын-юлга рус теленә тәрҗемә итеп, Мәскәүгә М.Горький исемендәге Әдәбият институтына конкурска җибәрә. Алар уңай бәяләнеп, авторы укырга чакырыла. Әмма урта белем аттестаты булмау сәбәпле, егет институтка кабул ителми. 1972 елда ул КамАЗ төзелешенә килә. Төрле объектларда электромонтёр булып эшли, кичке урта мәктәпне тәмамлый. Матбугатта шигырьләрен бастыра. 1973 елда яшь шагыйрь Татарстан Язучылар берлеге юлламасы белән Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Студент елларында университетның «Әллүки» әдәби түгәрәге җитәкчеләренең берсе була.

Җитмешенче еллар ахырыннан башлап, Ш.Гаделшаның хезмәт урыннары гел алышынып тора: йә ул туган якларында, йә Казанда электромонтёр, төзелеш трестларында инженер-энергетик, «Агитатор блокноты»нда әдәби хезмәткәр... ниһаять, үзе оештырган хосусый фирма җитәкчесе вазифаларын башкара. Көндәлек матбугатта шигырьләре күптәннән басылуына карамастан, беренче китабы 1997 елда гына дөнья күрә. Бүгенгәчә аның сигез китабы басылып чыккан.

Ш.Гаделша – 1999 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы[2].

Ни кызганыч, олы йөрәкле, талантлы каләмдәшебез 2024 елның 30 мартында арабыздан вакытсыз китеп барды. Авыр туфрагы җиңел булсын!

***

Шәүкәт Гаделшаның Себер табигате һәм Себер холыклы каһарманнарына җентекләбрәк тукталганчы, башта аның гомумән поэтик үзенчәлекләре һәм иҗади мөмкинлекләре хакында берничә сүз әйтеп китү урынлы булыр. Чөнки бу шигъри хәзинәнең төп генераторы, төп тудыручысы – шагыйрь шәхесе, аның үз поэтик фикерләү потенциалы.

Гап-гади бер Себер егете бай тарихлы шигъриятебездә, яңа заманда иҗатына соклandырып, югары поэтик осталык мәктәбеннән үрнәк дәресләр бирү дәрәҗәсенә ирешкән икән, әлеге феноменның бу ягына да монда махсус тукталып китү һич артык булмас.

Шигырьләрендә Себер татарлары диалекты һәм әдәби тел байлыгының үзара үрелеп килүе, халык идиомаларының мул кулланылышы, тасвир стиленең үтәкүренмәлелеге, төгәллеге аның шигырьләрен тагын да җанландыра, баета, табигыйләндерә. Ритмның

[2] Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том / төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 287-288 б.

кыскалыгы, рифмаларының шактый ирекле булуы: гадәттә, сузык авазларга яисә төрле сүзләрдән оешуы сурәткә сөйләм теленә хас гадилек, өстәмә хәрәкәтчәнлек өсти (ярым ай – сабыйдай, үч итә – чүплеккә, дәү эт – төбәлеп, куркыныч – кычкырдым – «Бик зур шәһәр...», 84[3]).

Шагыйрьнең күзе үткен: *«Кар очкыны чага күзне»* (72), *«Чәчрәп оча саескан»* (431), *«Укы учак булып янган сүзләремне»* («Мин сине сөям дип...», 65), *«Бал кортлары сарылган көнбагышлар йөзенә»* («Ак болытка карыйм да», 149), *«Хуҗаларча әйләнә ул, ник талпынсын аз гына! Әйтерсең лә зәңгәрлектә бөек фикер языла»* (Бөркет, «Күз буяу», 69), *«Елый агач эчләреннән чыга алмаган көймәләр»* («Күңелсез як...», 448).

Колагы яхшы ишетә: *«Көн бораулап очканына кызыкканнар күп булды»* («Шөпшә», 351), *«Коеналар яшь кызлар, чәчри сүзләр татарча!»* («Гөрли сыман елгада...», 355).

Аның сизү органнары армас-талмас локаторлар сыман актив эшли. Алар сизгер генә түгел, автор хис иткәнчә, үзенчә – Себерчә, күңел күзе аша тоемлыйлар: *«Көймә борынына учак асабыз. Төнгә ышкылып түбән агабыз»* («Мин бүген хан», 209); *«Ачуларны йомшарта күккә төбәп ату. Әфсен булып тоела күздән укны югалту»* («Тилгән оча һавада...», 356); *«Күпме аттым – баш очымда һаман да әйләнәсең. Әллә бабалардан калган берәр әманәтме син?!»* («Үрдәккә»,192); *«Күпме хата, гөнаһларым койрык булып арттан килә. Койрык өзеп качу җаен яшел кәлтә генә белә»* («Күпме хата...», 91).

Метафораларны шагыйрь, гомумән, коеп кына куя сыман:

*«Тоям сыман: алда көчле давыл поскан. Куркып түгел, сикерергә сыртын кыскан»* («Ничәнче кат күкнең...», 201); *«Карурман тынды да төрле шик кузгатты. Гүя ул – күләгә, өрәкләр зираты»* («Юк, төнлә урманда...», 214).

Хәтта еш кына алар, чамасыз күбәеп йә урынсыз кизәнгәндәй, хис-фикер үсешенә комачау да итә башлый. Кыскасы, сурәтлелек белән артык мавыгу иҗатта үзмаксатка да әверелеп куя: *«Кояшка гына кайчак килеп куя тибәсем. Нигә ул хәтерләтә черек чебен гөмбәсен?»* («Көн начар...», 258).

Күргәнебезчә, табигать белән аерылгысыз яшәү аңарда үткен күз, сак колак-ишетү, сизү органнарының мизгел эчендә җанлы бербөтен ассоциацияләр чылбырын тәшкил итү сәләтен генә түгел, сәнгатьнең нигезен тәшкил иткән ихласлыгын, күңел нечкәлеген дә саклап калган. Бу яктан да ул – чын-чынлап, табигатьнең үз баласы. Шигъри тасвирларында аның нечкә, сизгер психолог булуы күзгә ташланмый калмый. Рәссамлык таланты шигырьдән-шигырьгә ныгый бара:

*«Бу үҗәтле шомлы кош»* (431) – монысы гап-гади саескан рәсеме эскизы булды. Алдагы мисалда исә коллегасы – балыкчы портреты җанлана: *«Аяз, яңрау төн. Көймәдә чуртан. Бөтен Себергә мин – бердәнбер хан!»* («Мин бүген хан», 210). Ниһаять, алдыбызда тайганың сүзләрдән чигелгән шигъри полотносы – тылсымлы манзара хасил була: *«Мүкләнгән тынлык. Бүрткән яшеллек. / Пәрәвез җебе аркан ишәрлек. / Кое диимме, әллә – яшел төн? / Борынгы урман мине яшерде. / Кояш нурлары төшә тамчылап. / Ешлыкка эләгеп, җилләр талчыга. / Башта уйның юк хәтта шәүләсе. / Гүя мин – черек агач кәүсәсе»* («Карурманда», 89). Алга таба инде бу серле төбәкнең гади, гадәти, әмма узган гасырларда гына саклангандай легендага тиң кешеләре җанлана башлый:

*«Якташның хәлләрен сорарга онытам, күрсәмме өендә, чоланда туң чуртан»* («Туң чуртан», 105). *«Черкине тыңласам, тынлыкта оета тирән моң. Хәтерем урманын, күз йомып, үтәләй күрәмен»* («Черкине сагынам», 110). Черкиләр безләвендә лирик герой җанга үз булган мәңгелек «вакыт агышын» тыңларга керешә.

Монда, күрәсең, аның тумышыннан үткен күз, сизгер җан таләп иткән аучылык һөнәрен профессиональ дәрәҗәдә үзләштерүе дә нигез шартларының берсе булып тора торгандыр. Масштаблы фикерләвенең һәм гамәли тынгысызлыгы башлыча әнә шуның белән бәйледер.

[3] Шигъри мисаллар авторның «Табигать баласы» китабыннан (Шәүкәт Гаделша. Табигать баласы. Казан: ТанДим, 2014. – 488 б.) алынып, биредә аларның исеме һәм бит чыганагы күрсәтеп барыла.

Һәм, ниһаять, эчкерсез кызыксынучанлыгына, тылсымлы соклану халәтенә, тирән һөнәри вазифа җаваплылыгына тумыштан бирелгән вөҗдан сафлыгы һәм тәрбия-иман әхлагы да килеп өстәләдер. Шулай итеп, шагыйрь иҗаты, һәр яктан өлгереп, максатчан кыйблалы фәлсәфи бөтенлеккә – идеологик-гамәли көрәш учагына әверелә.

Менә аның хуҗа булыпмы, үзен кунак тоепмы, бөтен тайганы бер итеп, тамак төбе белән җыр әйтүе: *«Нидер җитми минем җанга: / төзәп аттым ак томанга. / Кичке кояш яньчелде күк. / Тел сындырып тынды кәккүк. / Сырт кабартты куак, үлән. / Кош дөньясы купты күлдән. / Күп нәрсәнең очты коты. / Үземне дә курку тотты. / Колагымны яра язды / мылтыгымның кайтавазы»*.

Безнең алда өлкәннәребезгә һәм балаларыбызга әзер-өлгергән классик җыр тексты. Мондагы бунтарьлык рухы, киңлек, кодрәт, мондагы кешелеклелек, юмор – барысы да салынган. Милләте һәм тыңлый белүчесе генә табылсын.

Поэтик фикерләүнең нигезе шартлылыкны тою нечкәлеге, аны куллану осталыгы белән дә автор бик күп каләмдәшләре арасында аерылып тора. Шагыйрьнең бу хыялый хасияте иҗатының башында – өйрәнчек шигырьләрендә үк игътибар үзәгендә: *«Ботаксыз наратны бик дәртләнеп чукый тукран. / Ә мин сөйгәнемне җырлар җырлап көтеп утырам. / Икенче агачны бик тырышып чукый тукран. / Ә мин сөйгәнемне бик сагаеп көтеп утырам. / Өченче агачны тыз-быз килеп чукый тукран...»* Дүртенче строфада реаль тышкы табигатьне тасвирлау бетә, шигырь тулысы белән сәнгати шартлылыкның икенче канаты – эчке күңел халәтен сурәтләүгә күчә: *«Агачларны түгел, йөрәгемне чукый тукран»* («Ботаксыз наратны...», 53).

Шигъри шартлылык ярдәмендә автор үзенең ерак яшьлеген эзли: *«Яшьлегем, син кайда – яшердеме тайга?»* Табигый ки, әсәрдәге һәр сорау һәм җавап, һәр фараз шушы шартлы шигъри сурәтләүгә корылган: *«Агачтан-агачка сикерә бер тиен. Белмәссең, шул тиен яшьлегемдер минем»* («Сердәшләр булганга...» 67).

Авторның «Бер урамда» (44), «Ике ярдан...» (51) шигырьләренең дә нигезендә әнә шундый хыялый-шигъри шартлылык ята: *«Яктырып көл, язгы кояш, күз камашсын, / – кара күзен йома-йома кыз адашсын. / Ул, адашып, туган йортын табалмасын. / Булышыйм, – дисәм, мине кире кагалмасын»; «Ике ярдан икәү барабыз, / төнбоеклы тын күл – арабыз. / Синең якта йөзә аккошлар, / яфракларда көмеш балкышлар...»* Йөзеп чыгар иде егет – кинәт барысын да югалтудан курка. Шуңа әсәр яңа шигъри ачкычта дәвам итә: *«Бер пышылдау – безнең арабыз. / Тик карашып кына барабыз. / Дулкын күлдә кайчан күренер? / Кайсы ярдан башлап йөгерер?»*

Шигъри шартлылык авторның яшьлек шигырьләрендә генә түгел, әлбәттә. Ул – яшәешнең иң катлаулы проблемаларын хәл иткәндә дә шагыйрьнең төп иҗат коралы, шигъриятенең төп локомотивы. Менә «Март төне» (54) шигыренә күз салыйк: *«Түбәләрдә дәртле тетрәү – мәче туе тәгәри. / Усал карчык таяк тотып йөгерә өе тирәли. Тәрәзәгә маңгай терәп, күрше бабай сөйләнә: / – Карчык акылыннан язган – язга каршы селтәнә»*.

Аның ярдәмендә нечкә шигърият автор яшәешенә үзеннән-үзе агылып керә сыман: *«Йөгерә ата болан куакларны ярып: / җанына тынгы бирми мөгездәге ярык. / Җил иссә, кубыз булып суза башлый ярык, / ана болан чакырган авазлар чыгарып»*. Җилләр үгезне егылганчы алга куа, шигъри финал исә тынгысыз лирик геройның үз хыял-мөгезендә дә ярык булу ихтималы детале килеп өстәлү белән тәмамлана («Мөгездәге ярык», 42).

«Әй, язмышым, кызып килә торгач...» (52) шигыре дә безгә барыннан да элек үзенең шартлы тасвирга корылуы белән кызыклы: *«Бик тә йоклар идем, иреннәргә орынганчы язның җылы бите, – былтыр куып килгән җәнлеккәем, Яңа елга кереп, качып китте»*. Шулай итеп, һич кудырып җиткермәгән тиз агышлы абстракт гомер, конкрет сурәт алып, җанланып китә. Бу инде метафора гына түгел, ә бәлки реаль яшәү психологиясенә нигезләнгән тормыш фәлсәфәсе.

«Аучы җыры» (72) шигырендә поэтик шартлылык әсәрнең композицион сюжеты

белән үрелеп бара. Биредә, аучылык психологиясенең төрле кичереш этаплары тасвирланып, каһарман үзенең сөюендә дә нык кына үзгәрешләр кичерә: *«Ниятемне әйттем иртән: / «Көмеш бүрек бүләк итәм. / Атмый кайтсам әгәр бүген – / чынлап сөйми йә син, йә мин...»* дип сөйгәне алдында бик зурдан кубып, һавалы сөйләнеп чыгып киткән егет, көне буе йөреп тә, буш кул белән өйгә кайтканда инде мәхәббәттә бөтенләй капма-каршы тойгыларга бирелеп, өенә атлый: *«Ә сусарны бүтән кумыйк. / Сөйгәнемнән бүләк булып калсын. / Әйдә, туар таңга, булсын бүләк карурманга. / Сусар да пар тапкандыр ла; / шуңа оста качкандыр ла. / И сусаркай, өметтәшем, / шаһитлеккә сине дәшәм»* дигән яңа фикергә килә ул.

Шагыйрь үз иҗатында бернәрсәгә дә битараф түгел, карчыга тырнагындагы тычкан чинавыннан ярылган туң җирдән башлап («Шик», 210) боегып калган көзге кырмыска оясына кадәр һәр җанлы-җансыз аның нечкә күңел кылын тибрәтә.

Гап-гади шигырьгә язмышларыбызның җанны тетрәтү кодрәте салынуын, мөнәҗәттәге шигъри моңны монда тою авыр түгел.

Биредә без тагын Шәүкәт Гаделшаның хис-кичерешләр белән генә чикләнмәгән, рациональ акыл көчен алга куеп иҗат иткән хикмәтле шагыйрь булуын да ассызыклап үтәргә тиеш булабыз. Бу сыйфаты да, әлбәттә, иҗатында аңа җаваплылыктан гайре һич җиңеллек китерми: *«Тели күңел хисләремнең акылымны йотуын. Капкыннарга кабуыңны белеп яшәү, ай, кыен...»* Әмма акылга тышаулык салып буламыни? Шәүкәт Гаделша шигырьләрен, гомумән, акыл башлангычыннан башка күз алдына китерү мөмкинме икән?! Һәрхәлдә шагыйрь иҗатында хис-акыл берлеге аерылмас гармоник бөтенлек тудыра.

Әнә «Язгы кар» (106) шигырендә дә ул хикмәтле-оригиналь фикерләве аша укучыга чын Себер әхлак-философиясен тәкъдим итә: *«Күкнең юмартлыгы җиргә ишелә. / Аклык бер дә юкка әрәм ителә. / Күңел, җепшек кардан шатлык теләмә: / кар боткасы булып таптала мәгънә... / Кирәк түгел, язмыш, мәңгелек гомер, – / Язгы ялкаулыкны гына син бетер».*

Табигать күренешләрен, бу очракта Себер тайгасының үзенчәлекле тереклек дөньясы нюансларын шулкадәр нечкәләп, бөтен каршылыкларын йөрәгә аша уздырып, укучысы күңеленә үз сулышында китереп җиткерә алган икенче бер шагыйрьне минем, әйтик, дөнья поэзиясендә очратканым булмады. Моның өчен, мөгаен, Себер татары булып туу һәм яшәү сораладыр. Күпмедер йокымсырауга бирелгән цивилизацияле җаныбызда авторның әледән-әле меңъеллык урман стихиясенең тынып калган поэтик кодрәтен кузгаткан давылларын уятып җибәрә алуы тикмәгә түгел, әлбәттә. Димәк, аның шигъри таланты үзендә бу могҗизалы көч белән аңлашыр уртаклык таба алган!

***

Себер табигате, Себер холкы, Себер шигърияте турындагы теманы дәвам итеп, шуны әйтергә була: әлеге халык теленә дә күчеп, киң кулланышта йөргән сүзтезмә, күрәсең, барыннан да элек Себернең рәхимсез кышкы салкын табигате, черки тулы иксез-чиксез кыргый җәйге тайгасы, шушы кырыс яшәү шартларына җайлашып, нигездә аучылык, балыкчылык белән көн күргән, һәртөрле уңайсызлыкларга каршы торып чыдарга өйрәнгән сабыр, нык характерлы кешеләрен күз алдына китереп әйтелгәндер. Җәнлек тиресен бозмау өчен тиеннең күзенә атып тидерүләре, юан агачтан берничә сәгать эчендә үзләренә утырып елга кичәрлек каек әмәлләп алулары кебек бик күп могҗизалы һөнәрләре цивилизацияле җәмгыятьтә күптән инде экзотикага әверелгән. Аларга булган хөрмәтнең дә һич кимегәне юк. Хакимият түрәләре өчен генә ул, ни кызганыч, әлегәчә арзанлы материаль табыш чыганагы һәм кайчандыр яулап алынган юмарт күңелле халыкларның җимерелеп барган күрше биләмәсе мөнәсәбәтеннән һич узганы юк. Бу хакта без соңгы бүлекчәдә җентекләбрәк тукталырбыз. Хәзер исә әлеге «Себер холыклы» геройлар белән якыннанрак танышып үтик.

«Йөз яшьлек аучы» (43) шигырендә шагыйрь укучысына Себернең абруйлы бер вәкилен – чын яшәү белән мавыгып китеп, үзенә йөз яшь тулганны һәм дөньясының

тынып калуын да сизми калган карт аучы образын тәкъдим итә. Автор биредә чын Себерчә яшәүнең йөзьеллык хакыйкатен ачып сала: *«Сызгырмый, кычкырмый – урманы тып-тыныч. / Үлем берни түгел, шул тынлык – куркыныч! / Йөз яшькә җиткереп, язмышы көлгән бит. / Урманы-дөньясы алдарак үлгән бит...»* («Йөз яшьлек аучы», 43-44).

Икенче бер «Балык шулпасы» (69) шигырендә лирик герой авылдашлары янында сыйланып утыра: *«Эчкән идем бер тустаган, яктырды күз алларым! / Күз кысалар чәчәкләре аргы як аланнарның. / Туймадым мин, тагын эчтем, Тәнемә йөгерде дәрт. / Йолкып ташлый күрмәсен дип, нарат тора дерелдәп. / Исердем бит! Миңа рәхәт! Оҗмахка кергән кебек. / Бәдәннәре дерелдәгән карт идем – булдым егет».* Тасвирның шартлылык һәм җылы юмор белән үрелеп бирелүе безне әнә шулай исән-күтәренке рухлы яшәү оптимизмы белән сугара.

Авторның «Аңлый төшәрсең» (116) шигырендә Себер татарының нинди шартларда яшәве һәм аларның бу язмышларын ничек кабул итүе тасвирлана:

*«Актарылган бураннарда юлга чыгып кара. / Шаулап яуган яңгырларда шырпы сызып кара. / Ач бүренең күмер күзен төнлә күреп кара. / Черки канатыдай юка боздан йөгреп кара. / Ай астында кыр-урманда кышын йоклап кара. / Шунда Себер татарыдай сузып җырлап кара».* Фикерен йомгаклап, автор якташларының ни өчен һәрвакыт тормыш ваклыгыннан өстен булып калуы һәм аларның оптимистлык сәбәпләрен ачып сала.

«Без ыштансыз Себер татарлары...» (430) шигырендә шагыйрь бу теманы тагын да киңәйтә һәм психологик яктан тирәнәйтә төшә: *«Без ыштансыз Себер татарлары – кашка тәкәләре түгел җирнең...»* Әлеге төп фикерен ул, үзенә хас булмаганча, публицистик кайнарлык белән турыдан ярып дәвам итә: *Кайсыбыз соң безнең, йә, кайсыбыз, / Берне биреп, унны өмет итә? / Безгә без биргәнне алганнарның, / Аз булса да, елмаюы җитә.*

Ә оялу ул, әйтүебезчә, бүгенге заман төшенчәсе түгел! Аның үткәне һәм киләчәге генә бар сыман.

Шулай итеп, Шәүкәт Гаделша милләт укучысына өр-яңадан ул белгән, әмма әле белеп бетермәгән милләттәшләренең яңа сыйфатын ачып бирә! Олы шагыйрьнең халкы алдындагы тарихи миссиясе шунда түгелмени?!

Бу урында Шәүкәтнең шагыйрь буларак кына түгел, кеше-шәхес буларак та гаҗәеп тыйнаклыгын ассызыклап үтәсе килә. Тукай премиясен тапшырасы көнне очрашкач, ул: «Миңа шул Себер татары булган өчен бирделәр бугай инде...» – дип, үз шагыйрьлек бәясен сәяси якка борыбрак акланып маташты. Кызганыч, үз иҗатына тулы поэтик анализны ул күрә алмыйча китеп барды. Бүләк бирелү аның алдында безнең йөз аклыгыбыз булды. Тыйнаклыгына килгәндә, бу темага без мәкалә азагында тагын да бер җентекләбрәк тукталырга уйлыйбыз.

Чын табигать баласы буларак, шагыйрь иҗатының үзәк бер төркемен аның табигатьне саклауга багышланган әсәрләре тәшкил итә. Шунысын әйтергә кирәк, алар китапка махсус көчләп тагылган тема булудан бигрәк, лирик геройның эчке рухи үсеш эволюциясе процессында үзеннән-үзе килеп туган проблема буларак кабул ителә. Кырыс-уйсыз аучы психологиясенең иртәме-соңмы шигъри күңелле лирик герой дөньясы белән каршылыкка керүе бик табигый. Автор әлеге үзгәреш эпизодларын әсәрдә бик оста файдалана. Иң көчле шигырьләренең шушы проблеманы үзәккә алып язылуы да һич очраклы түгел.

«Поши аткач» (93) шигыре – әнә шуларның берсе. Әсәр Себер табигате өчен дә бик үк гадәти булмаган салкын кышкы көнне тасвирлаудан башланып китә: *Шундый салкын. Нарат шартлый. / Эт селәгәе боз булган. / Җан чыгарып яткан поши / Җылысына сыенам.*

Автор каләменә хас булган кыска, кырыс тасвир өченче-дүртенче юлларда кинәт, яшь-тәҗрибәсез лирик герой халәтенә якынайтылып, бөтенләй үк нечкә материя теленә күчереп җанландырыла. Әмма бу бер мизгеллек йомшаклык икенче строфада ук кабат реаль, кырыс тормыш конкретлыгына әйләнеп кайта: *Карт аучылар ашыгалар – / Пычаклары йөгерә.*

Әмма шушы берничә юлда, күз алдыбызда лирик герой халәтенең кыл урталай бүленеп, без алга таба да шушы ике – традицион аучылык һәм яңа уянган теләктәшлек-кызгану халәте логикасы юнәлешендә дәвам иттереләчәген сизеп алдык: *Сунарчымы? Үтерүчеме? – / Үземне кем дияргә? / Ирексездән сораусынып / Текәләмен Галәмгә. / Аң көчәнә – динсезлегем / Алланы эзли мәллә?..*

Монда инде без лирик геройның гомуми социаль яшәү дөньясын да үтәдән-үтә күреп алабыз. Ул үзенең бу уңайсыз рухи халәтен яшерми, киресенчә, аны логик – акыл теленә күчереп аңламакчы: *Карт аучылар сөяк чаба – / Өлешләргә бүләләр. / Итне түгел, гүя кучләп, / Гөнаһларын өяләр.*

Ассоциация чылбыры төгәл эшли, ул бик тиз логика аша әхлак системасы теленә күчә: *И табигать, нишлим инде? / Алам миңа тиешне. / Бабалардан калган гөнаһ – / Өлешемнең көмеше.*

Автор шунда әле генә үзе ерагая башлаган икенче төркем халәтенә дә тарихи караш ташламый булдыра алмый: *Картлар йөзе шундый кырыс! / Куркамын эндәшергә. / Шул кырыслык бик борынгы / Күңелсез сер яшергән.*

Димәк ки, «картлар» яшь герой тойган нечкә тойгылырны да, моңа өстәп, башка бик күп кырыслыкны да инде күптән беләә, ул бары тик кысылып, өлкәннәрнең сүзсез кырыслыгына әверелеп яши.

Ниһаять, әсәр гомумиләштерү көчен ачып, үзенең азагына якынлаша:

*Җылынмый көн. Нарат шартлый.*
*Үзәндә – аксыл томан.*
*Үр артында, күпләп атып,*
*Поши туныйлар сыман.*

*Шумый юкә чаңгыларым –*
*Табаннарга кан каткан.*
*Эзәрлекләп гомерлеккә,*
*Авыр хис кайта арттан.*

Шигырь тәмамлана. Тик чаңгы табанына каткан канлы тарихның гына күңелдән һич юыласы юк.

Табигатьне чиксез яратуы автор иҗатында аның мәхәббәт шигырьләреннән аерылгысыз. Алар шагыйрьнең – җан аклыгы, күңел сафлыгы. Байтагын эчтән балкытып юмор тойгысы яктырта.

«Сыерчыклар яратмаган» (132) шигырендә лирик герой, иртә таңнан торып, сызгырына-сызгырына, сыерчык оясы ясап маташа. Аның янында яшүсмер күрше кызы: *«Ниятендәниләр бардыр – әй сөйләнә, әй көлә. / Кайчак эссе толымнары беләгемә түгелә. / Туңган куян баласыдай калтырана күкрәге. / Карашыма тирән батып эзләнә керфекләре».*

Ә күрше абыйсының ник бер гамендә булсын – тик үз эшен белә: *«Юк, алданмам, игътибарым чүкечтә дә кадакта. Тырышма, дим, күршекәем, суктырырга бармакка».*

Чибәркәйнең дә бит горурлыгы чиксез түгел: *«Ә кыз китте. Толымнарын чорнап тотып, тарткалап. Черек такта очып төште каты япкан капкадан».*

Билгеле инде, күршесен кыерсыту геройга бер дә шатлык китерми. Иң күңелсезе тагын шунда: баксаң, кыз аның бар эшләгән эшен дә мәхәббәтсез калдырып киткән икән: *«Язгы таңнан ләззәт тапмыйм, чыксам, иртән уянып. – Сыерчыклар яратмаган мин ясаган ояны».* Моңа карап шигырьдәге җылылык бер дә кимеми, әлбәттә.

«Мин поши куалыйм» (128) шигыре, буш сөйләнеп йөреп, күрше кызын кулдан ычкындырган егет турында. Ул гыйбрәтле үткен сатира белән сугарылган.

Драматик реальлеккә нигезләнгән «Кемгә икәнен үзе белә» (208) шигыре үзенең тирән кичерешлелеге, төгәл сурәте, оригиналь чишелеше белән игътибарны тарта: *Алка итеп, йөзек итеп, / Күрәм төннең алтын аен. / Бичәм ята аңа карап – / Сиңа бүләк италмаем.*

Әсәрнең финалы да әллә кайгылы, әллә фаҗигале, аңламассың, әмма аңарда әрнүле чын тормыш дөреслеге коеп куелган: *Белмим мине ниең тарта? / Әллә җаның, әллә каның? / Бичәм ята ирнен тешләп, / Сине уйлап куйган саен.*

«Балыкчы хатын» (104) шигырен автор укучыга эпик ачкычта – вакыйга рәвешендә тәкъдим итә. Анда яшь бер егет һәм яшь хатынның кышкы урманда чанада бергә өйгә кайтып

барулары тасвирлана. Әсәргә һич уйламаганда, эротик детальләр килеп кереп, вакыйга-сюжет бик тиз мавыктыргыч һәм дулкынландыргыч поэтик сурәтләр тезмәсенә әверелә. Мәхәббәт эпизоды көтмәгәндә ничек тиз башланса, шулай тукталып та кала*: «Ыргылды ат: туң күлне барабанлап чабабыз. Кайсыбызны үчекләп ыңгыраша чанабыз?»* Әмма шушысы хак: әсәрдән алган тәэсир, һич онытылмыйча, безне гомер буе озатып барачак.

«Ышык җирләрдә» (102) шигыре дә эпик башлангычта язылган. Әсәр бер хатынның иренә хыянәте һәм аның ире тарафыннан «себерчә» кырыс җәзага тартылуы турында. Гыйбрәтле картиналар, авыр эмоцияләр кузгаткан шигырь.

«Табигать баласы» (324) шигыренең үзәгендә хатыны хыянәт иткән фаҗигале аучы язмышы. «Табигатьтә гаеп» (395) шигырендә автор, кабат әхлак темасына кайтып, аны икенче – тугрылык аспектында бәян итә.

***

Шагыйрьнең алдагы чор иҗатын үз эченә алган китапларында торган саен ешрак Себер төбәгенең бүгенге авыр язмышына тирән борчылып язган шигырьләре урын ала. Аларны якынча өч өлеш-тематикага бүлеп карарга мөмкин: 1) яңа заман изүе, милләттә эчке һәм тышкы деградация; 2) шагыйрьнең бабалары үткәненә ешрак мөрәҗәгать итүе; 3) ирекә ымсыну, «Себерчә бунт» шигырьләре.

Империя золымының яңа заманда Себер татарларына ясаган иң зур зыяны – халыкның эчүгә сабышуы. Бу чир аларны һәм җисми, һәм рухи яктан таркатып, тәмам аяктан екты, милләтне халык буларак юкка чыгу куркынычы алдына китереп куйды. Шагыйрь өчен бу абстракт проблема түгел. Себердә аның якташлары, авылдашлары, якын энекәшләре яши. Фаҗиганең асылын ул ишетеп түгел, эчтән торып белә. Авторның «Кунакка кайткач» (129) шигырендә без әлеге таркалу процессының натураль чагылышы белән якыннан торып очрашабыз. Менә ул – әлеге заман авыруы тарихының «социаль медицина карточкасы»:

*«Бу нарасый төбәкне дә замана аямаган. / Яман чирен – аракысын читтәрәк коялмаган. / Утка төшкән күбәләктәй көйгән күпме күңелләр. / Алар сабыйдай самими һәм эчкерсез иделәр. / Әүхәт тә бит шундыйлардан: сүнгән йөзе, күз нуры. / Йөрәгемне учлап кысып, энем белән сөйләшәм».*

Ә ул инде әнә күптән ихтыярсыз чын Россия философына әверелгән:

*– Нигә, энем, калош тишек,*
*Оегың да күренми?*
*– Яланаяк йөрү, абый,*
*Озынайта гомерне.*
*– Ятса икән өстәлеңдә*
*Сыңык икмәк телеме.*
*– Гөмбә, балык, җиләк ашап*
*Озынайтам гомерне.*

*– Кайда балаларың? Бичәң*
*Мич янында йөреми...*
*– Бу дөньяда ялгыз яшәү*
*Озынайта гомерне.*
*– Ялгызың син. Озын гомер*
*Сиңа, энем, нәрсәгә?*
*Җитмимени калган гомер*
*Бер туйганчы эчәргә?*

Ирексездән шагыйребез Хәсән Туфанның узган гасырның егерменче елларында язылган классик «Урал эскизлары»нда абыйлары белән сөйләшкән диалоглары хәтергә килә. Тик аерма шунда: узган гасыр абыйлары – яңа, күрелмәгән тормыш төзүчеләр... Ә биредә бер гасырдан соң яшәгән бу энекәш – булган бар дөньясын (монда матди кирәк-ярак та, табигать байлыгы да, рухи дөнья да, кан-кардәшлек тә – барысы да керә) сатып эчүче. Шулай итеп, империя золымы идарә-буйсындыру законнары һәм гамәлләре белән генә түгел, аракысы белән дә халыкларны юкка чыгаруда тарих каршысында үзенең кара эшен башкарды.

Әлеге теманы лирик герой «Яшьтәшем Фатихка» (149) шигырендә авылдашы белән сүзсез генә берүзе дәвам итә. Чөнки инде авылда янәшә утырып сөйләшерлек кешесе калмаган: *Озаккамы туган якта / Гәп-сүзсез йөрүләрем? /Заман сөяк итте, ахры, /Телләрен шул ирләрнең.*

Күңелдә йөзләгән сорау, йөзләгән тема – яннарына утырып сөйләшер кеше

табылмый. Эчкерсез шаян йөзләр капка артына кереп бикләнгән, чорның деградацияле фаҗигасе урамга бүселеп чыккан: *Нишли ирләр? Ниләр уйлый, / Качып капка артына? /Җырларыма көч, моң кирәк /Капкаларны ачарга.*

Күрәбез, бүгенге шагыйрьнең бурычы инде мәйданнарда меңләгән йөрәкләрне алгакөрәшкә җилкендерү түгел, аларны кабат күрше итеп, авылдаш, замандаш итеп телен ачтыру, нормаль кеше итү. Боларны савыктыру мөмкинлеге, мондый кодрәт, әлбәттә, Себер татарлары гына җитәрлек төштә түгел, тирәндәрәк. Ул проблемалар катлы-катлы, төрледән-төрле. Инде монда килеп, *«чит телләләр урманнарда нарат, усак, каеннарга суга тамга»* («Урманнарга кабам», 171), инде мәктәпләр ябыла, халык үлә («Авыл-авыл кимедек», 309), Себер татары исә татлы оюда – бәхетен йоклап үткәрә («Төмәнне корткә төрә», 248; «Госман», 155). Соңгы шигырьнең финалы гыйбрәтле: *«Туган якның менә шушы тыныч матур иртәсендә минем бәхет йөри, дустым, синең бәхет тирәсендә».*

Шагыйрь «Урманда» (42) шигырендә күңел төшенкелегенең иң түбән сызыгына төшеп җитә шикелле:

*Югалды барыр ноктам.*
*Сүнде соңгы өмет.*
*Качып ятам урманда,*
*Кайгырып, яшем түгеп.*
*Салкын кыш наратларны*
*Йомычкалый, телә.*
*Йөрми җәнлек, очмый кош –*
*Оясында үлә.*

*Учак ягарга куркам,*
*Кеше кермәсен дип.*
*Дөнья хәлен, ил хәлен*
*Сөйли күрмәсен дип.*

*Кайчагында тәрәзәдән*
*Бүре танавын суза.*
*Кер, әйдә, кер, – дим, – ташлан! –*
*Гомерем тиккә уза.*

Шагыйрьнең бу үз барлыгына биргән соңгы бәясе. Нинди кыскалык һәм күпме әрнү-кичереш, мәгънә?! Шәхес бунты урамнарга лозунглар күтәреп чыгу белән генә чикләнми. Аның чагылыш формалары күп төрле. Биредә, күренгәнчә, аның икенче чиккә җиткереп кысылган «Себер варианты» гәүдәләнә. «Себер бунты»ның мондый рәвеш алып яшәве гаҗәп түгел, белүебезчә, аның берничә гасырга сузылган үз традициясе бар.

Җитмешенче еллар татар поэзиясендә әнә шундый тыштан сүнгән вулканны хәтерләткән тыйнак, әмма эчтә вулканик магма кайнатуга сәләтле өлгергән шигърият тә үсеп чыкты. Бер якта таркатылган, хокуксыз калдырып хәлсезләндерелгән Төмән татарлары, икенче якта – аларның сынмас рухлы ялгызак шагыйре... Шигырь туксанынчы елларгача булган сәяси ситуацияне чагылдыра. Әмма аның актуальлеге бүгенге көндә тагын да көчлерәк. Димәк, әсәр әһәмиятен югалтмау – искермәү генә түгел, сәяси яктан да елдан-елга кискенләшә, кырыслаша гына бара.

«Йолдызга менимме?» (107) шигыре авторның гаять нечкә эчке табигатен аңларга ярдәм итә: *«Учагымны ашыгып яктым күк тоела. / Күбәләкләр туп-туры учакка коела. / Инде күпме җәнлек, кош читләшер бу яктан; / Куркыныч кара тамга, ис калыр учактан. / Бик авыр төннән төнгә күченеп барулар; / Урын сайламый гына ут-учак ягулар...»* Әнә шундый тирән фикергә килеп чыга шагыйрь! Бу сүзләр буш урында килеп тумаган – аларның нигезенә *«Үземдә гаеп тоеп күңелем сүрелә. Кайда, кайчан артык мин? Эх, ничек белергә?»* дип яши белгән Себер психологиясе салынган. Ишетелер-ишетелмәс әйтелгән бу сүзләр бүген бөтен планета масштабында яңгырарлык көйдергеч шигъри фикергә әверелә: *Һәр якта ят учаклар – / Очкынлы, төтенле. / Үз урынымны эзләп, / Йолдызга менимме?*

Менә ул бүгенге «Себер бунты!» Бунт дигәч тә, без элеккечә акыру-бакыру, ызгыш-талаш, талау-җимерү, канлы сугыш афәтләрен күзаллыйбыз. Шагыйрьләрдән дә Маяковскийлар әмәлләгән бугаз шигъриятен көтәбез. Бактың исә, бүгенге Себер бунты инде ул күптән әрнүле сыктауга, ым-ишарә теленә, ярым пышылдауга күчкән, ә бездә һаман аңардан большевиклар кулланган рәхимсез, ачык, кискен чаралар көтелә... Соңга калмадыкмы, иптәшләр, заман корткычлык-рәхимсезлеккә түзә алмыйча, кешелеккә кулын селтәп, алга – цивилизацияле башка йолдызларга күчеп китү алдында тора бүген.

Шәүкәт Гаделша иҗатында әледән-әле Себер ханлыгын сагынып искә алулар урын ала. Тарихи хәтернең үлмәве шагыйрь шәхесенең гармоник бөтенлеген күрсәтүче билге ул. *Карасам йолдызлы күгемә: / Чемердәп хәл китә тәнемнән: / Әйтерсең бай ханлык качканда, / Тәңкәләр, чулпылар чәчелгән («Йолдызлы төндә», 243).*

Үзенең дингә мөнәсәбәтен җанландырып язылган «Таңын ауда азан ишеттем», 77) шигыре шагыйрь иҗатының тагын бер иң камил әсәрләренең берсе булып саналырга хаклы. Ул да бит, чынлап уйлаганда, «Себер бунты»ның бер варианты. Тагын да тирәнгәрәк төшеп уйлансаң, аның контрасты!

*Төнен берни булмагандай*
*Җайлап кына кызара таң.*
*Кайсы авылдандыр ага*
*Җылы бөркеп моңлы азан.*
*Нинди тылсым алыштырды*
*Тирә-юньнең манзарасын?*

*Чыршы тора, әйтерсең лә*
*Яңа мәчет манарасы...*
*...Тоньк кына яңгырый азан:*
*«Яңа заман, яңа заман!»*
*Ә мин бүре баласыдай*
*Караңгыга карыйм һаман.*

Авторның таң шикелле эчтән балкып китүе дә, җан канәгатьсезлеге дә – күз алдында. Әлеге илаһи этәргеч аның бөтен рухи дөньясын гармоник яшәү-көрәш дулкынына көйләп куя. Иң мөһиме – заманабызның яңа югарылыктагы классик шигъри үрнәге барлыкка килә:

*Сизә күңелем, әй, сизә:*
*Ята монда хәзинә.*
*Кучүмнеңме? Кайсы ханның?*
*Әйтә алмыйм хәзергә.*

*Сизәм дә кайда ятканын,*
*Теләмим кагылырга.*
*Иректән мәхрүм халыкның*
*Ирексез алтыны да.*
(«Хәзинә», 240)

Һичшиксез, бу юллар шигърият сөючеләргә бүгенге көннең иң кадерле бүләге булып кабул ителә.

«Бармы ирләр?» (249) шигырендә, ниһаять, без үзебез яратып көтеп алган традицион «Россия бунты» белән, ул гына да түгел, шагыйрьнең эчкә яшерелгән «Идел – Иртеш арасы!» идеясенең ургылып тышка бәреп чыгуы белән дә («Казанлы мин дияр идем...», 319) очрашабыз:

*Күк томан эчендә «дөп» тә «дөп»,*
*Тышаулы елгырлар килә күк.*
*Ятып та, басып та мин карыйм:*
*Күрмәмме аларның сыртларын.*

*Күрмәмме шунда мин берәр ат –*
*Иярле, кылычлы, чукмарлы.*
*Җилфердәп килмәсме сөңгедә*
*Кучемнең ак кыллы бунчагы.*

Менә шунда без «Россия бунты» белән «Себер бунты»ның, инде тәмам аерылып, бер сызыкта тора алмыйча, гамәлдән чыкканлыгын да күреп алабыз:

*«Дөп» тә «дөп» – инде ул бик якын!*
*Чынлап та, ат булса, нишләрмен?*
*Ничек мин туктатып тотармын?*
*Ничек мин тышауны чишәрмен?*

*Болгана каршымда күк томан.*
*Белмимен: артымы, алдымы?*
*Атларны чүктереп атланыр*
*Берәр ир Себердә калдымы?*

Бу инде зур шагыйрьнең зур халыкка әйтә торган соңгы зур соравы. Бу сорауның төп адресаты да инде, мөгаен, халык түгел, ә бәлки Хак Тәгалә үзедер.

**Равил РАХМАНИ.**

# МИН СЫЗЛАНАМ, СИН ДӘ СЫЗЛАН ӘЛЕ, УКУЧЫМ!*

***(Шагыйрь Ркаил Зәйдулланың соңгы еллар лирикасына бер караш)***

*Ишетми һәм күрми генә,*
*Бикләнеп үз җәсәдемә,*
*Сызланыйм мин, сызланыйм.*
«Бикләнеп үз җәсәдемә»

Чал тарихлы татар сүз сәнгатенә Р.Зәйдулла үткән гасырның сиксәненче елларында, үзе турында «хәбәр салып», тиз арада фикерен төгәл һәм образлы сурәтләр, соңгы сүз булуга дәгъва итмәгән шигъри күзаллауларга таянып, замандашының өермәле дә, сагышлы да кичерешләренә барәбәр өслүб белән чагылдыру сәләтенә ия шагыйрь буларак таныла.

Аның масштаблы фикерләү сәләте, күк җисемнәрен каләмендә «уйнатканда да», җир кешесе булып калуы милләтен, туган телен рәнҗетүчеләргә турысын әйтүе, публицистик сүз-хөкемне чишмә суыдай лиризм белән «җылыту» үзенчәлеге күңелләрне эретерлек иде. Р.Зәйдулла иҗаты тәнкыйтьтә дә, рәсми тарафтан да тиешле бәясен алды. Инде 1990 елда һәм яңа гасыр башында ук ул М.Җәлил, Ф.Хөсни исемен йөртүче әдәби премияләрне яулады һәм, озак та үтми, Г.Тукай исемен йөртүче бүләккә ия булу шатлыгын кичереп, Татарстанның халык шагыйре дигән олуг исемгә дә лаек дип табылды. Үзен Дәүләт Советы депутаты буларак раслагач, альтернатив рәвештә Язучылар берлеге рәисе итеп тә сайланды, ягъни Милли күтәрелеш чорында азатлык рухында тәрбия алган «холыксыз», «баш бирмәс», җитмәсә, талантлы «мишәр егетен» «кулга ияләштерү» юнәлешендә барысы да эшләнә. «Коллар без – үзара хан булып кыланабыз» («Яңа тарих») яисә «Бөтен бер ил үз телендә укырга Мәскәү ханнан көтеп ята ярлыкны» («Ис китә») кебек Р.Зәйдулла каләменнән төшкән юллар үзәк белән араны тагын да «кискенләштерер» дип борчылалар. Һичсүзсез, гаҗәеп талантлы Ркаил әлеге югары дәрәҗәләргә очраклы булса да, мондый «үстерү – азындыруларның» алдан уйланылган «мәкере» дә булгандыр кебек. Шундый олы дәрәҗәләр биреп, олырак аудиторияләргә чыгарып тавышын киңрәк катламга яңгырату мөмкинлеге ачылуны шәйләп җиткермәгәннәрдер кебегрәк тәэсир кала.

Аның Дәүләт Советы депутатлары алдында республикабызның статусын, милли мәктәпләрне, болай да мыскаллап бирелгән мөстәкыйльлегебезне саклау турындагы ялкынлы сәяси чыгышлары – шуңа асыл мисал.

Әдәбият «тормыш көзгесе» дигән ышанычтан чыгып бәяләгәндә, яңа гасырның унъеллыкларында пәйда булган сәяси-иҗтимагый үзгәрешләр Р.Зәйдулла иҗатына да тәэсир итми калмыйлар. Башка каләм әһелләре кебек үк ул да, нәрсәләрнедер югалту белән беррәттән, яңа рухи кыйммәтләр турында да уйлана. Аның соңгы еллар шигърияте, нинди сыйфатлары белән үзенә җәлеп итеп, кайсы яңа үзенчәлекләре белән сөендерә соң? Иң әүвәл шуны искәртәсе килә: теләсә кайсы әдип иҗатын мәүзугъ, өслүб таләбеннән чыгып чорларга бүлү шартлы; яшьлегендә табылган алымнар,

---

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан 2023 елда уздырылган татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсының «Әдәби тәнкыйть, рецензия» номинациясендә икенче урынны алган мәкалә.

шигъри «бөртекләр» җанлы җепләр белән иҗатчының икенче үсеш баскычына барып тоташалар, соңгылары яңа үрентеләргә үсеп чыгарга җирлек әзерлиләр.

Тынгысыз, эзләнүчән каләм иясе Р.Зәйдулланың соңгы чор (2018–2022) иҗатында күбрәк яшәү мәгънәсе, гомер кыйммәте, милли хәзинәләргә тугрылык турында уйлануларны чагылдырган фәлсәфи күңел лирикасы үзәктә торса да, мыскаллап булса да көрәшеп алган суверенлыгыбызны югалта килүебез өчен әрнү, сызлану, хәтта пессимизм «өянәкләре» белән каушап калу үзен сиздерә. «Җир әйләнә» шигырендә ул һәммәбезне кисәтеп куя: «Мәңгелеккә килдем димә, Бу дөньяда кем булсаң да, югалырсың».

Үткән гасырның соңгы унъеллыгы тәҗрибәсе «Халкым минем төнгә кереп китә» шигыре рухына туры килгән «Минме синең улың, мокыт кавем? Кем син? Кайда? Кемгә хезмәтең?» дип нәгъраләр орып кына, дөнья барышын үзгәртеп булмавын сизенә шагыйрь җаны, үзенең борчылып, хәтта югалып калуын яшерә алмыйча.

Башы – Хәйран! Ахыры бик истә түгел.

Үтеп китте күзне ачып караганчы, – дип ачынып яза ул «Кайчак татлы» шигырендә.

Барча буйсындырылган, бигрәк тә дәүләтчелеген югалткан татар халкына авыр тәэсир иткән бу үзгәрешләр Р.Зәйдулла иҗатында да «тамгаларын» калдыралар. Әле генә ярларына сыешмаган язгы ташкынны хәтерләсәк, төрле дәрәҗәдәге хакимият әһелләре белән «бил алышкан», нервларында «уйнаган» Р.Зәйдулла тынып калгандай була. Бу борылыш шул чорның программ шигырьләренең берсе – «Сау бул»ның лирик каһарманы бәргәләнүләрендә ачык күренә: *«Сау бул син, сау булсын мәңгелек яр! / Арада – юллар, арада – еллар» («Сау бул»).*

Башлам бабта ул үзенә «текә» шәхес битлеген үлчәп караса да, үткән белән араны өзеп ташлау ниятенең барып чыгасына ышанмый һәм «җил тегермәне белән көрәштә» үзенең көчсезлеген таныргa мәҗбүр була. Барысы да – аннан тормый икән шул: *Чишмәләр инде миннән еракта, / «Сау бул!» димәдем аерылган чакта («Сау бул»).*

Шагыйрь кайнар хисләрен, «такташлыгын» сабырлык чикмәненә сыйдырырга мәҗбүр була.Чарасызлык, гомернең олы мәңгелектә бер мизгел булуын аңлау кичерешләрне, язмышларны сурәтләүдә дә үзгәрешләргә алып килә. Шул хакыйкатьтән чыгып бәяләгәндә, Р.Зәйдулла шигърияте тарихны объектив яктырту, дөреслек эзләү, милләт мәнфәгатьләрен кайгырту кебек юнәлешләрен саклаган хәлдә дә, рухи дөнья хасиятләренә игътибар арту ихласи лиризмның көчәюенә алып килә. Иң соңгы «Төштән соң» (2022) исемле (Ркаил бу әйтемнең «Татар акылы» дигән беренче өлешен белмәгәндәй, башын «җүләргә салып», укучыларын ирештерә, җыентыгының 2018-2022 елларда язылган шигырьләре шуңа мисаллар. Аларда дуамаллыкны фикерен күңелләргә лирик чаралар ярдәмендә ирештерү үзәк тенденциягә әверелә. «Кара болыт йөзә иртәдән үк...» (2019), «Яз килгәндә әллә нишли иде» (2020), «Күз яшьләре тамган көйгә» (2020), «Таң» (2019), «Шөлдер» (2019) кебек шигырьләренә хас үзенчәлек – шәхеснең катлаулы хисләренә табигать, әйләнә-тирә күренешләре аша якын килү. Мәгълүм күләмдәге төшенкелек, югалып калу хисе, экзистенциаль сагыш «упкынына» ташламаса да, мәгәр бөтен иҗаты белән таныш кешеләрне гаҗәпләндереп, пошаманга салуы да мөмкин иде.

«Кара болыт йөзә иртәдән үк...» шигырендә лирик зат «Үтәр әле, ачылыр күк йөзе» дип хыялына бирелеп алса да, аның өмете иртәнге томан кебек тарала: «Баш өстендә һаман кара болыт йөзә», – ди ул, ачыргаланып. Биредә Р.Зәйдулла иҗатына хас «тәртәгә тибүләрне», изүләрне чишеп ташлауларны гади күзәтүчәнлек, талгын салмаклык, хәтта күндәмлек алыштыра: *«Баш өстендә һаман кара болыт, / Керфегемдә – якты тамчылары» («Кара болыт йөзә»).*

Икенче бер шигырендә ул, төшенкелеккә бирелеп, дөнья мәшәкатьләреннән, гаделсезлектән туеп, яшәешкә «кул селти»: *«Бу далада бер калкулык калыр, / Күмеп китәр аны ачы әрем» («Күз яшьләре тамган көйгә...»).*

Аның соңгы чор иҗатына үлем-үлемсезлек төшенчәләренә барып тоташкан моңсулык, тормышның мәңгелек кануннарын үзгәртеп булмасын аңлаган чарасызлык мотивлары үтеп керә. Иҗатында шагыйрь С.Хәким моңсулыгы «уянып», бәгырен әрнетә: *«Кич белән китәрмен моннан / Көймә туктар, утырырмын. / Инеш томаны ябынган / Төш кебек онытылырмын...» («Инеш»).*

«Син бары тик фасыл» шигырендә ул үзенә юанычны табигать күренешләре белән бердәмлектә күрә. «Мин өрәңге булып басып торам Һәм озатам көзге кәләшләрне». Ләкин бу бердәмлек тә аңа рухи ләззәт бирми. Кеше гомере кебек үк табигать фасыллары да мәңгелек түгел икән: *«Аһ, син көз! / Син тик сүз лә...» («Син бары тик фасыл»).*

Шул ук вакытта шагыйрьнең табигать күренешләрен, андагы даими үзгәреш-яшәешләрне тирәнтен сиземләве белән сокланмый мөмкин түгел. Аерым алганда, «Ишкәкче»(2019), «Инеш» (2020) шигырьләренең эчке тирән мәгънәләренә төшенү аерым ләззәт бирә, табигать ямен бернинди ясалма матурлыкның да алыштыра алмаячагына инандыра. Үзәктә күпмәгънәле көчкә ия көз белән саубуллашу рухы гаҗәеп матур итеп бирелә: *«Түгәрәк күл...Әйтерсең лә көзге, / кершәнләнеп томан йөгертелгән. / Соңарган көз ямансулап тора» («Ишкәкче»).*

Әлеге парчада ишкәкче вазифасын үзенә алган лирик зат, каегын тау ягына борып, «ап-ак томаннарга» кереп урала. «Инеш» шигырендә дә томанга киләчәкнең өметсезлеген чагылдыру бурычы йөкләнә: *«Кич белән китәрмен моннан. / Көймә туктар, утырырмын. / Инеш томаны ябыган / Төш кебек онытылырмын» («Инеш»).*

«Истанбул базары» шигырендә ул «Яңа Бабил... Пычрак базар... Йөрим... Нәрсә югалттым» диеп Гогольнең «Моңсу, моңсу, әфәнделәр, яшәве җир йөзендә» дигән сүзләрен искә төшерә. Чынлыкта, 2019-2022 елларда язылган шигырьләренең төп бер юнәлешен, телисез икән, асылын «моңсу – моңсулык» билгели.

Р.Зәйдулланың бөтен иҗаты дәвамында иң еш мөрәҗәгать итеп, яратып үстергән алымнарының берсе – тирәлек яшәешендә кешегә хас сыйфатларны, адәми затларның рухи чагылышын күрүе дигән идек. «Боз астында кояш», «Җил», «Каен кызы», «Юеш карда синең эзләрең» кебек соңгы еллар лирикасында бу ысул кеше кичерешләрен, холкын ачуда таяныч ноктасы булып тора. «Җил» парчасында җилнең явыз итеп сызгырып килеп, чия җыючы чибәркәйгә «Әйдә, алып китәм сине» дип «бәйләнүенә» кыз «Юк» дип көлеп җавап бирә. Кызның үзен мөстәкыйль тотышы, катгый җавабы «бәйләнчек» җилнең «күңелен йомшарткан» булып чыга: *«Үз бәхетемне көтәм мин – / Хәбәрен җил китерде» («Җил»).*

«Чалкан ятты җир өстенә» шигырендә киң алан буйлап йөгергән кызның гүзәллегеннән «үләннәр йөзләрен учларына яшерәләр». Иҗатчының бу төр шигырьләреннән «кеше – табигатьнең иң югары казанышы» дигән нәтиҗә «башын калкытып» тора.

Югарыда атап үтелгәнчә, «Яз килгәндә әллә нишли иде» парчасында лирик зат күңел тынычсызлыгын киңрәк җирлектә аңлатырга тырышып карый: «Безне дөнья дәшми кайгыртырга», «Шыпырт шатланырга өйрәтте». Яз быел башкачарак килеп, һавасы «кургашындай» булса да, шәхеснең кәеф-сихәтләре бер дә яхшы якка үзгәрми, бигрәк тә, аңардан «йөз чөергән» яры очрап, аны тәмам «чыгырыннан чыгара». «Шыксыз җилләре, караңгы кояшы» аның шатлыклы хисләренә тернәкләнеп китәргә ирек бирмиләр. Нәтиҗәсе нәкъ безнең көннәр вазгыятенә киная дип кабул итәрлек: *«Һич чыгасы килми дөньяларга / Чыгарга да, диләр, ярамый».*

Р.Зәйдулла интим хисләрне үзәккә алган, халкының ачы язмышы турында уйланган, тарих сәхифәләрен күңеленнән кичергән әсәрләрендә бер мизгелгә дә шәкел төрлелеге, эчтәлеккә бәрабәр «тышкы кием» хакында онытмый. Әлеге чор шигъри иҗатында да, бигрәк тә мәхәббәт газәлләрендә, сонетларында дөнья картинасы төрле мәгънәви төшенчәләрне янәшә куюда, ягъни антитезада ачыла: яшьлек – узган гомер,

мизгел – мәңгелек, тынлык – тавыш, хыял – торгынлык, хәтер – мәнсезлек кебек ике чик төшенчәләре кичереш динамикасына буйсыналар. Кайчакта аның «хыялый аргамагы» җилдерүенә күзләр дә ияреп өлгерә алмагандай була.

Бәян итү аһәңен бераз үзгәртеп, хәзер идарәче ханнарның өстән кушканын үтәүчеләренең «маңгайларына чиртмәсә» дә, ул миллилегебезнең рухын югалтуны «баскычларга салып» әрнеп-күрсәтеп, «үреп» бара. «Ачык авыз» памфлеты – шуның ачык мисалы. Бәйрәм бара, әбиләр дә, сабыйлар да «Җырның ертыгы юк» дип «шыңшып» утыралар. Барысы да бәхетле. Тик бер сорау һавада эленеп тора: «Ләкин шунысы – Җырлыйбыз соң бүген кем җырын?» Җырларны биюләр тулыландыра: бәя шундый ук кискен: «Кеше кубызына бии-бии, Төшеп кала бугай акыл да». Сатира угының кемнәргә юнәлгәнлеге яшерелми. Нәни кызларын «мисс-мисс-мисс» дип үсендереп, гайрәт биреп, «Королева булсын! Һәм бик тиз» диләр.

Күршеләргә «Воскресе!» дибез. Авыз ачарга ифтарларга җыелабыз. Шигырьнең соңгы юллары тирән символик мәгънәгә ия: *«Бар дөньяга мәшһүр ачык авыз – / Тик тел генә анда күренми».*

Бу шигырьне публицистик-сәяси әсәр дип бәяләү дөрес үк булмаса да, Гоголь әйтмешли, әфәнделәр, миллилегебезне югалтып барабыз дип лирик чаралары белән чаң каккан әсәр икәнен инкарь итеп булмый.

«Шөлдер» (2019) парчасында илдәге хикмәти үзгәрешләргә, шулай ук үзенчәлекле образларга бәя бирелә. Бер яктан, «аучы абайламый. Без бүре түгел күптән!» икәнлекне яисә үз хокукларыбыз өчен көрәшә алмавыбызны искә төшерсә, икенче сәбәбе – шөлдернең вакытында хәбәр бирмәвендә икән: «Тик телен өзеп алганнар, челтерәмәде шөлдер».

Күпчелек иҗат әһелләренең, бигрәк тә шагыйрьләр «токымының» иҗатларында тәнкыйди рухлы булып күренү теләге табигый. Мин хәзерге шигърияттә шәхесләрен объектив бәяләгән ике шагыйрьне генә таныйм: берсе – мәрхүм (урыны оҗмахта булсын) М.Әгъләм һәм икенчесе – Р.Зәйдулла. Соңгысының «Янды сөю чатырлары» шигырендә түбәндәге юлларны кайсы каләм әһеле иҗатыннан китерә аласыз? «Аккош күле урманында балан чәчәгенең исе» дигән ямьле табигать сурәтен түбәндәге юллар «тулыландыра»: *«Искә төште исерек төн / Инде онытылган исем».*

Чынлыкта шигырь «Суалчандай җиргә сеңгән үкенечләр», «Сискәнү булып түгелә ятим кәккүк тавышы» кебек шәхес сагышы ләззәтен «суырып чыгарган» газәл .

«Яралгы» шигыренең башында китерелгән түбәндәге юллар соңгы куплетта да кабатланалар: *«Мин исерек бүген, / Ничәнче кат / Аңны югалтканчы исердем».*

«Бөтен рухын җилләр» иркенә тапшырган шәхеснең укучысын, җәмгыятьне ирештереп булса да, үзенең «аңын югалтканчы исерүен» таныган каләм иясен очратканым булмады дигән идем. Р.Зәйдулланың шаян шуклыгына, нәфесенә «котырынырга» ирек бирмәүче мәзһәб – Ходай Тәгалә, аның барлыгына һәм берлегенә ышанычы. Төрле эчтәлекле тезмәләреннән күренгәнчә, Р.Зәйдулла фани дөньяда тәүге сулыш алуы, яшәве өчен Аңа бурычлы икәнлеген бер даим дә онытмый дисәк тә, зур хата булмастыр. «Тәңрем», «Күз яшьләре тамган көйгә», «Яза Тәңрем кеше тәкъдирләрен...», «Күрербез Ходай язганны», «Мин дә кеше нәселеннән, Тәңрем» кебек зикерләрендә Ислам фәлсәфәсеннән нур алган суфыйчылык – тәсаувыф йогынтысы сизелеп тора: *«Вакыт җиткән – / Шушы сүзләр туган: / «Күз яшь*ләре тамган көйгә */ Әрнеп, / Яза Тәңре кеше тәкъдирләрен...» («Күз яшь*ләре тамган көйгә»).

Шагыйрь «Тәңрем» робагыенда, әрсезләнеп китеп, дөресе Илаһны якын итеп, зиһенен «шикчел» дә, «гамьле» дә акыл биргәне өчен «үпкәсен» дә белдереп ала: *«Юллар уралыр бугазга, / Югалыр җирдән гүрем, / Тәңрем! / Шуның өченме / Син миңа гомер бирдең?» («Тәңрем»).*

Бөек көчкә генә тәвәккәл кылып табынырга, ихтыяҗи кирәклекне, бәхетле тормышны бары тик аңардан сорарга, үтенергә кирәклек мәҗбүрияте искәртелә:

*«– Бисмилла! – дип, сүзен башлый хәзрәт, / Әллә нинди якын, изге сүз... / Мөмкин түгел рухи исәннәрне / Куып керtү кысан кысага» («Бисмилла»).*

«Шигъри тәфсирләр» бүлеге Корьән сүрәләрен шәрехләүгә, дөресрәге, аларның илаһи көчләрен хәзерге әдәби телдә, бүгенге яшәешебездән килеп аңлатуга нигезләнгән дини шәрех-тезмәләрдән тора.

Корьән сүрәләренә тәкълид итеп язылган шигъри тәфсирләрендә суфичылык фәлсәфәсенең эзотерик, ягъни эчке, тирән, яшерен серле һәм кинаяле мәгънәләренә төшенүгә омтылыш көчле. Икенче сүрәне шәрехләүче «күз яшедәй бәллүр дулкын»да «Аллаһка мәдхиябез» белән «сусыл алма»га «меңенче кат» сузылсаң, андый бәхеткә ирешүе җиңел түгеллеге искәртелә: *«Аллаһ бүләк иткән бу ләззәттән / Өзгәләнсен җаннар, өзгәләнсен... / Күпергән дә көтеп ята үзән / Сәҗдәгә дип таулар тезләнгәнне».*

99 нчы сүрәдән зикерендә Җирдәге яшәешнең соңгы фаҗигаи хәлләрне шагыйрь хыялы болайрак күз алдына китерә: *«Мең яшәрлек дәү имәннәр бер көн / Шырпы кебек сынар, урман гүләр».*

Ул ахырзаман белән куркытмый, тик имансызларны кисәтә: «Тәкъва кебек кыланса да дәһри, Ул беркайчан алдый алмас Аны». 90 нчы, 77 нче, 80 нче, 94 нче сүрәләрнең дини-тәрбияви мәгънәләренә шигъри багышлаулары – аерым сөйләшүләрне һәм Р.Зәйдулла иҗатының яңа бер кыйбласын, юнәлешен ачкан эзләнүләр. Ул һәммәбезгә, мәңгелеккә юлны әзерләү үзебездән тора дигән фикердә төкәнә: *«Сәҗдәгә әгәр егылсаң, / Тәңре күкрәгеңне ачар. / Өстән иңгән хакыйкатькә, / Һәм яңгырар җанда – яшәр!» (94 нче сүрәдән).*

Иң мөһиме – адәм баласы, «вәгъдә ителгән», «Таулар тузан булып», «күкләр ишелер өскә» көннең килеп җитәсен онытмыйча, фанида байлык һәм шөһрәт артыннан кумасын, игелекле тормыш белән барыннан канәгать булып яшәсен иде дигән фикерен уздыра шагыйрь.

Җыеп кына әйткәндә, Р.Зәйдулла Ислам динен, аның асылын тәшкил иткән әхлакый-этик фәлсәфәне кешелек аңының иң югары казанышы дип саный һәм шуны исбатлый. Аның гомерлек хыялы: *«Бакыйлыкта хозурына керерменме / Һәм Тәңренең нурлы йөзен күрерменме?» (94 нче* сүрәдән).

Мәгълүм булганча, адәм баласы, бигрәк тә иҗат кешесе, билгеле бер дәрәҗәләргә ирешеп, тормышы нинди генә югары кимәлдә булмасын, бер гамәли сызыкны узгач, фани дөньяда яшәүнең мәңгелек түгеллеген сиземләп, дин, ахирәт турында да уйлана башлый. Күптән түгел олуг тормыш бәйрәмен уздырган Р.Зәйдулла тарихыбызны дөрес бәяләү, милли мәнфәгатьләрне, бигрәк тә туган телләрне мәкерле рәвештә кысуны кире кагуын саклаган хәлдә дә, үткәндәге яхшы гамәлләрне сагыну, рухи дөнья хасиятләренә, табигый яшәешкә омтылу, дини өйрәтмәләргә таяну зарури дигән олуг нәтиҗәгә килә.


**Фәүзия СОЛТАН.**

*Июль аенда «Казан утлары» редакциясе Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә оештырган «Яңа исем» иҗат лабораториясендә катнашучылар һәм аларның остазлары, язучылар, журналистлар Әтнә районына сәфәр кылды. Сәфәрдә алар Әтнә театрында, сәүдәгәр Гатаулла Даутов йортында, Олы Әтнәдәге Әхәт мәчетендә булдылар, аннары Күлле Киме авылында Сибгат Хәким, Лена Шагыйрьҗан музейларын карадылар. Күәм авылыннан ерак түгел Калатау дип йөртелгән Әйшияз шәһәрчеген, андагы Ханнар зиратын зиярәт кылдылар. Шулай ук Түбән Бәрәскә авылындагы борынгы мәчетне дә күреп чыктылар. Кунакларны Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе Айрат Каюмов белән шушы районда яшәп иҗат итүче шагыйрә Гөлүсә Батталова каршы алып, озатып йөрде.*

*Фотоларда әдәби сәфәрдән мизгелләр.*



*Күлле Кимедә Сибгат Хәким музеенда. Кунакларны музей директоры Гөлсинә Хәкимуллина (алгы рәттә уңнан икенче) каршы алды.*



*Сибгат Хәким музееннан күренеш.*



*Гөлсинә ханым яшь иҗатчыларга һәм язучыларга Сибгат Хәким турында сөйли.*



*Калатауда Ханнар зиратында. Сулдан уңга: Ихтыяр Кыямов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин, Юлай Низаев, Гөлүсә Закирова, Рафис Корбан.*



*Шагыйрә Гөлүсә Батталова Түбән Бәрәскә авылындагы 1769 елгы таш мәчетнең музеенда кунакларга Тукайныкы булуы ихтимал сандык турында сөйли. Гөлүсәнең «Тукай сандыгы» дигән поэмасы «Казан утлары»ның апрель санында дөнья күргән иде.*



*«Яңа исем» лабораториясе шәкертләре Лена Шагыйрьҗан музеенда. Сулдан уңга (утырганнар): Азалия Сабирова, Мәрьям Ибраһимова; басканнар: Камилә Халикова, Азат Әскәров, Ихтыяр Кыямов, Гөлинә Фәрхуллина.*

*Ландыш ӘБҮДӘРОВА фотолары.*

# КАЮМ НАСЫЙРИ – ПРАВОСЛАВИЕ УКУ ЙОРТЫ УКЫТУЧЫСЫ

## Казан рухани семинариясенең татар теле укытучысы

Сәгыйть мәдрәсәсен пишкадәм булып тәмамлаган Каюмның, берәр мәхәлләгә мулла булып сайланып, үзен тук тормыш белән тәэмин итү мөмкинлеге була. Әмма Насыйри бу юлны сайламый. Күрәсең, этисенең иҗтиһад турындагы сүзләре һәм үзенең дә бу җәһәттән рухи эзләнүләре аны муллалыктан ваз кичәргә этәрә. Бу аңа Казан руханилар әзерли торган училищеда татар теле укытырга тәкъдим ясалу белән дә бәйле. Шулай да Каюмның моңа ризалашуы бүгенге көнгә кадәр табышмак булып кала. Г.Рәхим фикеренчә, төп сәбәп аның рус телендә камил итеп сөйләшергә һәм язарга өйрәнергә омтылуында була *(Рәхим Гали. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия. Казан, 2020. Б. 45*).

Бу мәсьәләдә без башкача уйлыйбыз. Беренчедән, Каюм яшьтәшләре арасында үзенең кызу темпераменты, активлыгы һәм чаялыгы белән аерылып тормаган; киресенчә, тыйнак, басылып эшләүчән булган, кулъязмалар күчереп язу белән мавыккан. Ул, бер яктан, әйтеп үтелгәнчә, Сәгыйть мәдрәсәсендә укытудан – канәгатьлек, икенче яктан, биредә үзенә җан тынычлыгы тапмаган: мохтаҗлыктан бигрәк, ялгызлыктан газап чиккән. Каюм мәдрәсәдәге тормышы турында 1858 елның 23 апрелендә олы абыйсы Габделхәйгә язган хатында болай ди: «…ялгызлыктан башка читен эш бар микән? Әмма мин ялгызлыкның зәхмәтен чиктем. Унбиш елга якын мәдрәсәдә яттым, миңа һич тиң чыкмады, ялгыз булдым» *(Каюм Насыйри язган хатлар // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда. 3 том / Төзүче, гарәп графикасыннан аерым текстларны гамәлдәге язуга күчерүче һәм кереш мәкалә авторы Хуҗиәхмәт Мәхмүтов. – Казан, 2004. – Б.355)*.

Бер сүз белән әйткәндә, мәдрәсәдә, шәкертләр, хәлфәләр арасында Насыйри үзен ялгыз хис иткән. Рус православие уку йортында укытырга чакыру алгач, ихтимал, үзен беренче тапкыр җәмгыятькә кирәкле кеше итеп тойгандыр. Чакыруны ул рухи ялгызлыктан котылу чарасы дип тә кабул иткән. Ә инде рус телендә камил рәвештә сөйләшергә һәм язарга өйрәнү теләге шушы төп сәбәпкә өстәлгән генә дип уйлыйбыз. Шулай ук монда нәселендәге рус хакимиятләренә хезмәттә булган ата-бабаларына ихтирам хисе дә *(Гайнетдин М. Каюм Насыйри: шәхес һәм иҗат // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда. 1 том. Казан, 2003. Б.7*), Каюмның Михайлов училищесында укыганда, башка мәдәният мохитендә булып алуы да һәм, ниһаять, яшь чагында рухани хезмәтеннән баш тарткан этисенең үрнәге дә роль уйнаган, күрәсең.

Шулай да бу гамәле белән Каюм, «кызыл сызык»ны үтеп, үзен бөтен мөселман җәмәгатьчелегенә каршы куя, исламга «хыянәт» итүдә гаепләргә җирлек бирә. Шуңа да аңа «Урыс Каюм» дигән кушамат тагалар, чөнки ул булачак православие руханиларына татар телен укыта. Шул ук вакытта Каюм Насыйриның көчле рухлы булуын билгеләп үтәргә кирәк. Мөселманнарның зур күпчелеге православие руханиларын читләтеп үткәндә, Каюм иманын югалтудан курыкмый.

Шунысын да әйтеп үтү мәслихәт: Насыйри православие уку йортында белем биргән беренче мөселман кешесе булмый. Бу вакытта Казанда православие руханиларын әзерли торган өч баскычлы укыту системасы гамәлдә була. Казан руханилар училищесын тәмамлау турындагы таныклык урта һөнәри дини уку йортына – руханилар семинариясенә укырга керү хокукы бирә. Бу уку йортларының икесе дә Казан руханилар академиясенә буйсына, ул исә югары дини белем бирә. Академиядә татар теле кафедрасы һәм татар сыйныфы 1845 елда ачыла. Казан университетының «Шәрык разряды»нда мөселман каллиграфиясен укытучы Мөхәммәтгали Мәхмүдов 1846–1848 елларда Казан руханилар академиясендә татар теле дәресләре алып бара. Аннан соң, 1849–1859 елларда, бередә татар теле укытучысы, практикант булып Биктимер Янбулат улы Йосыпов эшли (*Ханбиков Я.И. Русские педагоги Татарии и их роль в развитии просвещения и педагогической мысли татарского народа. (Из истории русско-татарских педагогических связей): Пособие для студентов и преподавателей. Казань, 1968. С.74)*.

1854 елда Казан руханилар академиясе каршында Мөселманлыкка каршы миссионерлык бүлеге оештырыла, анда мөгаллимнәр итеп Н.И.Ильминский, Г.С.Саблуков (1856 елдан) һәм татар теле практиканты Б.Я.Йосыпов билгеләнә.

Казан руханилар академиясе каршындагы Мөселманлыкка каршы миссионерлык бүлегенә укырга керүчеләр, нигездә, Казан руханилар семинариясендә татар теле укыган кешеләрдән туплана.

1855 елның 1 мартыннан 30 яшьлек Каюм Казанның руханилар училищесында, укытучы-практикант Хәйрулла Айбәтов урынына татар теле укытуга керешә.

Казан руханилар училищесының документларыннан күренгәнчә, мөгаллим Насыйриның практик күнекмәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт була: «а) Телдән […], татар сөйләм теленең сүзләре һәм гыйбарәләре өйрәтелә, кыйссалар сөйләнә. Өйрәткәндә, гыйбарәләрнең һәм җөмләләрнең составлары турында грамматик кагыйдәләр аңлатыла. б) Язма, татар теленнән рус теленә тәрҗемәләр ясала» *(Хасаншина Л.Ж. «Желая открыть торговлю книгами» (Документы о Каюме Насыри в фондах НА РТ) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2010. №3/4. С.221)*. Замандашларының хатирәләреннән күренгәнчә, укучылар «татарча сүзләрне һәм гыйбарәләрне, гади грамматик кагыйдәләрне, төрләнешләрне өйрәнәләр... Татар теленнән рус теленә тәрҗемә иткәндә, җөмләләрне грамматик яктан тикшерәләр» *(Харлампович К. П.П.Масловский и его переписка с Н.И.Ильминским // Известия общества археологии, истории, этнографии. Т. XXIII. Вып.2. С.75)*.

1855 елның 29 сентябрендә Казан руханилар семинариясе идарәсе Академия җитәкчелегеннән татар телендә практик дәресләр үткәрү өчен өч сыйныф ачарга рөхсәт сорый. Руханилар семинариясенең татар теле укытучысы Г.С.Саблуков җитәкчелеккә К.Насыйрины училищедан семинариягә күчерергә тәкъдим итә. Чыннан да, Казан руханилар семинариясе хезмәткәрләренең 1856 елгы исемлегенә Каюм Насыйри татар теле укытучысы буларак теркәлгән. 1856-1857 уку елында ул Казан руханилар семинариясендә дә, Казан руханилар училищесында да укыта, алга таба семинария укучылары белән генә эшли булса кирәк *(Хасаншина Л.Ж. «Желая открыть торговлю книгами». С.118-120)*.

«Семинария курсы дәвамында татар теле дәресләре текстларны рус теленә тәрҗемә итүдән гыйбарәт була: а) 1862 елда татар керәшеннәре өчен чыгарылган әлифбага кергән догаларны һәм дин тарихын; б) шулай ук Иисусның зирәклеге китабыннан татар теленә аударылган 3, 5, 8, 10, 22, 30нчы бүлекләрне; в) «Фазаиле-ш-шөһүр» китабыннан мәкаләләр: Мөхәммәд пәйгамбәрнең Коръән аятьләре иңә башлаганчы булган тормышы, тәһарәт, ураза, садака; Әбүбәкер һәм Хәдичәнең ислам кабул итүе турында; Иов, Симеон хакында. Бу китаплардан тыш, дәреслек сыйфатында Троянскийның грамматикасы, К.Насыйриның мисаллар китереп эшләнгән «Кыскача

грамматикасы» (1860), А. Казембекның «Гомуми төрек-татар грамматикасы» (2 басма, 1846, Казан) кулланыла. Гарәп теле Болдырев грамматикасы, сүзлеге һәм хрестоматиясе һәм Фретагның гарәп-латин сүзлеге ярдәмендә өйрәнелә» *(Харлампович К. П.П. Масловский и его переписка с Н.И.Ильминским. С.75)*.

Константин Харлампович хезмәтеннән алынган бу өзекнең кайбер урыннары буенча төгәллек кертү сорала. Насыйриның без алга таба телгә алачак методик эшкәртмәләреннән тыш, ул укыту барышында Казан семинариясенең татар теле мөгаллиме, рухани Александр Троянскийның хезмәтләре һәм тырышлыгы белән тупланган гарәп һәм фарсы гыйбарәләрен дә үз эченә алган Татар теле сүзлегенең ике томлыгын *(Казан, 1833–1835)* һәм А.Казембекның «Гомуми төрек-татар грамматикасы»н *(2 нче басма, Казан, 1846)* кулланган. Укучыларның сөйләм телендәге күнекмәләренә таянып, Насыйри текстларның тәрҗемәләренә аерым игътибар биргән, моның өчен ул татар теленә тәрҗемә ителгән «Евангелие»ны һәм татар керәшеннәре өчен әзерләнгән башка дини китапларны, Җамалетдин Бикташиның татар-мөселманнар арасында киң таралыш алган, тормышның тискәре якларын, кешеләрнең начар гамәлләрен фәлсәфи һәм гыйбрәтле тарихлар аша сурәтләгән «Фөзаиле-ш-шөһүр яки саваплы гамәлләр» китабын файдаланган *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. – Б. 47)*. Дәресләрендә укучыларны туган халкының көнкүреше һәм бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре һәм йолалары, җырлары, мәкальләре, табышмаклары, экиятләре белән таныштырган, мөселман кардәшләренең ышануларын һәм риваятьләрен сөйләгән *(Хабибуллина Д.А. Деятельность Каюма Насыри в православных религиозных учебных заведениях // Гасырлар авазы-Эхо веков. 2023. №1. С.39-41)*, шулар турында укырга текстлар сайлап биргән.

Укыту эше Каюмның шактый вакытын алган. Руханилар училищесының урта һәм югары бүлекләрендә татар теле – атнага ике тапкыр, семинариядә кече сыйныфларда атнага – 3, урта сыйныфларда – 5, югары сыйныфларда 4 сәгать укытылган *(Харлампович К. П.П.Масловский и его переписка с Н.И.Ильминским. С.75)*.

Насыйри семинариядә үзен эшсөючән, тәртипле һәм таләпчән мөгаллим итеп таныткан, җитәкчелекнең дә, хезмәттәшләренең дә ихтирамын яулаган *(Шунда ук. Б.94)*. Уку йортының еллык хисапларында татар телен өйрәнү нәтиҗәләре түбәндәгечә тасвирланган: «Укучыларның күпчелек өлеше татар теленнән рус теленә шактый иркен тәрҗемә итә, рус теленнән татар теленә тәрҗемәләре канәгатьләнерлек. Татарчалары татарлар үзләре сөйләшкәнгә якын, берничә укучы татар телендә иркен аңлаша ала» *(Шунда ук. Б.76)*.

Руханилар әзерли торган уку йортларының 1867 елгы Уставы буенча семинариядә профессиональ дини белем алуда рухани сословиесе белән бәйле чикләүләр бетерелә һәм укыту системасы тамырдан үзгәрә. Хәзер руханилар семинарияләренә дөньяви уку йортын тәмамлаган яшьләр дә, өйдә белем алучылар да укырга керә ала. Алай гына да түгел, беренче дүрт сыйныфта, берничә дини предметтан кала, дәресләр дөньяви була *(Липаков Е.В. Казанская духовная семинария. Исторический очерк. Казань, 2007. С.48-49)*, бу исә, һичшиксез, К.Насыйриның эшенә уңай йогынты ясый.

Җитәкчелек укытучының дәресләргә җентекләп әзерләнүенә игътибар итә. Укучылар предметны яхшырак үзләштерсен өчен Насыйри дәреслекләр төзергә керешә. Насыйриның укыту-методик эшчәнлегендәге активлыгы иҗади характеры һәм җаваплылыгы белән аңлатыла: ул үзе дә күп укый, күп нәрсә белән кызыксына. Һичшиксез, мәдрәсәдә алган белеме һәм тәҗрибәсе дә файдалы була. Икенчедән, семинариядә татар телен укыту буенча кирәкле уку әсбаплары җитешми, булганнарын уку-укыту программасына яраклаштырырга туры килә. Гомумән, Насыйри укытуны югары сыйфатлы итеп оештырырга омтыла. Махсус дәреслек булу мөгаллимгә предметны тирәнрәк өйрәтергә, ә укучыларга материалны җиңелрәк үзләштерергә

мөмкинлек бирә. Дәреслек язганда, педагог үзе дә һөнәри яктан үсә, укыту предметы турында системалы күзаллау булдыра, укыту методикасын яхшырак үзләштерә һ.б. Шул рәвешле, төрле дәреслекләр эшләгәндә, Насыйри иҗади мөгаллим, тикшеренүче һәм методист буларак формалаша.

## Мөселман кешесе «кечкенә секуляр җәмгыять» шартларында

Насыйриның рус уку йортында эшләве аның мөселман дини даирәсеннән күпмедер дәрәҗәдә аерымлануына китерә, ягъни ул «кечкенә секуляр» – ислам диненнән аерымланган мохиттә – яши башлый дип әйтергә мөмкин.

Каюм, яшәү урынын үзгәртеп, Казанның руслар яши торган өлешенә күченә. Семинария укытучыларының күпчелегенең фатирлары уку йортының укытучылар корпусында урнашкан була *(Липаков Е.В. Казанская духовная семинария. Исторический очерк. С.45)*. Каюм, 1856-1857 уку елында семинария хезмәткәре булгач, уку йорты бинасының чарлагында, яңгыр яуганда, түшәменнән су саркый торган бүлмәдә яши. Олы абыйсы Габделхәйгә 1858 елның 23 апрелендә язган хатында инде ике ел семинариянең мансардасында, чарлагында яшим дип хәбәр итә *(Каюм Насыйри язган хатлар // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда. 3 том. Казан, 2004. Б.355)*.

Казанның рус өлешендә ашауны мөселманча оештыру мәшәкатьле була. Даими киеренкелектә эшләргә һәвәс улларын кайгыртып, әти-әнисе Каюм янына хезмәтче малайлар җибәреп тора. 1857 елны Каюм әти-әнисенә язган хатында, «малайсыз торырга өйрәнгән идем, тагын малай җибәргәнсез, ай саен күп вакытым килгән малайны өйрәтүгә китә» дип яза *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б. 56)*. Күрәсең, семинария бинасында яшәүче Каюмга хезмәтче булып Шырданнан килгән малайлар, православие руханилары арасына эләгүләрен аңлап, тизрәк кайтып китү ягын караганнар.

Каюм 1860 елдан да калмыйча яңа фатирга чыга. Буйдак егет, фатирны арендалау бәһале булу сәбәпле, әти-әнисенә 1860 елның 10 октябрендә язган хатында һаман да Мөхәммәдшаһта торам, элекке фатирның күп рәте булмаса да, малай тапсам, шунда менәрмен дип яза *(Әти-әнисенә язган хатлары // Каюм-Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б.542-543)*.

1862-1863 уку елы башында да ул, хезмәтче малай таба алмау сәбәпле, Мөхаммәдшаһ фатирында яшәвен дәвам итә *(Шунда ук. Б. 546)*.

1864 елның көзендә аның кабат семинария бинасында, чарлактагы бүлмәсендә яшәгәнлеге мәгълүм *(Абыйсы Габделхәйгә язган хатлар // Каюм-Насыри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б.565, 567)*.

Семинариядә, чит мәдәни мохиттә яшәү баштарак аңа билгеле бер уңайсызлыклар тудырса да, Насыйрига дини яктан нинди дә булса басым ясалмый. Чит даирәдә Насыйри мөселман тормыш рәвешенең бөтенлеген саклый, шулай да традицион даирәдән аерымлану аның дини капиталын киметә (Я.Яннакон концепциясе буенча) *(Опалев С.А. Критика теории секуляризма в теории рационализма // Религиоведческие исследования. 2010. С. 170-189)*.

Шунысын билгеләп үтү мөһим: Урта гасырларга хас дини карашлар өстенлек иткән конфессиональ җәмгыять вәкиленең кигән киеме шәхеснең традицион кыйммәтләргә чын күңелдән бирелгәнлеген раслаучы мөһим билге булып санала. Казан руханилар семинариясендә эшләгәндә, Насыйри киемен европачарак итеп яңарта *(Габдулла бине Таҗетдин әл-Кәчимири. Габделкаюм ән-Насыйри // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б.493)*, аерым алганда, үзе язганча, Татар бистәләрендә яшәүче мөселманнар арасында беренче булып «рус чалбары» кия

*(Насыйри К. Татар этнографиясе материаллары // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Беренче том. Казан, 1974. Б.96).*

Уку йортының җәдвәленә ярашлы, дәрес вакытында укытучының мотлак рәвештә дәрестә булырга тиешлеге биш вакыт намазның да үз вакытында укымавына сәбәп була.

Шулай ук Насыйриның җомга һәм гает намазларын өйдә уку гадәте дә семинариядә эшләү дәверендә формалашкан дип уйлыйбыз. Күрәсең, монысы да мөселман кардәшләре аның семинариядә укытуына кискен каршы булганлыктан хасил булган. Насыйриның тәмәке тарту гадәте семинариядә барлыкка килгән дип уйларга кирәк, ә тәмәке тарту ул чорда Казан татарлары арасында бидгать гамәл саналган.

Болар барысы да Насыйриның үз-үзен тотышында билгеле бер үзгәрешләр турында сөйләргә урын калдыра.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: К.Насыйриның бертуганнары, озак вакытлар руслар арасында яшәп, чит мәдәният мохите йогынтысына тагын да ныграк бирелгән була. Аерым алганда, Габделхәй абыйсы һәм энеләре Габделгани белән Габделвәли спиртлы эчемлекләрдән дә баш тартмаганнар *(Рәхим Гали. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б.44-45)*.

Сүз дә юк, Насыйри традицион дини мохиттән тулысы белән аерылмаган, иң элек туганнары белән элемтәләр саклаган. Ул бертуган абыйсы һәм энеләре белән даими рәвештә хат алышып торган, үзе еш яза алмаса да, әти-әнисеннән хатлар өзелмәгән. Еш кына әти-әнисе, абыйсы, энеләре һәм апасы, аннан көнкүреш әйберләре сатып алуын сорап, хатлар яза торган булганнар, шулай ук кием-салым, баш яки аяк киемнәрен тектерергә заказлар биргәннәр. Олы абыйсы Габделхәй белән ике арадагы хатлары, хәл белешүдән тыш, сәүдә-сәнәгать мәсьәләләрен хәл итүгә дә корылган була: абыйсы кушуы буенча Насыйри сабын кайнату өчен кирәкле материаллар сатып алып, Мәскәүгә озата. Бу җәһәттән Насыйри Казанның эшлекле кешеләре даирәсе, шул исәптән татар эшкуарлары белән дә актив рәвештә аралашкан.

Казанда әтисенең энесе – 1829 елдан алып 5 нче мәхәлләнең җәмигъ мәчетендә (Ак мәчет) мөәзин вазифасын башкарган Мөхәммәтгалим яши. Каюмның әтисе Габденнасыйр Казанга килгән чакларында Мөхәммәтгалимгә төшә торган булган. Билгеле инде, Насыйри да әтисе Казанга килгәндә генә түгел, башка вакытларда да абыйсына кунакка килеп йөргән.

Каникул вакытында туган нигезгә кайткач, Насыйри үзен хак мөселманча тота. 1864 елда төпчек энесе Габделкави туган авылында имам-хатыйб итеп билгеләнгәч, аның белән биш вакыт намазга да мәчеткә килә торган булган.

Насыйриның семинариядәге жалованьесы әллә ни күп булмый. 1857 елда әти-әнисенә язган хатында Насыйри түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Язасыз, запаслы булып тор, кайдан запаслы булыйм, биш йөз сум акчаны өч йөз алтмыш көнгә тәкъсим кыйлсаң (бүлсәң), ни калыр? Бер ай ач тормак кирәк яки бурыч итмәк кирәк; икесе дә минем кулдан килә торган түгел. Белмәйсез, сезнең икътикад (ышану) әллә ничек, гөман кыласыз (фаразлыйсыз) җыелган акча бар дип» *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б. 47)*. Күрәсең, бу чорда аңа олы абыйсы күпмедер матди ярдәм күрсәткән.

Семинариядә эшләгәндә, олы абыйсы Габделхәй Каюмның иң якын кешесе була: ул аңа бөтен эч серләрен, уй-хыялларын сөйли. 1859 елның җәендә Насыйри олы абыйсы янына Мәскәүгә бара *(Абыйсы Габделхәйгә язган хатлар // Каюм-Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б.558-559)*.

1865 елда 40 яшьлек Каюм Казан ямщигы Мөсәгыйть кызы Зөһрәгә өйләнә. Шул мизгелдән туган тел мохитенә әйләнеп кайта. Гаилә тормышы, хатынының кайгыртуы Каюмны озак еллар хыялланган күңел тынычлыгына китерә. Әмма бәхетле яшь

гаилә бер елдан соң җимерелә: Насыйриның сөекле хатыны бала тапкач вафат була. Кайгыга баткан Насыйри көн саен кулына алып укыган Коръән китабының тышлыгына үзенең гаилә тормышына кагылышлы төп даталарны язып куйган: Зөһрә белән никахның 1865 елда, июнь аеның икенче ункөнлегендә җомгадан соң укылуын; 12 августта кияү булып керүен; 1866 елның 16 июлендә, шимбә көнне, икенде вакытында хатынының баласы төшүен; үле туган балага Габделхәй дип исем кушуын һәм җирләвен; сөекле хатынының якшәмбе көнне кич белән кояш батканда мәрхүмә булуын; дүшәмбе көнне дәфен кылынуын *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б. 47-48)*.

Насыйриның, гаиләле булып, тигез тормышта яшисе килгән. Каюмның бабасы белән мөнәсәбәтләре яхшы була, хатыны Зөһрә вафатыннан соң алар тагын да якынаеп китәләр. Насыйриның Мөсәгыйть йортына күчеп яшәвен бары тик шулай гына аңлатырга мөмкин. Алдан килешенгәнчә, хуҗаның кече кызы балигълык яшенә җитүгә Каюмга кияүгә чыгарга тиеш була. Насыйри, бергәләшеп гаилә корып яшәргә өметләнеп, берничә ел дәвамында балдызына төрле фәннәрдән дәресләр бирә: география, математика, тарих укыта. Балдызы да укуга бөтен дикъкатен бирә. Әмма, 16 яше тулуга, яше үзеннән ике тапкырдан да артыграк ир-атка кияүгә чыгасы килмәвен белдерә. Шул сәбәпле Насыйрига Мөсәгыйть йортыннан китәргә туры килә. Каюм Насыйриның тәкъдименнән баш тарткан балдызы исә ахыр чиктә әхлаксызлык юлына баса, җиңел холыклы кызга әйләнә. Балдызының мондый начар гамәлләреннән соң, К.Насыйриның хатын-кызга булган ышанычы тәмам югала *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б. 48, 61)*. Моннан соң ул беркайчан да өйләнми, гомерен ялгыз үткәрә (Мәшһүр мәгърифәтче, үләренә бер ел чамасы кала, Насретдин Хуҗашиның «Картлык көнегездә үзегезне тәрбияләр өчен ник хатын алмадыгыз?» дигән соравына ике тапкыр өйләндем дип җавап биргән, имеш. «Берсе белән мәхәббәтебез булмады, өлфәт таба алмадык. Үзе аерырга сорады да, аердым. Бусы яшь вакытымда иде. Аннан соң тагын бер хатын алдым. Монысы белән яхшы ук мәхәббәтебез дә булды. Ләкин минем язу хезмәтемә бик күп кереп, кимчелек китерә башлады. Язу һәм башка хезмәтемә зыян килмәсен өчен, монысын үзем талак иттем», – дип җавап биргән. Г.Рәхим бу сүзләрне, Насыйри авырган һәм вакыт-вакыт хәтерен югалта, саташа башлаган заманда сөйләгән дип, ялганга чыгара. Ихтимал, үзенең өйләнүен бер-бер китаптан укыган мәзәге белән саташтыргандыр, яки хосусый хәяте хакында сорау биреп йөдәтүче яшь шәкертләрнең башларын әйләндерү өчен, белә торып, үзе хакында «Фәвакиһ әл-җөласа», «Хикәят»ләре тибында бер мәзәк сөйләп җибәргән булган дип өсти *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б. 48)*. Без Г.Рәхим фикере белән килешәбез.

Казан руханилар семинариясендә эшләгәндә, Каюм рус мәдәниятенә җәлеп ителгән мөселманнар белән еш аралаша. Ул дустанә һәм эшлекле мөнәсәбәтләрдә аралашкан татар зыялыларыннан иң элек каллиграфия остасы Мөхәммәтгали Мәхмүдовны (1824–1891) атау урынлы. Ул 1850–1868 елларда Беренче гимназиядә татар теле укытучысы булып эшли. 1860 елларда, Казан университеты ирекле тыңлаучылар өчен үзенең ишекләрен ачкач, берничә татар кешесе, шул исәптән Мөхәммәтгали Мәхмүдов белән Каюм Насыйри, лекцияләргә йөри башлыйлар *(Рәхим Г. Насыйриның тәрҗемәи хәленә гыйлавә // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия. Казан, 2020. Б. 86)*. Университетта уку аның гуманитар фәннәр буенча белемнәрен тирәнәйтүдә зур роль уйный, Насыйриның алга таба күзаллауларын үзгәртә, мәгърифәтчелек проектлары формалашуга йогынты ясый

Шулай ук Насыйриның дуслары арасында литограф Мөхәммәтвәли Яхинны да атап үтәргә мөмкин. Алар 1862 елда, татар телендә «Таң йолдызы» дигән атналык газета

чыгарырга рөхсәт сорап, хакимияткә гариза язалар *(Каримуллин А.Г. Издательская деятельность Каюма Насыри и проект газеты «Таң йолдызы» // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль җыентык. С.426)*.

Бу исемлеккә ил буйлап ярминкәләрдә сәүдә итүче берничә татар сәүдәгәрен дә өстәргә була.

Ул актив рәвештә Казан руханилар семинариясе китапханәсенә йөри, белем ала. Рус интеллигенциясе вәкилләре белән фән һәм мәгърифәтчелек өлкәләрендә аралашу һәм үзлегеннән дөньяви белем алу Насыйриның тикшеренүче, фәнни белемнәрне популярлаштыручы һәм мәгърифәтче буларак формалашуында зур роль уйный.

Тулаем алганда, Насыйриның педагогик эшчәнлек еллары Россиядә бер сословиегә дә карамаган кешеләрнең (разночинецлар) секуляризация (дөньяви карашларга өстенлек бирү) чорына туры килә. Россия югары уку йортларында һәм гимназияләрендә уку Европача дөньяви белем бирү казанышларына нигезләнә, укыту тәрҗемә яки яраклаштырып төзелгән дәреслекләр һәм уку әсбаплары белән алып барыла. Югары мәктәпкә православие дине йогынтысы бик аз була, ә православие дине нигезләре формаль рәвештә генә өйрәтелә. Бу чорда гимназияләрдә һәм университетларда укыту, асылда, мәгарифнең секуляр системасына корыла. Шуны да билгеләп үтү мөһим: православие чиркәве дворяннарның белем бирү системасыннан аерылган һәм аларның тәрбиясенә йогынтысы да йомшак булган *(Синелина Ю.Ю. Циклический характер процесса секуляризации в России (Социологический анализ: конец XVII – начало XXI века): Автореф. дисс... докт. социолог. наук. М., 2009. С.33-34)*.

Семинариядә дөньяви фәннәр укытучылары һәм Казан университетының профессорлары, мөгаллимнәре шул гимназияләрне һәм университетларны тәмамлаган шәхесләр була. Каюм Насыйрига алар белән һөнәри кызыксынулары җәһәтеннән еш аралашырга туры килә.

Семинариядә педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнеп, Насыйри мөгаллимнәр төркеменең бер вәкиленә әверелә, ул укучыларны туган халкының этнографиясе, фольклоры һәм көнкүреше белән таныштыра, грамматика буенча уку әсбаплары һәм уку өчен хрестоматияләр төзи. Дөньяви фәннәрдән белем бирүче укытучылар белән бер сафка баскан Насыйри да, мөселман кешесе буларак, Россия җәмгыятенең диннән ераклашкан, дөньяви интеллектуаль катлау вәкиле булып китә.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы.*

## Хатыйп Миңнегулов хаты

*Гыйнвар, 1963 ел*

Рәдиф!!!

Ачык хатыңны алдым. Рәхмәт. Вызов кичә килде. 2 нче гыйнвардан 10 нчы гыйнварга кадәр. 10 көн эчендә 800 км дан артык җирне бар да, кайт та, һәм 3 экзамен, 3 зачётыңны да бир. Әле бит тагын 60 сәгать лекциясе дә бар. Глупость просто! Берсе йокымсырап утырганда гына уйлагандыр аны! Вызов килмәсә, 25ләренә таба гына китәрмен дип торган идем. Дирекция дә килешкән иде, чөнки алар миңа бер 20-25 көн вакыт бирелер дип уйлап торганнар иде. Кәгазьне күрсәткәч, алар да аптырады. Иртә китсәң, берничә көн бушка китә (түләүсез). Шулай булгач, ай азакларына таба гына китәрмен дип торам. Әйдә, бу үземә дә әйбәт булыр, чөнки чирек билгеләрен дә чыгарып бетерәсе бар.

Ничего, яңадан бер 15 көннән очрашырбыз, Алла боерса!

Вакытның тарлыгын күреп, мин дә экзаменга хәзерләнә башладым (башладым гына!). Әле менә бүген ял көне, политэкономияне укый башладым. Колхоз строе турындагы бүлекләрне укыдым. Моңа кадәр аңлашылмаган нәрсәләр таң аткан кебек ачыла баралар. Колхоз, авылның киләчәге, аны үстерү юллары турында хыялга чумып куйдым. Күз алдыңа китер: яхшы йортлар, төз урамнар, ике якта агачлар тезелгән, урам – таш; электр, радио, телевизор. Механикалаштырылган фермалар: анда хатын-кызлар техниклар кебек кенә машиналарны карап йөриләр. Йөзләре шат.

Колхозларның бер буш җирләре дә юк. Тау итәкләрендә җимеш бакчалары, умарталыклар.

Зур клуб, уку заллары. Библиотекадан кеше өзелми. Анда колхозчылар авыл хуҗалыгына, техникасына караган китапларны укыйлар. Художестволы әдәбиятны карты да, яше дә укый. Менә бер механизатор керә дә библиотекарь кыздан: «Рәдиф Гаташның яңа поэмасы кайтмадымы әле?» – дип сорый. Теге: «Юк әле, шушы арада булыр», – дип җавап бирә. Механизатор егет Хемингуэй романы белән Давыт Сөнгати китабын алып кайтып китә.

Авылның исеме генә авыл булачак, ул чынлыкта посёлокны искә төшерәчәк.

Анда урта мәктәп эшли. Кичен дә, көндезен дә укыйлар. Агротехника, терлекчелек түгәрәкләрендә берничәшәр дистә яшьләр, хәтта олы кешеләр дә укый. Әдәбият түгәрәге дә эшләп тора. Эшкә сәнәк, көрәк күтәреп чыгучылар юньләп күренми дә. 40-45 яшьлек Гайниҗамал апалар да үз эшләрендә учёныйларга әйләнер. Кеше 6-8 сәгатен эшли дә калган вакытында китап укый, спорт белән шөгыльләнә. Өстәл тулы нигъмәт, өстә бостон костюмнар. Кеше үз хуҗалыкларында казынып та ятмый, чөнки аңа җәмәгать фондыннан һәм үзенә тигән продукция дә җитә.

Эх Рәдиф, без ничектер тормышның тоткасын күрмибез. «Бөркет күрсәм, бөркет буласым килә» дигәндәй, бер хуҗалыкның (ну, колхозның) җитәкчесе булып эшлисе килеп куйды. Партия, хөкүмәт, халык поддерживать итеп торганда, чәчәк аттырыр идек авылларны!

Ярый, Рәдиф, хәзергә җитәр. Йә Манилов[1] дип көләрсең. «Кабер булып тоелыр иде тормыш, җир йөзендә хыял булмаса», – ди бит кайсыдыр шагыйрь. Шунлыктан балалар белән эшләгән мөгаллимгә дә бераз хыялга чумып алу кирәктер.

Эх Рәдиф, тазалык кына булсын, без яшәрбез һәм эшләрбез әле.

*Сәлам белән, Хатыйп*

[1] Николай Гогольнең «Үле җаннар» повестендагы персонаж.

## Әнгам Атнабаев хаты

*1964 ел*
*Уфа шәһәре*

Рәдиф!

Хатыңны алдым. Рәхмәт. Хатың өчен дә рәхмәт, мине ялган бәлаләрдән коткаруда катнашуың өчен дә рәхмәт!

Бу фани дөньяда яшәве (яшәүне мин көрәш мәгънәсендә аңлыйм) шундый авыр, Рәдиф. Кайчагында шундый авыр, хәтта... тик үзеңнең якта хаклыкның сакта торуы гына коткара. Тагын да үчләшебрәк, чәмләнебрәк яшәргә тотынасың: йә алар – мине, йә мин – аларны! Урта юк.

Шагыйрьнең дошманнары булырга тиеш. Ул көн саен, сәгать саен, тын алган саен сугышырга тиеш. Сугышсыз үлә ул. Шуның өчен синең авылга китәргә карар итүең миңа ошый. Син шуннан сугыша-сугыша, Казанга кил, Казанны яулап ал! Бу – синең көчеңә сынау. Әгәр килә алмасаң, яулый алмасаң – кирәгең юк, димәк, син шагыйрь түгел. Ә болай – урта мәктәптән университетка, берсеннән икенчесенә – ул әле сынау түгел, үз-үзеңне алдау гына. Соңгы шигырьләрең, бигрәк тә «Дөресен сөйлим», «Синеке – минеке», «Укытучыма» һәм башкалар дөньяда Рәдиф Гатауллин дигән шагыйрьнең барлыгын сөйли – шагыйрьнең генә түгел, яхшы шагыйрьнең барлыгын. Тик шул яхшының көчле дә булуын күрәсе килә. Әйе, көчле дә – Есенин кебек яхшы, Маяковский кебек көчле.

Ярый, Рәдиф, акыл сатарга тотындым. Син, унбиш ел укып, ул акыл сатулардан болай да туеп беткәнсеңдер инде. Иң мөһиме – үзеңчә бул!

Эшләр ничава. Поэма язып ятам. Яртылаштырып киләм. Баш китәрлек зур темага тотындым: Ленин белән сөйләшү – формаль түгел. Кеше белән кешеләр турында кешеләрчә сөйләшү.

Кызларның, егетләрнең барысына да сәлам әйт. Флорага аерып сәлам әйт.

*Күңелеңә язгы ташкын теләп, Әнгам.*

## Мостай Кәрим хаты

*21 июнь, 1966 ел*
*«Йоматау» шифаханәсе*

Рәдиф туган!

Китабың өчен бик зур рәхмәт! Мин аны бүген Дим буендагы «Йоматау» дигән санаторийда укып чыктым. Көнем дә, күңелем дә ямьләнде.

Мин синең шигырьләреңне элек тә белә идем. Менә бергә җыеп укыгач, алар мине яхшы күңелле кешеләр генә яшәгән бер дөньяга алып килделәр.

Иң мөһиме – син талантлы. Талантыңны сакла, аның кадерен бел һәм аңа аның табигатенә ярамаган эш йөкләмә.

Безнең буын кешеләренең бер трагедиясе шунда булды: алар бер үк арбага – бер үк талант тартып бара торган арбага – теләсә нинди йөк төяделәр!

Моның ярамаганын сез яшьтән үк аңлап өлгердегез, һәм сезгә азрак сәрмәнергә туры килде.

Беренче китабың белән котлыйм. Татар поэзиясенә яңа китап кына өстәлеп калмады, ә яңа шагыйрь килде! Үтә яхшы!

*Кулларыңны кысып, Мостай Кәрим.*

**P.S.** Татарча имлям зәгыйфь, хаталарын төзәтеп укы һәм мине кичер.

# ӘДӘБИ СКАНВОРД



Язучы ... Зәйнуллин

Ракеткалы спорт уены

Язучы ... Мөхәммәтшин

Гаффар, Сафиуллин

Бөртекле әйберләрне төеп ваклый торган савыт

... машинасы

Кәнфит төре

«Зәңгәр ...» (К.Тинчурин)

«Баллы» агач

Галиәсгар ...

Шагыйрә ... Фәйзуллина

Гарәп артикле

... Туфайлова

Язучы ... Шабай

Гомәр Бәширов романы

Мушкетёрларның берсе

Рәсми җәза төре

...дә баягы

Беләң (иск.)

Бик кыйммәтле, затлы

... Карнеги

«... кем кулында?» (А.Гыйләҗев)

Сальвадор ... (испан рәссамы)

Шагыйрь ... Идиятуллин

АКШтагы шәһәр

Ренат Харис поэмасы

«Казан утлары», «Сөембикә», «Ялкын»

Татар халык җыры

... барда кулың тый

Жорж Санд романы

Яфраклы агач

Африкадагы чүл

Фёдор Шаляпин тавышы


... Мураками (япон язучысы)

Лампа калпагы

Йозак, бикләвеч

Альбер ... (француз язучысы)

Кучемсез милектән вакытлыча файдалану




**Рәис ГАБДУЛЛА** *төзеде.*

***Үткән санда чыккан сканворд җаваплары. Сулдан уңга:*** *Гариф, Зифа, «Рамай», Кәрами, су, Булат, Родари, галера, миф, Ирек, Әсән, «Ника», чал, рәт, Әсәй, «Хәят», Хәким, Зәйни, Рәмис, Нәҗип, җиһан, да, Жан.* ***Өстән аска:*** *Кәрим, чех, Бикә, фәләк, «Гарасат», Сиражи, Амур, әрәмә, Рәми, Игәнәй, зинар, Фәйзуллин, Хәсән, Ерикәй, Абрек, Ян, «Ида», ака, тимпан.*

*Рахмай Хисмәтуллинның тууына – 90 ел*

# ДӨНЬЯНЫ ТЫНГЫСЫЗЛАР ХӘРӘКӘТКӘ КИТЕРӘ



Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе, Гаяз Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты Рахмай Хисмәтуллин 1934 елның 25 сентябрендә Актаныш районы Әнәк авылында туа. 1952 елда – Пучы урта мәктәбен, 1958 елда Казан дәүләт университетының физика-математика факультетын тәмамлый. Питрәч һәм Азнакай район газеталарында эшли, аннары Казанда төрле өлкәләрдә хезмәт куя. Кама буенча нефть-химия комплексы төзелә башлагач, 1966–1978 елларда Түбән Кама шәһәрендә икътисадчы, «Социалистик Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе, математика укытучысы, төзелеш инженеры, Түбән Кама халык театры режиссёры булып эшли. 1989–1997 елларда Чаллы Язучылар оешмасының җаваплы секретаре вазифасында була. Язучы 2004 елның 30 гыйнварында бакыйлыкка күчте.

Сайтыбызда журнал укучылар игътибарына әдипнең якты рухына багышлап әзерләнгән тапшыру тәкъдим ителә. Язманы тыңлаганда, сез аның шигырьләрен, «Әнәк имәннәре» әсәреннән өзек, шигырьләренә язылган җырлар ишетерсез. Тапшыруда төп урынны Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров һәм Татарстанның халык язучысы Вахит Имамов белән әңгәмәләр алып тора.

Зиннур Мансуров, Рахмай Хисмәтуллинның әдәби мирасы, әсәрләренең үзенчәлеге турында уйланып, болай ди: «Иҗат ул шәхестән башлана. Әгәр дә шәхес күпкырлы, күркәм сыйфатларга мулрак ия була икән, аның иҗаты да зур, күпкырлы һәм кызыклы була. Рахмай Хисмәтуллинга килгәндә, аның аерылып торган шәхесе бик күп кешелекле сыйфатларга ия иде. Ул, иң беренче чиратта, ихлас булды. Шәхестә менә шушы ихласлык сыйфаты мул булганда гына каләм иясе зур казанышларга ирешә ала дип уйлыйм мин. Ул тәрбияле, югары интеллектлы, зур эрудицияле, әзерлекле шәхес иде. Киң күңелле, ярдәмчел, кайвакыт сабыйларча беркатлы була белде. Менә шушы күпкырлылыгы аның хикәяләр, нәсерләр, шигырьләр, пьесалар язуында да күренә. Ул Күктән бирелгән таланты белән әдәбиятта бөтен жанрларны да колачларга омтылып яшәде...»

Тапшыруда Татарстан радиосы фондында саклանган бер кадерле язма да урын алды. Ул – күренекле галимебез һәм җәмәгать эшлеклесе, академик Азат Зыятдинов (1939–2017) белән әңгәмә. Азат ага узган гасырның 80 нче еллары башында Түбән Кама шәһәрендә Рахмай Хисмәтуллин белән бергәләп «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсен оештырып йөргән чакларын хәтерендә яңартып сөйли. «Дөньяны тынгысызлар хәрәкәткә китерә», – ди ул. Шушы җөмләдә Рахмай Хисмәтуллин дигән олы шәхеснең бөтен асылы ачылып китә кебек. Чыннан да, ул янып яшәде, янып иҗат итте, әмма көлгә калмады, аның әсәрләре әле бүген дә күңелләргә ялкын сала.

*Шәүкәт Гаделшаның тууына – 75 ел*

# ЯЗМЫШЫМНЫҢ ДӘРЬЯСЫ: КАЗАН – ТӨМӘН АРАСЫ



Танылган шагыйрь Шәүкәт Гаделша (1949–2024) 2023 елда Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Әнә шул көннәрдә Татарстан радиосында Шәүкәт Гаделша улы Сибгатуллинның иҗатына багышланган тапшыру әзерләнде. Ул вакытта инде шагыйрьнең авырып яткан чаклары иде, шунлыктан әңгәмәдә үзе катнаша алмады. Студиягә кунак булып аның иҗатын һәм тормыш юлын тирәннән белүче каләмдәш дусты, университет сабакташы, күренекле язучы Рафис Корбан килде. Әлеге әңгәмәдә Шәүкәт Гаделша шәхесенең үзенчәлекләре, шигърияте тулы булып ачыла кебек. Шуңа да без журнал укучылар игътибарына нәкъ шушы аудиоязманы тәкъдим итәргә булдык. Р.Корбан сөйләгәннәрдән нәни генә бер өземтәне кәгазьгә күчерик: «Шигърияткә ул белем алу юлы белән түгел, балачагыннан әнисеннән-әтисеннән күчкән шигъри таланты белән килеп кергән. Ә инде университет аңа, әлбәттә, белем бирде, ул аны зур әдәбиятка алып кергән уку йорты булды.

Шәүкәт – бик үзенчәлекле шагыйрь. Без Себер татар әдәбияты дигәндә, 60-70 нче елларда иҗат иткән Булат Сөләймановны күз алдына китерәбез. Ләкин хәзер әдәбият сөючеләр даирәсендә Булат Сөләйманов кем ул дип сорасаң, белмәүчеләр дә булырга мөмкин. Ә менә Шәүкәт Гаделшаны без барыбыз да яхшы беләбез. Үзенең шигырьләрендә Себернең табигатен, Себер татарларының рухын чагылдырган шагыйрь ул. Шәүкәтнең шигырьләрен өйрәнеп кенә дә Себер татарлары фольклорыннан бай материал туплап булыр иде.

Шәүкәт белән бергә аның туган якларында булганым бар, анда аны бик ихтирам итәләр, шигырьләрен җирле матбугатта бастырып килиләр, Казанда чыккан китапларын алдырып, халыкка тараталар, хәтта Тубыл университетының татар теле бүлегендә Лилия Фәизова исемле яшь галимә кандидатлык диссертациясе язган. «Язмышымның дәрьясы: Казан – Төмән арасы» дигән исем белән ул хезмәт аерым китап булып басылып та чыкты...»

Инде, кадерле дусларыбыз, QR-код ярдәмендә сайтыбызга кереп, әлеге әңгәмәне тулысы белән тыңлыйк. Тапшыруның икенче өлешендә игътибарыгызга Тәлгат Хаматшин укуында Шәүкәт Гаделша шигырьләре тәкъдим ителә.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

### САЙЛАУ

8 сентябрьдә – Татарстан Республикасы VII чакырылыш Дәүләт Советына сайлау (шулай ук 38 муниципаль районда җирле үзидарә органнары депутатларын өстәмә сайлау) узачак. Парламентның яңа составына 100 депутат кирәк. Алар биш елга сайлана. Депутатларның 50се – партияләр исемлеге, 50се – бер мандатлы округлар буенча. Сайлауларда катнашу өчен 427 кеше (179ы – республика бердәм округы буенча, 248е – бер мандатлы округлардан) үз кандидатураларын тәкъдим итте.

ТР парламентына депутатлар сайлауда алты сәяси партия катнаша. Биш партия («Бердәм Россия», КПРФ, «Гадел Россия – Патриотлар – Дөреслек өчен», ЛДПР һәм «Яңа кешеләр») бердәм округ буенча да, бер мандатлы округларда да кандидатлар тәкъдим итте. Тагын бер партия – «Гражданнар инициативасы» берничә бер мандатлы округта үз кандидатларын күрсәтте.

Республикада 2700 сайлау участогы, 42се сайлаучылар вакытлыча булган урыннарда (сәламәтлек саклау учреждениеләре, шифаханәләр, аэропорт) эшли.

### АВГУСТ КИҢӘШМӘСЕ

Лаеш районы Усад авылындагы «Инноватика» күппрофильле лицеенда үткән Татарстан мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең республика август киңәшмәсенең пленар өлеше «Мәгарифтә лидерлык: стратегик ориентирлар һәм технологияләр» дип аталды. Анда Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин доклад белән чыгыш ясады. «Милли мәгариф торышының төп күрсәткече – туган телдә белем бирүне колачлау. Шул ук вакытта муниципалитетлар арасында бу күрсәткеч буенча зур аермалар булуын билгеләп үтәргә кирәк. Арча, Әтнә, Чүпрәле, Кайбыч, Сарман, Теләче районнарында ул шактый югары, һәм соңгы өч ел дәвамында аларда уңай динамика күзәтелә. Шул ук вакытта башка районнарга балаларның һәм аларның әтиәниләренең предметларны туган телдә өйрәнүгә кызыксынуларын арттыру эшен оештырырга кирәк», – диде ул. Министр әйтүенчә, әлеге юнәлештә мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларының хезмәттәшлеге мөһим. Быел туган телдән имтихан сайлау хокукыннан дүрт меңнән артык укучы файдаланган. Узган ел белән чагыштырганда – мең ярым укучыга күбрәк. Яңа уку елыннан тарих фәне программасының эчтәлеге яңартыла – ул «Туган төбәк тарихы» өлеше белән тулыландырыла.

Республика август киңәшмәсенең пленар утырышында Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады.

### МӘСКӘҮДӘ ТАТАРСТАН МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Мәскәү Халыкара музыка йортында Татарстан сәнгать осталары катнашында тантаналы кичә булды. Анда ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты. Ул кичәгә килгән РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин белән Мәскәү мэры Сергей Собянинга Татарстан белән хезмәттәшлеккә зур игътибар биргәннәре өчен рәхмәт белдерде. РФ вице-премьеры Марат Хөснуллин ТР Рәисе Рөстәм Миңнехановка Россия Президенты Владимир Путинның Рәхмәт хатын тапшырды.

Мәскәүдә Татарстан мәдәнияте көннәрендә кунаклар, Россия башкаласында яшәүче татар җәмәгатьчелеге вәкилләре Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр салды. Тантанада катнашучыларны ТР вице-премьеры – Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин сәламләде. Моннан тыш, Мәскәү Татар мәдәни үзәгендә Татарстан язучылары белән иҗади очрашу узды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, шагыйрьләр Факил Сафин, Рифат Сәлах, Эльвира Һадиева катнашты.

### ҖӘЛИЛ ҺӘМ ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕҢ ҺӘЛАК БУЛУЫНА – 80 ЕЛ

Казандагы 1 Май мәйданында узган митингта моннан 80 ел элек фашист төрмәсендә җәзалап үтерелгән Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре Гайнан Кормаш, Фоат Сәйфелмөлеков, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаровларны бер минутка тын калып искә алдылар. Чарада ТР Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева, ТР мәдәният министры Ирада Әюпова, Татарстан Язучылар

берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, шагыйрә Луиза Янсуар, «Крылатское» әдәби берләшмәсе (Мәскәү) вәкиле Ирина Каргина, халыкара «Җәлил укулары» дипломанты Луиза Гафиятова, җырчылар Рөстәм Насыйбуллин, Резеда Галимова, Җәлилнең кызы Чулпан ханым (оныгы, оныкчыгы да кайткан иде) чыгыш ясады. Искә алу мәрасимен Илдар Кыямов алып барды.

### ШАГЫЙРЬ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Башкортстанның Илеш районы Шәммәт авылында Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин истәлегенә бюст (авторы – сынчы Тимофей Тюрин) куелды һәм музей ачылды. Тантаналы чарада Башкортстан Республикасы мәдәният министры Әминә Шәфыйкова, Татарстанның, Башкортстанның Язучылар берлекләре рәисләре Ркаил Зәйдулла белән Айгиз Баймөхәммәтов, ТР Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты рәисе урынбасары Камил Нугаев, ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Башкортстанның халык шагыйре Кадим Аралбай, Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары Рафис Корбан, Мөхәммәт Мирза, Хәбир Ибраһим, Ләйлә Минһаҗева, Р.Миңнуллинның бертуган энесе, галим Ким Миңнуллин, хатыны Клара ханым, улы Алмаз һәм кызы Таңсылу катнашты.

### КИТАП БӘЙРӘМЕ

Казандагы әдәби кафе (Декабристлар урамы, 2 нче йорт) каршында Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, прозаик, шагыйрә, публицист, галимә Рифә Рахманның күптән түгел Татарстан китап нәшриятында чыккан «Татар кызы» (әсәр 2021 елда «Казан утлары» журналының 9,10,11 нче саннарында басылды) китабын тәкъдим итү булды. Чарада Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, язучы-тәрҗемәчеләр Фатих Кутлу, Наилә Яхина, язучы-мөхәррир Нурзидә Нотфуллина, галимнәр Илсөяр Закирова, Зөфәр Мөхәммәтшин, Зирәк Юсупов, җаваплылыгы чикләнгән «Белем.ру» оешмасы директоры Раил Гатауллин, китапның мөхәррире Рамилә Нуриева һ.б. чыгыш ясады. Әсәрдән өзекне Гөлнара Сафина укыды. Бәйрәмне Айдар Гыймадиев алып барды.

### ФӘЙЗУЛЛИН ЙӨЗҮЛӘРЕ

Быел «Фәйзуллин йөзүләре» әдәбият һәм спорт бәйрәме Теләче районы Олы Мәтәскә авылында узды. Татар әдәбияты классигы Фатих Хөснинең туган авылы бу. Олы Мәтәскә авылы мәдәният йортында язучылар белән очрашуда әдипне зурлап искә алдылар. Казаннан кайткан каләм ияләрен Теләче районы башлыгы Нәҗип Хаҗипов сәламләде. Кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла «Фәйзуллин йөзүләренең кырык тугызынчы ел узуын әйтте, тарихы белән таныштырды. Чарада Равил Фәйзуллин, аның каләмдәшләре Марсель Галиев, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Зиннур Хөснияр, Алмаз Хәмзин чыгыш ясадылар. Кунаклар Фатих Хөсни музеенда, Олы Мәтәскә урта мәктәбендә булдылар, җирле фермер Сәгыйть Гыйниятуллинның татар токымлы атларын күрделәр, «Туган авылым» музей-комплексы белән таныштылар. Ярышлар Түләмә инеше буасында булды. Р.Фәйзуллин йөзәргә Камил һәм Ильяс атлы оныкларын да алып килгән иде.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

17 сентябрь – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь Марс Хафизовка 75 яшь.

### ХУШ, ЯКУБ АРКАДАШ!

Анкарадан кайгылы хәбәр килде. 2024 елның 16 августында Евразия Язучылар берлеге рәисе, Төркиядә чыга торган «Кардәш каләмнәр» журналының баш мөхәррире Якуб Делиөмәруглы 59 нчы яшендә вафат булган. Якуб бәй игелекле, ихлас, сабыр холыклы дустыбыз буларак истә калды. Ул Татарстанда күп тапкырлар булды. Каләмдәшләр арасында багланышларны ныгытуда, татар әдәбиятын, язучыларыбызны, тарихи мирасыбызны Төркиядә һәм төрки дөньяда танытуда зур эш башкарды. Ул озак еллар буе юксындырыр әле.

Мәрхүмнең җәсәде Анкара зиратында җирләнде.

2024 елның 23 августында 90 нчы яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, журналист, җәмәгать эшлеклесе, ТР Президенты матбугат хезмәтенең беренче җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Дуслык ордены, А.Алиш исемендәге әдәби премия иясе **Әнәс Хәсән улы Хәсәнов** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Казандагы Тынычлык бистәсе зиратында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман А.ГАЯЗОВА «С какой же стороны встаёт солнце?», роман З.ГИМАЕВА «Каторжан», рассказ Л.АБУДАРОВОЙ «Старший брат»; стихи С.АХМЕТЗЯНОВОЙ, Г.БАСЫРОВОЙ, Р.БАШАРА.*
*«Новые имена»: стихи Г.АХМАДЕЕВОЙ.*
*Литературный конкурс «Нравы отчего дома…»: рассказ Э.ГАЛИАХМЕТОВОЙ «Будь милосердным, дитя!».*
*«Литература родственных народов»: стихи Б.АДЖИЕВА.*
*«Отклик»: статья Л.ФАТТАХОВОЙ и статья Р.ГАТАША к повести Л.Лерона.*
*Литературная критика: статья Р.РАХМАНИ; статья Ф.СОЛТАН, посвящённая лирике Р.Зайдуллы.*
*Фотоархив: фотографии с поездки в Атнинский район в рамках творческой лаборатории «Новое имя».*
*«Грот Абугалисины»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА, посвящённая 200-летию К.Насыри.*
*«Памятные письма»: письма Х.Миннегулова, А.Атнабаева и М.Карима Р.Гаташу.*
*Литературный сканворд. Составил Р.АБДУЛЛА.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 90-летию Р. Хисматуллина и 75-летию Ш.Гаделшы.*
*Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Дворец земледельцев на рассвете. Фото И.АБРАМОВОЙ; писательница Л.АБУДАРОВА. Фото М.ГАЛЕЕВА.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by A.GAYAZOV «In what direction does the sun rise?» novel by Z.GIMAEV «The Convict», story by L.ABUDAROVA «Elder brother»; poems by S.AKHMETZYANOVA, G.BASYROVA, R.BASHAR.*
*«New names»: poems by G.AKHMADEEVA.*
*Literary contest «Morals of the Father's House…»: story by E.GALIAKHMETOVA «Be gracious, child!»*
*«Literature of kindred nations»: poems by B.ADJIEV.*
*«Response»: article by L.FATTAKHOVA and article by R.GATASH to the story by L.Leron.*
*Literary criticism: article by R.RAKHMANI, article by F.SOLTAN, dedicated to the lyrics by R.Zaydulla.*
*Photo archive: photos from a trip to the Atninsky district within the framework of the creative laboratory «New Name».*
*«Grotto Abugalisin»: article by I.ZAGIDULLIN dedicated to the 200th anniversary of K.Nasyri.*
*«Memorial letters»: letters by H.Minnegulov, A.Atnabayev and M.Karim to R.Gatash.*
*Literary scanword. Compiled by R.ABDULLA.*
*«Priceless voices»: articles for the 90th anniversary of R.Khismatullin and 75th anniversary of Sh.Gadelsha.*
*The rubric is led by N.AKMAL.*
*Diary of public and cultural life.*
*On our covers: Palace of farmers at dawn. Photo by I.ABRAMOVA; writer L.ABUDAROVA. Photo by M.GALEEV.*

*Тышлыкның беренче битендә:* Таңда Игенчеләр сарае. *И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы Ландыш Әбүдәрова. *М.ГАЛИЕВ фотосы.*